ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2013



# ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕНӘ 60 ЕЛ


















**Казан утлары**

**Qazan utlari**

2013

**10**

**(1092)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закиржанов, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 222-09-83 өст.1612.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*

**Факс** — (843) *222-09-83 өст.1612.*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Мәдинә МАЛИКОВА. Көмеш билбау. *Роман.* ....5
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Чарасыздан жанны бер өн били. *Шигырьләр.* ....49
Фәрит ИМАМОВ. Күләгә. *Детектив роман.* ....54
Йолдыз МИҢНУЛЛИНА. Өтүкән жирендә ут яна. *Шигырьләр.* ....82
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. *Хикәяләр.* ....87
Розалина ШАҺИЕВА. Ана теле – гүзәллек. *Шигырьләр.* ....120

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Фәрит ГЫЙЛЬМИ. Салават күпере. ....123

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Карга күзен карга чукымый. Рәсәй Конституциясе һәм милек. ....127

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Заманчалык. ....136
Илшат ВӘЛИУЛЛА. Тәүбәле еллар, тәүбәле юллар... ....164

**СӘНГАТЬ**

Нәсимә ӘХМӘТҖАНОВА. Җырга бирде бар көчен. ....140
Мөнир АБДУЛЛИН. Җырланмаган әле безнең җыр. ....144

**ХӘТЕР**

Нурихан ФӘТТАХ. Четерекле булды безнең заман. *Истәлекләр.* ....149

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ....158
«Татар энциклопедиясе битләреннән». ....161

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Габдулла ГАЛИЕВ. Йөрәк ярасы. ....173

**БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ**

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Якты юл. ....177

Морад ДУСАЙ. Мәшһүрләр мәзәге. ....180

**ПЕЧӘН БАЗАРЫ**

Даһи ГАДЕЛШИН. Соңгы бүләк. *Сатирик хикәя.* ....182
Фарис ФӘСХИ. Фарисизмнар. ....189

«Казан утлары» архивыннан. ....156
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман М.МАЛИКОВОЙ «Серебряный пояс»;
детективный роман Ф.ИМАМОВА «Тень»; рассказы Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ;
стихи Р.ЗАЙДУЛЛЫ, Й.МИННУЛЛИНОЙ, Р.ШАГИЕВОЙ.
«Из сокровищниц татарских рассказов»: Ф.ГИЛЬМИ. «Радуга».
«Публицистика»: Р.МИР-ХАЙДАРОВ. «Россия в жадных объятиях чиновников».
«Конституция России и собственность».
«Литературная критика»: статья А.АХМАДУЛЛИНА о драматургии Д.Салихова;
И.ВАЛИУЛЛА. «Покаянные дороги».
«Искусство»: статьи Н.АХМЕТЗЯНОВОЙ о творчестве Г.Зайнашевой;
М.АБДУЛЛИНА о татарской песне.
«Память»: Н.ФАТТАХ. «Мы жили в непростое время».
«Наука»: страницы из «Татарской энциклопедии»; Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Рассказы из жизни»: Г.ГАЛИЕВ. «Душевная боль».
«Наш календарь»: А.ЗАКИРЗЯНОВ. «Светлый путь».
«Сенной базар»: «Д.АДЕЛЬШИН. «Последний подарок»; афоризмы Ф.ФАСХИ
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: город Альметьевск; писательница Минзифа АХМЕТШИНА.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by M.MALIKOVA «Silver Belt»;
detective novel by F.IMAMOV «Shadow»; stories by F.ZAMALETDINOVA;
poems by R.ZAYDULLA, Y.MINNULLINA, R.SHAGIEVA.
«From treasures of Tatar stories»: F.GILMI. «Rainbow».
«Journalism»: R. MIR-KHAIDAROV. «Russia in arms of greedy officials». «Constitution of Russia and property».
«Literary Criticism»: article about drama by A.AHMADULLIN of D.Salihov;
I.VALIULLA. «Roads of repentance».
«Art»: articles by N.AHMETZYANOVA about creativity of G.Zaynasheva;
M.ABDULLIN about Tatar song.
«Memory»: N.FATTAH. «We lived in difficult times».
«Science»: pages of «Tatar Encyclopedia»; F.GARIPOVA. «History of our villages».
«Stories of life»: G.GALIEV. «Heartache».
«Our calendar»: A.ZAKIRZYANOV. «Shining path».
«Hay Market»: «D.ADELSHIN. «Ultimate gift»; aphorisms by F.FASKHI.
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our coves: Almetevsk city; writer Minzifa AKHMETSHINA.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 02.10.2013, график буенча 02.10.2013.
Офсет ысулы белән басылд. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-2222. Тираж 3815.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Мәдинә
Маликова

# КӨМЕШ БИЛБАУ

РОМАН

Ак пароходка утырып, Идел буйлап сәяхәт кылганыгыз бармы сезнең? Яр чите белән пароходны тоташтырган тотрыксыз басма аша үтеп, өске палубага менгәч, култыксага таянуга дөнья үзгәрә дә куя. Көнкүрешнең һәммә ваклыгы, кере-тузаны, черки-чебене ярдан чигенеп, ыгы-зыгылы урамнарга кереп югалгандай була.

Пароход: «Сау булыгыз, көнкүреш ыгы-зыгылары! Хушыгыз, вак-төяк борчулар, ямансу уйлар, күңел төшенкелеге! Без саф, иркен дөньяга чыгабы-ы-ыз!» — дигәндәй, дәртле аваз сала да, салмак кына борылып, ярдан ераклаша. Күз алдында гаҗәеп манзара ачыла — дәрья киңлеге, кояш нурларында йөгерек дулкыннарын җемелдәтеп, серле рәшәгә уралган офыкка барып тоташа, яр буйларында урман-болыннар җәйрәп ята. Сулыш иркенәя, рух көрәя, йөрәк ашкына, күңелдә җыр уяна:

«Дулкыннар, дулкыннар, ник болай шаулыйсыз?
Ярларга бәрелеп, сез нәрсә даулыйсыз?
Дулкыннар, дулкынна-а-ар...»

Кемнәрнең генә күңелен очындырмаган Идел киңлекләре, нинди генә телләрдә, нинди генә җырлар тибрәлмәгән аның дулкыннары күкрәгендә!

Әнә, йомры башлы, салам чәчле, таза беләкле егет баян күреген киң ачып уйный, янындагы көлсу бөдрә чәчле, талчыбыктай нәфис сынлы кыз очынып җырлый:

«Кнопочки, кнопочки, хорошо играете,
Расскажите, кнопочки, что о милом знаете...»

Җырга күп сыя, Идел киңлекләрендә күп серләр яшеренгән. Шагыйрьләрнең гомер итүне дәрья кичү белән чагыштыруы да юкка гына түгел!

Мәдинә МАЛИКОВА — *язучы; «Кар сулары», «Шәфкать», «Алтын ятьмә», «Өермә» һ.б. китаплар авторы. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Кызның бәллүр чыңыдай тавышы, пароход тирәсендә очынган акчарлакларның ак канатларына эленеп, күкләрдә тибрәлә кебек. Аның янгырашында яшьлек ашкынуына үзәкнең өзелүе дә кушыла шикелле...

...Телевизор экранында мондый күренеш килеп чыккач, Әминә ихтыярсыздан аягына торып басты. Каян эзләп тапканнар моны? Әллә кайчан узган хәлләр бит инде!

«Бүген Казанга Украинадан зур делегация килде... Украина белән Татарстан арасындагы дуслык күптәннән матур традициягә әверелде инде, — дип сөйли диктор Инсаф Абдуллинның тавышы экрандагы күренешләр артыннан. — Моннан берничә ел элек тә Татарстанда Ворошиловград шәһәреннән дәрәҗәле делегация булып киткән иде. Арада сәясәтчеләр, рәссамнар, каләм ияләре бар иде... Экранда сез шул делегация килгәч төшерелгән кадрларны күрәсез.. »

Ә бит Әминә, бу күренешләр бөтен төсмерләре белән үзенең генә хәтеренә уелып калды, дип уйлый иде. Баксаң, телевидение саклаган икән...

Әйе, кунак булып төрлесе килгән иде, биредә дә аларны төрле иҗат әһелләре каршы алды. Алар арасында яшь журналист Әминә Мусина да бар иде. Әнә ул, экранда да күренә. Кунак җырчы белән баянчы янында басып тора. Чак кына арттарак яшьләр газетасы редакторы Әмир Нуриевнең җирән башы, сытык чырае чагылып узды. Бер генә дә кунакчыл хуҗа төсле түгел инде: авызы турсайган, куе кашлары җыерылган...

Ул чакта кунакларны ике зур төркемгә бүлделәр: берсе Чаллыга китте, икенчесе — Казан артына. Җырчы Нинаны башта беренче төркемгә язган булганнар, икенче төркемдәге баянчы Леонид тыз-быз килеп, делегация җитәкчеләре белән сөйләшеп, аны үз янына күчерде. Сизелеп тора: матур җырлаганы өчен генә түгел иде.

Арча, Балтач, Кукмара якларында аларны зурлап кунак иттеләр. Авыл клубларында, басуларда очрашулар уздырып, кичләрен урман аланнарында күңел ачып йөргәндә, әллә ничек кенә килеп чыкты, баянчы егет Әминә тирәсендәрәк бутала башлады бит. Нина моңаеп аңа карап-карап ала, тик инсафлы, тәрбияле кыз буларак, эчтән сыза, егетне кире үзенә авыштыру чарасын тапмый иде. Аның саен, тавышы моңлырак яңгырый:

«Кнопочки, кнопочки, кнопочки баянные,
Из-за вас влюбилась я, что же вы наделали...»

Хәлбуки, һич кенә дә Әминәнең ихтыярыннан тормады бу. Бергәләп концерт куеп йөрергә күнеккән бу парның арасын суытып, егетне үзенә карату уе ике ятып бер төшенә дә кермәде аның. Ә шулай да... Егетне читләштерү өчен бер ым, бер караш җитәр иде бит. Ник соң әле Әминә аның мөлдерәп каравына елмаеп җавап бирде, шаян сүзләрен хуплап көлде?

Моның төбендә үртәү ята иде. Нинаны түгел, һич юк, күңел түреннән бер дә китми торган башка берәүне үртисе килә иде аның. Ул егет гүяки Әминәнең һәр адымын, кыланмышын күреп, күзәтеп тора. Куе кашлары астындагы күзләренең карашы җитди, тирән, моңсу да кебек, аларның төбендә сүнми-сүрелми торган күмер көйри. Бәгырьне көйдерә торган ут иде бу.

...Казанга кайткач, аларны су трамваена утыртып, Идел буйлап сәяхәткә алып чыгып киттеләр. Ике төркем бергә кушылды, мондый күңелле вакыйга турында язарга дип журналистлар килде.

Менә хәзер, еллар узгач, телевизор экранында шул күренешләр җанланды. Әминәнең хәтерендә исә экранга сыймаганнары аермачык булып янарды.

Менә ул палубаның култыксасына таянып тора, менә Леонид аның

янына килеп басты. Пароходта йөзүнен шундый хикмәте дә бар бит: син күп кеше арасында, шул ук вакытта икәүдән-икәү колактан-колакка сөйләшү дә гаеп түгел.

— Күптән инде елгада йөзгән юк иде, — диде Леонид пароходка бәрелеп ургыган дулкыннарга карап. — Монда сулышлар иркенәеп китә, күз күреме бөтенләй башка. Уйлап карасаң, күпләрнең гомере кысынкылыкта уза бит... Мәктәпне тәмамлагач, мин шахтага төштем. Күмер чыгара торган шәһәрдә яшибез бит, ата-бабам шахтерлар. Беркөнне гадәттәгечә забойга барып житкән идек, бригададан бер абзый тормозогын подъемник янында калдырган булып чыкты. Ризык салган савытны шулай дип атыйлар бездә. «Син яшь кеше, аякларын жинел, йөгереп кенә барып алып кил инде», — диде бу мина. Чабып киткән генә идем: «Тра-а-ах! » — шартлау тавышы. Йөрәгем ярыла дип торам. Борылып карасам, забой юлын таш баскан. Ничек өскә менгәнемне хәтерләмим. Шуннан соң бүтән төшә алмадым. Анарчы баянда уйнауны күңел ачу өчен генә кирәк дип уйлый идем, ир-егетләргә лаек эш дип тә санамый идем. Шул хәлдән соң кадерен белә башладым. Музыка училищесына укырга кердем... Һәммәсе бирегә килеп, шушы пароходка кереп, сезнең белән янәшә басып тору өчен булган икән...

... — Башыгыз әйләнмиме?

Колак төбендә яңгыраган бу сорау сискәндереп җибәрде. Икесе дә сыннарын турайтып, борылып карадылар. Сузгә мавыгып сизми калганнар, яннарына өченче берәү — Әмир килеп баскан икән.

— Ни бар анда?

Шулай дип, ул якын ук килде, икесенең арасына басып, култыксадан түбән үрелеп карады. Сулышы белән Әминәнең битен өткәндәй итте.

...Бер уйласаң, ние бар инде моның? Яшь чакта андый шуклану-шаярулар — гадәти хәл бит. Тик бу күренеш нилектәндер хәтердән җуелмый, вакыт-вакыт, кайчак һич кирәкмәгәндә янарып куя. Әллә Идел өстендә булганга микән?

Ах, бар иде җәйләр, кояшлы көннәр, гүзәл күренешләр! Аннан соң күпме айлар-еллар үтте, баштан төрле хәлләр узды бит инде...

* * *

Әминә, тирән көрсенеп, дөнья хәлләрен сөйләүгә күчкән телевизорны сүндерде дә, тәрәзә янына килеп, алтынсу пәрдәне ачты.

Җир өстенә кыш үзенең калын кар түшәген салган, төн аны җиңел, йомшак караңгылык юрганы белән каплап куйган. Каршы йорт белән ике аралыкта фонарьлар юк, тәрәзәләрнең сирәгендә генә ут күренә, аларның пәрдәләре аша саран яктылык сирпелә. Бу турдан, шәрә ботакларын тырпайткан агачлар арасыннан, кеше-кара көндез дә сирәк уза. Хәзер исә бөтенләй җан иясе күренми. Тын, тыныч, бернинди хәрәкәт юк, җил дә исми, күрәсең. Ә менә күңел тыныч түгел, урамдагы тынлыкта нindидер хәвеф бардыр кебек... Юан кәүсәле, киң ябалдашлы тупыл астында, кар көртендә нинди зур кара тап анда? Әминә мангаен салкынча пыялага терәде. Гәүдә түгелме соң? Әнә башы, аяклары... Таеп егылган дисәң, соргылтланып, бераз ялтырап сузылган сукмактан читтәрәк... Исеректер. Андыйлар урамнарда аунаштыргалый шул. Алай дисәң, йөрәге тоткан янсә мие авышкан булуы да ихтимал бит. Карда озак яту берәүгә дә файдага түгел. Бик каты салкын тиясен көт тә тор...

Телефоннан шылтыратырга кирәк. Айныткычка... Килеп алсыннар, җылыга кертеп яткырсыннар... Алар игътибар белән карарлар, кирәксә, хастаханәгә озатырлар. Анда тиешле чараларны күрерләр... Үпкәсе шешмәс, буыннары сызлаулы булып калмас...

Ләкин Әминәне айныткычка шылтыратудан нидер тыя, аксыл-зәңгәрсу

жирлектә каралып яткан шәүлә нилектәндер йөрәкне сулкылдата иде. Нәрсәсе бар инде югыйсә. Шылтыратасың да бетте-китте... Калганын башкалар, шул эшкә куелган кешеләр карар.

Әмма, телефон трубкасын кулга алгач, бармаклар үзеннән-үзе «02» урынына «03» кә басты.

— «Ашыгыч ярдәм» тыңлый, — диде эшлекле, шул ук вакытта битараф хатын-кыз тавышы.

— Монда берәү карга чумып ята.

— Ни булган?

— Белмим.

— Үзе әйтмимени?

— Ул безнең йорт каршында. Тәрәзәдән күренә.

— Күптән ятамы?

— Әле генә күрдем. Салкын тидерүе бар, ә бәлки, йөрәге тоткандыр.

— Сезнең адрес? Фамилиягез ничек? — Хатын кырысланып киткәндәй булды. — Хәбәрегез кабул ителде, — диде соравына җавап алгач һәм араны өзеп тә куйды.

Шуның белән Әминәнең гражданлык бурычы үтәлде, ярдәмгә мохтаҗ адәм баласы игътибарсыз калмады. Хәзер юынып алырга да йокларга ятарга кирәк.

Ләкин җан тынмады. Кар өстендәге шәүлә нинди дер кодрәт белән аны тәрәзә янында тотып тора иде шикелле. Пыяла да, Әминәнең күзлеге дә парланды, аларны сөрткәләгәндә, борчылудан куллары калтыранды. Ник килмиләр икән инде? Туна бит...

Хәлбуки, йөрәге белеп сыкрана иде аның. Карда яткан кешенең аягына басарлык кына түгел, сынын тотарлык та егәре калмаган, телен әйләндереп сүзен әйтерлек тә хәле юк иде. Тик әледән-әле керфекләре күтәрелә дә мөлдерәгән күзләре алтынсу яктылык сибелгән тәрәзәгә төбәлә. Карашының күзгә күренмәс нурлары ике катлы пыяла аша үтеп, якты бүлмәдәге кешенең күнеленә барып ирешер кебек тоела. Әйе, шулай булырга тиеш. Бу затны үз янына күз карашы белән чакырып китергән чаклары бар иде бит аның.

«Мин килдем, тик янына керә алмыйм... Кил тәрәзә янына! — дип дога укыгандай ялварды ул күңеленнән. — Кара бирегә! Син генә коткара аласың мине... Син генә...» Күпмедер онытылып торганнан соң, тагын берничә мизгелгә зиһене ачылгач, ул чыннан да тәрәзә янында таныш шәүләне күреп алды. «Килдең... — дип пышылдады кипшенгән иреннәре. — Хәлемне сиздең...» Һәм бөтен вөҗүден биләгән куркудан арынгандай булып, күзләрен йомды да онытылды.

...Аны күзәтеп торган Әминәгә минутлар бик әкрен уза кебек тоелды. Ниһаять, каршы йорт артыннан яшел «УАЗик» килеп чыкты. Туктады. Кабинасыннан куртка кигән ике кеше төште. Иллә дә гамьсезләр, әкрен кыймылдыйлар инде! Бераз вакыт кулларын буташтырып, сукмакта таптандылар. Көрткә батасылары килми иде, күрәсең. Менә, ниһаять, берсе, әкренәйтелгән кинокадрлардагы кебек, пошмый гына аягы белән кар көртен сыдыргалады, таптанып, эз салгандай итте. Аннары теге гәүдә өстенә иелде. Икенчесе аның янына узды. Берсе тез астыннан, икенчесе иңбашыннан тотып, теге кешене күтәрделәр. Ә ул шактый таза гәүдәле икән, шуның өстенә сынын да тотмый, янбашы турыннан урталай сынгандай, карны сыдырып, салынып төште. Һушсыз иде булса кирәк. Тегеләр исә буй-сынга аннан калыш, авыр капчыкны өстерәгәндәй, бата-тая интегеп, ә бәлки, тиргәнеп-сүгенеп тәдер, машина эченә сөйрәп керттеләр, аннары, мөгаен, җинел сулаптыр, чалбар балакларын каккаладылар. Ниһаять, машина кузгалып, урам якка борылды да күздән югалды.

Һушсыз. Кемнендер газизедер... Ата-анасы, бәлки, хатыны, улы-кызы бардыр. Югалтканнардыр, эзлиләрдер. Кесәсендә документлары булса, шундук өенә шылтыратып әйтерләр, әлбәттә. Әгәр кемлеген белсә, Әминә үзе дә шушы минутта ук хәбәр итәр иде.

...Бу хәлләрне ул соңыннан мең мәртәбә күз алдыннан уздырды. Нишләп йөрәк сизгер икән дә, ник баш эшләп житкерми икән? Сизенде бит, сизенде, тик анлап житкермәде. Ах, әгәр белгән булса!.. Йөгереп чыгар иде дә күтәреп кенә алыр иде...

Ә ул чакта борчылуын куарга тырышты. Алты яшьлек Нариман караватында мышнап йоклый, ире Нәзир телевидениедән бер төркем белән Чиләбедә яшәүче татарлар турында тапшыру әзерләргә командировкага киткән иде.

Өйдә тыныч, борчучы юк. Арылган, йокларга вакыт. Әле генә Әминә үзе житәкләгән хәйрия җәмгыяте турында яшьләр газетасы өчен мәкалә язып тәмамлады, иртәрәк торып, баланы уятканчы шуны тагын бер тапкыр укып, төзәтеп чыгарга кирәк булыр...

* * *

Икенче кичне ул Нариманны бакчадан алып кайтып керүгә, телефон шылтырады.

— Хәерле кич! — диде бераз карлыкканрак ят ир тавышы. — Милициядән бу. Тикшерүче Вәлитов. Кичә кич, ишегалдында бер кеше ята, дип «Ашыгыч ярдәм»гә сез шылтыраттыгызмы?

— Әйе, мин.

— Көндез трубканы алмадыгыз.

— Мин эштә идем. Монысы — өй телефоны. Ә теге адәмне кичә шундук килеп алдылар, рәхмәт. Югыйсә карда күпме ятып була?..

— Озак яттымыни?

— Белмим шул. Мин аны очраклы рәвештә, тәрәзәдән карагач кына күреп алдым...

— Сезнең кемегез соң ул?

— Беркемем дә түгел. Бер-бер хәл булганмы әллә? Ник ук чирләп китмәгәндер бит? Үпкәсе-мазар шешеп...

— Ул нишләптер нәкъ менә сезнең турыгызга килеп егылган. Моның берәр хикмәте юк микән? Сез ничек уйлыйсыз?

— Аның хакында уйларга башыма да килгәне юк! Кем кайда таеп егылмас! Урам уртасы бит ул.

— Урам дип үк әйтмәс идем мин. Тыкрыкның да аулагы. Андый җирдә халык күп таптанмый... — дип уйлангандай дәвам итте тикшерүче. — Безгә очрашып сөйләшергә кирәк.

— Ә нәрсәгә? Кем соң ул? Ник якыннарыннан сорамыйсыз?

— Иртән тугызда очрашсак яхшы булыр иде. — Тикшерүче сорауларга җавап бирмәде. — Каршы килмәссез бит? Килештек алайса. Сездән ерак түгел бит без. Адрес... Егерме дүртенче бүлмә. Мин дежурныйга әйтеп куярмын, ул сезгә юлны күрсәтер...

Шулай дип ул, ни әйтергә белми аптырап калган Әминәнең телгә килгәнен көтеп тә тормыйча, телефон трубкасын куйды.

Юньлелеккә түгел иде бу. Әллә соң теге адәм үлеп үк киткәнме? Бик ихтимал. Машинага салганда, тәнендә җан әсәре сизелмәгән иде... Хәер, күз күрмәгән, колак ишетмәгән бәндә өчен ник хафаланырга әле? Миллион халыклы Казан каласында яшибез ләбаса. Морглары да, мәңгелеккә озатучы оешмалар да, зиратлар да туктаусыз эшләп тора. Бала тудыру йортлары кебек үк. Бәлки, ул адәмнең кесәсендә документлары булмагандыр, үзе һушсыз ятадыр. Эзләүчесе дә юктыр, күрәсең. Калада иясез сукбайлар күп диләр.

Шуларның берәрседер. Ә бәлки, кыйнап ташлаганнардыр үзен... Милиция андыйны тикшерергә мәҗбүр. Жеп очын таба алмыйлардыр. Кемгә барып ябышырга белми торганнардыр... Әрепләшеп тә булмый, бармасаң, үзләре килеп житәрләр. Иртән эшкә барганда, сугылып чыгарга туры килер шул...

Әминә шулай уйлады.

* * *

...Тышкы ишектән кергәч, Әминә каракүл тунының кесәсеннән кулъяулык алып, парланган күзлек пыялаларын сөрткәләде. Сул яктагы рәшәткәле тәрәзә артында утырган яшь кенә сержант аңа сынаулы, хәтта кырыс карашын төбәгән иде:

— Сез кемгә? Документыгыз бармы?

Кызыл күн тышлы таныкнамәне кулына алып, алтын хәрефләр белән уелган «Союз журналистов СССР» дигән язуны күргәч, ачылып китте, елмаеп жибәрде үзе:

— Безнең Мансур Хужиевичтан интервью алырга килдегезме? Аның хакында язып торалар шул. Һәм дөрес эшлиләр. Мәскәүдә ничектер, белмим, ә менә Казанда ул берд ә нбер. Үткен, төпле, гадел...

— Үзе биредәме?

— Әле генә килде. Көтәм, диде. Икенче катта, баскычтан менгәч сулга. Озатып куйыйммы?

— Табармын.

Мансур Хужиевич күксел төстәге бераз таушалган костюм кигән, нык бәдәнле, йомры башлы, чал кергән куе чәчле, бик тә житди чырайлы, илле яшьләрдәге абзый икән. Әминәне күргәч, өстәлдә яткан кәгазьләрдән башын күтәрде, күзләрендә дикъкать, таләпчәнлек тә, шул ук вакытта кайгыртучанлык та чагылды кебек. Кырыс холыклы әтиләр тиктормас балаларына шулай карый. Исәнләштеләр. Әминә аңа да таныкнамәсен сузды.

Иллә дә шәп документ иде бу! Аны күргән һәркем белә: СССР журналистлар союзына талантлы, тәжрибәле, язмалары белән танылган каләм әһелләрен генә кабул итәләр иде. Әминә Мусина аңа «Совет гаиләсе» журналында эшләгән чагында керде. СССРның таралганына берничә ел инде, әмма мондый таныкнамәнең бәһасе кимемәде, киресенчә арта бара шикелле. Моны яхшы белгәнгә, документ сораган жирдә Әминә паспортын түгел, шушы катыргыны күрсәтә.

Аны ачып карагач, тикшерүче абзыйның шома кырылган йөзе ачылып китте.

— Бәй, коллегалар икән бит без! Эш пешә инде болай булгач! — Шулай дип, урыныннан торып басты ул. — Узыгыз әйдә, утырыгыз.

Әминә көлемсерәп куйды:

— Мондый эштә сезнең белән тигезләшеп буламы? Аннары мин хәзерге вакытта редакциядә эшләмим, хәйрия җәмгыятен житәклим.

— Журналист кеше кайда эшләсә дә каләм иясе булып кала. Безгә ничек карыйсыз бит. Тигез итепме, әллә өстәнме. Бәгъзе журналистлар чамасыз һавалы кылана. «Эфир»дан килсәләрме? Сорауларына жавап табып бетерерлек түгел!

Чыннан да, «Эфир» исемле шәһәр телевидениесендә эшләүче егет-кызлар кыю, төпченүчән, хәтта әрсез буларак Казанда дан тоталар.

— Биредә сорауларны сез бирергә жыенасыз бит әле, — диде Әминә.

— Сорауларга керешкәнче, безгә бер жиргә барып килергә туры килер. Ярты сәгать вакыт табарсыз бит?

— Сез әйткәч ничек карышасың инде...

— Киттек алайса.
— Кая?
— Баргач күрерсез.

Гаҗәп иде бу. Әмма артыгын төпченә алмыйсын. Милиция бит ул, синнән бөтенесен сыгып чыгара, үзе исә теләгәнен генә әйтә.

Менә ул телефон трубкасын алды.

— Русланга әйт, машинасын кабызсын, хәзер барабыз.

— Мин машинада, — диде Әминә.

— Безнеке кулайрак булыр.

Иртәнге якта шәһәр урамнарында әле анда, әле монда машиналар тыгылып, туктап кала, «бөке»ләр хасил була. Шәһәрнең «Квартал» дип аталган районында яшәүчеләр мондый афәттән аеруча нык иза чигә. Хәзер аларга нәкъ менә шуннан Казансуның аргы ягына барырга кирәк икән.

Түбәсенә елкылдавык лампа (халык арасында аны «зәңгәр чиләк» дип атыйлар) куелган ак «Лада» елга аша салынган күпергә таба юнәлде. Әледәнәле сиренасын чинатып, туктап калган машиналарны әле бер, әле икенче яктан уратып, урыны-урыны белән тротуардан җилдереп барды. Сары чәче иңнәренә таралып төшкән, егерме бишләр тирәсендәге озынча ак чырайлы Руслан ара-тирә тиргәнеп алды:

— Карагыз әле, Мансур Хуҗиевич, нишлиләр болар, ә! Трамвай юлына басканнар бит! ГАИ ни карый? Акчага права өләшүдән башканы белмиләр, ахрысы. Күрәсезме, нинди әкәмәт? Дүрт машина «үбешкән» бит монда? Кайчаннан бирле торалардыр инде!

Аннары тәрәзәсен ачты да янәшәдә басып торган машинаның шоферын тиргәп ташлады:

— Ты куда, козел, прешь? Жить надоело? Прав хочешь лишиться? Или по нарам соскучился?

Казан шоферларының авызыннан коелып кына тора торган сүзләр бу. «Козел» дигәне дә кимен куймас иде, машинаның түбәсендәге ут күзен камаштыра, кысылган иреннәрен генә чәйнәргә кала.

Ниһаять, күперне чыктылар. Машина Көньяк трасса дип аталган, уртасыннан трамвай рельслары сузылган киң юлдан уңга борылып, сөзәк үргә менә башлады. Әминәнең күнеленә шом йөгерде. Юньле юл түгел иде бу. Анда медицина үзәкләре: иркен ихаталар эчендә кан салу станциясе, арырак унбишенче хастаханә. Алты катлы саргылт бина артында, киң ихатаның аргы ягында моргы да бар... Ник киләләр алар монда?

— Борыл, ишегалдына керәбез, — диде тикшерүче шоферга хастаханә турына җиткәч. Зур капка шар ачык, керер юлны аклы-каралы арата бүлеп тора иде. Машина сиренасы чинады, эчке яктагы биек будканың тәрәзәсеннән каравылчы картның куркынган чырае чагылып узды, аклы-каралы арата өскә күтәрелде. Милиция машинасының юлын бүлеп, документ-фәлән сорап тормадылар.

Алар тышкы ишектән эчкә керүгә, гардеробның култыксасы аша ак халатлы юан хатын үрелеп карады, каршысында тезелеп торган биш-алты кешегә читкә тайпылырга ишарәләп, тикшерүчегә кулын изәде:

— Исәнмесез! Килегез, кил!

Мансур Хуҗиевичның бирегә беренче килүе түгел иде, күрәсең. Хатын, сузылып, тикшерүченең курткасын, Әминәнең тунын, бүреген алды да ике халат, башмаклар сузды.

Эчкә уза торган ишек төбендә түшенә «Охрана» дигән язу тагылган ир заты басып тора иде, тикшерүчене күрүгә, юл биреп читкә тайпылды.

Дүртенче катка менеп, озын, биек, шыксыз коридор буйлап киттеләр. Аларга каршы зәңгәрсу пижама кигән ир затлары, чәчәкле фланель

халат кигән хатын-кызлар очрады. Төрлесе төрле яшьтә, җенес-кыяфәттә булуларына карамастан, чырайларына чыккан хасталарга хас күндәмлек, карусызлык галәмәте аларны бер иш итә иде. Әле кайчан гына күңелне алда торган мәшәкатьләр — гадәти яшәеш гамьнәре биләп алган иде һәм мондый халәт, көн дә кабатланып торганга, бүген дә шулай булыр иде кебек. Ләкин бирегә кергәннән соң яшәешнең агышы әкренләп, әмма котылгысыз рәвештә үзгәрә башлады шикелле. Әйтерсең лә җанга сиздерми генә җиңелчә томан сара иде. Ул шыксыз коридорларның почмакларыннан саркый, башмакларын сөйрәп атлаган кешеләрнең йөзләренә сарылган, аннан да бигрәк янәшә атлаган кешенең кыска керфекләренә уралган иде. Ник бер сүз әйтми ул?

Коридорның аргы башы акка буялган зур ишек белән бүлеп куелган, анда «Реанимация бүлеге» дип язылган иде. Мансур Хуҗиевич шакуга, ишек ачылып, авыз-борынын битлек белән каплаган кыз күренде.

— Без тикшерү бүлегеннән... Баш врач сезгә әйтеп куям дигән иде.

Эчтән аларга каршы шундый ук битлек кигән ак халатлы яшь табиб атлады.

Палатага кергәч, Әминәнең күз аллары караңгыланып киткәндәй булды. Караватларда хәрәкәтсез яткан гәүдәләр, алар янындагы тимер таякларга эленгән шешәләр, алардан сузылган көпшәләр аның өнен алды.

— Менә ул,— диде табиб пышылдап һәм түргә, жалюзи белән капланган тәрәзәгә башы белән куелган караватка ишарәләде.

Тоташ акка төренгән гәүдә зур иде, бите ак марляга уралган, күз уемнары белән авыз-борыны турында гына ачыклык калган. Борынына да, сул беләгенә дә нечкә пластик көпшә беркетелгән.

— Һушына килмәдеме? — дип сорады тикшерүче.

— Юк әле. Тиз генә айнымастыр кебек.

Аларның болай да пышылдап әйткән сүзләре Әминәнең колагына бөтенләй килеп ирешмәде. Ян-яктагы караватларны куе томан сарды кебек. Түрдә яткан кешенең марля астыннан бүселеп чыккан бакыр тимерчыбык кебек чәч очларыннан очкын чәчрәп, бәгырьгә ялкын үрләттемени... Булмас... Мөмкин түгел... Жирән чәчлеләр азмыни? Ләкин караватк кырыеннан салынып төшкән кул, шакмаклы киң тырнак берәүдә генә... Андый юк бүтән!

Әминә алга атлады, караваt янына тезләнде дә, кайнар кулны битенә терәде.

— Синмени бу, алтыным, нурлы ярым?.. Нишләттеләр сине?

Әминә һушсыз кешенең бармакларын күз яшьләре белән чылатып, назлы сүзләр пышылдап үбә, үзенә текәлеп карап торган ике ирнең барлыгын да оныткан иде.

— Әйдәгез, чыгыйк, — дип аның иңбашына кулын салды табиб. — Монда озак торырга ярамый. Бигрәк тә болай истерикага бирелеп.

Коридорга чыккач, Әминә ашыгып сумкасыннан кульяулыгын алды, күзлек астыннан күзләрен сөртеп, табибның йөзенә текәлде.

— Ни булган аңа?

— Күп төрле травма... Башында, эчке органнарында...

— Нәрсәдән?

— Кыйнаганнар.

— Кем?..

Табиб иннәрен генә сикертеп куйды. Әминә тикшерүчегә борылды:

— Кем кыйнаган? Ник?

— Без дә шуны белергә теләр идек.

— Мин моннан китмим, аның янында утырам, — диде Әминә.

— Мин сезне аңлыйм,— диде табиб. — Сез авыруның иң якын кешесе, хатыны.

Әмма без моны рөхсәт итә алмыйбыз. Ярдәмегез тимәс, комачаулаячаксыз гына. Өегезгә кайтыгыз, хәл алыгыз. Сезгә көч җыярга кирәк.

Соңгысы Әминәне сискәндерде.

— Әллә?..

— Хәзергә өзеп кенә берни дә әйтеп булмый. Комадан чыкканын көтәбез.

— Ә бәлки, кыйммәтле дарулар кирәктер? Консилиум җыярга?

— Консилиум җыярбыз. Дарулар җитәрлек.

— Бәлки, башка хастаханәгә күчерергәдер? Республиканскийга?

— Бу хакта сүз булды. Аны кузгатырга ярамый.

— Ләкин аны мондый шартларда яткыру бернинди кысага да сыймый!

Әминә соры таплар җәелгән биек түшәмне, зәңгәр буявы кыршылган стеналарны күздән кичерде.

— Авыруны стеналар дәваламый, — диде табиб туры кашларын җыерып.

— Белгечләр чакырырга? Иң яхшыларын?

Табиб хастаханәнең начар даны турында яхшы белә, шуңа күрәдер дә Әминәнең уйламый әйткән сүзләрен аеруча авырга ала иде.

— Үзегезне кулга алыгыз! Ирегез хакына! Кайда дәвалана иде ул? Безгә аның дәвалау карточкасы кирәк. Анамнезын ачыкламыйча торып, бернинди консилиум да тиешле дәвалау чараларын тәкъдим итә алмый! Мондый авыруның якыннарына көч кү-үп кирәк булачак әле! Әзер торыгыз!

Әминә чит кешене авыр хәлдәге хаста янына якын җибәрмәячәкләрен яхшы аңлый иде, шуны уйлап: «Мин аның хатыны түгел!» — диюдән тыелды.

— Һушына килүгә безгә хәбәр итегез, — диде тикшерүче табибка һәм, Әминәнең беләгеннән тотып, чыгу ягына тартты.

Коридордан баскычка борылгач, Әминә яшьле күзләре белән тикшерүчегә төбәлде:

— Хатыны, Луиза Нуриева, Төркиядә бит. Кичә генә очтылар, дип ишеттем радиодан.

— Сез бу кешене Нуриев димәкчемени?

— Ничек? Сез аны танымадыгызмыни?

— Әлегә ул билгесез кеше булып санала. Документлары юк, башы-бите уралган, үзеннән сорап булырлык түгел. Ә сез ялгышмыйсызмы?

— Якыннарыннан сорагыз.

— Хатыны китте, дисез бит.

Әминә үзен кулга алырга, сулкылдавын тыеп, булдыра алган кадәр эзлекле итеп аңлатырга тырышты.

— Анда Искешәһәр белән Казан арасында тугандашлык элемтәләре турында килешү төзиләр бит, — диде. — Нуриева делегация җитәкчесе, документларга ул кул куячак. Бүген-иртәгә кайтып җитмәсләр шул. Берничә көн Стамбулда да булачаклар. Үзләре белән рәссамнарны, җыр һәм бию ансамблен дә алып киткәннәр. Концертлар куячаклар, күргәзмәләр уздырачаклар. Соңгы хәбәрләрдән ишеткәнсездер бит? Шылтыратырга кирәк! Кайтсын! Шундук хәбәр итәргә иде!

— Кайчан ул шундук? Потерпевшийның, имгәнгән кешенең дим, кемлеге әле генә беленде! Анысы да әлегә ике сарылы. Ә бәлки, сез ялгышкансыздыр? Документларын карамадыгыз, йөзен күрмәдегез...

Әминә башын иде.

— Их! Ялгышсам гына иде лә! — диде үзалдына пышылдап, иреннәрен чак тибрәндереп. — Кайтсын соң Луиза! Юкка чыгарсын минем сүзне!

— Нуриевның дәвалану карточкасы «спец»тадыр инде?

«Спец» дип халык арасында Шмидт урамындагы хастаханәне атыйлар,

анда республиканың җитәкчеләре, абруйлы кешеләре дәвалана. Нуриев та, тешен яматырга яисә рентген үтәргә кирәк чакта, билгеле инде, участок сырхауханәсенең коридорында чиратта утырмагандыр!

— Анда хәбәр итәрбез. Ничек дәвалыйсын үзләре карарлар. Тиешлесе эшләнер. Әйдәгез! — диде тикшерүче.

Әминә ничек итеп бинадан чыкканын, ничек итеп машинага утырганын, ничек итеп кабат тикшерүче бүлмәсенә кергәнен аңышмады.

— Мин сезне аңлап бетермим, — диде Мансур Хуҗиевич карашын өстәлгә төбәп. — Мәктәп баласы түгелсез, үзегезне кулга алырга тырышыгыз. Хәзер без кайбер нәрсәләрне документлаштырып куярбыз.

Монысы сискәндереп җибәрде:

— Нәрсәне?

— Аңсыз яткан авыруны тануыгызны, аның халык депутаты Әмир Солтанович Нуриев икәнлегендә шигегез юклыгын кәгазьгә теркәп куярга кирәк... Баштук айныткыч машинасында дыңгырдатырга кирәкмәс иде. Нык исерек булмаган ул. Бераз салмыш кына. Канында бер промилле гына спирт табылган.

— Эчә торган гадәте юк аның!.. Караңгы иде! Карга чумган! Айныткычны мин чакырмадым бит, «Ашыгыч ярдәм»гә шылтыраттым. Сез дә инде... Әмир Нуриевны танымаска.

— Эчкә шом кергән иде керүен. Кай җирендер аңа охшаттым. Ләкин тәгаен әйтә алмадым. Соңгы булып аны сез күргәнсез бит?

— Нишләп соңгы?

— Сез күргәннән соң аны милиция алып киткән. Һәммәсен тиешенчә документлаштырганнар. Менә хәзер без дә шулай итәрбез...

...— Миңа китәргә рөхсәттер бит? — диде Әминә кәгазьләргә кул куеп аягүрә торып баскач.

— Мин сездән иртәгә иртән янә бирегә сугылып чыгуыгызны үтенер идем.

— Ник? Хәзер кем икәнен беләсез бит инде. Калганына минем кирәгем юк.

— Ә менә мин алай уйламыйм. Сез би-ик кирәк әле безгә. Миндә бик күп сораулар туды.

— Хәзер сорагыз.

— Бүгенгә җитеп торыр... Тагын шуны кисәтеп куям: сез бу хәбәрне Нуриевага ирештерми торыгыз.

— Анысы сезнең бурыч! Хәтәр хәбәрне гадәттә милиция китерә.

— Сез, журналистлар, кимчелекне генә күрәсез шул! Күпме кешене коткарабыз, күпмесен сөендерәбез, анысы сезнең каләмгә сирәк эләгә... Тик бу очракта сезгә телегезне дә, каләмегезне дә тыярга туры килер. Һәммәсен югарыдагылар хәл итәр... Нуриев бит ул! Нишләп нәкъ менә сезнең тәрәзә турында шушы фаҗигага юлыккан ул? Шәһәр урамнарын тәпи-тәпи таптый торган зат түгел — персональ машинасы кайда булган? Кем кыйнаган?

— Мин каян белим?

— Башка чакта җинаятьләрне тикшерергә журналистларны куш, бездән уздырып җибәрәсез, милициягә акыл өйрәтеп туймыйсыз. Бу очракта менә, урыслар әйтмешли, карты в руки! Уйлагыз! Тикшерегез! Рәхмәт әйтербез! Мактау кәгазе бирербез... Иртәгә иртүк мин сезне зар-интизар булып көтәчәкмен!

* * *

Милиция бүлегенең капкасы янында Әминәне зәңгәр бөркәвечле «ГАЗ-53» машинасы көтеп тора иде. Мондый машина башка беркайда да юктыр. Моны күпләр белә дә. Казан белән Чаллы арасын еш җилдереп узарга туры

килә, андагы ГАИ постлары туктаткалыйлар. Тик, борчыласы юк, юл йөрү кагыйдәләрен бозган өчен түгел. ГАИ егетләрен кабинаның ишегенә алагаем зур итеп ясалган бик тә матур Кызыл Ай сурәте кызыксындыра. Матур булмый ни! Аны газета-журналларны бизәү остасы, мәгълүм рәссам Айдар Үтәгәнов үзе ясап бирде бит! Әминәне хатын-кыз буларак яратканга һәм журналист буларак хөрмәт иткәнгә генә эшләде ул бу эшне. Юкса үз-үзен ихтирам иткән рәссам андый белән шөгыльләнә димени?

Сурәт шәп, ГАИ хезмәткәренең күңеле хуш.

— Мәчеттәнме әллә сез? — дип сорый ул.

— Юк, без хәйрия җәмгыятеннән.

— Фәкыйрьләргә ярдәм итәсезмени?! Юлларыгыз уң булсын!

Әйе, машинасы дөньяда бер, шоферы да тиңдәшсездер, мөгаен. Яше кырыкка житкәч тә сыек сынлы, сабый холыклы булып калган шоферны күргәнегез бармы сезнең?

Әнә ул, ачык тәрәзәдән башын сузып, сары керфекләре арасыннан зәңгәр күзләре белән мөлдерәп карап утыра.

— Киттек, Рәмис, эшкә, — диде Әминә кабинага менеп утыргач.

Аның эш урыны шәһәр уртасында, Татар иҗтимагый үзәге бинасындагы ике бүлмәдән гыйбарәт. Алар анда икәү эшлиләр: Әминә үзе һәм ярдәмчесе — яше алтмыштан узган Миннур апа. Бу арада алар бик матавыклы эшкә керешкәннәр иде: Казан янындагы санаторийга гарип балаларны гына җыеп, бер смена ял иттерергә кирәк. Юлламаларны хөкүмәт бирә. Оештыру гына җәмгыять өстенә төшә. Өстән караганда, әллә ние юк та шикелле. Ләкин, ныклап тотынгач, кыенлыклар килеп чыкты. Күп очракта гарипнең холкы да ташка үлчим, көен табу җиңел түгел. Өстәвенә иң авыр хәлдәге балалар шәһәрнең төрле якларында яши. Юлламалар исә районнарга бүлеп бирелә. Гарип баланы сәламәтләр белән бергә ял итәргә җибәрсәң, ул кимсенә, түбәнсенә, рәхәт чигәсе урында эчтән сыза. Әниләренә дә читен. Андый шартларда нинди ял итү дә, нинди дәвалану инде ул! Бер иш балалар җыелган җирдә исә бөтенләй башка!

Иң беренче эш итеп, шәһәрнең төрле районнарында яшәүче кулсыз-аяксыз бичара балаларның, урын өстеннән кузгала алмаганнарның исемлеген төзеделәр. Ата-аналары белән киңәшкәч, ныклап эшкә керештеләр.

Бик мохтаҗ, фәкыйрь гаиләнең берсе Юдинода ук яши икән. Телефоннары да юк. Әминә Миннур апаны машинага утыртып шунда җибәрде. Үзе төрле оешмаларга ярдәм сорап хатлар язарга утырды...

* * *

Тормыш мәшәкатьләре үз көе белән бара. Көндез эштә кирәкле кәгазьләр язылды, килгән кешеләр белән сөйләшенде. Кичен Нариманны балалар бакчасыннан алып чыгу, кибеткә кереп чират тору, пешерү-ашау, баланы юындырып йокыга яткыру, аннары керен юып элү мәшәкатьләре белән узды. Әле дә ярый ул бар, аның такылдавын тыңлау, башыннан сыйпау, әкиятләр сөйләү бәгырьне туктаусыз көйдереп торган утлы күмергә су сипкәндәй итә.

Инде менә бала күзләрен йомып, татлы мыснап, тынып калгач, йөрәккә янә ут капты. Әминә тагын тәрәзә янына барып басты.

Ничек булды соң әле бу? Нишләп ул Әмирне танымады? Күңеле тынгысызланган, хәтта ничектер шомланган иде бит! Юкка булмаган икән! Әгәр тәрәзәгә алданрак күз салса, Әмир табиблар кулына иртәрәк барып керсә, хәле болай ук начараймас иде, бәлки!

«Теләкләрең чынга аштымы? — диде Әминә ачынып үз-үзенә. — «Газаплансын-

сызлансын иде, бәгыре парә-парә телгәләнсен иде!» — дип күпме теләгән иден!» Бу уй ана коточкыч булып тоелды. Зур тизлек белән машинада барган шофер кинәт берәрсенә килеп бәрелсә, шундый хәлдә кала торгандыр. Әйе, рәнжеде, эченнән генә тиргәде, әмма беркайчан да авыр имгәнүен, үлемен теләмәде. Сөйгән ярын, уйлапмы-уйлап житкермичәме, газапларга дучар иткәнен, ниһаять, аңласын, аяныч хаталарын танып бәргәләнсен, үкенечләрнең утлы кисәве бәгырен көйдерсен — менә шуны гына күз алдында китерә иде Әминә. Аны үлем чигендә күреп, үкенечләр ялкынында үзем янармын, хәлсез кулларын күз яшьләрем белән юып, үбәрмен, дигән уй анын башына да килмәде!

Ах, нинди нык, көчле иде бит ул куллар! Нинди назлы була ала иде алар! Күпме төшләрендә күрде ул аларның иңнәренә сарылганын!..

...Бер күрүдә, беренче караштан ук алар арасында утлы җеп сузылып, йөрәкләрен бер-берсенә бәйләп куйгандай иткән иде бит. Әгәр дә тиң парлар бер алмадан яратыла, дигән сүз дөрес икән, алар, мөгаен, шундыйлардандыр.

Әйе, шулай, йөрәкләргә бер алманың ике яртысы бүлеп салынгандыр. Ә соң бу ике шәхеснең миенә-анына?.. Ул яктан карасаң ничек?

Күп нәрсә салынган иде аларның акылына, зиһененә, әмма теге алманың юка бер телеме дә юк иде анда...

Бик иртә хәреф танырга өйрәнгән һәм китап кортына әйләнгән Әминә әкият-хикәятләргә чын күңелдән ышана иде. Аларда мәхәббәт шулай тасвирлана бит: андый парлар бер-берсен өзелеп сөяләр генә түгел, ярты сүздән аңлашалар. Вакыт-вакыт кына да гайрәт чигү юк та юк инде, ачуланышу, үпкәләшү дә мөмкин түгел. Аларны аерса да кара эчле бәндәләр, залимнәр генә аера.

Бу очракта исә һич тә алай килеп чыкмады.

...Педагогия институтының тулай торагында спорт залы бар. Һәр якшәмбе анда бию кичәләре үткәрелә торган иде. Университетның тулай торагы да ерак түгел, яшьләр бию кичәләренә бер-берсенә йөриләр. Дөрес, университет абруйлырак уку йорты дип санала, анда укучыларның борыннары чөенкерәк. Алай да аралар гына түгел, күңелләр дә якын: тегесендә дә, монысында да авылдан килгәннәр күп, арада бергә үскән-укыганнары да бар...

Залда «Амур дулкыннары» исемле вальс яңгырый иде. Бии башламаганнар әле, егетләр-кызлар стена буенда тезелешеп басып торалар. Ишектән керүгә, Әминәнең карашы түр стена буенда, швед стенкасы фонында басып торган егеткә төбәлде. Дөресрәге, чәченә. Түшәмдәге лампочкалар яктысында анын йомры башы үзенә бер төрле булып ялтырап тора иде. Андый төсне музейларда күрергә була, борынгы курганнардан табып алынган хәзинәләр шундый. Һәм ул музейларның саллы ишек тоткалары. Ул тоткалар гадәттә арыслан башы рәвешендә ясалган.

Музейга куярга лаек башны нык җилкәгә утыртылган туры муен тотып тора иде. «Үзсүзле, киребеткәнгә охшаган, холкы кыскадыр», — дигән уй узды Әминәнең башыннан. Дәрәҗәсен бик беләдер, күрәсең: джинсы костюмы өстеннән ак якасын чыгарып салган. Оста киенгән: яшьләр арасында да бер иш күренер, саллы түрәләр янәшәсендә дә чит булып тоелмас.

Әминә ян стена буенда басып торган группадашы Фәрдия янына узды. Муенын теге егет тарафына борылудан тыярга тырышты. Әмма Фәрдиядән яшерә алмассың! Казах кызына охшаган җәенке чыраендагы шомырт күзләре тышындагыны гына түгел, эчендәгене әллә каян күреп-белеп тора!

— Кара, нинди егет килгән безгә! — дип, түгәрәк ияге белән чак сизелерлек итеп егет тарафына ымлады ул. — Тик син ымсынма.

— Нәрсәгә ымсынган әле мин?

— Каптырып өлгергәннәр шул инде...

Шулай дип, ак кофта, кара итәк кигән, шәм кебек төз сынлы, шома итеп таралган конгырт чәчле кызга ымлады. Өченче курста укучы Луиза иде бу, күптән түгел шушы тулай торакта яши башлады. Чибәр кыз, сүз дә юк. Кара тутлырак йөзе сөйкемле. Нечкә муенында башын югары тота, горур, әмма тәкәббер түгел. Андыйлар кеше көен таба, шул ук вакытта сиздерми генә башкаларны үз жаена сала белә. Әминә күнеленнән үзен аның белән янәшә баскандай чагыштырып карады. Буйга ул кыз, әлбәттә, биегрәк: Әминә метр да алтмыш кына, ә теге бер биш сантиметрга озынрактыр. Үкчәле туфли кигәнгә, егете белән тигез кебек күренә.

Куе конгырт чәчле, төсе-бите килешле, курчак кебек буй-сынлы Әминә беркем янында да ким күренә торган түгел, калын пыялалы күзлеге генә тәэсирне бераз боза. Әмма ул ачыклыгы, сүзчәнлеге, чаялыгы, күнел сизгерлеге белән алдыра.

— Бигрәк пар килгәннәр инде! — диде Фәрдия теге егет белән кыздан күзен алмыйча серле көлемсерәп. — Фотограф кына юк. Карточкага төшереп алырга да, икесен бер йөрәк сурәте эченә куеп, астына: «Без бергә гомергә», — дип язып, открытка чыгарырга булыр иде. Исемнәре генә туры килеп бетми. Әмир белән Луиза — сәер янгырый, шулай бит?

— Әмир исемлемени?

— Жисеменә лаек булганча. Борынгы чорда туса, чын әмир булыр иде. Дөресрәге хан. Чынгыз хан да жирән чәчле булган бит. Университетнын татар теле бүлегендә укый. Бик актив егет. Үзләренең профсоюз оешмасында бөтен эшне шул оештыра. .

Курсташлары арасында Фәрдияне «Инфәрдбюро» дип атаулары бер дә юкка түгел, кызый «Совинформбюро» («Совет информация бюросы») кебек — һәммәсен белеп тора! Белгәннәренен күбесен институтның «Педагогик кадрлар өчен» дигән күптиражлы газетасына яза йә бәйрәмнәр унаеннан чыга торган стена газеталарына урнаштыра. Үзе дә институтның профсоюз оешмасында. Группада взносларны ул жыя, катыргыларга маркаларны теле белән ялап ябыштыра. «Күпме сасы кeләй ашадың инде син?» — дип, егетләрнең кайсылары шаяртып та алгалый...

— Алай да өйләнешкән пар түгел бит. Бик теләсәң, тартып алып була, — дип дәвам итте Фәрдия.

— Бию кичәсендә егет аулап йөриммени инде?

— Бию кичәсе ни өчен соң ул? Әллә мине дә гаепләр иденме, Зайка белән шушында танышкан өчен!

— Ә Луиза?!

Фәрдия үчекләп көлемсерәде:

— Жинүче ич син! Теләгәненә ирешми калганың юк!

Чыннан да группада Әминәгә «Жинүче» кушаматы такканнар иде шул. Моңа беренче чиратта аның шахматтагы жинүләре сәбәп булды. Ул институтның жыелма командасында беренче тактада уйный, шәһәр ярышларында катнаша, студентларының зирәклеге белән дан тоткан авиация институты чемпионкасын да отты. Группада имтиханнарны гел «отлично»га бирел барган ике студентның берсе — ул, икенчесе Арнольд Мильграм. Сессия башланса, кем дә булса: «Мильграм, Мусина! Алгы сызыкка! » — дип шаярып ала.

Бу юлы да Фәрдия:

— Ошый икән, тарт та ал! Кызык булсын! Алга, алга! — дип үртәп алды.

Сүз шунда өзелде, артык каты янгырап танго көе уйный башлады. Жирән егет Луизаның биленә кулын салды. Әминә каршына КАИ студенты Володя килеп басып иде, Фәрдияне йөргән егете, физкультура факультеты

студенты Зиятдин — курсташлары атаганча Зайка — бөтереп алды. Озынча, ак чырайлы Володя елмаеп нидер сөйли, әмма Әминә аның сүзләрен ярымйорты гына ишетә, әйләнгәләгән арада бакыр башның аны күзәткәнен тоя, ихтыярсыздан һәр хәрәкәтен аңа ошарлык итеп ясый иде.

Музыка тынып, биюдән туктап торган арада, Фәрдия өзелгән сүзне дәвам итте. Ул инде һәрнәрсәнең дә төбенә төшәргә оста!

— Якташлар бит алар, бер мәктәптә укыганнар, — диде. — Луиза ике яшькә кечерәк.

Биегән-бөтерелгән арада Әминә чыннан да башта бик тиң булып күренгән бу пар арасында мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеклерәк икәнлеген сизеп алды. Әйе, Луизаның күзләреннән нур сибелә, ә егетнең чырае житди, ул кочагындагы кызга абыйсы кебегрәк карый шикелле. Бәлки, шулай тоелгандыр гына?

...Күзе сукыр түгел, башына тай типмәгән, нишләргә кирәген, дөресрәге, нишләргә ярамаганын баштук аңлады Әминә. Әмма аңлау бер, гамәл кылу икенче... Берничә биюдән соң ишектән ашыгып спорт костюмы кигән бер кыз килеп керде дә, Луиза янына барып, колагына нидер пышылдады. Икәүләшеп чыгып киттеләр. Була торган хәл. Тулай торакта бердәнбер телефон, ул аскы катта, ишек төбендә кизү торучы Наилә апа янындагы тумбочкада тора. Мөгаен, Луизаны телефонга чакырганнардыр. Ә бәлки, авылыннан берәрсе килеп төшкәндер?

Сәбәбе житдидер, чыгып китте кызый. Егет ялгыз калды. Ул арада «Дамский вальс» игълан иттеләр, кызлар егетләрне чакыра башлады.

— Мин синең Володяны чакырсам, каршы килмәссең бит? — диде Фәрдия. — Рәхәтләнеп бөтерелер идем бер.

— Зайканы миңа калдырасыңмы?

— Вальс әйләнә белми бит ул. Яратмый да.

Китте Фәрдия Володяга таба. Басып калды Әминә сураеп. Шунда нишләргә тиеш иде инде ул? Кайсы егет янына барып кул сузарга? Акыл моңа җавап биреп өлгермәде, аяклар үзеннән-үзе залның каршы ягына атлады. Бирегә беренче тапкыр килгән егеткә ятим кебек ялгызы басып тору читендер кебек тоелды, хәленә керү теләге туды.

Вальс биергә бик оста түгел икән үзе. Уңай якка әйләнгәндә иплe генә атласа да, кирегә бөтенләй бөтерелә белми.

— Таныш булыйк, — диде ул ничектер бик үз итеп, шул ук вакытта баласытыбрак. — Әмир мин.

— Беләм.

— Кем әйтте?

— Минем разведка яхшы эшли.

— Рәхмәт инде мине аңлавыңа.

— Нәрсәне аңлаган мин?

Әминә аңа гаҗәпләнеп текәлде. Егетнең йөзендә һәммәсе бик килешле иде: киң маңгайны карлыгач канаты кебек сызылган алтынсу кашлар бизи, төз борын, нык ияк. Күзләре якты, куе җирән.Читтән караганда кырыс кебек, ә менә елмайганда эчтән яктырып китә, бик гади, хәтта кечелекле булып кала. Алсу иреннәре читендә ун якта йомшак чокырчык хасил булып, ихтыярсыздан карашны җәлеп итә.

— Синең белән биисем килгәнне аңлавыңа рәхмәт инде, — дип Әминәне күкрәгенә кысып куйды ул. — Күземдә лазер бар минем... Шуның аша хәбәр җибәргән идем. Тотып алгансың. Шулай бит?

— Миңа лазер тәэсир итми, күзлегемнең пыяласы калын, — диде Әминә. — Ятим кебек басып торасың. Кызгандым.

— Син кем соң әле мине кызганырлык?

— Әминә мин.
— Шулай икәнлеге билгеле иде инде...
— Ничек икәнлеге?
— Исемнәребезнең бер иш икәнлеге...

Штраус дигән композитор «Вена вальсын» нишләп шулай кыска итеп язды икән? Музыка туктады, сүз ин кирәк жирендә өзелде. Егетләр кызларны, беләкләреннән тотып, элек басып торган урыннарына озата башладылар. Шунда гына күрде Әминә: Луиза да үз урынына кереп баскан, текәлеп аларга карап тора иде.

...Тулай торакта уза торган кичәләргә Луиза үзенең йөргән егетен бүтән алып кермәде.

Ләкин алтын чәчле Әмир Әминәнең күнел түренә урнашып калган иде инде.

Бер күрүдә бер-берсенә үлеп гашыйк булган парлар турында әдәбиятта күп язылган. Михаил Булгаковның «Мастер белән Маргарита» исемле романында бу аеруча үтемле тасвирланган. Буш урамда икәү кара-каршы киләләр. Күзләренә карашып, туктап калалар. Сүзләр кирәкми, һәммәсе шул мизгелдә болай да аңлашыла.

* * *

Бүлмәсенең ишеге ачылуга Мансур Хужиевич аягүрә торып басты.
— Хәерле иртә, Әминә ханым. Рәхмәт килүегезгә.

Бу юлы ул бик сак, кайгыртучан мөгамәләдә иде. Бәлки, үз сорауларына җавап тапкандыр? Өстәгеләр белән киңәшкәч, кайбер мәсьәләләр ачыклангандыр? Әминәнең моны бик тә сорашасы килә иде. Тик бу — аның эш урыны түгел, үзе дә бирегә интервью алырга килмәгән. Гадәттә сорауларны ул бирә торган иде, бирелә исә аннан рәсми рәвештә, беркетмәгә теркәп сорау алалар!

— Кәефләрегез ничек? — дип ана бертуган абыйсы кебек якын итеп карады Мансур Хужиевич. — Ничек йокладыгыз?

Әминәнең йөзе йокысызлыктан сулыгып киткәнен, яшь түгүдән күз төпләре күгәреп, карашының тоныкланып калганын күреп тора, билгеле. Әмма сорашуы мәгънәсезлектән дә, үчекләүдән дә түгел, хәлгә кереп, араларны җылытып, күнел бикләрен ачарга омтылудан иде. Әминә күзлеген салып, пыяласын сөрткәләде:

— Аның хәле ничек?
— Әле генә белештем. Үзгәреш юк, диделәр. «Состояние стабильно тяжелое». Кичәге кебек үк.
— Нуриевага хәбәр иттеләр микән?..
— Югарыдагыларга хәлне аңлаттык. Калганы алар кулында. Әйдәгез, без үзебезнең кулдан килгәнне эшлик әле.
— Ни килә минем кулдан? Нишли алам?
— Иң элек минем сорауларга төп-төгәл итеп, бернәрсәне дә яшермичә, ачыктан-ачык җавап бирсәгез иде. Өстән караганда вак-төяк булып тоелган әйберләр, вакыйгалар безнең эштә еш кына бик мөһим булып чыга.

Әминәнең ияге салынып төште. Ни хакында сөйләргә бу абзыйга? Нәрсәне яшермичә? Ачыктан-ачык диме? Әмир турында иң якын дустына да ахыргача ачылып сөйләгәне юк аның! Сер саклаудан гына түгел, һәммәсен ачып салу мөмкин түгел, моңа сүзләр җитмәячәк.

Тикшерүче аның сулыгып киткән йөзендәге үзгәрешләрне игътибар белән күзәтеп утырды. Аннары тавышын тагын да йомшартып:

— Әйдәгез, иң баштан башлыйк әле, — диде. — Кайчаннан бирле таныш сез?

Бу табигый сорау иде. Әминәнең үзенә дә, журналист эше буенча, еш

кына анарчы күз күрмәгән кешеләр, төрле һөнәр ияләре белән әңгәмә корып утырырга туры килә. Араларны жылытып жибәрү өчен иң яхшысы шул — баштан башлау. Кайда тудың-үстең, атаң-анаң кем. Әти-әнисе турында сүз чыкса, әңгәмәдәшнең чырае шундук яктырып китә, билгеле. Яшь вакытлар искә төшсә дә шулай. Ә яшь чакта егет-кызның танышып китү хәлләре кемнең күңелен жылытмас!

Ләкин моның жинаятьне ачуга ни мөнәсәбәте булсын да ни ярдәме тисен? Табигый ки, тикшерүче моны төп сүзгә керешкәнче Әминәнең күңелен жебетү, ихтыярын какшату өчен генә сораштырып маташа. Бию кичәсендә, егетнең алтынсу чәченнән үрләгән ялкынның йөрәкне ничек өтканен сөйләп утырырсыңмы әллә аңа?

— Без бер чорда укыдык, — диде Әминә сүзләрне чүбек чәйнәгәндәй әвәләп.

— Бер группадамыни?

Тикшерүченең куе кашлары тырпаеп килгән, күзләре хәйләкәр кысылган. Юри генә сорый, Әмир белән Әминәнең төрле жирдә укып, төрле тулай торакта яшәгәнен беләдер, мөгаен. Алай гына түгел, бу икәүнең язмышы ничек үрелгәне турында да шактый мәгълүмат жыйгандыр. Чын тикшерүче бит ул! Аннары хәзерге вакытта Нуриевның да, Мусинаның да исемнәре күпләргә таныш, аларның шәхси тормышы белән кызыксыну көчле. Тик моның әлеге фажигага ни катышы бар?

— Уку йортлары төрле иде. Әмма факультетлар шул ук. Икебез дә филологлар. Студент елларында яшьләр өчен чыга торган газеталарга языштык, эшли башлагач, бер комсомол оешмасында исәптә тордык. КПСС ка әгъзалыкка да ул шуннан тәкъдим ителде.

— Бер мәйданда биегәнсез икән. Шунда дуслаштыгыз дамы?

Әминә аның эчен актарырга теләгәндәй өздереп карады. Нинди дуслык турында сорый бу абый? Газета-журналларны күзәтеп бармый микәнни? Мусина үзенең мәкаләләрендә еш кына депутат Нуриевны тәнкыйтьләп телгә ала лабаса.

— Төрле чаклар булды инде, — диде Әминә тоныкт авыш белән.

—Бәхәсләшә дә идегезме? Жыелышта аңа каршы кул күтәреп тавыш та биргәнсездер, бәлки?

Ник сорап тора инде! Ә кысылган күзләре шундый хәйләкәр — күпне белгәне әллә каян күренеп тора.

— Минем үз фикерем бар иде...

— Нинди фикер инде ул? Нуриев яшьләр газетасының баш редакторы булырга лаек түгел, дидегезме?

— Киресенчә! Редактор урынына утыру аңа зур зыян салачак, дип санадым.

— Ничек алай?

— Урыны, бәлки, югары саналадыр да. Ә эше? Башкалар язганны укып, төзәтеп миен черетә. Кемнәрнедер эшкә ала, кемнәрнедер куып чыгара. Хезмәткәрләренә фатир алып бирү, балаларын бакчага урнаштыру артыннан чаба. Акча табарга, кәгазь юнәтергә, подписка жыярга... Яшь кешегә шундый эш кирәкме? Чын журналист һәрвакыт халык арасында айкала, үз илен генә түгел, дөньяны гизәргә омтыла. Аннары, «мин — коммунист», дип, күкрәк кагып масая торган заманалар үтеп бара иде бит инде. Тар идеология кысаларына бикләнү ник кирәк? Журналист киң карашлы булырга тиеш. Анысын да әйттем.

— Ә үзегезне киң карашлы дип саныйсыз инде.

— Мин тарих бүлегендә укыдым бит. Кешелекнен борынгыдан хәзергәчә узган юлын күз алдына китерергә тырыштык, коммунистлар партиясенен тарихын ятладык... Ә ул татар теле бүлегендә инде. Анда сәяси белем бирү

бик үк житди куелмады бит. Милләтне, аның киләчәген кайгырту алга сөрелде. Без сәясәт серләренә төшенергә тырышканда, алар Лобачевский китапханәсендә борынгы татар китапларын укып-өйрәнеп утырдылар. Каникулларда без, «Белем» җәмгыяте әһелләре буларак, хезмәт кешеләренә партия сәясәтен аңлатып йөрибез, алар исә, ерак авылларга экспедициягә барып, халык авыз иҗатын җыялар иде.

— Шуннан, сез каршы чыгыш ясагач, Нуриев ни диде инде?

— Дәшмәде. Башын иеп тик утырды. Аның урынына башкалар сикереп торып миңа каршы төштеләр. Талантлы, унган, тырыш егет ул, житәкче булырга лаек, диделәр.

— Дәшмәгән, димәк. Дөрес эшләгән! Сез белгәнне ул белми, дип уйлаган идегезме әллә? Һәр адымын үлчәп атламаса, Нуриев булыр идемени ул? Ә сез аңа акыл өйрәтергә алынгансыз. Яшь башыгыз белән!

— Явызлык теләгәннән түгел лә! Күңелемдәгене әйттем. Ул миңа моның өчен үпкә сакламады.

— Сез сәяси мәсьәләләрдә генә бәрелешә идегезме?

— Һич тә аңа шәхсән үчләнгәннән түгел... Карашлар туры килмәгән чакларда гына.

— Һәм көннәрнең берендә сез депутат Нуриев белән карашларыгыз туры килмәү аркасында үз-үзегезгә кул салыр чиккә життегезме? Ачыклап әйткәндә, агуланырга...

Башка күсәк белән китереп ордылармыни, Әминә имәнеп китте. Каян белгән? Әллә кайчан булган хәлләр бит инде! Кем казып чыгарган?

— Аның аркасында түгел! Бер катышы да юк иде! — диде Әминә ачынып.

— Әйтүләренә караганда, ул сезнең янга тулай торакка килеп йөргән. Берзаман күренми башлаган... Ә сез сырхаулап киткәнсез...

— Сез... әллә кайчан узган эшләрнең үчен алу нияте белән өченче көн аны мин кыйнап ташлаган дип әйтмәкчеме әллә? Үлем хәленә житкереп? Ул миңа бирешер идеме?..

— Каршы торырлык хәлдә булмаган шул. Нидер эчергәннәр аңа. Бер төрле психотроп препарат.

— Нинди препарат?

— Бәлки, үзегез дә беләсездер?

— Рөхсәт итсәгез, мин китим әле, — диде Әминә авырлык белән урыныннан кузгалып. — Аның янына барырга ярыйдыр бит?

— Кертмиләр ич. Кичә үзегез ишеттегез.

— Табиблар белән сөйләшермен, шәфкать туташлары белән. Авыруның хәле кинәт үзгәреп торучан. Берәр нәрсә кирәк булуы ихтимал...

— Алай да кызганасыз, ә?... Анысы аңлашыла... Мин баш табибка үтенеч язам, сүзегезне аяк астына салып таптамас.

Шулай дип, тикшерүче каршындагы каләм савытына сузылды.

* * *

Бер-берсенә каршы төшкәннәр... Дошманлашканнар... Болары бөтен кешегә фаш. Ә бер-берсенең күзләренә карап туя алмыйча, назларыннан эреп ләззәт чиккән чаклары? Алары беркемгә, беркайчан да фаш ителмәс, мәңге сер булып калыр!

Шаяртышу-үртәшүләр исә кеше күз алдында иде. Ник кирәк иде Әминәгә һаман-һаман аның бәгыренә энә чәнчеп тору? Хәзер исенә төшкәндә, үкенеп туймый. Ә үз вакытында аннан уздыру, аның гарьләнгәнен күреп кинәнү бик рәхәт сыман тоела иде...

Студент чакта алар лекцияләрдән соң берсе — Кремль үреннән, икенчесе

— астан, Болак буеннан, Казансу артына, ерактан күренеп, тырпаеп торган унөч катлы бетон бинага — газета-журнал редакцияләре урнашкан йортка юнәләләр. Юллары бер ноктада — лифт янында тоташып, сигезенче катка күтәрелгәч, тагын аерыла: Әминә «Комсомолец Татарии» газетасы редакциясенә керә, Әмир «Татарстан яшьләре»нә. Шунлыктан, бер үк юлны таптасалар да, сирәк очрашалар иде.

Соңгы курсны укыганда, Әминә газетада эшли үк башлады. Аны вакытлыча корректор итеп алдылар. Редактор Дамир Халиков, кырыкка якынлашып килгән абзый, гел үсендереп тора иде. Язга таба журналистларның бәйрәме була, шунда зурлап Әминәгә комсомол өлкә комитетының мактау кәгазен тапшырдылар. Бүләкләнүчеләр арасында иң яше ул, калганнары өлкәнрәкләр иде, аларга башка төрле бүләкләр бирелде. Биек трибунага менеп, рухланып чыгыш ясаганда, Әминә карашын залда утырган Әмирдән ала алмады. Хәтәр ялтырый иде егетнең күзләре, көнләшү ярылып ята иде аларда.

Укуын тәмамлауга, Әминәне «Совет гаиләсе» журналына эшкә алдылар. Әмиргә исә берничә ай болганып йөрергә туры килде. Нииндидер танышлары аша, ялга киткән бер хезмәткәр урынына гына кереп утыра алды, шунда нык тырышлык куеп, берегеп калды ул. Хәер, егет унган да, үткен дә булып чыкты, тиз арада өскә үрләде: бүлек мөдире булды, аннары, озак та үтми, газетаның редакторы урынына менеп утырды.

Ул чакта мондый җаваплы эшкә коммунистларны гына алалар иде. Әмир исә, ни сәбәптәндер, студент чагында ук партиягә керергә өлгерми калган икән. Хәзер инде ана комсомол оешмасының рекомендациясе кирәк булды. Барлык редакцияләрдә эшләүче яшьләр бер оешмага беркетелгән иде. Мәсьәләне шуның җыелышына куеп тикшерделәр.

Менә шул җыелышта булган хәлне искә төшерде дә инде милиция тикшерүчесе Вәлитов. Әйе, каршы кул күтәрде Әминә.

Хәзер искә төшкәч, үкенеп туймаслык. Ник алай итәргә иде инде?

Хәер, уйлый башласаң, үкенечләр аннан башка да җитәрлек...

...Ул елларны яшьләрнен «Идел» лагерена киләчәге өметле саналган, инде үзен күрсәткән яшь артистларны, язучыларны, журналистларны, рәссамнарны җыеп, семинарлар үткәрәләр иде. Комсомол өлкә комитеты эшли иде моны. Төп максат, билгеле инде, киләчәктә милләтнең рухи элитасы булачак кадрларга ленинчыл идеяларны ныграк сеңдерү, аларны коммунистик идеялар белән рухландыру иде. Бу максаттан лекторларның кайберләрен Мәскәүнең үзеннән үк чакырып китерәләр. Алар исә еш кына провинциядә авыз ачып әйтергә ярамаганны да сөйләп җибәрәләр. Мәскәүдә рух мондагыдан башка, басым да ул хәтле көчле түгел кебек — анда КГБ бер генә катлы бит, СССРныкы гына. Ә монда Казанныкы да бар.

Ләкин сәләтле яшьләрнең күпчелеге сәясәтнең мондый нечкәлекләренә кереп тормый. Лекцияләрне күнелсез бер мәҗбүрияткә саный да, бар булган сабырлыгын җыеп, тыңлап утырган булып кылана. Аның урынына кичләрен сахра: җырчы-биючеләр концерт куя, рәссамнар күргәзмә ясый, шагыйрьләр шаян шигырьләр язып, стена газетасы чыгара. Нәкъ менә шул чакларда төрле өлкәдә иҗат итүче сәләтле егетләр-кызлар бер-берләре белән якыннан танышып, дуслашып киттеләр дә.

Бер кичне, яшеллеккә төренгән, стеналары тоташ тәрәзәдән торган ашханәдә Фәрдия белән Әминә янына Әмир килеп утырды.

— Безнең тарафка да кояш чыгар икән, — диде Фәрдия.

— Шуны белеп килдем дә инде, — диде Әмир. — Бу өстәлгә мин җитми идем.

Идел аръягына таба баеп барган кояшка карап утырган Әминә дәшмәде.

— Түгәрәк табынның күрке шәраб. Шампанский белән сыйларга теләк бар сезне.

Ашханә залының бер кырыенда буфет бар, анда төрле эчемлекләр сатыла. Яшьләрнең кесәсе сай, ул тирәдә артык күп болгана алмыйлар, алай да бәгъзеләре әйләнеп килгәли. Әмир шул тарафка юнәлде. Кояшта янмый торган ак чыраена бик тә мәгънәле кыяфәт чыгарып, яшькелт шешәне өстәл уртасына шакылдатып китереп куйган гына иде, күрше өстәлләрдәге халык кузгалышып, чыгу ягына юнәлде. Буш залда бөке шартлатып, хәмер чөмереп утырып булмый бит инде! Кеше күп җирдә анысы да әлләни гаеп булмас иде дә бит, ә өчәвең генә... Бусы инде бозыклык булып күренәчәк иде. Әмир урындыгына урнашып өлгермәде, Әминә аягөсте торып басты.

Ашханәнең алгы ягына, стенага рәссамнар шаян сурәтләр элеп куйганнар икән. Рәсемнәр астына шагыйрьләр такмак язган. Китте шау-шу, шаярышу, көлешү. Очраклы рәвештәме, әллә берәр нәрсә сизенепме, Әмир белән Әминәнең портретлары янәшә туры килгән. Егетнең йомры башы кояш кебек нур чәчә, чәчләре балалар өчен ясалган сурәтләрдә генә була торганча җирән энәләр булып тырпайган, уктай керфекләре Әминәгә төбәлгән:

«Минем чын Әмир булганны күрәсегез бар әле,

«Боер!» — диеп башыгызны иясегез бар әле», — дип язганнар ачык авызы турына.

Әминә аның каршында нечкә сынлы, озын муенлы үсмер рәвешендә, кыска киселгән куе кара чәче астыннан күзлек пыялалары белән борыны гына күренеп тора. Кулындагы озын каләме Әмиргә төбәлгән:

«Чәчем кыска, борыным сизгер, каләмем — очлы сөңге,

Җаен гына көтеп тора эләктерергә сине».

Рәсем астына «Дуэль» дип язылган иде. Күренеп тора: бу икәү бәрелешәчәкләр... Берсе һәлак булачак... Яки авыр яра алачак... Тән җәрәхәте үк булмаса да, җан җәрәхәте булыр ул...

...Соныннан беленде: сурәтне шушы рәвешле ясарга телевидениедә эшләүче Нәзир Шәрифҗанов котырткан, астындагы сүзләрне дә ул язган икән.

* * *

... — Тор әле, Фәрдия, йокы симертеп ятма! Мондый иртәдә!

— Әй лә... Һаман шул инде ул, таң ата да кич җитә...

— Мондые гомердә бер була!

— Икегез каршы алыгыз әнә таңнар атканны! Парлашып тыңлагыз сандугачлар сайравын! Кичә дә әвәрә килеп беттегез...

— Үпкәләттек без аны.

— Ник үпкәләттең соң? Шампанскиен әрәм иттең... Башта эчәбез дип ризалаштың, аннары торып киттең. Бөтен кеше алдында. Егетләр аның ишене бик авырга ала. Мин беләм!

— Белгәч, ник үзең утырмадың?

— Миңа дип алган шешә түгел иде лә! Их, Зайка монда булсамы? Шул марафон чабуы белән үзәккә үтте инде... Ярышлар, күнегүләр, диета... Гомер буе газаплар микән. Ә синең рәхәт... Әмир андыйлар белән интектерә торган түгел... Икегез дә ирекле һөнәр ияләре...

— Тор инде! Галибанә яктырып әкрен генә ал таң ата анда!

Сүз сүзгә ялганды, Фәрдиянең йокысын таратты, ул кузгалып киенә башлады.

Бусаганы атлап чыгуга, алар чыннан да әкияти дөньяга күчкәндәй булдылар. Ябалдашлары белән белән күк гөмбәзен тотып торырга омтылган, төз сынлы наратлар, күпшы итәкләрен киң җәеп, көязләнеп утырган

чыршылар, яшел толымнары белән ак сыннарын төргән каеннар... Татлы һаваны сулап туймаслык...

Кызлар, сандугачлар сайрау көенә атлап, наратлар арасындагы бормалы йомшак сукмактан, яр буена таба киттеләр. Идел кинлегенә шәфәкъ нуры алсу ефәген җәйгән, күз ирешмәс иркенлек күнелләрне очындыра-талпындыра иде.

Бу җәннәттә алар гына түгел икән: урман юлыннан өч егет килеп чыкты: рәссам Рәшит, журналистлар Нәзир белән Әмир иде болар. Әллә инде, төн йокламый, талпынып иҗат итү, киләчәктә дан казану турында әңгәмә корып утырганнармы?

— Күр, боларның да йөрәге түзмәгән! — диде Нәзир. — Таң-таң ата, Чулпан калка, таң кызларны уята шул ул.

Алар шаярышып, тел чарлап, үртәшеп торганда, Идел уртасында моторлы көймә пәйда булды. Көзгедәй ялтырап яткан су өстендәге шәфәкъ чагылышын урталай ярып, тавышы белән кошлар сайравын күмеп, яр буенда басып торган төркем турына килеп туктады. Көймәдә тузгыган коңгырт чәчле бер егет кенә утыра.

— Хәерле иртә барыгызга да! — ди.

— Хуш килдегез, исәнмесез.

— Сезнең көймәдә йөзеп буламы? — дип сорады Әминә.

— Рәхим итегез!

Әминә чак кына чайкалыбрак торган көймә эченә атлады, койрык ягындагы салкынча эскәмиягә утырды. Аның артыннан Фәрдия кереп алгы эскәмиягә урнашты. Аннары Әмир атларга омтылыш ясаган иде, көймәче егет кинәт кырысланып, капитаннарча катгый тавыш белән:

— Перегруз! — дип кычкырмасынмы! — Бүтән кеше сыймый!

Һәм моторның бавын тартып, үкертеп җибәрде, көймә дерт итеп кузгалды да дәрья кинлегенә ургылды.

Әминәнең күп корабларда, көймәләрдә йөзгәне булды, әмма мондый талпынуны, очынуны кичергәне юк иде шикелле. Моңа табигатьнең гүзәллегеннән бигрәк, яр буенда аптырап калган берәүнең мөлдерәгән карашын тою сәбәпче иде, билгеле. Ул җырлап җибәрде.

«Идел бит ул тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул»...

Фәрдия аңа кушылды.

— Кызлар, филармониядәнме әллә сез?

— Каян белдегез?

— Бигрәк моңлы тавышыгыз!

Егет Хәйдәр исемле, суда коткаручы булып эшли, төнге сменасын тәмамлап кайтып килүе икән. Шактый озак хозурланып баргач, ул көймәсен ярга борды, йөрешен әкренәйтеп, тар, бормалы, ярларына камыш, таллар үскән ерганакларга кереп китте. Андый күренешләрне телевизордан «Киносәяхәтләр клубы» дигән тапшыруларда күрсәтәләр.

Бакча эчләрендә агач өйләр, өй тирәләрендә гөлләр. Үрмәле гөлләр ышыгында зур агач өстәлләр, эскәмияләр. Дуслар-туганнар бергә җыелып, мул табын янында кәеф-сафа корып утырыр өчен һәммәсе эшләнгән.

— Зур начальниклар менә шушында ял итә, — диде Хәйдәр көймәсен әкрен генә шудырып барганда.

Әминәнең күнелен исә Әмирне әвәрә итүе турындагы уй кытыклады. Калдыңмы нәүмиз булып яр буенда? Киттемме мин сахра чигәргә?.. Шул кирәк сиңа! Күрербез хәзер чыраеңның ни төсле икәнен!

Тик нинди иде егетнең йөзе — ачулымы, рәнҗүлеме — анысын белеп булмады, көймәнең ярга якынайганын күрүгә, борылып, наратлар арасына кереп күздән югалды ул. Яр эргәсендә берәү генә басып калды — ул да булса телевидение редакторы Нәзир Шәрифҗанов. Авызында сигарет, аяк очында төпчекләр.

— Кыланмышларыгыз кырга сыймый, — диде ул сигаретын тирән итеп суырып. — Кеше утка баса монда...

— Кем утка баса, кая?

— Без инде бу тагаракка утырып, сезне эзләргә китмәкче идек, ишкәк тапмадык, — дип, читтәрәк аунап яткан такта көймәгә ишарәләде ул. — Кайсыгызның танышы инде ул көймәче?

— Әле таныштык.

— Тәмам башсыз икәнсез. Күз күрмәгән кеше белән шулай олагалармыни? Бер-бер хәлгә юлыксагыз, кем җавап бирер?

...Шул ук көнне Әмирнең бәгыренә басарга тагын бер җай чыкты әле. Мәҗбүри уку сәгатьләреннән соң, кояш баю ягына авышкач, яшьләр су коенырга киттеләр. Кайчан, ничек өйрәнеп җиткәндер, кечкенә елга буенда үскән Әминә яхшы йөзә. Дулкын кузгалмаса, судан сәгатьләр буе чыкмый тора ала, чөнки чалкан ятып, хәрәкәтсез ял итә белә. Өстәвенә аягына «ласты» дип аталган йөзгечләр дә киеп куйса, берәүне дә уздырмый. Йөзгечләре җиңел пластиктан, бала-чаганыкы гына, әмма шундый унайлы!

Менә ул аларны киеп куйды да, комлык янында шаулашкан егет-кызларны калдырып, елга эченә кереп китте. Ярдан шактый ераклашкан иде, артыннан кемнеңдер җан-фәрман колачын киң сала-сала куып килгәнен күреп алды. Таныш кешегә охшамаган кебек. Башка басып, суга чумдырып шаяртмакчымы әллә? Әминә йөзүгә оста, әмма чумуга килгәндә күзлеге комачаулый. Борынына су кергәнне дә яратмый. Ул, йөзгечләрен су астында бар көченә җилпеп, дуга ясап теге явызны әйләнеп үтәргә тырышты. Ул әйләнеч юлдан бара, теге турыдан бәрә. Алай да куып җитә алмады, ара ерагая башлагач, судан башын сузып кычкырды:

— Девушка, у вас какой разряд?

Ул, бичара, бу кызны йөзү ярышларында катнашучы спортчы дип белгән, аның белән узышкан икән! Әминә йөзгечләрен су өстенә калкытып җилпегәч кенә, хәлне аңлады, ухылдап куйды да эчкәрегә таба йөзеп китте.

Бу узышны арырактан Әмир күреп алган, тик серен аңлап җиткермәгән булса кирәк, ярга якынлашканда ул Әминәгә каршы килә иде.

— Әйдә, кире киттек! — диде ул.

— Әйдә!

Әминә кире борылды. Бер ике колач салуга, егетнең башына яна уй килде.

— Әйдә, теге өянкегә кадәр! — дип, яр читендә, шактый еракта бер ялгызы тырпаеп утырган өянкегә ишарәләде.

— Мин каршы түгел.

Киттеләр болар йөзеп. Әминә егетне шактый артта калдырып алга китә дә чалкан ятып хәрәкәтсез кала:

— Тәнәфес!

Ә егет дулкын уйнатып, башын бер батырып, бер чак кына калкытып йөзүендә. Узасы, кызны әллә кайда артта калдырасы килә. Әмма ул тигезләндем дигәндә генә, Әминә кире күкрәгенә ята да, кабаланмый, суны шапылдатмый гына, балыктай елдам шуышып алга китә. Аннары янә кулларын ике якка җәеп, йөзен кояшка куя.

— Тәнәфес!

Егет исә һаман давыл уйнатуында. Кызарынган-бүртенгән, тәненнән пар бөркелә шикелле...

Ах, Идел, Идел! Ник син алгысынган күңелле кыз алдында назлы кочагыңны киң җәйдең, ник ашкынып, талпынып йөзәргә ирек бирдең, ник горур егетне җинеп, аннан көләргә мөмкинлек тудырдың?

Суда йөзү — болын буйлап чабу түгел, шактый озак дәвам итте бу. Ниһаять, менә өянке янәшәдә. Әминә ярга якынаеп су төбенә басты да, йөзгечләрен салып, канат итеп баш очында җилпеде:

— Ха-ха-ха!..

Аның көлгән тавышы кичке, аулак сөзәк яр буенда еракларга яңгырады.

— Бу нәмәрсә шулай тиз йөздерәмени соң?

Адәм баласының йөрәгенә яра салу өчен коралның бер кечкенәсе дә җитә кайчакларда!

Идел киңлеген, сөзәк яр буен инләп, тантана белән шаярту катыш көлү авазы шактый чыңлап торды. Бу — чая кызның горур егеттән шулай көлүе иде.

Әмма бер чиге булырга тиеш иде моның. Гел-гел үртәп-үчекләп торуга кайсы егет түзеп торсын? Ниһаять, үзенең өстенлеген расларга тиеш иде ул. Һәм Әмир моны бөтенләй башка килмәс рәвештә эшләде. Кызны үз мәйданына тартып алып керде дә, үз көенә биетте...

* * *

— Казаннан килгән пассажир Мусина! Сезне белешмәләр бюросы янында көтәләр.

Халык кайнап торган Внуково аэропортында кат-кат яңгырады бу игълан.

— Пассажир Мусина! Сезне көтәләр!

Мусина? Нинди Мусина? Кемне шушылай меңләгән халыкка ишеттереп эзлиләр? Әминәне бире дә каршы алырга җыенган кеше юк. Казан самолеты белән тагын бер Мусина килеп төште микәнни?

Ләкин... Алай да... Ашыгыр җир юк, чыгар юлны бераз гына уравыч итеп, белешмәләр тәрәзәсенә күз салып китәргә була. Нинди Мусина икән ул тагын?

Ләкин... Анда Әмир басып тора түгелме?! Ул!

...Өч сәгать элек кенә Казан аэропортында очрашканнар иде алар. Көн эссе, халык җиңелдән киенгән, ир-атның күпчелегендә кыска җиңле футболка, Әмир исә күксел костюмнан, кулында кара күн дипломат.

Исәнләштеләр, хәл-әхвәл белешеп алдылар. Икесе дә Мәскәүгә баралар, тик Әмир ике сәгатькә алданрак — уникедә оча икән.

— Ник миңа шалтыратмадың? Билетны үзем белән бер рейска алып биргән булыр идем, — диде ул.

Әмир республика газетасының баш редакторы. Андый урында эшләүчеләргә командировканы партия өлкә комитеты оештыра, билетларны ул алып бирә.

— Ашыгыр җирем юк, — диде Әминә.— Барып кунам да иртәгә иртән Журналистлар союзына барам.

— Анда ни йомыш?

— Иҗат йортына юлламаны үзләренә килеп алырга куштылар. Иртәгә сәгать дүрттә Мәскәүдән Кырымга очачакмын.

— Алаймыни-и-и... Куанычлы юлга чыккансың икән. Кызганыч, ул самолетта да бергә оча алмабыз, — дип, гадәттәгечә үң бит очын чокырайтып, шаян елмайды Әмир. — Ә мин ифрат җитди эш белән

йөрим әле. — Шулай дип, серле кыяфәткә кереп, дипломатын сыйпады аннары.

...Әйе шул, эшем житди, дигән иде! Нишләп тора ул монда? Ни көтә? Әллә сон... игъланны ул бирдергәнме? Әнә, күреп тә алды, әнә, каршыга килә...

Ничә мең кеше айкала икән биредә — кинлеге дә, биеклеге дә күз ирешмәслек бинада? Шулар арасында Әминәдәй бәхетле тагын кемдер бар иде микән?

Тирә-юньдәге һәммә нәрсә: бина да, кешеләр дә — кечерәйде, вакланды, исерткеч томан белән капланды, күз алдында борынгы Рим чорында бронзадан коелып, алтынга манылган Геркулес кыяфәтендәге егет кенә торып калды...

Әмма бөтенләй үк чишелү килешми, күңелдә айкалганнарның һәммәсен чыгарып түгүдән тыелырга кирәк иде. Әминә үзен кулга алырга тырышты:

— Бөтен Рәсәй халкына яңгыратып эзләмәсән, Казанда чакта үземә генә әйтеп булмадымыни? — диде.

— Хуш киләсез, туташ, башкалага! Бир сумканны! Киттек әйдә.

Халык агымына ияреп, метрога төштеләр.

— Миңа Измайлово станциясенә барырга кирәк, — диде Әминә. — Аннан автобус белән Балашихага.

— Кемең бар анда?

— Танышлар.

— Әйдәле син минем белән!

— Кая?

— Баргач күрерсең! Бир сумкаңны!

...Метродан чыгып, бераз баргач, бик тә чиста, иркен, халык аз йөри торган урамда, ачык-соргылт төстәге мәһабәт бина каршында туктап калдылар. Аның биек, саллы ишеге кырыендагы алтактага алтын хәрефләр белән «Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты» дип язылган иде. Партиянең Татарстан өлкә комитеты бинасы да Казанның иң затлы мәйданында, әллә каян күренеп тора, аның тирәсендә дә эленке-салынкы йөреп булмый, үзеңне ниндидер куәт каршына килеп баскандай хис итәсен... Әмма барыбер дә ул бина жанга якынрак икән. Биредә исә хакимиятнең биеклеге чагыштыргысыз ныграк сизелә. Мәскәүгә һич тә хас булмаганча, үтеп-сүтеп йөрүче сирәк, пыяладай шома асфальт юлдан кәттә машиналар гына зур тизлек белән выжт итеп үтеп китә. Кемнәргә генә ачыла икән бу Алып батыр өчен ясалгандай ишек?

Әмма Әмирнең кулы килеште, ул жиңел ачылды. Эссе урамнан килеп кергәч, эчтә салкынча, каяндыр биектән, театрларда гына була торган бәллүр люстралардан сибелгән яктылык саран булып тоелды. Каршыдан югары катка бик киң мәрмәр баскыч менеп китә иде.

Ишек төбендәге өстәл янында утырган төз милиционер, аларны күргәч тураеп басты:

— Исәнмесез! Тыңлыйм сезне!

Әмир, уң кулындагы сумканы идәнгә куеп, портфелен ачты, аннан ниндидер кәгазь алып, аңа суздн. Милиционер янындагы тумбочкадан телефон трубкасын алып шылтыратты. Минут та үтмәгәндер, баскычның югары мәйданында пөхтә соргылт костюм кигән, чибәр, ыспай егет күренде. Һәм кадерле кунакларын каршы алгандай, бөтен йөзе белән елмаеп, аска таба атлады:

— Исәнмесез! Сезне генә көтә идем. Ничек килеп життегез? Без сезне иртәрәк килерсез дип уйлаган идек. Нишләп жәмәгатегез белән киләсегезне әйтмәдегез? Гостиницага пропускны аңа да әзерләп куйган булыр идек!

— Безнең танылган журналистыбыз бу, — диде Әмир. — Яшьләр газетасыннан.

— Бер генә минут көтегез, зинһар. Мин хәзер.

Шулай дип, ул кире менеп китте. Әминә хәйран-вәйран иде. Һәркемгә мәгълүм: бирегә жир шарының алтыдан бер өлешенә җәелгән ил белән идарә итүчеләр утыра. Шунда сине көтеп торсыннар әле!

Дөрес, егетнең чын күңелдән түгел, ясалма елмайганы үзеннән-үзе аңлашыла. Житәкче урыннарга куярлык кешеләрне партия күпләр арасыннан сайлап ала, өйрәтә, билгеле. Ә шулай да... Мондый мөгамәлә ихтыярсыздан йөрәккә сары май булып ята шул инде. Менә ул янә күренде, шулай ук якты елмаеп, аска таба атлады.

— Рәхим итегез, — диде. — «Россия» гостиницасына. Берәр төрле ярдәм кирәксә, шылтыратыгыз. Менә минем телефон, — дип катыргы кисәге сузды.

— Ишектән кергән һәркемне шушылай каршы алалар микән ? — дип сорады Әминә кире урамга чыккач.

— Мин һәркем түгел, Татарстан республикасыннан килгән үз кеше. Беренче секретарьның вәкаләтле вәкиле. Менә монда, — дип кара дипломатын күтәреп күрсәтте Әмир, — аның «Новый мир» журналына язган мәкаләсе. Мин шуны китерә килдем.

— Мәкаләсен син язгансыңдыр инде?

— Әллә үзе кәгазь тырнап утырсынмы? Йә машинка шакылдатсынмы?

— Иң зур житәкче авызыннан үз сүзеңне сөйләтәсең, димәк...

— Мин ул әйтергә тиешлене язам.

Кунакханәдә Әмирне бер кешелек бүлмәгә, Әминәне ике кешелеккә урнаштырдылар. Ул юынып, шул ук катның коридорындагы буфетта чәй эчеп алды. Аннары кире бүлмәсенә керүгә, телефон шылтырады.

— Син кайда йөрисең? Ник трубканы алмыйсың?

— Буфетка чыккан идем...

— Нинди аерым хуҗалык син, ә? Бергә килгән икән, бер-береңне барлабрак йөрергә кирәк.

— Бер-беребезгә көтүче түгел лә...

— Ә менә мин көтәм.

— Нәрсә көтәсең?

— Буфет чәен женем сөйми. Чәй пешереп бирмәссең микән, дип көтеп утырам.

Аның чакыруын шома гына кире кагып, шаяртып җавап бирергә кирәк булгандыр. Әминә сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел. Тик нишләптер кирәклесе табылмады. Мондый очракта ничек киреләнәсең? Кермим дип карышсаң, аның хакында бик начар уйлыйсың, дигән кебек аңлашыла түгелме? Алай гына түгел, үз-үзенә дә ышанмыйсың, дигән фикер туа. Аннары... кереп күреп чыгуның ни гаебе бар? Журналистка кемнәр белән генә ялгыз калып сөйләшеп-серләшеп утырырга туры килми! Күп очракта шунсыз рәтле мәкалә дә яза алмыйсың.

Баскычтан өске катка күтәрелгәндә, Әминә үзен шушылай юатты. Ә йөрәк тигезсез тибә, тез буыннары йомшаган иде...

Әмирнең бүлмәсе алтынчы катта, гостиницаның почмагына туры килә икән. Бер як стенасы тоташ тәрәзә булып, ул Кызыл мәйданга караган. Күз алдында Кремль, Василий Блаженный соборы. Дөньяда иң гүзәл шәһәр манзараларының берсе, атаклы рәссамнарның картиналарында тасвирланган күренеш. Ишекне атлап керүгә, карашны шул җәлеп итте. Кызыл мәйданда, урамнарда бихисап лампалар кабынган. Кремль манараларын, чиркәүнең алтын гөмбәзләрен прожекторлар нурга күмгән. Әкияти дөнья!

Люкс номер иде бу, зур кунакларны, дәрәҗәле шәхесләрне урнаштыра торган. Бүлмә тышта балкыган утларның яктысы белән генә яктыртыла, шунлыктан бик серле иде. Йокы бүлмәсе эчке якта икән, ачык ишектән алсу атлас япма белән капланган киң карават күренә. Ә бирге якта кием шкафы, стена буенда затлы савыт-саба тезелгән шкаф, суыткыч. Тәрәзә каршында яшел торшер, кара күн белән тышланган иркен, йомшак кәнәфиләр, тәбәнәк пыяла өстәл. Аның өстендә, озын аяклы бәллүр вазада алма, әфлисун, кара йөзем тәлгәше, ике тәлинкәдә буфеттагы иң кыйммәтле тәм-том: балык уылдыгының кызылы, карасы, ысланган колбаса телемнәре, шоколад шакмаклары... Әмир суыткычтан муенына ука уралган яшькелт шешә чыгарды.

— Теге чактан калган шампанский бар бит әле безнең. Хәтерлисеңме, «Идел»дә алган идек. Сыйла диден, өлгермәдем, ашыктың. Бүген ашыгыр җирең юктыр бит?

Шешә муенының укасын каерып, бөкесен ачкач, күбекләнеп торган шәрабны бокалларга салды да, кәнәфигә утырып, тышкы якка карады ул.

— Ә син беләсеңме, бу мәйдан патша сараеннан күренми, чөнки аннан Кремль стеналары каплый. Без патшалардан бәхетлерәк. Аларның өстәленә куела торган шәраб, нигъмәтләр табыныбызда, алар күрә алмый торган манзара күз алдыбызда. Дөньяның төрле кыйтгаларыннан нинди генә ханнар, императорлар хыялланмаган, бирегә килеп, шушы ноктага басып, шушы манзарага карап ләззәтләнү турында! Хыялларына ирешү өчен күпме җаннарны кыйганнар, күпме кан койганнар. Әмма морадларына ирешә алмаганнар. Хәтта Наполеон өчен дә мәйдан болай бизәлмәгән. Төтен, сөрем, корым аша гына күрә алган ул боларны, янгын телләре аша гына. Без Наполеоннан бәхетлерәк! Әйдәле, иң беренче итеп шушы бәхетле кичебез өчен күтәрик!

Чыннан да дөрес бит! Император Наполеон Мәскәүне йөз меннәрчә корбан биреп яулап алган, әмма бирелә мондый бәхетле кич үткәрү насыйп булмаган аңа — шәһәргә ут төрткәннәр, бөек яулап алучы янгын эчендә калган. Чагыштырып карасаң, Әмир аннан күпкәрәк ирешкән түгелме? Дөньяны шаккатырып, зур сугышлар ачмаган, берәүнең дә җанын кыймаган, хәтта һичкемнең юлына аркылы басмаган, әмма Мәскәүне яулап алган! Әйе шулай, бирегә килеп, югары күтәрелгән шәхесләр турында нәкъ менә шулай, Мәскәүне яулап алган, дип сөйлиләр бит.

Әллә аның хыялга бирелеп сөйләгәннәре , әллә шәрап күбеге башны бутады, Әминәгә көлке дә, кызык та, рәхәт тә булып китте.

Әмир бушаган бокалларны тутырды да, өстенә шоколад ваклап салды. Валчыклар бокалда күбеккә төренеп биештеләр, бу — үзенчә бер мәзәк тоелды.

— Икенчесен синең өчен күтәрәбез, — диде Әмир.

— Башта синең өчен тиеш. Монда син беренче.

— Тост әйтәсеңме соң?

— Синең Мәскәүне яулап алганың өчен!

Әмир бокалын сузып алгарак авышты, күзләрендә хәтәр очкыннар кабынды, йөзе җитдиләнде.

— Син шулай дип уйлыйсыңмы? Минем хакта Мәскәүне алган дип?

— Күз алдында лабаса!

— Ә бит син каршы идең. Хәтерлисеңме теге җыелышны?

Әминәнең эчен ялкын теле ялап алгандай булды.

— Ул бит бөтенләй башка! Минем сине зур исем казанган каләм иясе, халыкның соеклесе итеп күрәсем килә! Үзең дә аңларга тиеш.

— Безнең башка да чүбек тутырмаганнар аңысы, — дип каты гына

төрттереп куйды Әмир. — Кеше акылы белән генә йөрмибез. Төрле ягын уйлыйбыз... Син белгән атаклы журналистларның кайсын биредә зурлап кабул итәләр икән? Андыйны ишеткәнең бармы?

Әминәнең башында давыл купкандай, дулкын артыннан дулкын бәрә иде.

— Мәскәүне яулап алганың өчен дип тост тәкъдим иттем бит инде! — Шулай дип, бокалыннан бер-ике йотып куйды ул.

— Мәскәүне генә микән? — диде Әмир аңа таба авышып. — Ә бәлки, башка җиңүләргә дә ирешергә телимдер мин? Наполеонга да, Чыңгыз ханга да тәтемәгәнгә?

Әминә башын иеп, йөзем өзеп капты, кинаяне аңламамышка салышып, шаяру җиле белән очыртып җибәрергә тырышты:

— Яулап алганыңны нык тот, кулыңнан ычкындырма! — диде. — Наполеон кебек хурлыклы рәвештә чигенергә язмасын!

Тост шәп әйтелде, бокалны янә төбенә кадәр бушатырга туры килде. Шәраб затлы, ризык тәмле, сүзләр әчкелтем татлы иде.

— Әгәр берәрсе бүген иртән миңа, кичен син шундый җирдә сыйланып утырачаксың, дисә, саташкан дип уйлар идем. Адәм ышанырлык түгел! — диде Әминә.

Чыннан да, моннан караганда бик ерак тоелган, кара дип саналган татар авылында үскән балалар бит алар. Яшьтәш якташларының күпмесе генә югары уку йортына кергән, кемнәр генә Казанда яхшы эшкә урнашып, үзен таныткан.

— Күпме аралашабыз, ә менә кара-каршы утырып, ачылып сөйләшергә җай чыкканы юк, — диде Әмир. — Шуны сорамакчы идем: студент чакта син безнең әдәби түгәрәкләрдә күренми идең. Кайчан яза башладың?

— Мин тарих бүлегендә укыдым бит. Читтәрәк йөрдем.

— Ә нишләп татар бүлегендә түгел?

— Татар мәктәпләре бетеп бара иде бит. Эш булмас, дип курыктым. Аннары көннең көнендә бер кочак дәфтәр тикшерү. Күзләрне сакларга кирәк булыр, дип тә уйладым. Ә тарих укытучысы класска керә дә сүзен сөйләп чыгып китә.

— Җиңел юл эзләгәнсең икән.

— Авырны кем эзли инде!.. Хәреф танугя яза башлаган идем үзе. Мәктәптә шигырьләрем белән калын дәфтәр тулган иде. Стена газетасын гел мин чыгара идем. Аннары педагогия училищесына кердем. Анда шигырь чыгаручылар күп иде. Үсмер чакта күпләр шуның белән мавыга бит... Мин инде ул мавыгуым мәктәп елларында калды, дип уйлаган идем. Күбрәк сәхнә тирәсендә чуалдым. Кичәләрне алып барам, пьесалар куябыз... Мирхәйдәр Фәйзинең «Асылъяр»ында Ләлә булып уйнагач, бөтенесе мактаган иде. Берничә авылга барып куйдык. Нәрсәсе гаҗәп? — дип көлеп куйды ул, егетнең йөзе үзгәргәнен күреп. — Сәхнәгә чыкканда күзлегемне сала идем.

— Җәл, мин ул спектакльне күрми калганмын.

Әминә аның тавышында чагылган кинаяне аңламамышка салышып, сүзен дәвам итәргә ашыкты:

— Стипендия акчасын үзең беләсең. Мин әле тегү фабрикасына барып, төнге сменага эшкә алмассыз микән, дип тә сорашып йөрдем. Сезгә яраклы эш юк бездә, диделәр. Аннары институтның комсомол комитетына бардым. Илдус Кадыйрович Хәйруллинга. Ул әйтте, бер атнадан кил, диде. Ә өч көннән комсомол җыелышы булды да, аны секретарьлыктан төшереп, башканы сайладылар. Бер көнне коридорда очраштык. «Син нишләп миңа килмәдең?» — ди. «Сезне эштән алдылар бит инде», — дим. «Эштән

алдылар, әйткән сүзем урынында калды, — ди бу миңа. — Бар әле син редакциягә. «Комсомолец Татарии»га. Юлия Колчановага әйтерсең, мин җибәрде, дип.

— Менә бит, егет кеше әйткән сүзен онытмый! Әйдә, без аның хөрмәтенә бер бокал күтәреп куйыйк әле. Ул моңа лаек. Шулай бит?

Чыннан да, Илдус Кадыйрович — мең рәхмәтләр укып, кат-кат искә алуга лаек кеше бит! Ул очрамаса яисә әйткән сүзен онытса, Әминәнең язмышы нинди булыр иде икән?

Тагын шәраб йотарга туры килде.

— Тарих бүлегендә укулар урыс телендә бара бит. Миңа ул газетага язу авыр түгел иде. Гонорар ала башлагач, яшәү бөтенләй икенчеләнде. Тамак туя башлады...

— Авылдан ярдәм килми идемени?

— Анда үзләренең хәле хәл бит... Әткәй трактор тәгәрмәче басып ике аягын да имгәтте. Без биш бала. Әнкәй колхозчы.

— Барыбызның да хәл шундыйрак иде инде, — дип көрсенеп куйды Әмир. — Без дә дүрт бала... Әткәй-әнкәй колхозда...

— Училищега керүем дә җитмәүчелек аркасында булды. Стипендиясенә ымсындым. Аны тәмамлагач, институтка юллама бирделәр. Кызыл диплом иде миндә, имтихансыз кереп була иде. Казанга киткәндә, әткәйгә, ярдәм сорамам, дип сүз бирдем... Өчәр көн ач торган чакларым булды...

Үткәннәре искә төшкәч, Әминә үз-үзен кызгана башлады. Беркем белми: тиресе калын булып күренгән бу кыз баланың үзәгендә кош баласыдай көчсез җан яшеренгән иде. Үсмер чакта ук ата-ана куенынннан чыгып китеп, ташлы, сикәлтәле юлларда айкалып бирчәйгәнгә күрә генә, чыныккан, чыдам булып күренә иде ул. Ә аның бу кабыктан котыласы, җанын ачасы, кемгәдер салынасы, сыланасы, үзен иркә бала итеп хис итәсе килә иде. Әнисенең куен җылысы күңелнең иң нечкә җирендә саклана һәм җан шундый җылыны, якынлыкны эзли иде.

Сүзгә-сүз ялганды, башка томан сарылды, күңел нечкәрде. Өстәвенә биредә ул соңгы елларда күнеккән мохитыннан аерылган иде. Идел кинлеге түгел бу, аягында йөзгечләр дә юк. Әмир тамыр җәя башлаган җирлек иде монда, мәйданны ул тота иде.

Шампанский күңелне дә, тәнне дә әкренләп йомшартты. Вакытның агышы сизелмәде.

Әллә ни булды Әминәгә. Таякка таянып, авырлык белән атлаган әтисен, эштән бушамаган әнисен, аркасына биштәр асып авылдан җәяү чыгып киткән унбише дә тулмаган кыз баланы — үзен күз алдына китерде. Нәрсә иде аның биштәрендә: бераз сохари, иске оекка тутырылган борчак, бодай, бер бәләкәй банка кайнатма, карлыган кагы... Күзгә яшь тыгылды. Аның беркемгә дә болай зарланып утырганы юк иде әле.

...Менә бер мизгелдә Әмир, алга авыша төшеп, аңа төбәлде, күзләрендәге чаткылар гадәттәгедән яктырак җемелдәде.

— Яле, сал күзлегеңне! Ләлә чагыңны күрәсем килә!..

Ул кушканны үтәргә кирәк булмагандыр ла! Күзлеген салгач Әминә үзен кечерәеп калгандай хис итә, гүяки тимер кыса белән ике пыяла кисәге аның чаялыгын, кыюлыгын үзләре белән бергә алып китә иде.

— Әрәм булып йөрисең икән... Болай син бөтенләй башка... — Әмирнең кайнар сулышы битне өтте. — Кил монда!

Сүзләр беләнме, әллә утлы күзләренең карашы белән генәме боерды ул шулай? Ничек кенә булмасын, каршы тору мөмкин түгел иде. Әминә гипнозлангандай берни уйламый, аңламый, әкрен генә урыныннан күтәрелде дә аңа таба атлады. Теге чакта, бию залында да, күз карашы

белән үз янына килергә боерганлыгына шик юк иде. Хәзер исә ул үзенең затлы сараенда, тәхеттә кебек утыра иде. Шундый көчле, кодрәтле, аңа буйсынмаслык зат бар иде микән бу минутта?

Йа Раббым, куллары нинди назлы, күкрәге нинди киң, иреннәре нинди кайнар икән! Үзе килеп керде Әминә бу татлы тозакка. Егетнең ничек аны күтәреп алып, күрше бүлмәдәге ятакка кертеп салганын аңышмый калды... Үзенә үзе дә икърар итәргә базмаган гына: күптәннән, беренче күргәннән бирле көткән икән ул аңа кайнарланып бирелүне. Аның һәр хәрәкәтенә, һәр ымына буйсынудан да татлы нинди ләззәт бар икән бу җиһанда! Юк иде биредә бернинди киртәләр, гаеп-кыеклар. Иделләр, калалар, мәйданнар, патшаларга лаек манзаралар күз күременнән читкә чигенгән иде. Бер булып үрелгән тән, бергә кушылган татлы, кайнар сулыш, сызлану аша күкләргә ирештерерлек тоелган ләззәт кенә калды...

Яше егерме өчкә җитеп ир назы күрмәгән кызның тәне күптән сусаган иде шул инде...

Күпмедер минутлар үтеп, сулышы тигезләнә төшкәч, Әмир башын калкытып, бу юлы бик сак, бик йомшак итеп, аның иреннәреннән үпте.

— Әйтсәләр, ышанмас идем, — диде.

— Нәрсәгә?

— Синең монарчы үзеңне шушылай саф саклаганыңа. Төрле халык арасында шулхәтле айкалып...

— Айкалганда сакланмасаң, сәләмәң калмас, ди минем дустым Фәрдия. Мин үземә күнелем белән гыйффәт путасы кигән кебек тоя идем.

— Нәрсә, нәрсә?

— Урысчасы пояс верности. Хәзергечәгә яраштырып әйткәндә, сафлык йә тугрылык билбавы буладыр инде. Мин аны үзем, күңелемнән киеп куйган идем. Керләнеп йөрсәм, ни йөзем белән башкаларны сафлыкка-чисталыкка өндәрмен? Әхлак кагыйдәләре кушканча яшисем килгән иде. Башта мәхәббәт, аннары туй, аннан соң гына зөфаф киче. Халык безнең кебек күз алдындагы шәхесләрнең, каләм ияләренең өлге булуын тели! Менә хәзер...

— Һәммәсе нәкъ син уйлаганча булыр. Язылышырбыз, туй ясарбыз. Минем каршымда синең намусың кершәннән ак. Бүтән берәүнең дә сүз әйтергә хакы юк!

— Ник болай сонарып килдең син? Мин көттем-көттем...

—Үзең киреләндең... Бәгыръгә энә кадап тәм таптың... Моннан ары алай итмәссең бит! Гороскоп буенча кем әле син? Туган көнең кайчан?

— Унберенче август. Арыслан мин.

— Мин дә арыслан. Унҗиденче августта туганмын. Ике ерткыч бер ояга ничек сыярбыз икән? Сине буйсындырырга туры киләчәк бит!

— Минем өчен бәхетнең иң зурысы шул булачак.

— Мин синнән теге ... Нинди билбау дидең әле?

— Сафлык путасы...

— Анысын салдырдым. Тик син котылдым дип уйлама!

Әмир аны янә кочаклап, иреннәренә беректе.

— Мин сиңа янасын кидерәм. Тугрылык путасын кигезеп куям... Әйтүен әйтәсең, күзең белән күргәнең бармы андыйны?

— Чехословакиягә турист булып баргач, бер музейда күрсәткәннәр иде.

— Мин Венециядә күрдем. Дожлар сараенда. Анда урамнар су бит инде, канал. Бер ярда дожлар ягъни патшалар сарае, каршы якта — зиндан. Анда хәзер музей. Дожлар яуга киткәндә хатыннарының биленә, бер чатын ике аягы арасыннан үткәреп, тимер кыршау кигезә торган булганнар. Аны йозак белән бикләп, ачкычын үзләре белән алып киткәннәр!

— Ни генә уйлап чыгармаган бу адәм баласы! Төрмәсе дә коточкыч, ул син әйткән тимер кыршавы да.

— Яратуың чын булса, кыршавына гына түзәрсең.

— Син кидергәне минем өчен бизәк булыр, алтыным! Нурлы ярым бит син минем! Бер күрүдә күзләрем чагылды. Беләсеңме, кемгә охшаттым мин сине?

— Вак-төяккә түгелдер, шәт...

— Геркулеска! Аның «Үгез Форумы»нан дип ясалган сынына! Борынгы Рим турындагы китапларда сурәте бар.

— Ничектер күзгә чалынган иде кебек... Ниткән «Үгез форумы» әле ул?

— Римның иң зур базарын шулай дип атаганнар. Иң шәп үгезләрне дә шунда китерә торган булганнардыр, күрәсең. Ил язмышын хәл кыла торган карарларны кабул итү өчен халыкны да шунда җыя торган булганнар. Иң гайяр егетләр шунда үзен күрсәткән, шунда танылган.

— Рәхмәт инде мине шулай зурлаганың өчен. Ул Геркулес үгез кыяфәтендә түгел бугай үзе? Әллә үгез тиресенә уранганмы?

— Бернигә дә уранмаган. Бронзадан коелып, алтынга гына манылган! Кеше тәненең гүзәллегенә мисал. Уң кулында — сугыш чукмары, сулында — өч алма.

— Алмалары вак икән, бер учка өчәү сыйган...

— Алтын бит алар. Патшаның әмере буенча, Геркулес, җир читенә барып, анда Гесперида исемле кызларның бакчасыннан алтын алмалар алып кайтырга тиеш була. Ул барып житкәндә, илбасарлар килеп, кызларны урлыйлар. Геркулес явызларны җиңә, кызларны коткара. Моның өчен аларның әтисе Геспер аңа өч алтын алма бирә... Мин сине шул Геркулеска охшаттым. Борынгы сынчы каршында өлге булып нәкъ синең төсле егет басып торгандыр, мөгаен.

— Ә синең кебек кыз үзенең бакчасында алтын алмалар үстергәндер... — дип, күкрәгенә кысты аны Әмир.

...Тик ник алма бирәү генә дә, икәү генә дә түгел, өчәү?

Бу сорау күңелне кытыклады, әмма әйтелмәде.

...Бер исем телгә алынмады — ул да булса Луиза. Кара чәчле, төз сынлы ул кыз, бу дөньядагы барча җисемнәр кебек, бик еракка, күз күреме житмәс, уйлар барып ирешмәс офыклар артына чигенгән һәм шуннан кире кайтмаячак кебек иде.

Бер-берсе өчен яратылган пар кавышкач, арада өченчегә урын каламы?

* * *

Иртән Әминәгә ванна бүлмәсендә озаграк юанырга туры килде — җәймәдәге тапларны юарга кирәк булды. Кайсыдыр заманнарда, кайсыдыр халыкларда, зөфаф кичennән соң шушы рәвешле тапланган җәймәләрне туйга килгән бөтен кунакларга чыгарып күрсәткәннәр, җилпеп-җилпеп мактанганнар: кызыбыз гыйффәтле килеш кияүгә чыкты! Улыбыз чиста намуслы кызга өйләнде! Бөтен нәсел-ыруның йөз аклыгын раслый, абруен күтәрә торган дәлил алар — зөфаф кичендә тапланган ак җәймәләр. Әминә «Совет гаиләсе» журналына профессор Ильясовадан мәкалә яздырган иде: өлкән яшьтәге, тәҗрибәле табибә анда кыз баланың сафлыгын саклау сәламәтлек өчен дә, яңа корылган гаиләнең ныклыгы өчен дә ифрат мөһим, дип, мисаллар китереп, аңлата. Әминә үз мәкаләләрендә дә җае туры килгән саен бу хакта әйтеп китә. Ә үзе хәзерге минутта нишли? Горурланып халыкка күрсәтерлек җәймәне, сафлыгының дәлилен юкка чыгарырга тырыша,

чөнки алар киткәннән соң шушы бүлмәгә кереп, урын-җирне алыштырачак хатыннардан ояла...

Ак җәймәнең уртасын учына йомарлап, кран астында сабынлап ышкыганда аның күңелен шундый уйлар тырнап узды.

Ләкин патшаларга тиң мохитта кичергәннәре күз алдына килде дә, назлы дулкын булып, күңелгә сарылган ачы күбекне юып алды: Әмир абруйлы, республиканың иң зур кешесеннән үз сүзләрен сөйләтә, Мәскәүдә аны кочак җәеп каршы алалар. Сөйгән ярының намусы чиста икәнлекне ул белә, бәяли. Башканың фикере ник кирәк?

— Әй, су анасы! Алтын тарагыңны югалттыңмы әллә? Чык тизрәк! Соңга калмыйк тагын!

— Кая?

— Редакциядә сәгать унда баш редактор көтә мине!

* * *

...«Новый мир» журналында да аларны ачык чырай белән каршы алдылар. Өстәлгә кофе, шикәр, печенье, коньяк шешәсе куелды. Әминә җентекләп карады: шешәгә «NAPOLEON» дип язылган, ә көмеш балкашыкларга Фаберже мөһере чүкелгән иде. Әшләнмәләре патша өстәлләренә куела торган, исеме бөтен дөньяга мәшһүр остаһың тамгасы! Ерак мәмләкәтнең илчесеме әллә мин, дип уйларсың!

Коньяк кушып кайнар кофе эчкән арада, кыскарак буйлы, юан гәүдәле баш редактор белән какча яңаклы, ак чәчле бүлек мөдире Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Усмановның бу мәкаләсендә бөтен ил өчен мөһим мәсьәләләр күтәрелүен әйттеләр, республика хәлләрен сораштылар.

Аннан чыкканда, таш стеналар, күксел асфальт шактый кызган, эссе һава биткә бәрә иде инде. Әмма Әмир җиңел сулап куйды:

— Хәзер синең йомыш белән китсәк тә була.

Әминә югалып калган иде.

— Нишлибез соң?

— Юлламаңны журналистлар союзыннан аласы, диден бит. Әйдә киттек. Самолетың ничәдә оча әле?

— Сәгать дүрттә...

— Ә мин соңгы рейска билет алдым. Сәгать унга. ЦУМны, ГУМны айкап чыгарга туры килер. Мәскәүдән буш кул белән кайтып булмас. Сине озаткач та бераз вакыт кала икән әле.

Әминәнең башы буталып китте: ничек була соң әле бу... Рәтле парлар никахтан соң кулга-кул тотынышып туй сәяхәтенә китәләр. Ә ул үзе генә очамыни?

— Әллә соң бармаскамы? — дип башын күтәреп, ялварулы карашын Әмирнең йөзенә төбәде ул.

— Башта белик әле... Бармы анда юллама... Бәлки, бөтенләй юктыр. Мәскәүләрне белмәссен...

Журналистлар союзында көмештәй чаларган куе бөдрә чәчле, кылыч борынлы абзый өстәлдә таралып яткан кәгазьләреннән башын калкытты да, аларны күргәч, елмаеп җибәрде:

— Җәмәгатегез белән килдегезмени? Иллә дә шәп иткәнсез. Сезгә ике кешелек менә дигән апартаментны тәгаенләп куйган идек. Хәзер юлламага сезнең исемне дә теркәрбез. Димәк, сез Мусин... исемегез-атагызның исеме ничек? — дип торып басты ул.

— Юк, мин бармыйм, — диде Әмир кашларын җыерып. Абзыйның уйламыйча әйткән сүзе аның егетлек дәрәҗәсен чеметкән иде. — Без танышлар, юл унаеннан озата гына килдем.

Шулай дип, үзен Әминәдән читләштергәндәй итте дә куйды. Соңгысын ук әйтми калса ни булган!

— Юкка баш тартасыз, — диде абзый, егетнең чырае каралганга бераз гаҗәпләнгәндәй. — Менә диган иҗат йорты. Күктүбәдә, шагыйрь Константин Волошинның йорты белән янәшә. Мондый мөмкинлек сирәк була. Юлламаны Мостай Кәримгә дип саклап тоткан идек, делегация белән Болгариягә китә икән.

Әллә ничек кенә килеп чыкты бу. Чит кеше алдында сүз көрәштерү яхшы түгел, зиһен дә чуалган иде, Әминә, рәхмәт әйтеп, ике канатлы зур открыткага охшаган юлламаны алды. Анысы кулда, билет кесәдә...

Сөенергә кирәк кебек үзе, әмма күңел сүрелеп киткәндәй иде. Узган төннән соң икең ике самолетка утырып, берең мәгърипкә, берең мәшрикъка дигәндәй очу гайре табигый булып тоела; шул ук вакытта алдан уйлап, әзерләнеп чыккан юлдан кинәт борылып читкә тайпылу да мөмкин түгел кебек. Һәрхәлдә андыйга минут эчендә тәвәккәлләү авыр...

Урамга чыккач, Әмир иртәгә сәгать сигездә Беренче секретарь каршында басып торырга тиешлеген аңлата башлады. Сүзләре колакка керсә керде, кермәсә кермәде. Болай да һәммәсе бик яхшы аңлашыла иде бит. Һәр газета, журнал — партия күзәтүе астында нәшер ителә. Кайберләре миллионнарча данә белән тарала. Рәсәйдә өлкәләр сиксән сигез, һәркайсының җитәкчесе бер-берсе хакында матбугатта ниләр язылганын зур игътибар белән күзәтеп бара. Мактап мәкалә чыгаралар икән, бу инде ул җитәкченең Үзәк комитет каршында абруе югары булуы турында сөйли, урынында нык утыра, дигәнне аңлата. Әгәр дә (Алла сакласын!) кимчелекләре күрсәтелсә, бер-бер гаебен тапсалар, бетте баш. Димәк, югарыдагыларның сиңа ышанычы какшаган, түбән тәгәрәчәягенне көт тә тор.

Әлбәттә инде, Усманов үзенең ышанычлы кешесен Мәскәүдә ничек-ничек каршы алуларын, кунакханәнең нинди бүлмәсенә урнаштырганнарына, редакциядә ни белән сыйлаганнарына кадәр җентекләп сорашачак.

Әмир үзенең җитәкчесенә сөенечле хәбәрләр алып кайтачак иде. Билгеле инде, аның патша сараена тиң апартаментында зөфаф кичәсе ясаганы да беленми калмас. Бу — башкаланың төп кунакханәсе, чит илдән килгәннәр дә шунда урнаштырыла. Һәркайсының ни кылганы, ни сөйләгәне, кемнәр белән очрашканы тиешле урыннарга җиткерелеп тора.

Гайбәте таралмаса, «исе» чыкмаса, хатын-кыз белән төн кунганга күз йомачаклар, билгеле. Егет кешегә, үз вазифасын җиренә җиткереп үтәгәч, күңел ачып алу гаеп түгел. Коммунистның да бар җаны, бар җанашы. Шагыйрь әйтмешли, эш беткәч уйнарга ярый.

Боларны Әмир бик яхшы аңлый, Әминә дә чамалый иде. Егеткә корыч авызлыклы йөгән кигезелгән, кыз да яшьтән тәртәгә кертелгән. Берсе дә, гашыйк булдым дип бөтен киртәләрне җимереп, белер-белмәс тарафка койрык чәнчеп чаба торган тай түгел. Уңга-сулга карамый, һични белән исәпләшми, бер-берсенең күзенә карап, кулны кулга ялгап, үзләре теләгән якка китүче гашыйклар әкиятләрдә генә була торгандыр.

Әмма нәкъ менә хәзерге сәгатьтә күңел чыгымлый башлаган иде. Болай булырга тиеш түгел иде! Төн уздырган йортка кире кайтырга, янә татлы нигъмәтләр белән сыйланырга һәм... патша сарайларына гына куела торган киң йомшак ятакта бер-берсенә берегеп, ләззәт болытында күкләргә ашарга тиешләр иде алар!

Әмма ул йортның ишек төбендә басып торучы елтыр сары тасмалар белән бизәлгән куе зәңгәр форма, шундый ук фуражка кигән швейцар аларның юлын кисәчәк. Тәрәзәләре гүзәл мәйданга караган бүлмәдәге киң ятакка яңа җаймалар җәеп, башка берәү кереп ятсын өчен әзерләп куйганнардыр...

— Әйдә монда кереп чыгыйк әле, — диде Әмир. Кечерәк кенә кибет янышнан узып баралар икән. Ишеге өстенә «Комиссионный магазин» дип язылган.

— Ни бар анда?

— Хәзер карарбыз: бармы, юкмы...

Ишектән керүгә, унга борылды ул. Анда, өсте пыяла белән капланган озын тартмаларда шушындый кибетләрдә генә була торган күп төрле бизәнү әйберләре ята иде: йөзек-беләзекләр, алка-муенсалар, брошка-каптырмалар...

— Алып китмәгәннәр икән әле, — диде Әмир җиңел сулап. Һәм читтәрәк басып торган сатучы хатынга эндәште. — Менә бу әйберне күрсәтегез әле!

Хатын өске пыяланы шудырып, кырыйдарак яткан ак металл билбауны алып бирде.

— Узган килүдә күреп киткән идем, — диде Әмир. — Безгә насыйп булган, күрәсең. Алмаганнар.

— Аласылары бик килә дә, бөтен кешегә дә ярый торган әйбер түгел шул, — диде сатучы. — Элекке дворян кызларының биленә үлчәп ясалган, хәзергеләр сыймый. Сыярлыкларының кесәсе такыр. Иясе көн аралаш килеп тора, тизрәк сатасы килә, акча кирәк, ди. Бүген иртән килеп тагын хакын төшерттерде.

— Ә менә без хәзер үлчәп карыйбыз.

Бик нечкә чыбыктан үрелгән билбау каты, саллы иде. Көмешкә охшаган. Әмма, бәясенә караганда, көмеше өстән генә йөгертелгән булырга тиеш. Чәчәк ясап үрелгән аелының уртасына зур гына түгәрәк гәрәбә куелган.

— Яле!

Әмир билбауны Әминәгә кигезеп, аелын эләктереп куйды.

— Әллә сезнең дә әби-бабаларыгыз дворяннармы? — дип сорады хатын.

— Жиде буыннан килә, — диде Әмир. — Мусиннарны ишеткәнегез бармы?

— Мусин-Пушкиннарны кем белми инде, — диде сатучы ихтирам белән.

Әминә аелны ычкындырмакчы иде, Әмир аның кулыннан тотып алды.

— Торсын шулай.

Вак чәчкәле ак ситсы күлмәк өстеннән бик килешеп бетми иде кебек билбау, тантаналы кичәләргә, театрларга бару өчен яхшы иде. Әмма егетнең сүзен сүз итү, аңа буйсыну шулхәтле рәхәт иде ки, билгә ул салган тимер кыршау да жылы, назлы кебек тоелды.

— Тиешлелнең яртысы гына булды инде бу, — диде Әмир урамга чыккач.

— Нәрсәнең яртысы? Тиешлесе ни төсле соң аның?

— Мин сиңа тугрылык путасы кигездем, дип бел. Монысы өске өлеше, калганын мин сиңа күңелем белән кигезәм. Әгәр дә берәрсе билеңә кулын салса...

— Ни сөйлисең син! Каян башыңа килә?

— Беләм мин сине! Йөрәгең чуар... Күңелең күпне сыйдыра.

— Ничек шулай әйтә аласың? — дип аңа борылды Әминә рәнжеп. — Минем ниндилегемне белмәдеңмени?

— Хисләргә биреләсеңме? Биреләсең... Кара аны, сиңа тугрылык путасы кигезелгән. Суга кергәндә генә салырга рөхсәт. Ә башка чакта гел тәнеңдә булсын. Көнен дә, төнен дә!

— Бигрәк кансыз икәнсең! Жайсыз бит ул!
— Мине онытмаска яхшы булыр!
...Аэропортта, регистрация өстәленә чиратка баскач, күңел тәмам төште.
—Бигрәк озак инде — бер ай дигән сүз бит ул, путевканы ярты гына срокка аласы калган! — дип сөйләнде Әмир. —Ярый ла син рәхәт чигәргә барасың. Ә мина синсез нишләргә?.. Суга кергәч дөньяңны оныта торган гадәтең бар, кара аны, коткаручылар күзеннән югалып, ерак китмә. Үзеңнеке генә түгел, минеке дә син хәзер. Күбрәк экскурсияләргә йөр. Кайткач сөйләрсең. Э-эх, утырып кына китәр идем дә, булмый шул!..
...Чал чәчле абзый хаклы булган, ижат йорты яр читендәге гөлбакчага таралып утырган бер-ике катлы йортлардан гыйбарәт булып чыкты. Әминәнең кулына ачкыч тоттырдылар. Бүлмә зур, ике якта ике карават тора. Тәрәзә каршында кытай чынаягы кебек ак чәчкә аткан магнолия киңәеп утыра... Әминәне ожмахка керткәннәр иде. Әмма бу ожмахта аңа ямь юк иде. Ул сумкасын идәнгә ташлады да, караватка капланды: ник килде ул монда? Ник кире Казанга кайтып китмәде? Әмир белән бер самолетта, аның белән янәшә утырып?
Ул үксеп елап жибәрде.

* * *

Көннәр санаулы булса да, бик әкрен үтте. Ул төнге күлмәк өстеннән билбауны киеп ята, борылган саен, тимер тәнне кыра. Әмма жан сөйгәнененә биргән вәгъдәсен үтәүне аңлаудан авырту да татлы тоела иде.
...Кайтканда самолет белән Мәскәүгә очты, аннары Казан поездына утырды ул. Вагоннан телеграмма биреп була иде, әмма Әминә Әмирнең өй адресын белми, ә эшенә жибәрсә, читләр укыр да, төрле сүзгә сәбәп булыр, дип, тыелды.
Күпләрне вагон ишегеннән чыгуга кочак жәеп каршыладылар, ул исә үзен ятимәдәй хис итте.
Икенче көнне генә билгеле булды: Әмир, чираттагы ялын алып, якын дуслары белән көймәдә Ык буйлап сәяхәт кылырга чыгып киткән икән. Елга буйлап телефон чыбыгы сузылмаган, суда тибрәлгән көймәгә почтальон хат ташымый... Ярый әле, Нәзир Шәрифжанов та шул көймәдә икән, ул туган якның табигате турында зур бер тапшыру әзерли дип, яңалыклар тапшыруында телевизордан әйтеп куйдылар. Шунысы да билгеле булды: сәяхәтчеләр ике атнадан кайтачак икән.
Тагын көннәрне, сәгатьләрне санарга калды.
...Бераздан бәгыръ сызлану өстенә тән сырхавы килеп бәйләнде. Бер иртәне нык сусап уянды Әминә. Өстәлдәге чәйнектә су юк иде, утны кабызмый гына коридорга чыкты, кухняга кереп, краннан агызып салкын су эчте. Сусыны басылды, әмма берничә минут үтүгә күңеле болгана башлады. «Агуландым, ахры, бигрәк начар инде бу водопровод сулары!» — дип уйлады. Томана түгел, нинди хәлгә тарыганын аңларга тиеш иде. Әмма, үз башыңа килгәндә, хәлеңнең аянычлыгы тиз генә аңга барып житми шул ул. Хасталавыңны ничек тә жиңелгәрәк юрыйсы, көйсезлектән тизрәк котыласы килә.
Кайнар чәй эчеп карады, алма ашады, әмма күңел болганудан туктамады. Берничә кулъяулык манма булды...
Эштә кулдан каләм төште, әледән-әле коридор буйлап әрле-бирле йөрергә туры килде. Бер бүлмәдә утырган хезмәттәшләре — зирәк акыллы Йолдыз Таһирова белән жиңелчәрәк холыклы Динә Зәбирова — аңа текәлеп карап-карап тордылар да, серле елмаештылар.

Ә төштән соң аны журналның редакторы Әлфия Зарифовна үз бүлмәсенә чакырып алды.

— Утыр әле, Әминә, — диде ул. — Киңәшәсе бар иде. Бик тә мөһим мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк безгә.

Кайсыдыр халыклар, адәм баласы балчыктан яратылган, дип саный. Әгәр бу хак булса, Әлфия Зарифовна балчыкның иң яхшы сыйфатлысыннан, үзлесеннән эшләнгәндер. Аны бер тәҗрибәле оста озаклап басып, укмаштыргандыр, чәбәкләп тигезләгәндер, сыйпап шомарткандыр да кызу мичкә куеп чыныктыргандыр. Аннары фәрештә килеп, эченә зирәк акыл, сүнмәс дәрт, нык ихтыяр, тынгысыз холык өргәндер дә, чыдам тире белән тышлап куйгандыр. Дөньяның дилбегәсен нәкъ шундыйлар тота, ирләрдән узып шулар алга атлый. Кыяфәте белән дә ир-ат арасында югалып кала торган түгел: буйга калку, бәдәне нык, кыска киселгән, җирәнсу төскә манылып, күпертелгән чәче дә, эредән уелган йөз сызыклары да ир заты өчен килешлерәк булыр иде. Дулкын-дулкын кара сызык төшкән аклы күлмәк өстеннән билен киң кара пута белән буып куйган – бу да аның кыяфәтенә ныклык өсти кебек. Яше алтмыштан узган булса да, җинелчә иннек кершән-ягылган йөзендә сулу чалымнары күзгә ташланмый, соры күзләре яшьләрчә якты.

Мондый шәхесләр тарлыкны сөйми, аяк баскан урыннарын киңәйтергә тырыша. Бүлмәсенең түренә зур картина элеп куйган, анда серкә очырып утырган арыш басуы, басу уртасында киң җәелеп үскән каен, аяз күкнең зәңгәрлеге, офык киңлеге. Бүлмәнең уң ягы – тоташ тәрәзә, сулы – тоташ китап киштәләре, уртада озын өстәл, түрдә ана аркылы өстәлнең кыскасы куелган, аларда газета журналлар, рәссамнар ясаган сурәтләр.

Бирегә килеп кергәч, ихтыярсыздан күз күремең киңәя,баш югарырак күтәрелә, сулыш иркенәя кебек. Әмма бу юлы Әминә үзен эчтән бөрешеп киткәндәй хис итте. Чөнки апакайның кәефен кырачагын сизә иде.

Хезмәткәренең буйга узганын белгәч, кайсы гына җитәкче сөенер икән? Декрет ялы бирергә, урынына кеше эзләргә кирәк. Вакытлыча эшкә рәтле кеше киләме? Әйе, вакытлыча, чөнки декрет ялыннан соң теге хезмәткәрең, телисеңме-теләмисеңме, кире үз урынына кайтып утырачак — закон шулай куша.

Һәр редактор әйтер: оста журналист табу җинел түгел. Каләм тибрәтүчеләр күп, ә менә җанга сары май булып ятарлык, күңелне кузгатырлык, уйландырырлык, моңландырырлык итеп язучы сирәк. Журналны исә нәкъ менә шулар тота. Бу нисбәттән Әлфия Зарифовна Әминәгә зур өметләр баглый иде. Ходай бу җитәкченең үзенә язу сәләтен мул итеп иңдермәгән, әмма талантларны бәяли алырлык акыл, аларның кадерен белеп, ярдәм итәрлек сизгер һәм киң күңел биргән иде. Сәләтсезләр күп очракта көнләшүчән, ә менә «Совет гаиләсе» дигән бу журналның редакторы каләм әһелләрен таба һәм үстерә белүе белән горурлана иде. Ә бу ансат эш түгел, чөнки талантларның күбесе хискә бирелүчән, мавыгучан була, шунлыктан кайчак акылга сыймаслык гамәлләр кылып куя.

— Син дингез буенда кызынып ятканда, монда бер кызык хәл килеп чыкты бит әле, — диде редактор. — Мәскәүдән, «Советская женщина» журналыннан бер хатын килгән иде. Профессор Ильясова турында очерк язарга булганнар. Үзең беләсен, атаклы шәхес, бөтенсоюз хатын-кызлар оешмасының идарә әгъзасы. Җәмилә Закировна моның язганнарын укыган да, беләсеңме, тегеләргә ни дигән?

Әминә моңлы күзләрен җитәкчесенә төбәгән хәлдә дәшми-тынмый утыруында иде. Редактор үткен күзләре белән ана текәлде. Бөгәрләнгән юеш кулъяулыгы белән әледән-әле авызын сөртеп утырган хезмәткәренә керфек какмый сынап карап-карап торды да, җавап булмагач, үзе дәвам итте:

— Бу мәкалә миңа ошамый, минем хакта Мусина язсын, дип хат салган тегеләргә. Үзебезнең журналда чыккан мәкаләнне тагын бер тапкыр җентекләп карап чык та, урысчага тәрҗемә итеп, Җәмилә Закировнаның үз кулына бир. Җай чыкканда мәскәүләрнең борынына чиртеп алу начар булмас. Үзләрен әллә кемгә куеп, безне гыйбатларга санап йөрмәсеннәр.

— Нишләптер ашказаным борчып тора әле, — диде Әминә житәкчесенә туры карамыйча, тонык тавыш белән.

— Нәрсәдән икән?

— Белмим шул... Монарчы андый хәл булганы юк иде...

— Ник Җәмилә Закировна белән киңәшмисең?

— Болай гына үтмәсме, дигән идем.

— Син нәрсә, Әминә, шыр надан авыл хатыны да болай гына үтмәсен белә. Нуриев ни ди соң? ЗАГСка гариза бирдегезме?

Әминә упкынга убылгандай булды. Каян белгән? Кем әйткән?.. Тәҗрибәле хатын аның эчендә ниләр кайнаганын ап-ачык күреп утыра иде.

— Бөтен Мәскәү каласына янгыраганны мин генә белми, дип уйламыйсындыр бит? Внуково аэропортында йөзләгән Казан кешесе булган, радиодан ни кычкырганнарын ишетеп торганнар, белешмәләр тәрәзәсе янында кемне кем көткәнен күреп узганнар. Ә синең күзенә ак-кара күренмәде инде, ә? Үз-үзенне тыя белергә кирәк, дип, кызларга вәгазь укып, күпме мәкаләләр яздың... Шулкадәр җилбәзәк булалар димени?! Башны җуяр хәлгә житкәч кенә баралар андыйга...

Әминәне башын җуймаган дип беләме? Хисләр давылында һушыннан язганын күз алдына китерә алмыйдыр! Бу апакай андыйны оныткандыр шул инде. Кайчандыр кичергән булса да...

— Ә синең башыңны югалтырга хакың юк, — дип дәвам итте Әлфия Зарифовна. — Күптән балигъ булгансың. Көннәрне санап көттем мин сине. Ә хәзер... Бу хәлендә сине эштә бар дип буламы?... Безне мең күз күзәтә! Редакциянең йөз карасы булып утырырга теләмисеңдер бит? Мә кәгазь, яз гариза!

— Нәрсә дип?

— Бер атнага үз хисабыңа ял сора. Чираттагы ялыңны файдаландың бит инде, түләүлене биреп булмый. Бу санда мәкаләң чыгып килә. Никахланышкач кына җан сөйгән яры кочагына кергән кәләшләрнең бәхете турында... Әйбәт яздың, гонорарны арттырыбрак түләргә тырышырбыз.

Шулай дип, янә бер кат төрттереп алды апакай.

— Яманатың чыкканчы, язылышып куйсагыз, яхшы булыр иде. Бу хакта Нуриев үзе ни ди? Соңгы вакытта Шәйхразиев канаты астына елышырга маташа, дип ишеттем. Әле дә шул тирәдә йөри икән. Кәләшнең көттәсен әләктергән, дигән сүзләр колакка чалынды. Тик сине күз алдында тотмыйлар бугай. Синең бу хәлеңне беләдер бит ул?

Урыннарын алыштырып утыртсалар, Әминә үзе дә нәкъ менә шушындый сүзләрне тезәр иде. Алай гына да түгел, үткенрәкләрен, үтемлерәкләрен сайлар, үзәккә үткәзеп әйтер иде. Ә хәзер үзенә ни дияргә?

— Кеше күңеле — кара төн, бу очракта мин сезне аңлап та җиткермимдер, — дип уйлануын дәвам итте редактор. — Бәлки, ул сина башын югалтыр дәрәҗәдә гашыйктыр. Чын мәхәббәт таулар күчерә. Тик менә Нуриевның башы муеныма нык беркетелгән кебек күренә... Бер генә дә дуамалга охшамаган... Ни генә дисәң дә, синең урыныңда булсам, мин үзем аңа әлләни зур өмет баглый алмас идем... Нишләрсең икән инде? Гаиләле булсаң, фатир чиратыңны алгарак күчерергә тырышыр идем. Ә болай... кайда яшәрсең икән? Авылга кайтырга уйламыйсыңдыр бит?

Авылга кайтып, анаң сыртына атлану турында сүз дә булуы мөмкин

түгел. Хурлык йөге анда катырак басачак. Икенчедән, әтиләренең үлгәненә ике ел, бер ана жилкәсендә мәктәп яшендәге дүрт бала. Әминә ничек булса да үзеннән арттырып, акча жибәрергә тырыша тырышуын да... Бу илдә каләм хакының мул булганы юк. Журналистларга үз тамакларын туйдырырлык кына түләнә. Аена йөз тәңкә. Өч ел буе Әлфия Зарифовна, хезмәт хакын менә арттыралар, менә арттыралар, дип сөйләнеп йөрде. Ниһаять арттырдылар — биш тәңкә өстәделәр. Тик аның да яртысы налогка кала булып чыкты. Ярый, бераз гонорар эшли алсаң...

Кыскасы, әле ике ай элек кенә дөнья якты, күңел күге кояшлы иде. Чарасызлык тозагына килеп эләккәненне сизми дә каласың икән. Кайтсын иде Әмир. Капкыннан тизрәк йолып алсын — күңелгә редактор салган шик-шөбһәләрне тизрәк юкка чыгарсын иде!

* * *

Алда нинди авырлыклар көтеп торганын Әминә ул чакта күз алдына да китерми иде әле.

Иң ачысы — Әмирнең үлем хәленә төшүе... Янында утырсаң, жиңелрәк буласы иде дә бит... Әмма кем рөхсәт итсен аңа?

Тикшерүче Әминәнең эшенә шылтыратып, тагын үзенә чакырды. Иртәгә иртән килсәң дә ярый, дигән иде дә, тик кичне-төнне ничек үткәрәсең? Әмирнең хәле ничек икән? Мансур Хужиевич беләдер, билгеле...

Таныш бүлмәнең бусагасын атлап керүгә, Әминә, исәнләшергә онытып, тикшерүченең йөзенә текәлде.

— Нуриев аның килдеме?

Мансур Хужиевич каш астыннан кистереп карап алды да, тыныч кына:

— Исәнмесез, узыгыз, — диде. — Нуриевның хәлен белешергә өлгермәдек әле бүген.

Ничек инде шуны да белешеп тормаска! Эчендә жаны бармы бу адәмнең?!

— Сез артык борчылмагыз, — диде тикшерүче аның тынсыз калганын күреп. — Ул-бу булса, шундук үзләре хәбәр итәрләр иде. Хатыны кайткан, янында утыра, диделәр.

Анысы яхшы икән. Тик нигә соң аның урынында Әминә түгел? Авыр хәлгә тарыган алтынсу тәнле егет янында ул булырга тиеш иде бит!

— Утырыгыз, — диде тикшерүче. — Сезнең бер ижат жимешегез турында фикер алышасы килә иде.

Ул өстәл тартмасыннан журнал чыгарды. «Совет гаиләсе»нең жиде ел элек чыккан саны иде бу. Соргылт кәгазьдә басылган, чөнки агын, сыйфатлысын бирмиләр; тышы да юка, күрексез, тиз таушала торган. Тикшерүченең каты тырнаклы юан бармакларында ул бигрәк тә чәрексез булып тоелды. Ни тапкан анда бу абзый?

— «Котлы булсын туегыз!» дигән мәкаләгезне, хатын белән янәшә утырып, тагын бер тапкыр укып чыктык әле, — диде ул журналны ачып. — Туйларын шушылай итеп уздырган парлар нинди бәхетле, дип кызыгып куйдык. Кызганыч, без яшь чакта мондый матур киңәш бирүче булмады. Туебыз бик гади үткән икән. Шуңа уфтандык. «Кешенең өч туе була, дип язылган менә монда, — дип, журналны ачып, башын иеп укый башлады ул. — Бәби туе, никах туе, вафатыннан соң женазасы. Шуның икесендә без үзебез катнаша алмыйбыз. Фәкать никах туенда гына без — түр башында. Оныкларына мактанып сөйләрлек итеп үткәрергә кирәк аны! Сүз акчаны күп түгү турында түгел, бәйрәмне ямьле, күңелле, рәхәт итеп оештыру турында бара. Барлык кунаклар сагынып сөйләрлек булсын!» — Шунда ул башын күтәреп, Әминәгә текәлде. — Йөз меңләгән кешегә шушындый

матур кинәшләр биргән кеше үзенен туен гаҗәп матур уздыргандыр инде, дип уйладык. Кимен куймагансыздыр шәт.

— Ничек үткәрсәк тә, бу безнен шәхси эшебез. Тикшерүчеләр казынырлык гаеп-кыек булмады.

— Гаебе юктыр да, бәлки, ә минә кыегы бар кебек тоела мина. Сез гомумән туй ясамагансыз икән. Бу гаҗәп бит! Эшегездә дә котламаганнар хәтта. Чөнки өйләнешкәнегезне белми дә калганнар. Ә ник сез авылга барып язылыштыгыз?

— Ирем ашыктырды. Шәһәрдә бер ай көтәргә кирәк бит.

— Менә монда... — Тикшерүче бармагы белән журнал битенә төрткәләде, — бу эштә бер дә ашыгырга кушмагансыз бит. Башта үзара килешергә, аннары кодалар җибәрергә, аннан сон ярәшергә, туй хәстәрен алдан күрергә... Нишләп сон үзегез ул хәтле кабаландыгыз?

— Иремә... Безгә фатир алырга кирәк иде.

— Нуриев шулай кинәш иттеме әллә?

— Анын ни катышы бар?

— Нәкъ шул чорда сез анын белән тыгыз мөнәсәбәтләрдә булгансыз. Өйләнешәсез дигән хәбәрләр йөргән.

— Юк сүз! Кара гайбәт. Безнен хакта ниләр генә сөйләмиләр! Әнә, авылларда җырчы Нургата Мусиннан, Әминә Мусина синен хатынынмы, дип сорыйлар икән.

— Сез аннан, Нуриевтан дим, бала да төшермәдегезме?

Тикшерүче монысын читкә борылып әйтте. Әнгәмәдәшенен коелып төшкәнен күрмәмешкә сабышты.

Әмма Әминә үзен тиз кулга алды, тураеп утырды, дәшмәде. Тикшерүче көрсенеп куйды.

— Фактлардан чыгып караганда, ул чакта Нуриев белән сезнен аралар кинәт өзелгән. Һәм яхшылык белән дә түгел. Ашык-пошык башка берәүгә кияүгә чыгуыгыз да шуны дәлилли. Әмма, күренеп тора, Нуриев бүген дә сезнен өчен чит түгел. Бик якын ул күнелегезгә. Димәк, анын сезнен тәрәзә төбенә килүе очраклы түгел. Бүтән районда яши бит ул.

— Һаман бер сүз... Бүтән фаразыгыз юкмыни сон сезнен?

— Бүтән фаразлар турында без башка кешеләр белән сөйләшербез... Нәкъ шул кичне сез өйдә ялгыз булгансыз, — дип дәвам итте тикшерүче. — Акылга сыярлык итеп анлатырга кирәк бит моны.

...Чыннан да, шәһәрнен күпчелек эшче халкы яши торган ягына, Казансу артына ничек килеп чыкты икән сон ул? Кем, ник, ни гаебе өчен аны кыйнап имгәткән дә нәкъ менә Әминәнен тәрәзәсе төбенә китереп ташлаган? Депутатларга фатирны үзәктән бирәләр. Урамнан читтә, үр битендә биегәеп, яшеллеккә төренеп, тәрәзәләре белән балкып утырган ак йортны автобус тәрәзәсеннән генә күреп узасын.

— Сезнен яннан чыгып егылгандыр, бәлки?

Тикшерүченен бу соравы тиз генә анга барып житмәде. Бу ни дигән сүз?

— Сез, аны мин кыйнаган, дип шикләнәсезме әллә? Кешелектән чыгарып изгән дә, өстерәп алып чыгып, йортнын каршы ягына илтеп ташлаган, дип?

— Кыйнавын ук булдыра алмагансыздыр анысы. Ә менә башкасы... Әйтик, берәр хикмәтле эчемлек белән сыйлау мәсьәләсенә килгәндә...

Әминә урыныннан сикереп торып, өстәл аша тикшерүчегә таба иелде.

— Агулаганнармы әллә?

— Көчле үк түгел диләр. Әмма канынннан сәер матдәләр табылган. Әйтүләренә караганда, кайчакта им-томчы, сихерчеләр шундыйрак нәрсәләрне сөйдергеч дип эчерәләр икән. Газета-журналларда да язгалыйлар бит, бәлки, үзегез дә анын ише белән шөгыльләнүчеләрне беләсездер.

— Ник кирәк алар мина?

— Мөнәсәбәтләр болай буталган чакта төрлесен кирәксенәләр. Имтомчылар, сихерчеләр тик утырмый. Ишек төпләреннән чират өзелми... Килгәннәрнең һәммәсе дә шыр дивана түгелдер. Сез дә кызыксынсагыз, аның ни гаҗәбе бар?

Әминә телен йоткандай булды. Ни дигән сүз бу? Ничек инде аның хакында, сихерче-багучы ише шарлатаннар, кеше башын бутап акча җыючылар белән аралаша дип уйларга мөмкин? Каршысында кем утырганын чамаламыймы әллә бу абзый? Ир хатыны утыра аның каршысында! Шуның өстенә җитди эш кешесе! Сөяркә артыннан чабып, сөйдергечләр эчерә торганмыни?

— Язганнарыгызда андый хорафатлар күзгә чалынганы юк-югын, — диде Мансур Хужиевич. — Сез Нуриевның кемнәр белән аралашканын яхшы беләсез. Шундыйрак эшкә сәләтле берәрсе исегезгә төшмәсме?

Бу сорау бераз анга китерде. Хәтердә берәүнең йөзе-кыяфәте түгел — һич юк! — тавышы янарды: «Депутатлыкка кандидат Әмир Солтанович Нуриевның ышанычлысы Хөснуллина тынлый! Гозерегезне кычкырыбрак әйтегез!» Нинди дәртле, хәтта куанычлы яңгыраган иде бу нечкә тавыш! Әминәнең күз алдында яшен камчысы булып уйнаган иде! Әйе, сизгер күнел тавыш иясенең нилектән шулай очынганын шундук тоеп алган иде. Әмма ул чакта акыл моны сыйдырырга теләмәде.

Ул кызның эчендә ниләр кайнаганын белеп булмады. Гәрчә менә ничә ел инде еш кына нәшрият бинасында йөзгә-йөз очрашалар.

Илзирә Хөснуллина Багыш район газетасында университет тәмамлаганнан соң беренче елын эшли торган булган икән. Сайлаулар уңышлы узганнан соң, аны Казанга тартып китерделәр, «Социалистик Татарстан» газетасының хатлар бүлегенә кертеп утырттылар. Анда-санда шигырьләре басылып чыга башлады. Нечкә күнелледер, күрәсен. Кыяфәтен күргәч, күнел тынычланып киткән иде: Әмир кызыгырлык түгел. Арык гәүдәле, төссез чырайлы, юка борынлы, сыек көлсу чәчле. Алай да... Ирләрне кем аңлап бетергән?! «Нуриев аны якын итә, яклый, фатир бирдертте», — дигән сүзләр юкка гына таралмагандыр, бәлки?

Чыннан да, утырган урыны җылынып өлгермәде, куышлы булды — кешедән бушаганны булса да, үзәктән бер бүлмәле фатир бирделәр. Тик менә чынлап оя кора алмады, яше бара, ә һаман ялгыз, сазаган кыз чутында.

Ә бәлки, гел генә ялгыз утырмыйдыр... Килеп-китеп йөрүчесе бардыр... Төп эш урыны исә әле дә шунда — инде берничә ел исеме «Ватаным Татарстан»га алыштырылган газетада.

Бу уйлар Әминәнең башыннан яшен тизлеге белән яктырып узды. Әмма мондый шикләренне тикшерүчегә ачып салсаң, үзең кара эчле, үч алучан хатынга әвереләчәксең.

— Белер-белмәс килеш андый явызлыкны кемгә сылтамак кирәк, — диде ул карашын читкә төбәп.

Мансур Хужиевич аңа тагын кистереп карап куйды. Сүзне озайтуда мәгънә юклыгын аңлады, тирән итеп сулыш алды да:

— Нәрсәдер исегезгә төшсә яисә ишетсәгез, миңа шылтыратыгыз, — диде. — Җинаятьнең ачылуын, гаеплеләрнең җәзага тартылуын телисездер, дип беләм.

* * *

Әйе, туе тыйнак булды Әминәнең. Ләкин үзе шулай теләгәннән түгел. Әмир белән кавышсалармы! Аларның бәхетенә меңнәр кызыгыр, сокланыр иде!

Ә бит моңа өмет зур, алай гына да түгел, бернинди шик юк иде. Егет сәяхәттән кайткач, очрашуга ничек атлыгып килгән иде аның янына! Хәзер дә күз алдына килгәндә, тәннәр кайнарлана...

— Әминә! Йоклап ятасың инде әллә? Тор тизрәк? Сина килгәннәр анда!

Кая ул йоклау, күзләре шар ачык Әминәнең. Тәрәзәне нидер тырнаганын баядан бирле ишетеп ята. Кем икәнен дә сизенә. Йөрәге леп-леп тибә. Сулышы кайнарланып, иреннәрен өтә. Тик ышанып та бетә алмый. Ә бәлки, жил чыккандыр да тәрәзә турында биегәеп үскән каен тармакларын пыялага бәргәлидер... Аларның бүлмәсе тулай торакның икенче катында, йөргән кызын сагынып килгән егет үрелсә дә чиртә алмый. Каен ботагын тибрәлдереп тырнатадыр....

Әминә түгәрәк чырайлы, тынгысыз холыклы чуаш кызы Шураның төн карасында караватыннан кузгалганын, тәрәзәне ачканын күреп ятты. Аның Павлушасы кайчакта шулай итә — тәрәзәне тырный. Менә Шура тәрәзәдән аска үрелде, аннан ишетелгән тоныкк тавыш колакка килеп ирешә.

— Әминәне чакыр!

Ул туп кебек сикереп торып, тәрәзәгә атылды.

Каен белән янәшә, багана башыннан төшкән яктылык түгәрәгендә Әмир басып тора. Кулларын баш очына күтәреп җилпи. Сагынып кайткан, ашыгып килгән!

Бу кофтаның җиңе нишләп буталган соң әле? Итәкнең сәдәфе кая киткән? Ә-ә, тискәре ягы белән киелгән икән. Босоножканың каптырмасы ватылган икән бит...

Баскычтан төшүгә ул җанашының кочагына керде, бөтен тәне белән аңа беректе.

— Сагындырдың, гажиз иттең! Бер минут түзәр хәлем калмады! — диде аны суырып үпкәч, сулышына кабып Әмир.

— Тагы да бераз килми торсаң, янып көл була идем...

— Әйдә! — дип, аның кулын каты кысып, урам якка атлады Әмир.

Кая дип сорамады Әминә. Почмактан борылып, олы урам буйлап киттеләр.

— Җәяү генә барасы... Базар артына гына...

Җир асты юлы белән Декабристлар урамын аркылы кичеп, «Мәскәү базары»ның корылмалары янына чыктылар. Көндезләрен бу тирәне халык сарган була, хәзер исә аулак, лампочкалар да биредә сүрәнрәк яна кебек. Арырак узгач, уңга борылып, биш катлы ак кирпеч йортның ишегенә юнәлделәр. Әмир кызның кулын ычкындырмыйча, баскычтан өскә әйдәде. Сагаеп, тавышланмаска тырышып, сандалилары белән йомшак басып атлый иде ул. Бишенче катка җиткәч, ямьсез көрәнгә буялган ишек каршында туктады, кесәсеннән ачкыч чыгарды, тик тиз генә ача алмады, бу йозакка кулы күнекмәгәне сизелде.

Кем фатиры икән?

Менә ниһаять ул җиңел сулап куйды, ачкычның борылганы ишетелде, ишек җиңелчә чинап ачылды. Әмир кызны кулыннан тотып эчкә атлады. Сандалиларын шапылдатып сыдырып төшерде дә, утны яндырып та тормыйча, Әминәне күтәреп, каршыдагы бүлмәнең ачык ишегеннән алып кереп китте. Пәрдәсе корылмаган тәрәзәдән төшкән сүрән яктылыкта бүлмә уртасындагы түгәрәк өстәл, аның артында диван шәйләнде.

Әминә нидер сорарга авызын ачкан иде:

— Дәшмә, — диде Әмир каударланып. — Аннары... Аннары..

Һәм өстәлне әйләнеп узып, кызны диванга салды да иреннәренә беректе. Аның бөтен тәне уттай яна иде. Сулышыннан бөркелгән ялкын телгә килгән сорауларны эретте, уйларны бутады.

...Бу юлы Әминәнең кичергәннәре элеккесеннән аермалы, башкачарак булды. Ул үзеннән бигрәк парына ләззәт биргәнгә куанудан рәхәтлек тойды. Аннары сөйгәненең әкренләп сулышы тигезләнгәнен, йөрәгенең тырпылдавы тынычланганын тоеп кымшанмый ятты. Соңгы вакытта җанны талкыган борчулар һәммәсе юкка чыккан, дөнья түгәрәк иде. Менә бит, ул кайтты да бер селтәнүдә күңел күген каплаган кара болытларны таратты да ташлады.

Әминә борылып бармаклары белән аның күкрәген сыйпады.

— Әниең сине тугач та алтын суында коендырганмы әллә? Тәнеңә алтын сарган. Дөньяның бар нуры синдә икән... Синсез көннәр якты түгел, төннәр йолдызлы түгел. Һәммәсе бертөсле эчпошыргыч соры.

— Ә мин сине елга буенда, йолдызлар астында моңаеп торганда күп тапкырлар күз алдыма аермачык итеп китердем. Менә шушы хәлеңдә, бернинди чүпрәккә төрелмәгән килеш... Чишендереп... Элегрәк, үртәп көлгән чакларыңда мин, тәне керпе кебек энәле микән әллә моның, дип уйлый идем. Ә син чын кытай ефәгенә төренгәнсеңмени, шундый нәфис, назлап туймаслык... Әниең иң элек ефәккә биләп, бал каптыргандыр, иреннәрең шуңа татлыдыр. Гомер буе шулай булсын, яме?

— Ничек булсын?

— Ефәген, балың минем өчен генә. Энәләрең, телеңдәге керәнең ятларга. Вәгъдә бир миңа!

— Вәгъдә бирәм: тырнамам, чәнчемәм!

— Кара аны, сүзеңдә тора торган бул!.. Кучтәнәчем бар бит әле минем. Хәзер, утны гына кабызам да...

Ул торды, өстәлне әйләнеп узып, ишек тарафына атлады, анда кабызгычны тиз генә таба алмыйча, шактый капшанды. Ниһаять, түшәмдәге өч ак шарлы, арзанлы яктырткычта лампалар кабынып, күзләрне чагылдырды.

— Менә монда...

Әмир алгы бүлмәдән кара дипломатын алып кереп, биген шартлатып ачты. Әминә көлеп куйды:

— Көймәдә дә портфель тотып йөздегезме әллә?

— Ансыз булмый. Авыл җирендә кирәкне табу мең бәла. Райкомга керергә, үзеңнең кемлегеңне әйтеп кенә түгел, күрсәтеп сөйләшергә туры килә.

Чыннан да авыл кибетләрендә балык консервысы белән каткан печеньедан гайре азык-төлек тормый шул. Ипине дә иртәнге якта гына китерәләр, халык аны чиратка басып көтеп тора һәм эһ дигәнче алып та бетерә.

— Дипломатың булмаса, ачка үләр идегезме?

— Ыкта балык җитәрлек, үлүен үлмәс идек. Әмма иписез тамак туймый. Әгәр мин әлсерәп, телемне салындырып кайтсам, ни дияр иден? — дип шаян елмаеп карады ул.

— Син миңа нинди хәлдә дә тансык.

— Синең янда дәртле, хәлле буласым килә минем... Бу дипломат шәп хезмәт итте безгә. Аны күргәч, район хуҗаларының ихтирамы арта, сыйнигъмәтне яр буена машина белән китереп бушаталар.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Әмир дипломатның елтыр ак биген шартлатып ачып, таушалган газит төргәге чыгарды.

Ә анда... карлыган икән.

— Ык кучтәнәче бу.

Әминә эре кара тәлгәшне алып иреннәренә китерде. Йа Хода, карлыган да шушы хәтле татлы булыр икән! Бу кадәр дә рәхәт итеп тәнгә сеңәр икән. Ниләр генә кабып, суырып карамады Әминә соңгы көннәрдә: тозлы кыяр,

лимон, шифалы су, аскорбин кислотасы... Берни ярдәм итми иде. Баксаң, Әмирнең сулыш өрүе хәл кертте, күчтәнәче тамакның уйнаклавын шундук онытырды. Карлыган базар тулы, алырга ничек башка килмәде икән? Хәер, аның да әллә кем бакчаларында түгел, нәкъ менә Ык ярында үскәне, Әмир кулы белән өзеп алынганы гына шифа бирә торгандыр шул.

Сөйгәненә ни кирәген каян белгән, диген!...

Ә бәлки, ул Әминәнең ни хәлдә калганын сизгәндер инде?

— Әмир, мин сиңа... әйтмәкче идем...

— Әйт чын дөресен! Өзелеп сөям диген, синнән башка берәүгә дә борылып карамам, диген. Гел янында булырмын, диген.

— Юк әле, мин башка турында...

— Әйдә, башкасын бүтән вакытка калдырып торыйк. Минем дә сиңа сөйлисе сүзләрем бик күп. Нинди генә урыннарда йөрмәдек тә, нинди генә гүзәллекләр күрмәдек. Менә фотоларын ясармын да, күрсәтә-күрсәтә сөйләрмен. Әллә кайларга барып та йөрисе юк, үз жиребездә ачылмаган серләр шулхәтле күп икән. Киләсе елда без синең белән икәүдән-икәү генә сәяхәт итеп кайтырбыз әле. Мин сиңа могжизалы жиһан бүләк итәрмен. Син анда хужа, ханбикә булырсың. Ә мин синең тугрылыклы вәзирең...

Әмма Әминә аның сүзләреннән алай ук очынып, кабынып китмәде. Әйтер сүзе теленә уралган, ычкындыру бик авыр иде.

— Мин бүгеннән ялда бит, — диде ул.

— Отпускың бетмәгән идемени әле? Сездә ничә көн сон ул?

— Чираттагысы бетте... Мин үз хисабыма ял сорап гариза яздым.

— Әллә тагын путевка алып бирәр кая китмәкчеме? Юк инде! Минем рөхсәттән башка ике аягыңның берсен дә атламыйсың. Фәкать мин кул куеп, пичәтемне баскач кына. Алга таба да гел үзенчә генә яшәмәкчеме әллә? Телисең — эштән китәсең, телисең —әллә кайларга барасың! Юк инде, моннан ары андый башбаштаклыкка юл куелмас!

Бу сүзләренең кыз күңеленә нинди шифалы дәва икәнен белә идеме соң ул?

Әминә үрелеп аның муенына сарылды, Ык сыеннан каралган иреннәре белән күзләрен үпте.

— Әйт кенә. Бер сүзеннән дә чыкмам... Бөтенесе синеңчә булыр!

— Миңа әйтеп тә тормыйча, нинди ял ул тагын?

— Редактор мәжбүр итте...

— Ничек мәжбүр итә ала ул сине?

— Журналның абруен төшерәсен, ди.

— Нәрсә ди?!

— Сине яраткан өчен гаепли.

— Аңа минем хакта сөйләдеңме әллә?.. Шулхәтле дә ачык авыз булырсың икән!

— Нишләп сөйлим... Теге чакта аэропортта Казаннан барган кемдер синең игъланыңны ишетеп калган.

— Шуңа бәйләнәме? Телен тыйдыру чарасын табармын мин аның!

Алтмыштан узган карчык эш урыны өчен тетрәп тора, кем беләндер араны бозу һич кенә дә аның файдасына түгел иде, билгеле.

Әминәнең күңелен тагын бер куаныч дулкыны назлап узды.

— Анысын ул миңа болай гына әйтте. Башкага бәйләнә.

— Монарчы гел мактап тора иде бит әле. Бездә бик яхшы журналистлар эшли, ди, иң беренче итеп сине телгә ала. Ниең ярамый башлаган?

— Кыяфәтем...

— Күпләр редакциягә сине бер күрер өчен киләдер әле, ул карчыкка карар өчен түгелдер. Шулаймы?

— Һич туктамый күнелем болгана. Янымда банка йөртергә туры килә хәтта. Ә редакциягә килгән кеше хәл-әхвәлен сөйләп, озаклап утыручан. Күрергә — күзе бар, уйларга — башы...

— Ни булды? Ник турысын әйтмисен?

— Мин авырлы, Әмир... Һәм миндә бик көчле беренчел токсикоз...

Бу сүзләрнең мәгънәсе егетнең аңына тиз генә барып җитмәде кебек. Ул диваннан торып басты, саташудан айнырга теләгәндәй, башын селкеде.

— Нәрсә?... Кай арада?... Мин синең беренчең ләбаса... — дип буталып сөйләнде.

— Ай ярым үтте бит инде... Ә бу хәлнең башланганына бер атна...

Әмир ишек яныннан әйләнеп килде. Чуалган фикерен бер эзгә сала алмый азапланганы күренеп тора иде.

— Бигрәк хатын-кыз икәнсен... Сөйләсәң адәм ышанмас. Бер орынуга шундый хәл... Назлар бигрәк тиз сеңә икән үзеңә.

Әминә аннан карашын алып, ниһаять бүлмәне күздән кичерде. Төп җиһаз бер як стена буйлап тоташтан тезелгән коңгырт төстәге шкафлардан гыйбарәт иде. Кырыйдагысы ябык — кием-салым өчен, уртадагысының пыяла ишекләре артындагы киштәләрдә китаплар, чынаяклар, бәллүр бокаллар. Өй пөхтә итеп җыештырылган, уртадагы өстәлдә чигүле ашъяулык. Буйдак куышы түгел иде бу, унган хатын-кыз кулы ярылып ята. Фатир бер бүлмәле, караватурынына җәелмәле диван. Димәк, алар әле генә чит-ят парның ятагында сөештеләр... Кемнәр алар, кайсы бәхетле парның куышы бу?.. Сорау бәгырьне боз кыйпылчыгы булып тырнады...

Егетнең исә гаме башкада иде.

— Ничек инде ул алай... Үсмер кыз түгел... Журналыгыз хатын-кызларны һәммәсенә өйрәтә. Табибларның мәкаләләрен басып чыгарасыз. Саклану чаралары турында язасыз. Ә үзең соң шундый ваемсызмы? Башка сыярлык түгел бит бу!

— Синең белән очрашуны алдан планлаштырып куймадым ла мин! Андый чараның кирәк булганы да юк иде.

Әмир дәшмәде. Башын иеп, бүлмә эчендә йөренде. Бу хәлендә ул читлеккә эләккән җанварны хәтерләтте. Әминә гаепле кешедәй сагаеп аның сүзен көтте. Менә ниһаять, ул туктады, бер адым ара калдырып:

— Редакторына әйт, сине аерым утыртсын! — диде.

— Безнең ике генә бүлмә бит, белеп торасың.

— Тагын бер бүлмәгез бар бит әле!

— Рәссам бүлмәсен әйтәсенме? Аның яныннан кеше өзелми... Фотографлар, рәссамнар... Һәммәсе ир-ат... Мина да кеше еш килә. Әхлак темасы, медицина миндә... Хатын-кызның аһ-зары гел шул тирәдә, үзен дә чамалыйсыңдыр...

— Ничек була соң әле бу? — дип әйләнгәләде Әмир. Аның бөтен кыяфәтенә соң дәрәҗәдә пошыну бәрелеп чыккан иде. Туктале, нишләп болай бәргәләнә соң ул? Аларның сабые туачак бит! Кыз яисә ир бала! Яңа кеше дөньяга киләчәк! Бер-берсен сөйгән парның кайсы гына моңа куанмас! Ә ул ни сөйли? Ник бу рәвешле хафалана? Сөенәсе урынга! Әминәнең дә бәгыренә төшкән боз кыйпылчыгы да эреп бетәсе урынга зурая, катылана шикелле....

— Балагыз тугач, фатир бирүне ашыктырачакмын, дип вәгъдә итә Әлфия Зарифовна. Өч кешелек гаиләгә ике бүлмәлене сорарга була...

Фатирлар акчага сатылмый, партиянең өлкә комитеты, район комитетлары фатихасы белән бушлай өләшенә. Түләүсез бирелә торган әйбергә, бигрәк тә шундый зур милеккә, чиратның озын булуы табигый, күпләр утызар ел көтә. Бу шартларда җитәкченең мондый вәгъдәсен бәялəп бетермәслек яхшылык дип кабул итәргә кирәк иде.

Әмма егетнең йөзе ачылмады.

— Фатирдан эш тормас анысы, — диде ул. — Мин үзем дә чиратта. Әйдә, бераз капкалап алыйк, ач карынга башны эшләтеп булмый. Минем дипломатның төбенә төшмәдек бит әле.

Аш бүлмәсе кысан, чит йортта әйбер-кара кулга ипсез тоелды. Газ кабызырга шырпы табылмый интектерде.

Дипломат төбеннән балык, колбаса телемнәре, ярты булка чыкты. Аларны күргәч, Әминәнең тамагы янә уйнаклый башлады.

Әмир, ипи белән колбасаны тәмләп кабып чәй эчәргә кереште.

— Ни карап утырасың? Аша! Ач кешенең ачуы яман. Йә тирги башларсың мине.

— Ә ни өчен?

— Редакторың миңа каршы котырта икән бит. Китереп кыскан тәмам. Алай өстенә бастырып торма. Егет кеше бит син! Күргән-белгәннәрнең һәммәсе шулай ди синең хакта. Баскан жире убылса да, авызын ямьшәйтеп елап ята торган түгел, диләр.

— Комплиментмы инде бу?

— Мисаллары житәрлек! Мине генә дә күпме кәкре каенга терәдең, ничәмә-ничә тапкыр авыз ерып көлдең! Шушы авызың белән!

Әмир урыныннан торды да үбәргә үрелде.

— Шулхәтле баллы иреннәрдән каһкаһәле көлүнең ачысы ничек чәчри алды икән? Бәгырьне ачыттыра торганы! Кара аны, бәбигә балыңны гына сал, керәнеңнең тамчысын да бирмә! Ачы телле кыз алып кайта күрмә тагын!

Әминәнең күңеле яктырып киткәндәй булды.

— Ә малай булса?

— Егет кеше төче булмас, аңа бераз керән кушу зыян итмәс. Минем өчен син жырдагы шикелле: « Нигә, нигә,, синең шаян күзләр,, күзләремә болай багалар?.. Кайчак күзләреңнән көчләр алып, биеклеккә таба ашам мин, ә кайчакта башым түбән иеп, ай Әминәм, синнән качам мин»... Искитәрлек хәл бит бу! Бер очрашып сөешкәннән малай булсын әле! Димәк, алда безне зур үзгәрешләр көтә. Һәммәсе берьюлы туры килә икән.

— Нәрсә ул тагын? — дип сорады Әминә аны аңламыйча.

— Көзгә РСФСРның югары советына сайлаулар була. Мине шунда тәкъдим итәргә дигән фикер бар. Без анда, су өстендә ишкәк уйнатып кына утырмадык. Чуртанга кармак салып, яр буенда гына да ятмадык. Кирәкле кешеләр белән очраштык. Алдагыга карадык. Хәзер юллар ачыла. Жәмгыятьнең баскычын әйләндереп куюлары ихтимал. Өстәгеләр коелыр, астагылар баш өстенә менеп утырыр. Мондый мөмкинлек булса да йөз елга бер була торгандыр! Моментны ычкындырмаска кирәк. Минем түбәндә калуымны теләмисеңдер бит? Әгәр дә сөюләрең чынлап икән, теләктәш бул! Ярдәм ит!

Ул, урыныннан торып, Әминәнең каршына тезләнде, биленнән кочып, башын артка ташлап, очкынлы күзләре белән аңа текәлде.

— Ничек ярдәм итә алам соң мин? — дип сорады Әминә сагаеп.

— Безгә шәхси тормыш мәсьәләләрен хәл итүне кичектереп торырга туры килмәгәе. Бераз сабыр итәргә. Серне ике арада сакларга. Монда берничә ай турында гына сүз бара бит. Сайлаулар ноябрьдә. Сиңа өметем бик зур иде. Авылларда сине беләләр. Чөнки журналыгызны өйдән-өйгә йөртеп укыйлар, төпләмәләр ясап куйганнар. Аннары... хатыннарның күбесе йөккә узганын сиздерми бит... Декрет ялы жиде айдан гына бирелә, шуңарчы эшләп йөриләр. Син, үз хисабыңа ял алып, сайлау кампаниясе чорында минем «ышанычлым» булырсың, дип өметләнгән идем.

— Ә хатының булсам, ышанычлың итә алмыйсыңмы?

Әмирнең йөзе үзгәреп китте.

— Андыйны күргәнең бармы синең? Ышанычлы дигән кеше, ул бит алдан йөри, кандидатны мактый, күтәрә! Хатыны итәгенә тагылып йөргән адәмне кем хөрмәт итсен, кем аны яклап тавыш бирсен? Аңла, мондый эштә бөтен көчне куйсаң гына уңышка ирешеп булачак. Башкаларны әйтмим дә инде, Татар иҗтимагый үзәгеннән дә һәркайда үз кешеләрен үткәрмәкчеләр. Бигрәк тә авылларда. Алар белән узышырга туры килмәгәе. Мин дә авыл малае, шәһәрдән сайлана алмыйм, үзең беләсең. Бу хәлне белеп алсалар, мине салып таптаячаклар. Син шуны телисеңме?

— Минем ни катышым булсын? Кандидатларның күбесе гаиләле ләбаса.

— Алар әллә кайчан өйләнгән! Сайлау чорында бер ахмак та туйлап йөрми. Аннары, безнең мөнәсәбәтләрне һәммәсе кул чабып хупларга, дип тә булмый бит әле. Монда һәр сүзеңне үлчәп сөйләргә, һәр адымыңны уйлап атларга кирәк. Чөнки меңләгән кеше күзәтеп тора!

Шунда Әминәнең хәтеренә келт итеп Әлфия Зарифовнаның сүзләре янарды: «Зур өметләр баглый алмас идем...» Арада монарчы телгә алынмаган берәүнең шәүләсе калыккандай булды: Луиза! Багыш районының хакимият башлыгы Шәйхразиевның кызы! Бу гаиләнең хәтерен калдырудан алла сакласын!

— Британия королевасының улы сөйгән яры хакына тәхеттән ваз кичкән иде... — диде Әминә.

— Син дә мине киләчәгемнән ваз кичтермәкчеме әллә? Хатын итәге астында көн итәр, дип уйламыйсыңдыр бит? Шундый язмыш юрыйсыңмы син миңа? Аңла: минем язмышым гына түгел, икебезнең генә дә түгел, өчебезнең киләчәге синең кулда хәзер. Ике-өч ай вакыт турында гына сүз бара бит. Шул чор эчендә сер саклап булмыймыни? Йә күтәрәсең, йә бетерәсең мине... Үзеңне дә. Нинди көчләр тамар синең керфек очларыннан, Әминәкәй!?..

Ул учлары белән башын кысты.

— Исләремнән гел чыкмадың, — диде сыкранып. — Төрлесен уйладым, мондые башыма да килмәгән иде...

Әминә урыныннан торып, маңгаен аның күкрәгенә терәде.

— Ничек сиңа зыян салыйм, ди? Син зур кеше булырга тиеш! Бар көчемне куярмын... Ни әйтсәң шуны эшләрмен...

— Чынлапмы? Вәгъдәме?..

Әмирнең күзләре өмет, рәхмәт, очынып сөю хисләреннән балкып яктырган иде.

— Беләсеңме, син кем?... Клеопатра! Борынгы Мисыр патшалыгының соңгы фиргавене!

— Клеопатраның сурәтләре күп, һәммәсе төрле-төрле, минем төслесе юк бит!

— Ә ник алар күп төрле?

— Үзен күреп белмәгән кешеләр ясагангадыр.

— Һәркем аны үзенчә күргән. Әмма һәммәсе бер иш хисләнгән. «Патшабикә Клеопатра килеп керүгә, һәммә хөкемдарлар сикереп торды», — дип язган бер бөек каләм иясе... Дәрт кузгата торган булган ул! Тәкатьсез иткән! Син Клеопатра, мин синең Антониең!

*Ахыры киләсе санда*



Ркаил
Зәйдулла

# ЧАРАСЫЗДАН ҖАННЫ БЕР ӨН БИЛИ

## Кирмән

**Үрмә гөлләр чорнап алган кирмән
күз күрмәгән ерак якларда
нинди сере белән – нинди сихер? –
тартты мине, гүя саклады**

**Мең дә бер кичәнең кан уйнаткан,
гел кичеккән соңгы мизгелен.
Зелпе үскән яшел үзәннәрдән
Ак коланнар чапты тезелеп.**

**Буаз болыт тиеп үтте саксыз
якты кыяларның очына.
Яңгыр тамчылары сикерештә
тере – түм-түгәрәк – кечкенә.**

**Яшел хәтфә сарган кара кирмән!
Кыя киртләченә ябышкан...
Өстән әхрам, эчтән сукыр төрмә,
кош оясы сыман ул тыштан.**

**Карап торам астан. Күңелем буш,
сискәнергә әзер. Ни көтәм?
Бичара кош, үксез, исемсез кош
очып чыгар кайсы төннектән?**

**Тоткарлар бит чәнечкеле гөлләр...
Энәләргә төренеп үзе дә
кып-кызыл бер гөлгә әүрелер ул,
һәм сикерер минем эземә.**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962) – *шагыйрь, прозаик, драматург; «Ил», «Мәгарә», «Ташка ордым башны» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Җил таныды безне

*Күз матур гына бер җәйге*
*иртәдә килеп җитә.*
М. Мәһди.

**Офыктагы учак ялкыны**
**и дөрләде капшап күк йөзен.**
**Таң сызылды, йотты яктысы**
**өметемнең сүрән йолдызын.**

**Янәшәдә урман. Тып–тын ул.**
**Кулны салып башың астына**
**нишләп ятам монда, җиде ят...**
**Ә күңелем кая ашкына?**

**Юл бик озын сыман иде бит!**
**Мин сак кына сине уяттым.**
**Басу калды артта чайкалып.**
**Янәшәдә урман.**
**Бик якын.**

**Кайнап торды үлән ул көнне.**
**Урман авызында күренде**
**ялгыз поши –**
**карт ул, карт инде –**
**чал кояшка карап йөгенде.**

**Җил таныды безне, эндәште.**
**Сизденме син? Нинди сүз икән?**
**Ике яфрак тамды тын гына**
**өрәңгенең сары күзеннән.**

## Җәлил

**Богауланган чакта ил карабы,**
**Давылларга уралган чакта,**
**Ясак сорый мәрхәмәтсез диңгез,**
**Корбан кирәк була ясакка.**

**Иң мөкатдәс жанны таләп итә!**
**Чын шагыйрьнең фидаи чагы**
**Давылга тиң.**
**Көтә аны диңгез –**
**Мәңгелекнең салкын кочагы.**

## Риваять

**Рәсүлебез безне онытмаган! –**
**Чорлар аша хәбәр калыкты:**
**Өч сәхабә белән юллаган ул**
**Чалма, таяк, кара савыты.**

**Иман әйткән, чалма кигән башка, –**
**Ерак бабам юлга кузгалган.**
**Аның эзен бераз чамалыйбыз**
**Төнге күктә калган кузлардан.**

Кылыч түгел кулда, таяк булган, –
Авыр чакта илем таянды.
Ничә тапкыр егылсак та юлда,
Кабат бастык, тәкъдир аяды.

Каурый каләм кара савытында, –
Кем сөенә: имеш, кара әз?
Рәсүлебез фатихасын алган –
Кәгазьдә эз мәңге өзелмәс.

## Җиз кыңгырау

*Инде соңгы сүз...*
Ә. Еники.

Чарасыздан җанны бер өн били,
Ул шундый да салмак, тыенкы ки,
Тын зилзилә булып канда гүли,
Кайтмаган үч кебек... Бу – Еники.

Кояш баеганда төсләр үзгә,
Яңгырашы үзгә соңгы көйнең.
Бар да кыю булган чакта сүздә,
Эндәшмәвен сагынам Еникинең.

Хәтта офыкларда күчәр эзе!
Күк сикерә өскә, дөнья чүгә.
Әрсез җилләр кискән чакта күзне,
Мин сыенам олпат Еникигә.

Нәфес колы булып тез чүккәндә,
Бил бөккәндә күндәм иле-көне,
Телдән язып тыныч йоклар өчен
Онытырга кирәк Еникине.

Толпарыбыз күптән бугазланган.
Алашага хәтле камыт тигән.
Булдырабыз! – дип салганда сөрән,
Ваз кичәргә кирәк Еникидән.

Әллә кайдан өне ишетелә...
Килер, килер, диме дөнья игә?
Шартлатылган кизләү кебек тибә
Җиз кыңгырау... анда... Еникидә.

## Азат дәүләт

Сәхнә тар ул – безнең күңел кадәр.
Киң дә була кайчак – ил хәтле...
Күккә тоташа ул – Хәлим Җәләй
Укыганда ярсып Зөлфәтне.

Көтү-көтү кошлар күтәрелә,
Түтәлендә сына сабаклар.
Кабаланып юллар юлга менә,
Безнең үткәннәрне кабатлап.

Хәлим Җәләй сөйли. Тавышында
Әллә өмет...әллә... белмим ни...
Офыктагы актык йолдыз кебек
Күккә ашкан кулы дерелди.

Галәм сагышына күчә аваз,
Кузгата да кичке тузанын,
Сиздермичә сыза аңыбызга
Яшәү белән үлем ызанын.

Әйтерсең бу – борынгы бер камлау,
Әйтерсең бу – серле бер әфсен:
Учларына салып суза безгә
Азат дәүләт – татар сәхнәсен.

## Төрек кызы

Каршымда – син. Өстәлдә – гөл. Лаләме?
Гарсон килми. Бездә аның юк гаме,
Күренә дә тагын китеп югала...
Яна, яна кулыңдагы пиала.

Янып шулай калыр сыман күмергә.
Без мондамы? Әллә инде шигырьдә?
Әхмәд Һашим фатихасы күңелдә:
Бөек фетнә бу пиала төбендә.

Авыз иткән Фөзули дә ялкыннан,
Эчеп ауган Мәҗнүн, тормый хакыннан.
Тамчы гына йоткан Ширин көндезен,
Тапкан анда төнлә хәсрәт диңгезен.

Ымсындыра безне гыйшык кичәсе,
Пиаладан янар өчен эчәсе, –
Актарырлар аннан безнең көлләрне,
Һәм ташларлар өскә лалә гөлләрен.

## Гөнаһ

Апрель күгендәге йолдызлар да
Иләсләнгән көннәр узышыннан.
Тыгыз көмеш һава киерелеп
Ымсындыра кызлар түше сыман.

Кайсы кош ул күтәрелә өскә? –
Истә тотар илне, анык юлы...
Чыршы төбендә кар елап ята –
Үкенечле сөю таныклыгы.

Ә ул калды! Калды... калды... калды...
Әллә туйды, әллә чынлап арды.
Мин югалдым апрель төннәрендә,
Йөрәгемә салып бер уч карны.

Дерелдиләр апрель йолдызлары!
Сулышлары сыйпый яңагымнан...

Сәер бер моң булып таралырлар
Ялгыз сандугачның тамагыннан.

Бер уч кардай гына сагыш иде, –
Ник йөрәкне болай әчеттерә?
Эреп бетәр.
Иңеп куяр бераз
Янәшәдә карсак мәчет кенә...

## Төн кошы

Ах, бу нинди чыршылар соң?
Ылыслары лас та лас...
Арасында бер кош чаңрый –
Һичкайчан дан казанмас.

Бу нинди төн? – Йөзгә төтен
Эленә – керфектә чык.
Саңрау урманга төбәлгән
Кырларның күзе ачык.

Яктыртып тирә-ягыңны
Ятасың... Карашың – ут!
Ымсындыргыч оятсызлык,
Гөнаһка баткан минут.

Карашыңны чаршаулар тик
Чыршыларның ышыгы...
Таң тишегенә кысылыр
Төн кошының томшыгы.

***

Юеш карда синең эзләрең бар.
Күңел әллә нинди, әллә нинди шунда.
Юеш карда өзеләләр юллар.
Эзлеклелек бар тик гомер агышында.

Беркем белми кайда тукталасын.
Юеш карда синең йөреш чалымнары.
Яусын карлар, үкенечкә калсын!
Мин соң нәрсә... мин соң... карап калдым бары.

***

Келәм кага ялгыз хатын өй каршында,
Чәчләренә куна аксыл тузаны.
Келәм кага... үзе елый... үзе елый,
Елый узган гомеркәен кызганып.

Юешләнгән бераз арка турысыннан
Кызыл чия төшкән ап-ак күлмәге.
Каккан саен ачыргаланып кычкыра
Иске келәм – кемнеңдер туй бүләге.

Фәрит
Имамов

# КҮЛӘГӘ

ДЕТЕКТИВ РОМАН

* * *

Хафиз — авыл мәчетенең мулласы. Аларның нәселе электән үк бик динле. Атасы Сәлмәнне тирә-юньдә танылган гыйлемле кеше булган дип сөйли өлкәннәр. Ул әле 1917 елгы революциягә кадәр үк, мәдрәсәдә белем алып, кайсыдыр мәхәлләдә муллалык иткән. Соңыннан, Октябрь революциясе җиңеп, большевиклар мәчет манараларын җимерә башлагач, аларның бу гамәлләренә бик нык каршы чыккан: «Алланың каргышы төшәр, кайчан да булса моның җәзасын алмый калмассыз», — дигән. Аны, шундый карашлары өчен, Советларга каршы пропаганда алып барды, дип, сөргенгә җибәргәннәр. Сигез ел чит җирләрдә каңгырап йөргәч, туган якларга кайткан. Колхозга эшкә кергән, гаиләсен ныгытып, тынычлап яши башлаган. Дөрес, динне дә ташламаган. Чалма-чапан киеп мулла булып йөрмәсә дә намазын укыган, уразасын тоткан. Балаларында, оныкларында исламга карата ихтирам тәрбияләгән, аларга дини йолаларны өйрәткән. Хафиз да беренче дин гыйлемен атасыннан алган.

Дөнья — куласа, бер әйләнә, бер баса, дигән кебек, тормыш бертөрле генә тормый икән. Илдә «үзгәртеп кору» башлангач, кайчандыр мәчет манараларын кырып йөргәннәрне, чын-чынлап тәнкыйтьләргә тотындылар. Диндарлар хөрмәтле кешеләргә әверелде. Авылдагы иске клубның түбәсенә манара утыртып, мәчет корып куйдылар. Шуннан ерак кына түгел яңасын да сала башладылар. Хафизны мәчеткә мулла итеп билгеләделәр. Совет чорында да динне алга сөргән кеше өчен бу зур сөенеч булды, әлбәттә. Ул җиң сызганып эшкә кереште. Авылда дини йолаларны белеп, җиренә җиткереп үти торган мулла булуына Күкташлылар үзләре дә сөенеп бетә алмый. Кайчак аны күрше авыллардан да коръән ашларына чакырып килүчеләр булгалый...

Әнә шулай тыныч кына яшәп ятканда, Хафизга кайгы килде. Үзбәкстанда яшәүче бертуган апасы ире белән бергә фаҗигага очрап үлде дип хәбәр алды. Тик җирләшергә барырга соң иде инде. Элекке Советлар Союзы түгел, Үзбәкстан хәзер чит илләр рәтендә. Авыл кешесе җыенып чыгып, анда барып җиткәнче шактый вакыт кирәк булыр иде.

Шул вакыйгалардан соң күпмедер вакыт узгач, апасының улы Таһир, ягъни пеләмәше була инде, Күкташка кайтырга телим дип хәбәр иткәч, шунда ук чакырып хат язды. Әйдә, кайтсын, үз каныбыз бит, читтә каңгырап

*Ахыры. Башы узган санда.*

йөрмәсен, дип уйлады ул. Элегрәк жәйләрен авылга кайтып йөргәнлектән, Таһирның бик тәртипле, инсафлы бала булуын да белә. Хафизның үзен дә бик ярата, Тәти абый, дип кенә тора. Кызы Гөлназ белән дә бик якын, туганнарча мөнәсәбәттә. Монда кайтса, бергә-бергә яшәр идек әле. Тора-бара үз кешебезгә өйләнеп, шушында гаилә корып җибәрер. Көчтән килгәнчә ярдәм итәрбез дип үзенчә фикер йөртте...

Тик Таһир бу кайтуында бик нык үзгәргән. Хафиз моны егет йорт капкасын ачып кергән мизгелдә үк аңлап алды. Үзен сәер, бик сәер тота шул. Бераз олыгаеп та киткән кебек. Дөрес, күрешмәгәннәренә дә байтак анысы. Бер-бер артлы әти-әнисен җирләү, егет күңелендә эзсез калмагандыр, холкына йогынты ясагандыр. Монысын Хафиз алдан да шулай чамалаган иде. Тик болай ук булыр, дип кем уйлаган. Хәтта Хафизга да «Тәти абый» дип түгел, «абый» дип кенә эндәште...

Егерме яшьлек егет өйдә кул кушырып ятмас, берәр җирдә эшләсә яхшы булыр, әкренләп әти-әнисен югалту кайгысы да онытылыр дип уйлады Хафиз мулла. Авылда ул башкара алырдай эше генә юк менә. Дөрес, элек пеләмәше рәсем ясарга бик һәвәс иде. Тик авылда рәсем ясаучы кирәк түгел шул. Берсендә: «Синең берәр һөнәрең бармы соң?» — дип сораштырып та маташкан иде. Егет иңнәрен генә сикертте.

— Ярты ел чамасы машиналар ремонтлау мастерскоенда эшләп алган идем. Ачкыч тота беләм, — диде ул.

Хафиз мулла, бераз уйлана торгач:

— Әйдә, алайса, авылдагы машина-трактор паркында эшләп кара. Мин директор белән сөйләшәм. Алыр, бәлки, — диде.

Егет моңа да иңнәрен генә сикертте. Эшләрмен дип әйтмәде, эшләмәм, димәде. Хафиз, икенче көне үк конторага кереп, хуҗалык директорын күреп сөйләште. Гали Басыйрович авылдашлары арасында ихтирамга ия Хафиз мулланың үтенечен кире какмады. Паркка килеп, эшләп карасын, яхшы эшләсә укытып трактор бирербез дип куйды.

Әнә шулай итеп, егет машина-трактор паркында слесарь булып эшли башлады. Хафиз моңа сөенеп бетә алмады. Хәзер авылда да эш юк шул. Яшьләр берни белән дә мәшгуль түгел. Эшсез кеше кыңгыр юлга тиз басучан. Дөрес, кайбер егетләр авылдан китеп шәһәрдә дә эш таба. Шәһәргә «сыймыйча» кабат авылга кайтучылары да бар. Андыйлар, беркайда да эшләмичә эчеп йөри. Элек, совет чорында, «киләп сарып» йөрүче мондый яшьләрне мәҗбүриләп эшкә урнаштырсалар, хәзер хәл киресенчә, эшләгәннәрен куып чыгарырга да күп сорамыйлар. Аяусыз язмышка дучар булган кеше тайгак юлга кереп киткәнен сизмичә дә кала. Яшь килеш дөньядан туеп, үзләренә кул салучылар да булгалады... Әнә шундый заман житте.

Хафиз мулланың яшьләр өчен барыбер күңеле тыныч түгел иде. Дөрес, кызын ул бик инсафлы итеп тәрбияләде. Өлкәннәргә ихтирамлы, кечене кече итә белә, тәртипле, мөслимәләрчә киенә. Гөлназ кечкенә вакытыннан ук, Рамазан аенда, әти-әнисе белән берлектә, ураза тота иде. Аларга ияреп, дини йолаларны башкарырга да бик иртә өйрәнде. Кыз, дин гыйлемен яхшы белгән кебек, мәктәптә дөньяви фәннәрне дә дүрткә-бишкә генә үзләштерә. Ә өйгә кайткач әтисе өйрәткән догаларны ятлый иде.

Таһир да, Үзбәкстаннан Күкташка кунакка кайткан чакларында Гөлназ белән ярыша-ярыша коръән аятьләре өйрәнде. Өйрәнгән догаларын Хафиз муллага матур итеп сөйләп тә бирә иде. Әйе, балачакларында бу нәкъ шулай булды... Аннан соң инде күп сулар акты. Ә хәзер...

Таһирга тиешенчә дәрәҗәдә тәрбия бирелмәүне Хафиз мулла апасы белән җизнәсеннән күрде. Югыйсә, элегрәк татарларга караганда үзбәкләрдә дин

көчләрәк, дип белә иде. Ә монда киресенчә килеп чыга. Бу кайтканында Таһир аны бөтенләй гаҗәпләндерде. Ул, кем әйтмешли, «әлифне таяк дип тә белми» иде. Егетне тезгеннән ычкындырганнар дип кыз туганын һәм кияүләрен эчтән генә әрләсә дә, инде аларның вафат икәннәрен искә алып, урыннары җәннәттә булсын дип тынычланды. Тик барыбер бу егетне ныклап тәрбияли башларга кирәк, юкса, әнә табын яныннан кузгалганда «әппәр» әйтергә кирәклеген дә оныткан. Аннан соң бер дә исе китмәгәндәй, баскычка утырып, тәмәке кабызды. Бу әшәке гадәткә кайчан өйрәнгәндер?..

Беркөнне Гөлназ: «Әти, Таһир абый үзе дә машина белән бәрелгән икән бит. Шунда хәтерен дә югалткан булган», — диде.

Булгандыр, юкса кеше шулкадәр үзгәрмәс, дип нәтиҗә ясады Хафиз. Мәчеткә йөрсә, башындагы ул кимчелекләре дә бетәр, зиһене дә ныгыр, Алланың рәхмәте зур ул! Мәчеткә йөртергә кирәк аны. Көн саен булмаса да, җомга намазларына йөрсә, бераз инсафка килер. Анда сөйләнгән вәгазьләрне тынласа бераз колагына үгет-нәсыйхәт керер. Әнә, Бакырчы Рәхмәтулланың армиядән кайткан улы Назыйм да мәчеткә йөри бит, түбәноч Мулланур да ундүрт яшьлек кече улын үзе белән намазга ияртеп йөртә.

Шуларны уйлагач ул Таһирны мәчеткә йөртергә кирәк дигән карарга килде. Хәтта бер кичне, өйдә барысы бергә җыелган чакта, бу хакта авыз ачып әйтеп тә куйды. Сүзләре үтемле булсын өчен вәгазь сөйләгәндәй итте.

— Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһиссәллам үзенең бер хәдис-шәрифендә: «Балаларыгыз жиде яшькә житкәч намаз укырга кушыгыз. Балаларыгызны намаз укырга өйрәтегез», — дигән. Димәк, һәр мөселман, үзе намазын уку белән бергә, жиде яше тулган баласына да намаз өйрәтергә тиеш. Бала, намаз фарыз булган яшькә житкәч, шундук, вакыт сарыф итмичә, намаз гыйбадәтен жиренә житкереп һәм кимчелексез кыла башласын, бу ата-ананың баласы каршындагы дини вазифасы. Дөрес, хәзер сина жиде яшь кенә түгел инде. Күпкә артык. Әгәр исемдә булса, кечерәк вакытында сина догалар өйрәткән идем. Хәзер аңлавымча, әегездә әтиәниең моны алга сөрмәгән. Инде урыннары оҗмахта булсын, алар бу хакта бик пошынмаган булырга тиеш. Ата-анаң урынына калган абыең буларак, мин соң булса да әлеге вазифаны үз өстемә алам. Мәчеткә йөрергә туры килер, балакай...

Әлеге сүзләрдән соң Марат белән Гөлназ астан гына үзара карашып алдылар. Бу йортта ата сүзе — закон. Ул әйткән икән, үтәлергә тиешлеген һәркем белә. Шуңа күрә Гөлназ әтисенең сүзләрен хуплап утырса, Марат Хафиз мулланың сүзләрен житди кабул итмәде, мыек астыннан гына елмаеп та куйды.

Хафиз:

— Мәчеткә барып, намаз уку оят эш түгел, анда беркемне дә муенчаклап алып бармыйлар. Шуңа күрә мәжбүриләп әйтүем түгел. Үзең уйла, хәл ит, — дип, сүзен тәмамлады.

* * *

Йомышы төшеп, авылның югары очына менгән Марат үз уйларына бирелеп кайтып бара иде. Шунда «Таһир» дип эндәшкән тавышка күтәрелеп карады. Дөресрәге, бу исем берничә мәртәбә кабатлангач кына күтәрде ул башын. Беренчеләрен әллә ишетмәде, әллә бу ят исемгә һаман ияләнеп житмәгәнгә күрә, аңына барып ирешмәде.

— Таһир!

Марат урамның югары очындагы ярым ачылган йорт капкасы янында бер хатынны абайлап алды. Башына шәл бөркәнгән, өстендәге телогрейкасы

астыннан юка күлмәгенең бәби итәкләре күренеп тора, шәрә аякларына шактый зур үлчәмдәге резина итекләр кигән. Бу хатынны кайдадыр күргәне дә бар сыман. Карале, Күкташка беренче кайткан көнне чишмә янында очраган чибәр түтәй түгелме соң? Исеме ничек иде әле? Ә, Нәфисә иде кебек. Әйе, үзен «Нәфисә апаң булырмын» дип таныштырган иде ул.

Әнә шулай, күпмедер вакыт, күзгә-күз карашып торгач, Нәфисә кабат телгә килде:

— Әй, энем, исемеңне әйтеп, өченче мәртәбә кычкыргач кына борылып карадың. Нуль внимание... Әллә яшь кенә башыңнан колакка катылангансың, әллә безнең ишеләрне пүчтәккә чутлап, санга сукмавың?!

Бу чая хатын чынлап сөйләшәме, әллә уйнап-көлеп кенә әйтәме, анысын Марат аңлап бетермәде.

— Ә-ә, исәнме, Нәфисә апа? — диде ул, бераз фикерен туплагач.

— Шулай диген аны! Югыйсә, күрмәмешкә салышып узган буласың...

— Күрмәмешкә түгел лә инде... Тәк, үз уйларым белән онытылганмын, — дип сөйләнде Марат, аклангандай.

Соңгы сүзләрне Нәфисә ишетмәде дә кебек. Хәер, аның әһәмияте дә шуның кадәр генә иде, күрәсең.

Хатын:

— Өемдә өстәл аягы ватылып чыкты. Өстәлем авышкан килеш тора. Үзем төзәтә алмыйм. Булышырдай ир кеше юк. Урамда да беркем күренми. Авылда бер ир заты калмаган диярсең... Әле синең югары очка менеп киткәнеңне күреп калган идем. Төшкәнеңне көтеп тордым, — дип сөйләнде дә, борылып капкадан керә башлады. «Әйдә, булыш әле», — дип әйтмәде. Егетнең ризалыгын алу өчен шушы сүзләр дә бик житкәнне аңлый иде, күрәсең. Маратның иярми хәле калмады...

Тыштан караганда да әллә ни төзек күренмәгән өйнең эче бөтенләй фәкыйрь икән. Яман шыгырдап ачыла торган тышкы ишектән башлап, һәр жирдә инде шактыйдан ирләр кулы тимәгәнлеге күзгә ташлана. Шушындый чибәркәйнең мондый «тишек»тә яшәп ятуына ышанасы да килми хәтта. Аның урыны хан сарайларында, мәһабәт биналарда ук булмаса да, ул үзенә лаек төзек йортта яшәргә тиеш тә бит... Ире юк микәнни?..

Чыннан да, өй түрендәге өстәлнең бер аягы чалшаеп авышкан, өстендәге япмасы шуышып яртылаш идәнгә төшкән. Аякны беркетә торган болтның гайкасы сүтелгән булырга тиеш. Монысын Марат шунда ук чамалады. Иелеп өстәл астына караган иде, шикләнгәне дөрес булып чыкты. Болтның башы чак кына эләгеп тора, гайкасы төшкән, ерак китмәгән — өстәл аягы янында гына идәндә ята. Аны тапкач, Марат, мүкәләп өстәл астына ук кереп китте.

— Мин гайканы борып куйганчы, өстәлнең бу почмагын күтәребрәк тор әле, — дип әмер бирде ул хатынга.

Нәфисә, якынрак килеп өстәл читен күтәрде. Аның йомры тезләре иңбашына тиеп алгач, егет гайканы бора-бора шул якка карады. Өстәл авырлыгыннан булса кирәк, хатынның төз, матур аяклары калтыранды, тыгыз балтырларында мускуллары сизелер-сизелмәс кенә уйнаклады. Марат: «Шәп бу!» — дип куйды. Ул бу сүзләрне кычкырып әйткәнен үзе дә сизмичә калды.

Хатын:

— Нәрсә, булды дамы әллә? — дип сорады.

— Әйе, шәп бу... булды, — дип, сүзләрен төзәтергә ашыкты егет.

— Башка аякларын да тикшереп чык. Алары тәртиптә микән?

Марат өстәлнең калган аякларын беркеткән гайкаларны боргалап карады да:

– Өстәлнекеләр тәртиптә, — диде һәм, хатынның матур аякларына тагын бер мәртәбә күз төшергәннән соң, юл уңаеннан гына дигәндәй, ап-ак балтырларына уч төбе белән чәпелдәтеп алды да, өстәл астыннан чыгып басты. Нәфисә аның каршында ук тора. Сулышының җиле колак читләрен кытыклап узганы да тоела хәтта. Ул Маратка күкрәге белән терәлеп үк баскан иде.

Нәфисә, сөйләшүен дәвам иткәндәй:

– Өстәл аяклары тәртиптә булса, башкасы өчен борчылма. Аларын андый болт белән генә рәтли алмассың, — дип чытлыкланды.

Бу вакытта Маратның куллары хатынның биленнән кочып, әкрен генә аска шуышты, тыгыз йомры «шарлар» өстендә әрле-бирле «адашып» йөри башлады. Яшь хатын бөтен тәне белән калтыранып куйды. Дулкынланудан, еш-еш сулыш алып, инде ярым пышылдап өзек-өзек сүзләр сөйләнде:

– Мин бит өстәл аягын гына... Болт белән дип... Оялтасың бит... Уңайсыз бит... Әллә ничек...

Марат та, аның ритмына күчкәндәй, шулай ук ярым-йорты авазлар белән дәртле сүзләр тезде:

– Хәзер, аякларын да рәтләрбез... Болтын да... гайкасын да... табарбыз, — диде ул хатынның итәк астына үрелеп. Ә үзе иреннәре белән аның битләренә, муеннарына орынып узды. Кайнар иреннәр бер-берсен табышты... Йомшак ястык түшәлгән агач карават янәшәдә генә иде...

Ләззәтле мәхәббәт уены озакка бармады. Монда ишекләр ачык килеш озак ятарга ярамаганлыгын икесе дә аңлый. Урыннан сикереп торгач Нәфисә төзәтенде, итәкләрен тарткалады, көзге каршына килеп чәчләрен рәтләгәндәй итте дә, почмак якка, чаршау артына кереп, кыштыр-мыштыр нидер эшләде. Аның аннан сөйләнгәне генә ишетелеп торды:

– Ах син, Таһир-Таһир-Таһирҗан... хулиган, — дип такмаклады ул. — Мин сине мондый ук дип уйламадым да. Әле кайчан гына малай-шалай иден югыйсә...

– Ә мин сине нәкъ менә шундый итеп күз алдына китергән идем, — дип, Марат көлеп җибәрде..

Нәфисә, чаршау артыннан чыгып шкафның аскы бүлеменнән башланган «ярты» алды. Инде китәргә җыенган Маратны туктатты:

– Чыкмыйча тор... Эшең өчен бәхилләргә тиештер бит мин сине... Югыйсә, бик нык тырыштың, — диде дә, өстәлгә ике стакан куеп, Маратка дигәненә яртылаш, үзенекенә төбенә генә салды.

Моны күргәч Марат учын-учка ышкыштырды.

– О-о, мондый нәрсәне күрмәгәнгә инде! Булган хатында бөтенесе дә була шул, — дип хуҗабикәнең салпы ягына салам кыстырырга да онытмады.

– Йә, йә, артык кәпрәймә! Компресска дип саклаган аракы гына бу. Артыгы юк. Эчеп куй да үкчәңне күтәр! Һәм бүген мулла абзаңның күзенә чалынмасаң әйбәтрәк булыр. Юкса...

Юкса нәрсә буласын әйтеп бетермәде, стакан төбендәгесен йотып куйгач, нәкъ алкаш ирләр кебек, кофта җиңен иснәде, икенче кулы белән өстәлдән ипи телеме алып капты. Марат та «илаһи-уптым» дигәндәй, бер сулышта үзенең бушатты.

– Бездә беренчесеннән соң закусить итмиләр, — диде ул, берара сулыш алмыйча торгач, Нәфисәнең ипи телеме сузып торган кулын читкә этәреп.

– Котмә, икенчесе булмаячак, — дип чытлыкланды бичә.

Марат:

– Ә мин өметләнәм әле, — диде дә, хатынның арт шәрәфенә чәпелдәтеп сугып алды.

— Хәерчегә ачык чырай күрсәтсән...

...Марат, чыгып китәр алдыннан, өстәлне селкеткәләп карады.

— Шәп кысылган бу, селкенми дә, калтырамый да!

— Кергәләп, тикшергәләп тор! Озак кысмый торсаң, тагын бушый башлый ул, — дип озатты аны Нәфисә...

Маратның күнеле күтәренке, кәефе шәп иде. Аның ни өчендер тартасы килеп китте. Тик бу уеннан тиз чигенде. Әле Күкташка кайткан беренче көндә, табын яныннан ашап кузгалгач, ишек алдына чыгып сигаретын кабызган иде. Ул аны гадәти бер нәрсә итеп, икеләнмичә эшләде. Шунда Хафиз абыйсы күреп:

— Нәрсә, тарта да башладыңмы әллә? Шул гына житмәгән иде, тапкансың бер әшәке гадәт. Бу йортка беркайчан да тәмәке кермәде. Моннан соң да булмас, иншалла. Хәзер үк ташла тәмәкенне. Бүтән күзем күрмәсен, — дип нык кына ачуланган иде.

Бик авыр булса да тартуын ташларга туры килде. Дөрес, вакыт-вакыт бу гадәте искә төшеп, үзен сиздергәли. Хәлен жиңеләйтү өчен сагыз чәйнәргә өйрәнде. Бераз нерваларын басарга шуның файдасы тиде. Ә менә бүген тагын шул тәмәкене суыру теләге уянды. Тик Марат аны жиңәрлек көнә ихтыяр көче тапты. Ярамый, бетте китте, вәссәлам...

* * *

Эш сәгате тәмамланып килә. Машина-трактор паркында ремонт белән шөгыльләнүчеләр ачкычларын, инструментларын жыештырып, эш киемнәрен алмаштырды. Марат та, майга баткан кулларын башта солярка, аннан соң сабын белән юып, коры чүпрәк белән яхшылап сөрткәч, инде кайтып китәргә жыенган иде, токарь Хамис күз кысып туктатты да тоткарланырга кушты. Трактор двигательләрен көйләүче Мансурга һәм, әле яңарак кына парк территориясенә килеп туктап, тракторын сүндергән Камилгә дә шундый ишарә ясады. Башкалар таралышкач Хамис аларны үзенең тимер кыру станогы торган бүлмәгә чакырды. Егетләр кереп: «Ни булды? Нәрсә бар?» — дип, бер-берсенә карашып торган арада, Хамис, тимер кискечләр, бораулар, зубилолар, ачкычлар саклана торган тимер шкафын ачып, андагы агач әржәләр артыннан аксыл сыекчалы бер шешә тартып чыгарды. Моны күргәч, егетләр бердәм: «О-о-о!»— диештеләр. Шешәдә самогон икәнлеген Марат та аңлап алды.

— Нинди хөрмәткә инде бу? — дип сорады Мансур.

— Кичә хатын бәби алып кайтты. Ниһаять, миннән рөхсәтсез генә туган ике кыздан соң — малай. Шуның тәпиен юып аласы бар.

— Да-а, зур куаныч бу, парин!

— Куаныч булмый соң! Хатынга, житте мин әйтәм кызлар ташырга. Монысында малай алып кайтасың, дим. Шулай булды да...

Алар, әнә шулай сөйләшә-сөйләшә, тумба өстендәге тимер-томырны бер әржәгә себереп төшерделәр дә өстенә гәжит жәйделәр. Хамис шкафтан ипи телемнәре, суган, тозлы кыяр салынган ярты литрлы банка алып өстәлгә куйды.

— Бу нәрсәдә бер туксан градус бардыр? Әйдә, яндырып карыйк.

Камил, калай кисәге алып, аңа шешәдән сыекча тамызды да шырпы сызды. Сыеклык зәңгәрләнеп яна башлады.

— О-о, шәп бу! Моның белән тәпи чиста юыла инде.

Стакан берәү генә икән. Хамис аның майланып беткән кырыйларын уч төбе белән сыпырып сөрткәләгәч, яртылаш самогон агызды. Алмашлап эчтеләр. Чират житкәч, Марат шикләнеп калды. Эчәргәме, юкмы? Элегрәк, рестораннарда коньяк белән шампан шәрабе чөмергәндә, ул мондый эчемлек

ягына борылып та карамас иде. Бик зәһәр нәрсә булырга охшый каһәр. Өстәвенә, инде эчмәгәненә дә күптән. Кукташка килгәч ул бер мәртәбә генә Нәфисәләрдә эчкән иде. Ул чакта Нәфисәнең: «Мулла абзаның күзенә чалынма», — дигән сүзләрен хәтерли әле. Анысында күзенә чалынмады да бит... Гел-гел майлы калҗа булмас. Болай салып кайткаласа Хафиз абыйсы сизми калмас. Аның гаиләсендә эчкән кешегә көн юк! Гомумән, Марат үзе дә ялганнары ачылудан куркып, үткәндәге күңел ачулы тормышын онытырга, яңача яши башларга дип үз-үзенә сүз биргән кеше бит әле. Ә монда ана әнә ничә күз төбәлгән. Эчкәнен көтәләр. Хамис закускага кыяр кыерчыгы тотып тора. Эчмәсәң дә начар, эчсәң дә әйбәт түгел.

Камил, аның икеләнеп торганын күреп:

— Син нәрсә, Таһир, хезмәттәшеннең олы шатлыгын уртаклашасың килмиме әллә? — диде.

— Хафиз абыйсыннан куркадыр әле. Теге көнне монда килгәч, карта уйнаганын күреп әнә нинди тавыш куптарды. Тагын шундый хәлдән шүрлидер, — дип Хамис та аның сүзләрен куәтләгәч, Марат стакандагы самогонны эчеп куйды. Зәһәр сыеклык тамагын көйдереп ашказанына юл алды. Бу арт ягына тиз утыртыр.

Бераз гәп куерткач, Хамис кабат стаканга үрелде. Кәефле Маратның уйлары да хәзер бөтенләй башка иде. Ә ник эчмәскә? Хафиз абый әйтә дип... Кем соң ул?.. Гомумән һәркемнең үзе теләгән нәрсәне эшләргә хакы бар.

Марат тост та әйтеп маташты хәтта:

— Бу тост русча әйбәт яңгырый... Татарчасы ничек килеп чыгар?.. Короче, хатыннарга ир кеше бераз йомшарып алу өчен кирәк, ә бала алар өчен шатлык. Шуна күрә, хатыннар үз гомерендә бер мәртәбә йомшаклык күрсәтә дә, аннан соң гомер буе шатланып яши. Сезгә дә балаларыгыз белән шатланып яшәргә язсын, — диде дә, артык кыстатып тормыйча гына, чираттагы өлешне авызына койды.

Әлеге бик үк урынлы булмаган тостны «шешәдәш»ләре артык күтәреп алмаса да, баш миен самогон җебетеп, акылы белән чынбарлыктан читләшә барган Марат анысына әллә ни игътибар итмәде. Шешәнең төбенә төшеп өйләренә таралышканда ир-егетләрнең барысы да шактый кәефле иде...

Марат өйгә кайта-кайта уйланды... Җитте, моннан соң үзем ничек телим, шулай яши башлыйм. Ни өчен Хафиз мулла сүзләре миңа закон булырга тиеш әле?! Мин иректә кеше! Мин дә бу дөньяның рәхәтлеген тату өчен туганмын. Монахлар гына бар рәхәтлекләрдән ваз кичеп яши. Ә мин?.. Мәчеткә намазга йөр, имеш. Китте ди, хәзер, тот капчыгыңны! Болай да бик яхшы әле... Исерткеч баш мие күзәнәкләренә тирәнрәк үтеп кергән саен аның хәзерге тормышка карата битарафлыгы арта гына барды. Ул инде үткән тормышындагы фаҗигаләрне дә, Хафиз мулла йортында кем урынында булуын да исәпкә алырлык дәрәҗәдә түгел иде.

Шунда аның югары очтагы таныш капкага күзе төште. Өй тәрәзәләреннән пәрдә аша тоныкына яктылык сирпелә. Нәфисә өйдә бугай. Күреп чыгарга кирәк. Югыйсә, кергәләп, өстәл аякларын тикшергәләп тор дигән иде түгелме?..

Марат, уздыдына елмаеп: «Тикшереп чыгыйк», — дип, ниндидер күңелле генә көйгә сызгыргалап капкага борылды.

Ул ишекне курыкмыйча, каерып ачып керде. Нәфисә, каядыр чыгарга җыенганмы, ишек янында ук басып тора иде. Марат, кирә-керешли аның биленнән кочып алды.

— Нәфисәкәй, җанкай, хәлләрең ничек? — дип сөйләнә-сөйләнә үзенә тартты. Шулчак ул әле беркөнне генә Нәфисә белән әүмәкләшкән агач

караватта бер ир затын күреп, кинәт туктап калды. Түр яктагы өстәл янында утыручы ике хатынны да шунда гына шәйләде ул.

Нәфисә аны бар көченә этеп җибәрде.

— Син нәрсә? Акылыңдамы? Аракы эчәләр дә нишләгәннәрен белмиләр...

Теге хатыннар да: «Бу ни бу?», «Нишләвегез бу?», «Әстәгъфирулла», — дип сөйләнеп алды. Ә караваттагы ир, берни дә эндәшмичә, сабыйларча күзләрен мөлдерәтеп, һаман Маратка карап ята. Маратның башыннан: «Нәфисәнең ире!»— дигән уй йөгереп узды. Теге көнне, ирең бармы дип сорарга оныткан иде шул. Ире бар, күрәсең... Тик нишләп соң ул берни дә эндәшми? Аның әнә шулай гаҗизләнеп карап ятуы Маратка бик авыр тәэсир итте. Ичмасам сикереп торып, нәрсә белән булса да китереп орса, алай ук авыр да булмас иде.

Марат:

— Гаф... Гафу, гафу, — дип сөйләнә-сөйләнә артка чигенде дә тиз генә чыгып шылды...

Өйдә аны дүрт күз белән көтәләр иде. Бүтән чакта эштән соңармагач, бер-бер хәл булгандыр дип кайгырганнар күрәсең. Тик Маратның үзен күрүгә, эшнең нәрсәдә булуын чамаладылар. Нурия апа почмак якка кереп табак-савытлар юган булып маташты. Хафиз мулла тамагын бер-ике мәртәбә кыргалады да түр өйгә кереп китте. Гөлназ, абыйсына куркынган кыяфәттә карап алды да, өстәлдәге китапларына иелде. Өйдә авыр тынлык урнашты. Марат белән беркем дә сөйләшергә теләми иде кебек. Ул өстәл почмагындагы урындыкта шактый утырды. Аннан, курткасын иңенә элде дә болдырга чыгып баскыч култыксасына таянып басты. Монда салкын. Тәненә суык үтә башласа да өйгә керәсе килмәде. Курткасын киеп, төймәләрен эләктерде дә бөтен гәүдәсе белән куырылып, бөрешеп калды.

Шулчак әкрен генә ишек ачылды. Сак кына атлап, кемдер чыкты да Маратка таба килә башлады. Җылы йомшак куллар Маратның иңбашына кагылды. Бу Нурия апа иде.

— Ник салкында торасың, наным? Тунгансың бит. Әйдә, өйгә керик. Болай ярамый. Юкса салкын тидерүең бар.

Ләкин Марат аның сүзләренә игътибар да итмәде кебек. Аннан кинәт кенә:

— Нәфисә кем ул? — дип сорап куйды.

Нурия аның янәшәсенә үк килеп басты.

— Кайсы Нәфисәне сорыйсың?

— Безнең урамда, аргы очта яшәүче Нәфисәне әйтәм.

— Ә-ә, Сәгыйть Нәфисәседер инде. Бүген шуның янында иденме әллә?

— Нишләп шулай сорыйсың?

— Тәк кенә. Янына ир-атлар кергәләп йөри дип ишеткәнем бар...

— Ялгыз булгангамы?..

Нурия бераз эндәшмичә торды. Аннан Маратның җилкәсенә кулын салды. Җылытырга теләгәндәй кочыбрак тотты.

— Ялгыз түгел ул. Аның ире бар. Сәгыйть! Электрик иде... Нәфисә — чибәр хатын, тик бәхете генә булмады. Өйләнешеп бер-ике ай яшәгәч, ире авариягә эләгеп умырткасын имгәтте. Хәзер ничә еллар инвалид... Аллам сакласын! Нәфисә шуннан бирле инвалид ирен тәрбияләп гомер итә. Балалары юк. Сәгыйть әле бер-ике атна больницада яткан иде. Бүген алып кайтканнар икән.

Әнә бит ничек... Димәк, Нәфисәнең ирен бүген больницадан алып кайтканнар...

– Юк, мин Нәфисәләрдә булмадым. Токарь Хамисның хатыны бәби тапкан. Малай. Шунын тәпиен юдык...

Нурия Маратнын җилкәсенә әкрен генә суккалап алды.

– Таһир, наныем. Яна туган баланын тәпиен юарга кирәк түгел. Ул болай да чиста. Кеше дөньяга килгәндә бөтен яктан да чиста була. Тәне дә, күнеле дә пакъ, әле язылмаган кәгазь бите шикелле ак. Менә шул тәпи юулардан башлана да инде пычраклык. Син ялгышкансың, наным...

Аннан урыныннан кузгалды. Маратны да, кулыннан тотып, үз артыннан әйдәкләде:

– Әйдә, керик. Никадәр тунганынны үзең дә сизмисең, югыйсә...

Марат аның артыннан иярде.

* * *

Авылда гайбәт тиз тарала. Бу көннәрдә чыш-пыш килеп тә, кайбер кыюракларның кычкырыбрак та, һаман бер нәрсәне — Нәфисәләр өендә булган хәлләр турында сөйләшкәнен Марат яхшы анлады. Ул моны кайчак урамда очраган кешеләрнең үзенә текәлебрәк үтүләреннән дә тойды. Өлкәннәрнең карашы битәрләгән кебек булса, яшь-җилкенчәк ничектер аның яныннан серле генә елмаеп уза, кыз-кыркын арттан нидер пышылдашып, чыркылдашып та кала.

Авыл урамында очраган кешеләрнең дә, хәл-әхвәл сорашкач, сүз сөрешләре һаман шул бер эзгә төшә. Колонкадан су алырга килгән хатыннар, чиләкләре инде күптән тулганын да онытып, әлеге «искитмәле вакыйга»ны чәйниләр. Мондый сүзләрнең таралуына теге көнне Нәфисәләр өендә утырган ике хатын-кызның өлеше зур булгандыр инде.

Марат ул гайбәтләрне еш ишетте. Баштарак аларны күнеленә авыр алмады. Харап булган икән, Нәфисәнең биленнән тоткан имеш. Гыйшык-мыйшык уйнаганда өсләренә килеп чыкмадылар ләбаса. Ул анысын да әллә ни зур җинаятькә исәпләми. Дөньяда булмый торган хәл түгел. Сөйләсәләр сон, сөйли бирсеннәр. Чәйнәп туйгач, бер туктарлар әле...

Маратның әхлак төшенчәсенә карашы бөтенләй икенче. Балачагында да, үсмер елларында да ул бернинди рухи чикләүләр тоймады. Аны әхлак кысаларына яраклаштырып тәрбияләүче дә булмады. Әнә шуңа ул гайбәтләрне, «чыш-пыш»ларны җиңел үткәрде. Мондый «вак-төякләргә» җиңел каравының тагын бер сәбәбе — үткән тормышындагы кара таплар. Алар янында монын ише күнелсезлекләр кояшлы янгыр кебек кенә. Авыл халкының бу вакыйганы зур фаҗигага әйләндергәнен генә һич башына сыйдыра алмый егет.

Ә беркөнне, урамнан көянтә-чиләкләрен асып, суга килүче Нәфисәне очраткач имәнеп китте. Дүрт-биш көн эчендә кеше шулкадәр дә үзгәрер икән! Өстендә бөгәрләнеп беткән иске пәлтә, яулыгын җайсыз бәйләгән, кыяфәте — авырудан янарак кына терелеп килүче кешене хәтерләтә. Талчыгып сулыккан йөзендә күзләре тагын да зураеп калган кебек.

Ул Маратка күтәрелеп тә карамады. Аны күрмичә, читләтеп үтеп тә киткән булыр иде, тик егет аның каршысына килеп басты. Бу гамәле авыл кешесе күзлегеннән караганда ничек булгандыр, анысын уйлап өлгермәде. Гомумән, бернинди начарлык та юк иде аның уенда. Шушы мизгелдә бу хатынга ниндидер юату сүзләре генә әйтәсе килгән иде анын.

– Нәфисә...

Шулай диде дә төртелеп калды. Чөнки ул бу очрашуга да, сөйләшүгә дә әзер түгел иде. Нәрсә әйтергә, мескен хатынны ничек юатырга? Бу турыда үзе дә тәгаен генә белми.

Нәфисә, яна гына күреп алган кебек, егеткә күз сирпеде. Нидер әйтмәкче

булып, авызын ачты да кинәт тынып калды, башын түбән иде. Ул шул халәтендә шактый басып торды. Кем белә, Маратның башлап әйткәнен көткәндер бәлки. Аннан, кинәт кенә башын күтәрде дә:

– Бу дөньяның бөтен каргышы төшкәндер инде... Бөтенесе мина кырын карый... Гөнаһыларым күптер анысы. Тик кем гөнаһысыз соң? Минем дә кечкенә генә булса да бәхеткә хакым бардыр бит. Моңа кадәр сер бирмәдем, күнелем белән әрнеп сыкрасам да беркемгә «аһ» дип тә әйтмәдем. Эчтән еласам да тыштан күрсәтмәдем, яшь аралаш булса да елмаерга тырыштым... Инде бүтән түзәрлегем калмады...

Хатынның битеннән яшь тамчысы тәгәрәде. Ул тавышсыз гына елый иде. Шуны күрсәтмәскә тырышып булса кирәк, карашын кабат читкә юнәлтте. Аның иңбашлары калтыранып-калтыранып куя. Шактый шулай эндәшмичә торганнан соң, Нәфисә, җиңе белән битен сөрткәләде дә китеп барды. Кем белә, бәлки ул Мараттан юату сүзләре көткәндер? Әмма егет тавыш-тынсыз гына карап торудан ары узмады. Чибәр, әле дөнья рәхәтенә куанып кына яшәрлек бу хатын ни өчен шундый газаплар кичерергә тиеш соң? Аны шундый күнелсезлекләргә дучар иткәне өчен Маратның бераз гына булса да гаебе бармы?

Маратның газаплану халәте озакка бармады. Гомумән, ул холкы белән озаклап, авыр кичерешләргә бирелә торган кеше түгел. Кул селтәп кенә куйды да онытты...

Маратны кичен өйдә тагын бер зур сөйләшү көткән икән.

Кичке ашны ашап табыннан кузгалырга җыенганда Хафиз тамагын кыргалады да вәгазь-нәсихәтен башлады:

– Дөньяда һәр начарлык, азгынлык әхлаксызлыктан һәм динсезлектән килә. Рухы нык булган кеше генә шайтан коткысына бирелмәс. Ә синең соңгы вакытта кылган гамәлләрең, энем, нык булуыңа шик тудыра. Инде хәзер, иманым камил, бала чагында тиешле тәрбия алмагансың. Калебең нык түгел. Чак буынлы булып үскәнсең...

Марат берни дә әйтмичә, буйсынучан гына тыңлап утырса да, барыбер Хафизның соңгы фикере белән килешмәде. Чак буынлы булып үскәнсең, имеш... Юк, ул үзен беркайчан да көчсезләр рәтенә кертмәде! Әле бала чагында ук, малайлар белән сугышырга туры килгәләгәндә күп вакытта җиңә торган иде. Аннан соң армия, Чечня вакыйгаларын башыннан кичерде. «Боевик»лар белән бәрелешләрдә җебеп калмаска, кыю булырга өйрәнде. Армиядән соңгы еллары да тыныч кына бармады. Йомшак буынлы булса андый хәлләргә түзәр иде микән?

Хафиз абыйсы, әйтерсең аның уйларын белгәндәй, сөйләвен дәвам итте:

– Монда сүз беләк үстереп, сугыш чукмары булып йөрү турында бармый. Начарлыкка өйрәтеп торасы юк, бар да булдыра. Үзеннән көчлерәкләргә тап булып, әҗерен алганчы, барчасы көче белән масаерга ярата. Ә рухи тазалык бөтенләй икенче. Калебең нык булса, ихтыяр көче дә була. Хәзерге яшьләрнең күбесе азгынлыкка каршы үзләрендә, юк, мин моны болай эшләмим, дип әйтерлек көч таба алмый. Син дә, энем, әнә шундыйлар сыңары. Шайтан кызыктырыр ул, матур әйберләр белән дә, исерткеч эчемлек белән дә, матур кызлар белән дә... Әнә шул чакта үзеңдә, юк ярамый, дип әйтә алырлык көч таба белергә кирәк, энем. Шул көчне таба алмыйсың икән, син йомшак буынлы дигән сүз...

Хафиз мулла тагын тамагын кыргалады. Өстәл артында утыручыларга күз йөртеп чыкты. Аны барысы да баш иеп, игътибар белән тыңлыйлар иде.

– Энем, син берәр көнне мәчеткә кил әле. Андагы инсафлыларны күрерсең. Шуннан бәлкем җомга намазына үзең йөри башларсың. Мәчет ул

— Аллаһ йорты. Анда калебне чистарту өчен йөриләр. Көн саен юынгычта бит-кулыңны, атнага бер мәртәбә мунчада тәнеңне юасың бит. Рухыңны да шул рәвешле көн саен пакьләндерергә кирәк. Мәчет ул — жанны пакьләү урыны...

...Әлеге сөйләшүдән берәр атна үттеме-юкмы, Марат жомга көнне тәвәккәлләп, мәчеткә керде. Идәндә намазлыкка тезләрен бөкләп утырган картларның кайберләре ишек ачылган тавышка башларын күтәреп карады, икенчеләре исә игътибар да итмичә, Хафиз мулланың вәгазен тыңлауларында булды. Ишек тавышына мулла үзе дә сөйләвеннән туктап торды кебек. Юк, аның йөзендә аптырау яисә гажәпләнү галәмәте күренмәде. Маратның монда керүен ул бик табигый дип исәпләде бугай, карашын кабат үзен йотлыгып тыңлап утыручы мөэмин-мөселманнарга юнәлтте дә салмак кына сөйләвен дәвам итте:

— ...Үз гаебен хәтерендә тотмаган кеше генә, башкаларның гаебен үзенекеннән күбрәк, дип уйлый. Безнең кайсыбыз гөнаһсыз соң? Хәрам эшләр кылмаган кеше генә туры юлда...

Маратка, тегендә барып тезлән, монда килеп утыр, дип урын тәкъдим итүче булмады. Әйтерсең, ул монда көн саен кереп ияләнгән үз кеше. Идәндә утыручыларны бер кат күздән кичергәч, барысының да намазлык жәймәсенә утырганлыгын сизеп алды. Ә аның намазлыгы юк. Ярар микән, ярамас микән, дигәндәй, бераз аптырап торды да идәнгә тезләнде. Аннан соң мәчеттәгеләрне тагын бер мәртәбә күздән кичерде. Ләкин аңа игътибар итүче юк иде. Хәтта Хафиз мулла да исе китмәгәндәй вәгазь сөйләвендә булды:

— ...Белегез ки, фани дөньяда яшәү вакыты бик кыскадыр. Аңа таяну — алдану булыр; Андагы шатлык — мәрхәмәтле булудыр. Аллаһыдан һәр хәлендә дә курык, һичбер эшеңдә дә Аңа буйсынудан чыкма!..

Марат тагын, күңеле белән үткән гомеренә әйләнеп кайтты. Аның әлегә кадәр бу хакта ныклап уйлаганы юк иде. Яшәлгәне аз да түгел, күп тә түгел. Ул, әнә шул кыска гына гомерендә яманлыктан башка кемгә, нинди яхшылык китерде соң? Әнисе, мескен, улым кеше булсын дип алны-ялны белмичә эшләде дә эшләде... Хатыны Люба белән дә әнә ничек килеп чыкты — яшәделәр дә, яшәмәделәр дә кебек. Порхның күкрәгенә пистолет терәгәндә дә кулы калтырамады. Инде килеп, Таһирны?.. Аны Марат үтермәде дә бит... Тик кем ышаныр?.. Ә Артем үзе гаепле... Өлгермәгән булса, Марат үзе үлгән булыр иде... Алар инде күптән жир куенында. Марат исән менә. Әле алай гынамы?.. Кемнеңдер исеме астында... Башкаларны алдалап... Хафиз мулланы да, сабый баладай самими Гөлназны да алдады... Башкаларны алдарга була, ә менә үзеңне?! Үзеңнән беркая да качып котылып булмый... Кызганыч... Бар да... Нәфисә дә, әнисе дә...

Марат шунда күңеле тулганны тойды. Аның соңгы елларда елаганы юк иде. Гомумән, елауны йомшаклык билгесе дип кабул итә иде ул. Ә хәзер, әнә, әйтерсең күзеннән яшьләр ташырга тора. Ни булды, нишләп алай, Марат моны аңламый. Ул кинәт кенә сулкылдап куйды. Тирә-яктагылар ишетте микән? Ишеткәннәрдер... Менә аның күзеннән сытылып чыккан бер яшь бөртеге бите буйлап тәгәрәде дә идәнгә тамды...

Марат монда утырырлык хәлдә түгел иде. Ул кинәт кенә урыныннан купты һәм ишеккә томырылды... Сәждәгә оеп барган картлар әлеге хәлне сизми калды.

Урамга чыккач, егет үз-үзен белештермичә йөгерде дә йөгерде. Бары тик авыл башына чыга торган юл чатындагы карт өянкегә житкәч кенә кинәт тукталды. Шуның төбенә чүгәләп утырды. Ул инде бертуктаусыз аккан күз яшьләрен туктатырлык хәлдә түгел иде...

* * *

Максатлары бер булган кешеләр тиз дуслаша, диләр. Чыннан да шулайдыр. Соңгы вакытта Марат белән Рафат та якынайдылар. Алай зурдан кубып, максатлары бер дип әйтерлек әллә нинди гамәлләр кылмасалар да, соңгы көннәрдә күп эшләре уртак булды.

Баштарак алар мәчеткә килгән көннәрдә генә очраштыргалыйлар иде. Марат намазга көн саен йөрмәсә дә, әллә нигә бер баргалый. Рафат исә намазларны калдырмаска тырыша. Дөрес, ул да эш кешесе, төрле вакыты була. Гел теләсә дә мөмкинлек чыкмаган чаклары бар.

Рафат гәүдәгә бераз гына тәбәнәгрәк булса да яшькә Мараттан өлкәнрәк. Армиядә булган, акыл утырткан диләр андыйлар турында. Ул электромонтер булып эшли. Эшсезлектән вакытын ничек үткәрергә белмәгән чаклары да бар, ә кайвакыт кылны кырыкка ярырдай булып йөгерергә туры килә үзенә. Җил-давыллар вакытында электр чыбыклары өзелеп, авыл утсыз калганда, көнне төнгә ялгап эшли. Дөрес, алары бик сирәк була...

Соңгы вакыйгалар Марат белән Рафат дуслыгын тагын да ныгытты. Якын көннәрдә авылда яна мәчет ачарга тиешләр иде. Тик менә анда төгәлләнеп җитмәгән эшләр бар. Гыйбадәт йортының эчен бизәүче кирәк.

Рафат рәссам икән, ул бу эштә ярдәм итәргә теләк белдерде. Тик үзем генә вакытында өлгертә алмыйм, ярдәмгә тагын бер кеше кирәк булыр дигәч, кайсыдыр, ник, әнә Таһир менә дигән рәссам бит дип әйтеп куйды. Калганнар да аның сүзен хуплады.

Каршы килеп булмый. Марат, әйдә, нәрсә булса шул дип ризалашты. Алай да, минем инде күптән кулыма пумала тотып караганым юк дип әйтеп карады.

Рафатның, чыннан да кулыннан килә икән, рәсемнәре яхшы чыга. Бизәкләр, шамаилләр ясауны ул үз өстенә алды. Ә стена буяу кебек эшләрне Маратка йөкләде. Егет мона сөенде генә. Шулай булмый соң, кая инде ул аңа бизәкләр төшерү, шамаилләр ясау! Әле стеналарын тигез, шома итеп буяп чыга алса...

Әнә шулай итеп, эшкә тотындылар. Авыл җитәкчелеге бизәү эшләре беткәнче дип Маратны машина-трактор паркыннан мәчеткә күчерде. Рафат та буш вакыты булган саен шунда ята. Дөрес, ашыгыч эшләре чыгып каядыр киткәндә, карандаш белән сызылган урыннарны буяп бетерү Маратка кала иде. Ул, шулай итеп, азмы-күпме бизәкләр төшерергә дә өйрәнә башлады. Тырышсаң алай авыр да түгел икән.

Марат, бер мәлне ял итеп утырганда, Рафатның ничек итеп намазга йөри башлавы хакында кызыксынды. Тегесе, бераз икеләнеп утыргач сөйләп бирде...

– Армиядән кайтып, колхозда эшли башлаган вакыт иде. Габбас абый белән икәү эшлибез. Ул елны авылдан ике-өч чакрым ераклыкта тузган линияләрне алмаштыра башладылар. Эш күп. Безне көн саен иртән колхозның «техпомощь» машинасы эш урынына илтеп куя, кичен каршы ала. Комбайнчыларга ашарга йөртә, әбәт вакытында безнең янга да сугылып, ашатып чыга... Көннәрдән бер көнне нindидер саташулы төшләр күреп уяндым. Нindидер күңелсезлек буласын сизгәндәй аяклар эшкә тартмый. Әйтерсең, күңелнең кайсыдыр почмагында эшкә барма, барма, дип әйтеп торалар. Шунда, үземнең эшкә бара алмавыма төшендем. Авырый ул, дип әйтергә энемне йөгерттем...

Ә бер-ике сәгать узгач, Рафатларга аянычлы хәбәр китергәннәр. Эшчеләрне илтүче машина текә үрдән төшкән вакытта, тормозы тотмыйча, таудан аска тәгәрәгән. Шофер һәм Габбас абый шунда ук үлгән. Калган өч кеше авыр яраланган...

– Минем беркайчан да эштән калганым булмады. Ә ул көнне... Хәзер инде үзем дә аңлатып бирә алмыйм... Әйтерсең, кемдер мине шул фаҗигадән саклап калу өчен тырышты. Миңа элегрәк тә андый хәлләр турында ишетергә туры килгәләде. Саклаучы фәрештә кешегә шундый фаҗигаләрне алдан белгертергә тырыша дип сөйләгәннәре бар иде. Үзем белән шундый хәл булгач озак уйландым. Моның тикмәгә генә түгел, нindидер хикмәте барлыгын күңелем белән тоя башладым. Бабам мәрхүм әйткәндәй, күңеле изгелектә булганнарны Алла саклый икән ул...

Шул хәлләрдән соң Рафат тартуын да ташлый, эчми дә. Сәламәт яшәү рәвешенә күчә. Кешеләрне рәнҗетергә тырышмый. Әнә шулай итеп әкренләп ел арты ел уза. Хәзер инде дин тотуны тыймыйлар да...

Мәчетне ачу тантанасына авылның яше-карты — барысы да җыелган иде. Шулай ук, төзелешкә ярдәм күрсәтүчеләр, мәчетне салуга булышкан район төзелеш оешмасы вәкилләре дә чакырылган. Авыл җитәкчеләре белән беррәттән, республика башкаласыннан килгән дин әһеле дә басып тора.

Кешеләр төркеменә кушылып арырак баскан Марат мәчет янына көйләп куелган микрофон алдында торучы җитәкчеләрне һәм кунакларны күздән кичерде. Алар арасындагыларның берсе егеткә таныш кебек тоелды. Халык күп булып, арттарак торгач, ул кешегә башта игътибар да ителмәгән. Бу район төзелеш тресты начальнигы Наил Хәкимович иде. Марат шунда ук төркем артына елышты. Наил Хәкимович аны күрмәде, әлбәттә.

Тантана башлангач беренче булып Казаннан килгән кешеләргә сүз бирелде. Аннан соң микрофон түбәнгәрәк күчә барды, Наил Хәкимович та үз чиратында авыл халкын, дин тотучыларны әлеге зур вакыйга белән котлады.

– Авылларыбыз яңара, матурлана. Шуның белән бергә күңелләребезгә дә иман нуры иңә. Кешеләр дингә, Аллага тартыла. Бүгенге мәчет ачу тантанасы моңа ачык мисал. Күп еллар буе совет идеологиясе аңнарын томалаган милләттәшләребезнең, дин кардәшләребезнең күзләре ачыла башлады...

Марат аптырап калды, карале, Наил Хәкимович болай да сөйләшә белә икән! Шул «аңнарны томалаган совет идеологиясе» вакытында канат ныгытып, җитәкчелеккә үрмәләгәнлеген оныткан мы? Әллә юри генә күзгә төтен җибәрә микән? Кайчандыр партия әгъзасы булып башкачарак сайраган мондыйлар җил кайсы яктан иссә, шул якка авыша. Заманга тиз яраклашалар...

Хафиз мулла да чыгыш ясады.

– ...Газиз дин кардәшләрем, мөхтәрәм авылдашлар! Бу күркәм мәчетебезне төзүгә күпләрегезнең көче керде. Ана аз гына өлеше тимәгән авылдашыбыз калмагандыр да шәт...

Шунда, гөнаһ шомлыгына каршы, гел уйламаганда, Хафиз мулла Рафат белән Таһирның исемен дә телгә алды. Югыйсә, авылдашларыбызның барысының да өлеше керде, дигән иде. Башка берәрсенең исемен атаса соң... Дөрес, ул моны начар нияте белән эшләмәде кебек. Яшьләрнең күңелен бераз үсендерәсе килгәндер инде...

– Дин сукмагына яңарак кына килеп кергән яшь кешеләр, Рафат белән Таһир, әле менә соңгы көннәрдә генә, үз теләкләре белән мәчетнең эчен бизәп чыгарга алынганнар иде. Өлгерербезме, юкмы дип икеләнеп торсалар да, вакыт белән хисаплашмыйча, алны-ялны белмичә тырышкач бу эшне вакытында тәмамладылар. Алланың рәхмәте яусын аларга!..

Исемнәре чыккач, төркем алар ягына борылып карады. Рафат алгарак чыгып башын игәндәй итте. Марат, киресенчә, башындагы түбәтәен батырыбрак киде дә кешеләр артына елыша төште. Шунда аны Наил

Хәкимович та күреп алды. Хәтта берничә мизгелгә карашлары да очрашты кебек. Күрүен күрде, таныды микән? Юктыр, аралары ерак, таный алмагандыр дип, Марат үз-үзен тынычландырырга тырышты. Хафиз мулла, егетнең бу халәтен тартыну дип аңлап булса кирәк, сүзне озынга сузмады, мәчет ачуның саваплары турында кыска гына вәгазь укыды.

Кунаклар таралышкач, авыл кешеләренең мәчеткә сыйганы — мәчеттә, сыймаганы тышта намаз укыдылар.

* * *

Күкташтан мәдрәсә ачу тантанасыннан кайтып, бер-ике көн узгач, Наил Хәкимович Марат каберен зиярәт кылырга ниятләде. Маратны җирләп өч-дүрт ай узгач, ул Зәйтүнәнең өенә кереп чыккан иде. Болай, хәл белергә генә. Күмделәр дә оныттылар дигәндер югыйсә. Һәм шул көннән соң Маратның өендә бер мәртәбә дә булганы юк.

Зәйтүнә, кайгырса да, эчтән генә яна-көя. Наил Хәкимовичның хәл-әхвәл сорашуына да: «Аллага шөкер», — дип кенә җавап биреп утырды. Күренеп тора, улы үлү кайгысыннан бик бетерешкән. Шулай да нык булырга тырыша.

Шунда, сүз иярә сүз чыгып:

— Кабер ташы урынында һаман күмгәндәге такта башы гына тырпаеп тора. Ручка белән язылган хәрефләре дә унып беткән. Кабер ташы ясатып куярмын дигән идем. Бик кыйммәт икән. Аннан соң, артыннан йөрүчесе дә юк. Үземнең көчемнән килми, — дип куйды ана кеше.

Наил Хәкимович бу хакта уйлап житкермәгән икән шул... Тормыш мәшәкатьләре белән барысын да истә тотып буламыни?! Марат исән вакытта эшләгән мастерскойда Вася Кулагинның моңа беркайчан да кулы бармаячак. Соңгы вакытларда Маратның исемен телгә аласы да, аның турында ишетәсе дә килми бугай...

Локаль сугыш ветераннары оешмасы да проблеманы хәл итүдә читтә калырга тиеш түгел кебек. Марат бит — кайчандыр «кайнар нокта»да хезмәт иткән кеше. Оешманың рәисе буларак, Наил Хәкимовичка бу турыдан-туры кагыла. Андый эшләрне әлек тә башкарганнары бар, югыйсә.

Әнә шуларны уйлагач, «әфганлылар» белән дә киңәшкәч, Наил Хәкимович Марат каберенә таш куюны үз өстенә алды. Ә соңыннан, таш ясатуны бөтенләе белән үзе финанслап, үз исеменнән башкарырга кереште.

Кабер ташын яз урталарында коеп китерделәр. Аны урнаштыру көне дә билгеләнде. Тик, ни кызганыч, нәкъ шул чакта Наил Хәкимовичка бер-ике атнага командировкага китәргә туры килде. Чарада ул катнаша алмады. Ләкин ана карап кабергә таш кую вакытын кичектереп тормадылар. Бу эшне «әфганлылар» үзләре башкарып чыкты. Ә Наил Хәкимович командировкадан кайткач та зиратка тиз генә килә алмады. Калган эшкә кар ява дигәндәй, көн артыннан көн узды. Вакыты булмады. Дөрес, вакыт булмау сәбәп кенә анысы. Ә менә Күкташта яңа мәчет ачу тантанасында нәкъ Маратка охшаган егет күзенә чалынгач, кабергә барып килергә кирәк, дигән уй күңелендә кабат яңарды. Беркөнне базардан канәфер чәчәкләре алды да зиратка китте...

Кабер янында озак торырга уйламаган иде. Чәчәкләрен ташка куеп бер минутлап тын торгач, кесәсеннән кульяулыгын чыгарып, кабер ташындагы «Марат Салих улы Закиров» дигән язуга кунган тузаннарны сөрткәләде. Аннан, кульяулыгын кая куярга белмичә як-ягына карангалады. Аны янәшәдәге кабер янында чәчәкләрдән бушаган банкага салды да аягы белән этеп, чардуган баганасы төбенәрәк шуыштырды. Шулчак ерак та түгел, бер рәт аша гына, кабер янындагы егетләргә күзе төште. Ул аларны монда

кергәндә ничектер шәйләми калган. Югыйсә, шактыйдан кебек. Кулларында стакан. Араларыннан берсе сөйләгәч стаканнарын күтәреп куялар. Закуска кабалар. Наил Хәкимович егетләрнен берсен — Вася Кулагинны танып алды. Әйе, бу чыннан да ул иде. Вася да ничектер бу тарафка борылды. Ул да Наил Хәкимовичны таныды, күрәсең, аның ягына ишарәләп, янәшәсендәгеләргә нидер әйтте. Тегеләр, сөйләшүләреннән туктап, башларын бордылар. Ләкин күзгә-күз карашып тору озакка сузылмады. Егетләр кабат әңгәмәгә кереште. Вася гына төркемнән аерылып Наил ягына атлады. Таныш кеше белән исәнләшмичә китү яхшы булмас дип уйлагандыр инде.

Аның йөзе караңгы иде. Кул бирешкәч, бер-ике авыз сүз алыштылар. Алары да ничектер төртмәле килеп чыкты.

— Чыбык очы туганны онытмыйсыз, ә, Наил Хәкимович, — дип, кинаяле генә сүз башлады Вася.

— Әйе, үлгәннәрне онытырга ярамый. Үзегез дә бирегә еш киләсез бугай, — диде Наил, теге кабер янында басып торучы егетләргә ишарәләп.

— Еш, дип... Килгәлибез инде... менә Косой... то есть Расих исемле дус егетебезнен каберенә таш куйган идек... Туганнары юк аның... Яхшы егет иде мәрхүм...

Наил Хәкимович кара мәрмәр ташлы кабер ягына кабат карап алды.

— Ичмасам, үлгәч булса да дусларны онытмавыгыз яхшы, анысы.

Бу сүзләрнен үз бакчасына таш ату икәнлеген Вася бик яхшы аңлады. Нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде, кире уйлап туктап калды. Аннан, борылып китәргә җыенганда гына сорап куйды.

— Маратка кабер ташын сез куйдыргансыз дип ишеттек?!

— Әйе, соң булса да... Ташын мин заказ биреп ясаттым. Куйганда гына була алмадым. Командировкада идем. Дөресен генә әйткәндә, без — гөнаһлы бәндәләрен Алла кичерсен. Якыннарыбызны зиярәт кылырга бик сирәк киләбез. Югыйсә, кайчан да булса үзебез дә шушында барасы...

Наил Хәкимович, әй, нәрсәсен сөйләп торасы инде аның, дигәндәй, кулын селтәде. Аннан соң, аклангандай:

— Әле бүген дә һич уйламаганда гына килеп чыктым. Беркөнне Күкташ авылына мәчет ачу тантанасына барган идем. Ул мәчетне безнен трест эшчеләре житкерде. Шунда авыл кешеләре җыелып намаз укыдылар. Араларында нәкъ Маратка охшаган бер егет күземә чалынды. Менә шунда Марат каберенә барганым юклыгы исемә төште ...

Инде, китәргә дип, яртылаш борылган Васяга шунда әллә нәрсә булды. Ул кабат Наил Хәкимовичка текәлде. Хәтта йөзе дә яктырып киткәндәй булды. Бит мускуллары уйнап алды.

— Нәрсә?.. Маратка охшаган дисезме?

— Әйе! Кеше бер-берсенә шулкадәр охшар икән! Үзем дә шаккаттым...

— Кайсы авылда дисез?..

— Күкташта! Моннан 80 километр ераклыктагы авыл ул.

Вася, нәрсәдер исенә төшерергә теләгәндәй:

— Күкташ, Күкташ, — дип кабатлады. — Сез янына барып сөйләшмәдегезме соң?

— Юк, ул минем күземә генә чалынды. Сөйләшүдән ни мәгънә соң, ул барыбер Марат түгел бит.

Кулагин, ашык-пошык кына саубуллашты да җитез хәрәкәтләр белән егетләр торган тарафка атлады. Артыннан: «Күкташ, Күкташ», — дип берничә мәртәбә әйткәне генә ишетелде. Күкташта күзенә чалынган егет турында ишеткәч Васяның үз-үзен тотышы үзгәрүенә Наил Хәкимович сәерсенеп куйды: нәрсәсенә гаҗәпләнә? Бер-берсенә охшаган кешеләр күп бит ул дөньяда...

* * *

Соңгы вакытларда Зәйтүнәнең бер дә кәефе юк. Хәер, кәефе генә дип әйтү дөрес тә түгелдер. Анын сәламәтлеге дә нык какшады. Баштарак кан басымы белән интекте, аннан йөрәге чыгымчылый башлады. Ул күкрәгенең сул ягында әледән-әле кискен авырту тойгалады. Инфаркт булмагае дип шикләнсә дә врачка күренмәде, тел астына валидол кабып куйды да шунын белән тынычланды. Сырхавының өелеп килгән кайгы-хәсрәттән башлануын ул яхшы аңлый иде. Улы Марат хәсрәтеннән шулай бетереште Зәйтүнә. Кайчак, онытылыр әле дип, өй тирәсендә вак-төяк эшләр башкарган була да бит. Тик аларның барыбер файдасы юк: әз генә бушап торса да, улынын буй-сыны, йөзе күз алдына килә дә баса.

Бичара ана, нишләп әрәм булды соң әле бу дип баш вата. Югыйсә, шул бердәнбер улын аякка бастыру, аны сау-сәламәт үстерү өчен аз тырышмады бит. Нәрсә житмәде аңа? Бу фажига һич кенә дә башына сыймый... Кат-кат шуларны уйлый-уйлый, тиздән бөтенләй чирлегә сабышты. Күрше-күлән, очратканда, хәленең яман икәнлеген күреп, ник шулкадәр өзгәләнәсең, үлгән артыннан үлеп булмый. Тынычлан. Инде үзең турында уйларга вакыт дип юатырга тырышсалар да, ул башкача булдыра алмый иде. Бер кечкенә генә йөрәк шундый газапларга ничек түзсен?! Әнә шулай итеп бөтенләй урын өстенә егылды. Ирексездән, больницага барырга кирәк булды. Салдылар. Ләкин Зәйтүнә, бу хәлләрдән соң алга таба яшәүне күз алдына да китерә алмый иде инде. Аның өчен, әйтерсең, киләчәк бөтенләй беткән. Ул хәзер бары тик үткәннәр белән, узгандагы ачы сагышлары белән генә яши. Медсестралар кереп, тынычландыргыч уколлар ясап киткәч Зәйтүнә газаплы уйларыннан бераз арынып, ял итеп ала, онытылып тора. Ләкин уянуга, кабат күз алдына улы килеп баса да барысы янә кабатлана. Ана күңеле бәргәләнә-йолкына башлый. Шулай итеп, көн артыннан көн үтә. Ә аның сәламәтлеге яхшыруга түгел, киресенчә начараюга таба бара. Бичара хатын, бер ай дигәндә, коры сөяккә калды.

Жинаятьче анасы белән кемнең аралашасы килсен соң? Тик ана өчен баласы кем булса да, барыбер бала булып кала икән...

Һәр нәрсәнең ахыры була дигәндәй, кояшлы бер көнне, больница палатасындагы караватында түшәмгә карап, үзенең бетмәс-төкәнмәс уйларына бирелеп ятканда, Зәйтүнә, капылт кына күкрәген тотты да сагышлы күзләрен мәңгегә йомды... Әнә шулай итеп, соңгы вакытта тынгы бирмәгән газаплы уйларыннан ул бөтенләйгә котылды...

Аны бакыйлыкка юлга озатырга килүчеләр бармак белән генә санарлык иде. Йоласына туры китереп жирләгәндәй иттеләр. Ләкин югалту хәсрәтеннән илереп елаучы да, сыктап күз яше күрсәтүче дә, каберенә, исем-фамилиясе кулдан гына язылган кечерәк тактадан башка, чәчәк-фәлән куючы да булмады. Күмеп, чирек сәгать үтте микән, яна кабер тирәсе бушап та калды. Бар да гадәти, әйтерсең каберге кеше гәүдәсе түгел, ә утын түмәре генә күмгәннәр. Кеше гомере әнә шулай жир өстендә бер кутәренке урын белән чикләнде. Яшәвенең бөтен мәгънәсе бары шул гына булды...

* * *

Женя, гадәттәгечә, кичен сөяркәсе Галя белән ресторанда шампан шәрабе йоткалап, тегесен-монысын сөйләшеп, юк-барны искә төшереп, көлешеп утырганда, сулышына ут кабып, Вася Кулагин килеп керде. Ул Женяның кичләрен шушы ресторанда күңел ачып, акча туздырып утырырга яратуын белә иде. Егет бик дулкынланган. Галя ягына хәтта борылып та карамады.

Хәер, корешы янында нинди чәчбикә утырса да аңа барыбер иде. Ул Женя белән генә исәнләште:

– Сиңа ашыгыч сүзем бар. Бу нәмәстәнне өенә илтеп куй да, кабат кил, — диде. Үзе, сорамыйча-нитмичә, өстәлдә торган бокалның берсен алып, шәраб йотты.

Ә тегесенең сөяркәсе белән тиз генә аерылышасы килми, шуңа күрә Женя дустының тәкъдимен бик үк ошатып бетермәде.

– Шулкадәр ашыгыч нинди сүз соң ул? Бәлки, иртәгәгә калдырырбыз? Ут капмагандыр бит?! — диде.

Аның шулай карышып маташуын Вася, әлбәттә, ошатмады.

– Иртәгә калдырырга ярамый, аңлыйсыңмы? Бүген үк кирәк!..

Васяның уена берәр нәрсә керсә, аны башкармыйча туктамаганын белә Женя. Сукранып кына урыныннан торды.

– Жень, айда посидим еще, — дип назланып маташкан Галяны култыклап чыгу ягына атлады.

Аларның китәргә кузгалганнарын күреп, официант артларыннан бара башлаган иде, Вася аны тиз туктатты.

– Борчылма! Барысы өчен дә үзем түлим!

Егерме минут уздымы икән, Женя кабат ресторанга кереп, Вася каршысына утырды.

– Йә, сөйлә, иртәгә кадәр дә кичектереп торырга ярамаган нинди сүз ул синен?

Тегесе берара каш астыннан гына Женяга карап торды. Аннан өстәл өстендәге бокалда яртылаш калган шәрабне эчеп куйды. Шуннан соң гына әллә кайдан әйләндереп сөйли башлады.

– Хәтерлисенме, Марканы күмгәч без шушы ресторан янындагы скамейкада сөйләшеп утырган идек?

Женя кашларын сикерткәләде:

– Бер тапкыр гәпләшеп утырганны хәтерлим. Ә менә ни турында сөйләшүебез бөтенләй исемнән чыккан.

– Марат турында, аның үлеме турында сөйләштек ...

Женя, шактый вакыт исенә төшерә алмыйча утыргач:

– Ә-ә, син ул чакта күмелгән кешенең Марат булуына шикләнеп, мине гаҗәпкә калдырган идең... Әйе, хәтерлим... Марканың корсагында ярадан калган җөе, күкрәгендә «Орлы гнездятся на скале» дигән татуировкасы... һәм, имеш, Марат урынына икенче кешене күмгәннәр... Ха-ха, — дип, шаркылдап көлә башлаган иде, Кулак җете караш белән туктатты. Хәтта йодрыгы белән өстәлгә дә сугып алды кебек.

– Ә бит ул чакта мин хаклы булганмын...

Женяның ачыла башлаган авызы кинәт элекке хәленә кайтты. Гаҗәпләнүдән күзләре түгәрәкләнде:

– То есть... Ничек инде?.. Маратның мәете Маратныкы булмау хак сүз димәкчеме син?

– Әйе, мин чын Маратны таптым... Юк, юк, әлегә тапмадым, ләкин табылу алдында.

– Ничек?.. Чынлапмы?

– Ха! Орлы гнездятся на скале, имеш! Ә ул, адәм актыгы, бернинди кыяда да түгел, ә Күкташ авылында оялап ята икән.

– Күкташта?! Үзен күрденме?..

Васяның Наил Хәкимович белән очрашу хакында бөтен нечкәлекләренә кадәр сөйләп торасы килмәде. Ул эре генә кыланып:

– Әлегә күрмәдем. Ышанычлы кешеләрдән генә ишеттем, — дип, туры җавабтан котылды.

– Чыннан да үзенә бик нык охшаган берәүне бауга элеп, Күкташта аның исеме белән яшәп ята дип уйлыйсынмы? Ышанасы килми...

– Ята икән шул менә! Ул адәм актыгы Аллага да ышана башлаган имеш. Мәчеттә намаз укып йөри ди...

Женя тагын бер мәртәбә көлеп җибәрде.

– Ха, Марка мөселман булган! Ул нәрсә, элекке гөнаһларын шулай юмакчы буламы әллә? Юк, син әйткән бу хәлләргә барыбер ышанасым килми. Бигрәк фантастикага охшаган. Тормышта андый нәрсә була алмый, минемчә. Син үзен шуна ышанасынмы?

Васяның ышанычы зур иде. Ул Женяның соңгы сүзләрен ризасыз кыяфәттә генә тыңлады да үз фикерен белдерергә ашыкты:

– Әкият сөйләп утырырга мин бала-чага түгел лә. Марканың исән булуына туксан тугыз процентка ышанам. Эзенә генә төшим эт җанның, намаз түгел, иманын укытам мин ана...

Вася, официантны чакырып, тагын бер шешә шампан китерергә кушты. Женя сигаретын кабызып тирән итеп суыргач:

– Ялантау янында күрсәткән тамашасы өчен, мин үзем дә кабыргаларын санауга каршы түгел дә...

Кулагин ярсып аның сүзен бүлдерде:

– Кабыргаларын гына санау бик аз ул гниданың. Дөмектерергә кирәк аны...

– Женя, ничек булса да, безгә Марканы табарга кирәк!

Женя, Вася белән килешкәнлеген белдереп, баш какты.

– Тик минем һаман бер нәрсәгә исем китә. Әгәр, шул авыл кешесен үтереп, шунда ук барган икән, авылдашлары аңа ышанырлармы? Тышкы охшашлык бер нәрсә, монда холык-фигыле дә, үз-үзен тотышы, сөйләме, гадәтләре дә бар бит әле. Гадәтне үзгәртү ай-һай! Юкка гынамы, чир китә, гадәт китми, диләр?

– Женя, әйдә, тегеләй микән, болай микән дип, фаразлап утырмыйк. Маратны табарга кирәк! Тик мине тагын бер нәрсә борчый. Ул авылга үзебез барып, Марат кайда яши дип, белешеп йөри алмыйбыз. Күкташта аны беркем дә Марат дип белмидер. Ул икенче кеше исемендәдер. Әгәр карточкасын күрсәтеп, сораштырып йөри башласак — аңа җиткерәчәкләр. Ул шунда ук эзен яшерергә маташачак. Анда барып балкып йөрсәк безне үзенең күреп калуы бар. Аның Күкташта кем исеме астында яшәвен сиздермичә, артык тавыш чыгармыйча гына белергә иде.

Егетләр икесе дә уйга калды. Берәр минуттан Женя:

– Шәһәрдә Күкташтан чыккан кешеләр шактый. Ул авылда туганнары булып, кайтып-килеп йөрүчеләр дә бар. Шулар белән элемтәгә кереп, Күкташка яңа килгән кешеләр турында белешсән генә инде, — дип куйды.

– Минем ул авылдан белгән кешем юк. Бәлки синең бардыр?

– Берәү бар бугай. Бик якын дустым түгел түгелен. Тик сораштырырга була.

Васяның күзләрендә нindидер өмет чаткылары кабынып алгандай булды.

– Әйдә, алайса, шул юл белән эзләп карыйк. Сиңа — комсомольское поручение, ул танышыңны күреп, белеш. Тик, ишетсен колагың, артык шикләнерлек булмасын. Болай, сүз уңаеннан гына сөйләшкәндәй...

– Баш өсте, сэр, — дип, Женя кулына бокалын алды.

Вася да риза төстә елмайгандай итте. Әйдә, булгач булсын дигәндәй, үзенең бокалын аныкына чәкештереп куйды.

* * *

Гомәр Саттаровның йокысы бөтенләй качты. Узган ел Ялантау янында булган вакыйгалар, соңыннан Маратның сәер шартларда үз-үзенә кул салуы аңа һич кенә тынгылык бирми иде. Гомумән, Гомәр өчен бу хәлләрнең аңлашылмаган яклары шактый. Вася Кулагин нинди кеше? Марат белән нинди мөнәсәбәттә булган? Берничә атна качып йөргәннән соң, Артемны үтереп, үзенең дә башын элмәккә тыгарга Маратны нәрсә мәҗбүр иткән? Сораулар, сораулар, сораулар...

Җан тынычлыгын алган әнә шул сорауларга өлешчә генә булса да җавап табу өчен ул Наил Хәкимовичны күреп сөйләшергә теләде. Аны бик якыннан белмәсә дә очрашырга туры килгәне бар, хәтта берничә мәртәбә сөйләшеп тә утырдылар. Чечнядагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан кеше буларак, Саттаров Әфганстан һәм башка локаль сугыш ветераннары җыелышында да бер-ике мәртәбә булды. Ул чакларда әлеге оешма рәисе Наил Хәкимович анда уңай тәэсир калдырган иде. Әнә шуңа, җайнен бер көнендә, вакыт табып Наил Хәкимовичның эш урынына китте.

Эш көне ахырына якынлашып килә. Начальникның кабул итү бүлмәсендә утыручы җирән чәчле секретарь кыз әйтерсең лә Саттаровтан сорау алды:

— Нинди йомыш белән?

— Шәхси соравым бар иде.

— Шәхси сораулар белән чәршәмбе көнне генә кабул итә.

— Наил Хәкимович белән уртак эшебез буенча.

— Анда кинәшмә бара иде, егерме минутлап сабыр итегез.

Ябык ишек аша җитәкче кабинетыннан вакыт-вакыт йөткергәләгән, тамак кыргалаган авазлар ишетелеп куя. Кайчак мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар кочәя төшә. Кемдер кычкырып, нәрсәнедер расларга маташа, икенчесе аңа каршы чыга. Берникадәр шулай дәвам иткәч, тагын тынып калалар...

Секретарь кыз, Саттаровка күтәрелеп тә карамыйча, машинкасында ниндидер текст баса. Бу — аның хезмәте. Көн дәвамында мондагы урындыкларда кемнәр генә утырмагандыр! Кыз аларга ияләшеп беткән, күрәсең. Һәрберсе белән сүз куертып тормас. Ул үз эшен белә...

Гомәр сәгатенә ничә тапкыр күз төшергәндер, билгесез. Көткәндә минутлар акрын үтә шул. Секретарьның егерме минут дигәне кырык минуттан узып китте. Бары тик шуннан соң гына ишек ачылып, аннан кулларына папка, барсетка тоткан ир-атлар чыга башлады...

Кабул итү бүлмәсе бушап калгач, Саттаров, урыныннан кузгалып кабинет ишегенә юнәлгән иде, секретарь аңа көтеп торырга кушып башта кабинетка үзе кереп китте. Берәр минуттан чыгып: «Үтегез», — диде дә, кабат машинкасы артына утырып, төймәләрен тыкылдата башлады...

Кыяфәтендә талчыгу сизелсә дә, Наил Хәкимович ачык чырай белән каршылады. Күрешкәч, каршыдагы өстәл артыннан урын тәкъдим итте.

— Безнең якларга нинди җилләр ташлады? Сез, погонлы кешеләр, юкка гына йөрмисез. Сорау алу өчен килгәнсездер әле? — дип ярымшаярып башлады ул сүзен.

— Рәсми сорауларым юк-югын. Бары тик кайбер нәрсәләргә карата мөнәсәбәтегезне генә ачыклыйсым килгән иде. Болай, үзем өчен генә... Аннан соң, сезнең белән инде күптән очрашкан юк. Яхшы кеше белән сөйләшеп утыру — җан азыгы, диләрме әле? Әгәр вакыт тапсагыз, билгеле...

«Яхшы кешеләр»ең болай гына, салпы ягына салам кыстыру өчен әйткән иде. Дөрес, Наил Хәкимович та аның бу сүзләреннән әллә ни «эреп китмәде».

— Тынлап карыйк, нинди мөнәсәбәтләр икән ул, — диде, хәйләкәр генә елмаеп. — Яхшы кеше өчен унбиш-егерме минут вакыт жәл түгел, — дип, бик матур гына итеп, ана бүленгән минутларны белдереп, вакытны чикләп куйды да, өстәлдәге селекторның бер төймәсенә басып, секретарь кызга ике чокыр чәй алып керергә кушты...

— Вася Кулагин ниндирәк адәм ул? Мине шул кызыксындыра.

Наил Хәкимовичның кашлары җыерылып куйды. Беренче мизгелдә ул бәлки Нур Гаянович белән булган хәлләрне Вася боларга «тишмәде» микән, дип тә шикләнгәндер. Тик үзен тиз кулга алды. Андый сүзләр белән шаярырга Васяның башына тай типмәгән ләбаса. Юкса үзе юк..

— Кулагин белән мин күптәннән таныш. Заманында хәтта якын дуслар да идек. Ул да минем шикелле әфган төтенен иснәгән кеше бит. Мин ул сугышның башында катнаштым. Вася исә ахырына эләккән, соңгы көннәрен күргән. Безне якынайтуга төп сәбәп бәлки шул булгандыр. Аннан ул әфганчы ветераннар оешмасын оештырганда да активлардан булды. Миңа һәрчак теләктәшлек күрсәтте...

Секретарь кыз подноста ике чокыр чәй күтәреп кергәч, Наил Хәкимович сөйләвеннән туктап калды, бер чокырга шикәр комы салып, аны чәй калагы белән болгата башлады. Саттаров та икенче чокырны үз янынарак шудырды. Секретарь чыгып киткәч Гомәр өзелгән әңгәмәне ялгарга теләде.

— Менә сез, дуслар идек, теләктәшлек күрсәтә иде, дип үткән заманда сөйләшәсез. Хәзер мөнәсәбәтләрегез үзгәрдемени?

Наил Хәкимович, бер-ике мәртәбә чәй йоткач:

— Үзгәрде, дип... Әйе, Васяга нәрсә булганын баштарак үзем дә аңлап бетерми идем. Соңгы сөйләшүләрдән соң бераз сизенәм. Инфляция чәчәк аткан елларда, әфганчы егетләргә эш урыннары булыр дип җинел автомобильләр ремонтлау станциясе ачкан идек. Ул, шәхси предприятие итеп, минем исемгә рәсмиләштерелде. Яшерен-батырын түгел, депутатлыкка сайланырга йөргәндә миңа аны үз өстемнән алырга киңәш иттеләр. Ягъни, икенче кешегә сатарга тиеш идем. Башта Вася Кулагин исеменә күчерергә дип уйлашкан идек. Тик, холкындагы кайбер тискәрелекләрне исәпкә алгач, ахыр чиктә кире уйладым. Бу «хуҗалык»ны Анисимов атлы бер дустым карамагына тапшырдым. Васяга бу ошамады булса кирәк. Араларыбыз суыну да шуннан башланды кебек.

— Ә бит, Наил Хәкимович, чыннан да, ул предприятие турында яман сүзләр күп йөри.

Наилнең йөзе тагын да караңгыланды.

— Беләм, беләм, андый гайбәт сүзләрне үземә дә ишеткәләргә туры килә. Тик предприятиенең һәм анда эшләүче егетләрнең моңа бәйләнеше юк. Дөрес, Әфганда хезмәт иткәннәрнең шактые төрле сәбәпләр аркасында аннан киткән. Яңа кешеләр килгәләгәнен дә беләм. Монда бөтен хикмәт — Васяның ниндидер шикле адәмнәр белән аралашып читтә төркем оештырып йөрүендә. Аның ул җинаятьчел шайкасында әфганлы егетләрнең берninди катнашы да юк.

— Аның шундый кыңгыр эшләре мәгълүм икән, бераз йөгәнләргә мөмкинлек булгандыр ич?!

Кабинетта киеренке тынлык урнашты. Наил Хәкимович фикерен туплый иде булса кирәк. Ул мондый чакта «ордым-бәрдем» сүз ычкындыруның яхшыга илтмәсен белә.

— Мин Васяны бу хакта бер генә кисәтмәдем. Ләкин ул һаман үз киресен эшли торды. Сезнең братлар да әлегә үзен кыңгыр эш өстендә тотканнары юк. Вася хәйләкәр, шома гына ычкына белә. Судан коры чыга торганнардан...

Наил Хәкимович сәгатенә караштыргалый башлагач, Саттаров сораштырып өлгермәүдән куркып, Марат турында сөйләшүгә күчте.

— Марат минем чыбык очы туган тиешле егет. Ул Чечняда хезмәт итте. Армиядән соң шактый вакыт эшкә урнаша алмыйча йөрде. Хәмерле табыннар, җилбәзәк хатыннар, ирекле тормыш егетне бөтенләй боза язган. Әнисе Зәйтүнә апа, улының тайгак юлга кереп китүеннән куркып, бик үтенеп сорагач, аны үз яныма урнаштырган идем. Бәлки, эш белән йогынты ясап булыр дигән өмет тә бар иде. Тик Марат үзе Васяның тискәре йогынтысына бирелгән.

Наил Хәкимович, сүзеннән туктап, авыр сулап куйды.

— Егет тайгак юлга эләгеп харап булды. Кызганыч — аның үлемендә үзенең дә гаебе бар. — Уфтанып, сүз уңаеннан гына әйткәндәй, — әле беркөнне генә каберенә барып килдем, — дип тә өстәде.

— Анда еш буласызмы?..

— Мактана алмыйм. Күмгәннән соң беренче баруым... Дөнья мәшәкатьләре... Язмыш үзе искә төшерде: нәкъ Маратка охшаган бер егетне очраткан идем. Шунда аның каберенә барып кайтырга ниятләдем дә... Ни әйтсәң дә, чыбык очы...

«Маратка охшаган бер егет» дигән сүздән, Саттаровның кыяфәте кинәт үзгәрде. Наил Хәкимович моны үзенчә аңлады.

— Нәрсә, барыгыз да шул сүзләргә хәйран каласыз? Бер-берсенә бик нык охшаган кешеләр дөньяда буа буарлык бит!

— Барыгыз да?.. Тагын берәр кешегә сөйләгән идегезме әллә?

— Шул көнне көтмәгәндә зиратта Вася Кулагинны очраткан идем. Әйткәч ул да, могҗиза ишеткәндәй, күзләрен түгәрәкләндереп гаҗәпкә калды...

— Ә ул Маратка охшаган егетне кайда күргән идегез соң?

— Күкташ авылында мәчет ачу тантанасында очрады. Шул авыл егете булса кирәк. Мин аны читтән генә күреп калдым, бүтән күзгә чалынмады...

«Күкташ, Күкташ» дип кабатлады Саттаров үзалдына. Димәк, юрамалар дөрескә чыга инде. Бу егет Маратның үзе булуы бик ихтимал. Бу хакта Вася Кулагин аннан алдарак белгән... Нинди планнар корды икән? Һәрхәлдә, күңеле этлектәдер...

Ул Наил Хәкимовичтан моннан да кирәклерәк бүтән хәбәр алырына өметләнми иде. Шуңа күрә, ашыгып кына хушлашты да кабинеттан чыгып китте.

Саттаров, иске «шестерка»сына кереп утыргач: «Хәзер кич җитте, соң инде. Васяны эш урыныннан табып булмас», — дип уйлады. Иртән, таң әтәчләре белән торып, автомобильләр ремонтлау станциясенә барырга, Васяны күреп ачыктан-ачык сөйләшергә, дигән карарга килде.

* * *

Иртән Саттаров Гомәр гараж кооперативына юл алды. Ыгы-зыгы бераз кимесен, ремонтчылар үз урыннарын алсын дип ул эш сәгате башланып, берникадәр вакыт узганны көтте. Гомәр кергәндә, боксларда эш кайный иде. Чүкечләр тукылдый, шомарту машиналары чыжылдый, аргы почмакта тимерне эретеп ябыштыручы очкын чәчә, шул тавышлар арасында дивар почмагына эленгән динамикалардан матур гына көй ишетелеп ала.

Саттаров «Жигули»ның алгы көпчәген сүтеп маташкан бер егеттән Васяның кайдалыгын сорады.

— Әзерләүләр цехында булырга тиеш, — дип егет цехка урам яктан керергә кушты.

Беренче бокста таза гына егет эш урынын тәртипкә китереп, чүп-чар себереп маташа иде. Гомәр аңа да әлеге сорауны бирде.

— Күптән түгел генә Женя белән каядыр китте ул, — дип җавап бирде егет, милиция формасы кигән Саттаровны баштанаяк күздән кичереп.

— Кая икән?

— Белмим, мина әйтеп йөрмиләр. Юрий Николаевичтан сорагыз, бәлки ул беләдер, — дип егет директор бүлмәсенең ишегенә ишарәләде.

Тик Анисимов та Васяның кая китүен тәгаен генә әйтеп бирә алмады.

— Егерме минутлап элек, бер авылга барып кайтасы бар дип чыгып киткәннәр иде.

— Авылның исемен ничек диделәр? Күкташ түгелме?..

— Бәлки Күкташтыр. Исеме бер колагымнан керде, икенчесеннән чыкты. Мина барыбер. Машинага утырып, көне буе җил куып йөрүне генә беләләр. Алар урынына монда кем эшләргә тиештер?!

Бу төксе чырайлы кеше белән артык сүз куертуда мәгънә юк иде. Наил Хәкимович кооперативны ничек итеп шундыйлар кулына тапшыра алды икән? Хәер, ана артыгын такылдамый торган аз сүзле кешеләр кулайрактыр бәлки. Югыйсә, Васяның холкын бик килештермәдем ди бит.

Димәк, Вася белән Женя Күкташка киткән булырга тиешләр дип нәтиҗә ясады Саттаров. Маратны иснәнеп тапканнардыр... Ул, эчке бер сиземләү белән, егетләрнең тикмәгә генә түгел, ә ниндидер яманлык кылырга йөрүләрен чамалады.

Анисимов өстәлендәге телефонга ишарәләп: «Шәһәргә шылтыратырга ярыймы?» — дип сораган иде, кабинет хуҗасы:

— Теләсәгез күпме шылтыратыгыз, — дип җавап бирде.

Гомәр эчке эшләр идарәсе дежурныеның номерын җыйды. Патрульпост хезмәтендә эшләүче дусты, сердәше сержант Зәйнетдинов Рәшитне телефонга чакыруларын үтенде. Бер-ике минуттан трубкада таныш тавыш ишетелде. Кыскача гына хәл-әхвәлләр сораштыргач, Гомәр:

— Дускай, монда бик буталчык бер эш килеп чыкты. Синең ярдәмен кирәк. Эштән сорап ычкына алмассынмы? Тик мөмкин кадәр тизрәк кирәк, — диде.

— Шулай ук җитди эшмени? Бәлки үзегезнекеләрне — опер егетләрен чакырыргадыр?

— Рәшит, дөресен генә әйткәндә, вакыт бик тар. Артыгын күпертеп вакытны сузасым килми. Монда икебез ерып чыгарбыз мөгаен.

— Сине кайдан табарга соң?

— Мин үземнең «шестерка»мда, «Дуслык» клубы янындагы урам чатында көтәм. Калганын юлда сөйләрмен. Ашыга күр инде, яме!

«Дуслык» клубы янында тукталып бер-ике минут узуга, Рәшитнең ашыгып килгәне күренде. Ашыгып дип әйтү генә бик үк дөрес тә булмас, егет йөгерә иде...

Ул кереп утыруга, иске машина яман үкереп урыныннан кузгалды, бераз үзәк урамнан баргач, шәһәрдән чыга торган юлга борылды.

Юлда ук Гомәр хәлне Рәшиткә төшендереп барды. Үзенең шикләрен дә белдерде. Аны тынлап бетергәч, дусты, башын чайкап:

— Бик кызыклы хәлгә тарыгансың син, — дип әйтә башлаган иде, Гомәр аны шундук бүлдерде:

— Кызык түгел, кызганыч...

— Бәлки... Дөресен генә әйткәндә, мондый хәлгә үземнең дә ышанасым килми. Тормышта алай була ала микән?

— Ә менә Вася Кулагин, безнең шикелле ышаныргамы-юкмы дип шикләнеп тормаган, шунда ук эзләнә башлаган һәм эзләгәнен тапкан да кебек... Шулай булгач, дускай, безгә дә ашыгырга кирәк...

Гомәр болай да ашыга иде. Спидометр угы сәгатенә йөз ун километрны күрсәтә. Аның иске «шестерка»сы өчен күп инде бу тизлек.

Юл читендә ГАИ машинасы тора икән. Ашкынып килгән «шестерка»ны күргәч, инспекторларның берсе сырлы таягын күтәреп туктарга кушты. Тик Гомәр аның таләбенә буйсынмады, тизлеген дә киметеп тормыйча үтеп китте. Машинада утыручыларның милиция формасыннан икәнлеген күргәннәрдер, әлбәттә, арттан куа чыгучы булмады. Әйтергә кирәк, алар ара-тирә зур тизлектә узып киткән «Волга»лар, «иномарка»ларга да әллә ни игътибар итмиләр. Үзләренә өстәмә мәшәкать аласылары килми күрәсең. Ә менә берәр агайның иске «Москвич»ы белән «тыр-пыр» килеп баруын күрсәләр, туктатып гаеп эзләргә керешәләр. Иске машинадан гаеп табу җиңел ул: ник номерың юылмаган, нишләп кул тормозы эшләми, карбюраторың көйләнмәгән, төтенең бик куе һәм башкалар...

Бераз баргач Сattаров унга борылып, грунт юлга керде. Юл сикәлтәле булса да тизлекне киметмәде. «Шестерка» үз артыннан тузан болыты калдырып болыннар, басулар буйлап алга ыргылды...

Күкташ авылының кыр капкасы янында ун-уникe яшьләрдәге бер төркем малай футбол уйный. Моннан чит-ят машиналар үткән булса болар күрми калмас. Берсе күрмәсә, икенчесе күргәндер дип Саттаров шулар янына туктарга булды. Машинадан төшү уңаена «аут»ка очкан тупны оста гына эләктереп тә алды. Малайлар уеннарыннан туктап милиционерга текәлделәр. Гомәр якындарак торган берсен чакырып китерде.

— Нәрсә, егетләр, туп тибәбезме?

— Тибәбез, — диде малай.

Милиция киемендәге бу кешенең үзе белән сөйләшеп торуы, өстәвенә, малайларга «егетләр» дип эндәшүе кызык иде аңа.

— Моннан ярты сәгать чамасы элек бу тирәдән берәр машина узып киткәнен күрмәдегезме?

— Әйе, бер зәңгәр машина үтте. Аның шоферы туктап, безнең белән сөйләшеп тә торды әле.

— Ә нәрсә сөйләште?

— Таһир абыйларның өен сорады.

— Кайда яши соң ул?

— Сезгә дә кирәкмени?

— Әйе!

— Ү-ү-унә тегендә. Ул барыбер өйдә түгел лә.

— Ә кайда?

— Авылдагы бөтен абыйлар Куштирәкле болынына печән чабарга китте. Ул да шулар белән...

—Авылдан еракмы соң?

Малай бераз уйланып торды да:

— У-у, бик ерак. Без анда биләсәпид белән дә бә-ә-әк озак барабыз.

— Ә машина белән барсак, безгә ул Куштирәкле болынын күрсәтә аласыңмы?

Малай икеләнә калды. Аның барасы килмәгәне кыяфәтенә чыкса да, кистереп каршы әйтергә кыенсына иде, күрәсең. Ярый ла, шунда торган каракучкыл йөзле малай ярдәмгә килде.

— Абый, ул безнең главный нападающий. Бик кирәкле уенчы. Китсә, безне аръяк командасы җиңәчәк. Ул бара алмый...

— Ә кем бара ала?

— Әнә, Кәтүк Рәмзилне сорагыз, — дип, кырыйда «аут»ка чыккан тупларны тотып торучы җиде-сигез яшьлек малайга күрсәттеләр.

Гомәр ул малайны да чакырып китерде:

— Балакай, Куштирәкле болынының кайда икәнлеген беләсеңме?
— Беләм. Без анда җиләк җыярга йөрибез.
— Безгә юл күрсәтерсеңме?
Малайның машинага утырып йөрисе килә иде күрәсең, аннан соң гел «аут»ка чыгып тилмерткән туп артыннан куу да туйдырган булса кирәк:
— Ярар соң, — дип куангандай булды.
Авылны чыгып ерак та китмәделәр, боргаланып еракка сузылган елга тасмасының икенче ягында, тау менеп баручы машина күренде. Гомәр, «бардачок»тан бинокль алып Рәшиткә сузды. Дусты җентекләп күзәткәч:
— Зәңгәр төстә, «девятка» бугай, — дип куйды.
— Шулардыр мөгаен. Монда машиналар сирәк йөри. Аннан соң теге малайга борылып:
— Рәмзил, ә Куштирәкле болыны кайдарак? — дип сорады.
— Ә-әнә тегендә-ә-ү.
Чыннан да, малай төртеп күрсәткән якта, яшел үзәнлектә, ерактан чебен зурлыгында гына күренгән кеше фигураларын Гомәр шунда ук шәйләде. Тик ничек кенә тиз барсалар да теге «девятка»ны куып тота алмаячаклары көн кебек ачык иде.
— Болынга турыдан юл юкмы?
— Без малайлар белән җиләккә турыдан бара идек. Тик аргы якка елганы йөзеп чыгарга кирәк. Ә мин йөзә белмим. Шуңа күрә олырак малайлар мине биләсәпитләрне, киемнәрне сакларга бу ярда калдырып, үзләре теге якка йөзеп чыгалар иде.
— Без дә шулай эшләрбез! Әйдә, туры юлны күрсәт...
Машина елга ярына килеп туктагач, Гомәр бинокле белән аргы якны тагын бер мәртәбә күзәтеп алды. Бу вакытта теге машина болында эшләүчеләр янындагы куаклыкка якынлашып килә иде. Ашыгырга кирәк.
Егетләр, чишенеп трусикчан гына калдылар да, пистолет белән кул богавын гына алып аргы якка йөзә башладылар. Елга киң түгел, бер-ике минут узды микән, алар аргы якка чыгып та бастылар. Яр читендәге таллыкка ышыкланып болын ягына йөгерделәр. Бу вакытта «девятка»дагыларның берсе машинадан төшеп печәнчеләр тарафына атлады, ә икенчесе куаклар ышыгына посты. Беренче нәүбәттә, әнә шул куаклар янында калганын тавышсыз-тынсыз гына эләктерергә иде. Тик моның өчен аның янына артыннан әйләнеп керергә кирәк. Ярый әле Гомәр белән Рәшит бара торган таллар нәкъ шул урында куаклыкка барып тоташкан. Ышыкланып барсаң теге адәм күрмәячәк...
Куак төбендә посып утырганы Вася Кулагин үзе булып чыкты. Егетләр, аның артыннан килеп, тиз генә эләктереп тә алдылар. Ул «ык» итәргә дә өлгермәде. Тентеп карагач, биленә кыстырылган пистолетны килеп чыкты. Рәшит аны үзенә алды.
Әллә каян гына пәйда булган шәрә кешеләрне күргәч Вася баштарак чын-чынлап каушап калды. Тик, Гомәрне таныгач, авызын ыржайтып көлде генә:
— Ә, Марканың саклаучы фәрештәләре менә кемнәр икән! Легавыйлар ялчысыдыр дип уйлаган идем аны, тәки дөрескә чыкты. Гнида, — дип җиргә төкерде.
— Йә-йә, күп сөйләшмә, судта әйтергә сүзең калмас, — дип Гомәр тегенең касыгына җинелчә генә тибеп алды.
Вася кулына ни өчендер озын бау тоткан иде. Рәшит кызыксынасы итте:
— Монысы нәрсәгә?
— Бозау арканларга, — дип хахылдады Кулак.

– Үзенне бәйләп куярга шәп әле бу, — дип, Васяны аркасы белән юан агачка терәп, бәйләп куйдылар да.

Ун минутлап узды микән, Женя белән Марат күренде. Алар башта янәшә атлап, сөйләшеп килгән шикелле иде. Иңкүлеккә төшеп печәнчеләр күзеннән яшеренгәч, Женя берничә адым арткарак калды да куеныннан пистолет чыгарды.

Рәшит, моны күргәч кулындагы пистолетын кысыбрак тотты.

– Нәрсә, атарга җыенамы әллә?

– Кулагин янына килеп җитмичә атмаячак, курыкма. Аннан соң, әнә бит, аны атып үтерергә түгел, ә асарга җыенганнар, — дип Гомәр Васяны бәйләгән бауга ишарәләде.

Вася тагын хихылдады:

– Хәзер дускаегызга аллес капут булачак...

– Авызын берәр нәрсә белән томала әле шуның, юкса безнең монда икәнлегебезне сиздерүе бар, — диде Гомәр.

Рәшит озак уйлап тормады, Васяның күлмәк җиңен умырып төшерде дә авызына тутырды һәм, үрмәләп, Гомәр янына килде. Куаклык читенә якынлашкан Женя исә, үзен каршыларга чыгучы булмагач, күрәсең:

– Вася, Вась? Кая олактың син? — дип кычкырды.

Җавап ишетмәгәч, шикләнде булса кирәк, Маратка туктарга кушты да ана якынрак килде. Тагын икеләнеп як-ягына каранды. Хәзер Женяны Марат гәүдәсе каплап тора инде.

Гомәрнең теш арасыннан:

– Ах, шайтан, — дигән сүзләр кысылып чыкты. Женяны һич кенә дә мушкадан ычкындырырга ярамый. Юкса, болардан барысын да көтәргә була.

– Бар, син читкәрәк кит, кырыйдагы куак артына. Шуннан пистолетың белән Женяны мушкада тот. Атарга ашыкма. Юкса Маратка тидерүең бар.

Рәшит, ун метрлап араны үрмәләп узды да куак төбенә ятты. Хәзер Женя аңа ачык иде, ул аның уң ягындарак тора.

Женя тагын бер-ике мәртәбә Васяны чакырып кычкырды. Аңа каршы Вася, «бу-бу-бу» килеп, нәрсәдер әйтмәкче булып маташты. Тик, авызына тутырылган чүпрәк сөйләшергә комачаулады, Женя берни ишетмәде. Шулай да, предохранителен ычкындырып, пистолетын Маратның чигәсенә терәде. Һәм әкрен генә куаклыкка әйдәде. Гомәр дә пистолетын Васяның маңгаена терәде. Чөнки Женя аларны күреп алган иде инде. Шулай, бер тын карашып торгач, Женя телгә килде:

– Әһә, кунак бар икән. Тик коралың белән шаярсаң, менә бу тәти егетнең маңгаена тишек ясыйм. Аңладыңмы? Пушканы ташла һәм тизрәк бул, — диде.

Гомәр, чарасыз сыман кыланып, бөтен гәүдәсе белән күтәрелде дә пистолетын җиргә ташлады. Аның болай эшләвен күргәч, Марат:

– Саттаров, курыкма, ат! Мина тисә дә әллә нәрсә юк... Син аттың ни, алар аттылар ни — барыбер. Исән калсам да...

Гомәр аның сүзләрен бүлде.

– Борчылма, егеткәем. Без синең белән мондыйларны гына күргән инде!..

Вася тагын «бу-бу-бу» килеп боргаланды, нидер кычкырырга теләде. Якында гына Рәшитнең качып ятуын әйтмәкчедер күрәсең.

– Пушканы читкәрәк ыргыт та якынрак кил! — дип әмер бирде Женя.

Саттаров җирдәге пистолетны читкәрәк типте дә Марат каршысына

килеп басты. Женя аның трусигында эленеп торган кул богавын алып, бер ягын Маратның беләзегенә эләктерде, ә икенче ягын Гомәрнең кулында бикләде.

– Хап! Менә шулай яхшырак булыр, – дип сөйләнде ул. – Ә хәзер икегез дә җиргә йөзтүбән, – дип, команда бирде дә, янәшәдә яткан пистолетны алып, Кулагин янына китте.

Вася бу вакытта, нәрсәдер белгертергә теләп, башларын боргалый иде. Тик янарак кына булып узган «җинү»ләре шаукымыннан, Женя аны аңлый алмады. Менә ул, иелеп, Васяның авызыннан чүпрәкне ала башлады. Хәзер инде куак артында посып яткан Рәшиткә бер мизгелгә дә тоткарланырга ярамый. Ул Женяга төзәп атып җибәрде. Исәбе үтерү түгел, бары яралау гына иде дә бит, тик теге, ахылдап, җиргә ауды һәм тынсыз калды. Рәшит якынрак килгән иде, аның күкрәк турысыннан кан сирпелеп чыкканын шәйләгәч, янында озак тоткарланмады, Гомәр белән Маратны богаудан ычкындырырга китте. Богауның ачкычы аңарда. Бу чакта егетләр торып басканнар иде инде. Рәшит башта Гомәрнең кулын ычкындырды. Аннан Маратныкына үрелгән иде:

– Стоп, стоп, – дип Гомәр туктатты аны. Богауның яңа гына үз кулыннан бушаган ягын Маратның икенче беләзегенә кидерде дә:

– Гафу ит, дускай, шулай кирәк, – дип куйды.

Шунда Марат, кинәт кискен хәрәкәт ясап, Гомәрнең каршысына чыгып басты. Куаклыктан шартлаган тавыш ишетелде. Марат тез чүкте һәм җиргә егылды. Аткан кеше Женя иде. Рәшит ашыгычлык белән аның пистолетын алырга онытканы шул. Ул аны үлгән дип уйлаган иде бит. Ә егет исән калган булган икән. Аңына килеп пушкасын Гомәргә төбәгән. Ялантау янындагы кебек, бу юлы да ана Марат комачаулады – күреп калып гәүдәсе белән Гомәрне каплады. Аткач, Женяның пистолет тоткан җансыз кулы җиргә салынып төште. Егет борыны белән җиргә капланды, гәүдәсе җайсыз гына калтыранып куйды. Бу аның соңгы сулышы иде. Маратның томалана барган күзләре боларны да күрде әле. Калганы барысы да томанга кереп юк булды, барысы да бетте...

* * *

Юк, бетмәгән икән. Бу вакыйгалардан соң унбиш елдан артык вакыт узгач, каты режимлы бер колония капкасыннан кыска чәчле чигә сакалы чалара башлаган, борыны өстенә күзлек элгән, ябык кына бер адәм чыкты. Артыннан авыр капка шапылдап ябылгач ул берара туктап калды. Нәрсә эшләргә дә белмәгән кыяфәттә артына борылып, әле генә үзе чыккан капкага күз салды. Инде ничә еллар күзәтү астында яшәргә ияләнгән мәхбүс өчен иректә булу – чыннан да, гаҗәбрәк халәт шул. Хәзер аны беркем дә күзәтми, беркем дә тегендә барма, болай эшләмә, дип кисәтеп тормый һәм ул инде бу фани дөньяда беркемне дә кызыксындырмый иде кебек. Каршылаучысы да юк...

Юл аркылы гына бакча бар икән. Ир акрын-акрын шунда таба атлады. Килеп җиткәч, эскәмияләрне күздән кичереп берсенә утырды һәм, кулы белән чигәләрен тотып, башын иеп уйга калды. Ул тирә-якны күрми иде. Дөресрәге, соңгы елларда аның өчен ят булган бу ирек дигән нәрсәгә ул әзер түгел. Ә ияләнергә кирәк...

Шулай күпме утыргандыр, кемдер, иңбашына җиңелчә генә кулын куйгач, сискәнеп башын күтәрде.

– Нәрсә, Марат, башыңны түбән идең? Утырып туймадыңмыни әле?

Эскәмиядә утыручы бу ир, чыннан да, унбиш ел срогын тулысы белән утырып чыккан Марат иде. Ул үзенә эндәшкән милиция подполковнигын

танырга тырышып йөзенә текәлде. Каядыр күргәне дә бар кебек. Ай бу хәтер дигәнең!.. Олыгая-олыгая зиһен дә тоныкланып беткән. Гомәр... Саттаров түгелме соң?.. Кем булсын инде тагын, әйе ул, тавышы да аныкы!

Марат урыныннан торды. Ияләнелгән гадәт буенча:

— Гражданин начальник, — дип әйтә башлаган иде, туктап калды.

— Шайтан — сиңа гражданин начальник... Нәрсә, танымадыңмы?..

— Таныдым, граждан... Сезне танымыйммы соң?! Ә монда нишләп йөрисез?!

— Сине каршыларга махсус килдем. Югыйсә көтәр кешең дә юктыр... Нәрсә, кулга богау кидереп каталашкага тыгып куйды да, шуның белән вәссәлам, онытты, дип уйладыңмы?

— Юк, уйламадым... Гомумән, бернәрсә дә уйламадым...

Саттаров, аны ирләрчә кочаклап, җилкәсенә шап-шоп суккалады. Аннан соң, арткарак китеп, Маратны тагын бер кат баштанаяк күздән кичерде.

— Хәлеңне аңлыйм, дускай... Таушалгансың... Еллар җәлләмәгән сине...

— Әйе, гомер дигәнең гел юкка гына үтте дә китте...

— Бирешмә! Башыңны югары күтәр! Җебеп төшмә!

— Җебеп төшмичә генә яшәүләр бик авыр шул... Язмыш тез астына бер китереп сукса — егылырга куша. Ә кабат торулар, ай-һай... Тормышны гел яңадан башлап булса икән?..

— Тез астына суккач, сыек сыйраклылар гына егыла. Без синең белән шундый токымнанмыни? Аягүрә басып кала белергә кирәк! Тормышны кабат башлауга килгәндә... син бер мәртәбә тормышыңны гел яңа баштан башлап караган идең түгелме? Чит кеше исеме белән, ялган күләгә булып... Менә нәрсә, дускай, күләгә булып яшәргә кирәкми, үзең булып яшә!

«Күләгә, күләгә...», — дип кабатлады Марат үзалдына.

— Дөрес, хәзер гадәти тормышка җайлашу авыр булыр. Син тоткында вакытта, тышкы дөнья тукталып калды, дип уйлыйсыңдыр. Юк, Марат, аның бер мизгелгә дә туктап торганы юк. Һәрберсе хәрәкәттә, камиллеккә бару юлында, үсештә...

Үсештәдер шул, дип уйлады Марат. Югыйсә, Саттаровның авызыннан «камиллеккә бару юлында» дигән сүзләр чыгар идеме?! Элекке «опер» да шундый фәлсәфәгә бирелә башлагач инде!..

— Элек мин белгән кешеләр кайларда икән хәзер? — дип авыр сулады Марат. — Алар да сезнең шикелле фәлсәфә куертырга өйрәнделәрме икән?

— Ә кем кызыксындыра соң сине? Вася белән Женяны күздә тотсаң, аларның тәне күптән туфрак инде.

— Ишеттем, беләм...

— Бәлки, Наил Хәкимович турында сорыйсыңдыр? О-о-о, Наил Хәкимович хәзер бик зур кеше! Мәскәүдә ул. Дәүләт Думасы депутаты. Инде икенче чакырылышка сайланды. Әллә нигә бер сайлаучылар белән очрашуга кайтып китқәли.

— Аңлыйм, ул һәрчак зурдан кубарга ярата иде...

— Ә төзелеш трестын кем җитәкләгәнен беләсеңме? Анда хәзер генераль директор Фәнил Наилевич, Наил Хәкимовичның олы улы. Бездә бит хәзер, парин, җитәкчелек династия буенча китте. Малайлары булганнарга рәхәт...

Саттаров бераз эндәшмичә торды. Марат та сорау биреп, тынлыкны бозмады.Тик бераздан соң гына:

— Шулай инде, чабатачыдан — чабатачы, төзүчедән төзүче чыга. Хәкимечның улы да үзе шикелле «деловой»мы? — дип сорап куйды.

— Уздыра да әле. Районда иң зур особняк аныкы дип сөйлиләр.

— Юк, мин шәхси мәсьәләдә түгел... Кешеләрне кайгыртуы, хәйриячелеге дим?

— Ә-ә, анысы кызыксындырамыни?.. Әтисенең туган авылында олы гына мәчет төзеткән. Бабасы Хәким абзый шул мәчеттә мулла хәзер... Авылның иң хөрмәтле кешесе...

— Күкташ авылында ниләр бар икән? Хәер, сез каян белергә тиеш инде аны...

— Мин яртылаш Күкташныкы бит хәзер. Картаеп беткәнче холостой булып йөрдем дә, менә өйләнеп куйган идем... Хатыным Күкташныкы. Андагы хәлләр белән хәбәрдар мин. Сине Хафиз абыйлар гаиләсе кызыксындырадыр, билгеле. Хафиз мулла шактыйдан вафат инде. Кызы Гөлназ кияүгә чыгып каядыр еракка китеп барган. Йортта әнисе — Нурия абыстай үзе генә гомер кичерә. Кайчак, җәйләрен Гөлназның балалары кайтып, әбиләре янында торып китәләр икән... — Аннан соң, сер итеп кенә әйткәндәй, Маратның колагына иелде. — Ә беләсеңме, сине каршыларга үзем генә килмәдем бит, машинада тагын бер кеше көтеп утыра...

Подполковник Гомәр Саттаров аны юл читендәге «Фольксваген» машинасына әйдәкләде. Машинаның ярымкараңгы тәрәзәсе аша Марат чыннан да эчтә кемнедер шәйләп алды. Саттаров ниндидер бер тантана белән ишекне киереп ачты. Анда утыручы хатын-кызны Марат танымады, билгеле. Озаклап караса да... Барыбер ул аны белми иде кебек. Киеренкелекне йомшарту өчен Саттаров аларны үзе таныштырырга ашыкты.

— Бу минем хатынның бертуган сеңлесе, нәкъ менә Күкташ авылыннан...

Тик ул сүзләрен әйтеп бетермәде, хатын, мөлаем елмаеп, Маратка үзе кулын сузды:

— Нәфисә апаң булырмын...

— Нәфисә апа... Күкташ... Әйе, әйе, беренче мәртәбә Күкташка килгәндә, чишмә буенда... «Нәфисә апаң булырмын...» Таныш сүзләр... Ә аннан соң... Карале, бу язмыш нишләп һаман начар кичерешләр белән эзәрлекли соң аны?..

Марат кирегә борылды да машинадан читкәрәк китмәкче булды. Тик Гомәр аны иңнәреннән тотып туктатты, машинага керергә ярдәм итте.

— Юк инде, дускай, бер безнең кулларга килеп эләккәнсең икән, тиз генә ычкынырмын, димә... Ул да ялгыз, син дә... Икегезгә дә иптәш кирәк, — дип сөйләнде ул, Маратка утырырга ярдәм итеп.

— Ни дә булса килеп чыгарына ышанасызмы?!

Шунда Нәфисә, йомшак кына итеп аның кулларын тотты да тыныч кына:

— Яшәрбез, күрербез... — диде.

Кояш нурларында елкылдап торган аксыл машина салмак кына кузгалып китте дә, яшел агачлар белән ышыкланган тигез, киң юл буйлап алга омтылды...



## Йолдыз Миңнуллина

# ӨТҮКӘН[1] ҖИРЕНДӘ УТ ЯНА

*552 елда хәзерге Монголия, Кытай, Байкал күле буйларында, Көньяк Себер, Алтай далаларында дистәләрчә төрки телдә сөйләшүче кабиләләрне берләштергән I Төрки каганлыгы барлыкка килә. Ил башында Бумын — Ашина ыруыннан булган каган тора. Кытай империясе көчәйгән дәвердә, төрки каганатта эчке низаглар башлана, эчке каршылыклар нәтиҗәсендә 604 елны каганат ике өлешкә - Көнбатыш һәм Көнчыгыш каганлыкларга аерыла. Озакламый Көнчыгыш каганлык, үзенең дәүләт мөстәкыйльлеген югалтып, 50 ел чамасы Кытай хакимлеге астында яшәргә мәҗбүр була.(Ф.Ш.Нуриева. «Борынгы төрки тел. Орхон-енисей язмалары теле. VII-VIII гасырлар»)*

**1**

**Җир әйләнә, Кояш сүнә,**
**Кам эндәшә Тәңресенә,**
**Кич, елышып, учка сеңә — тыңла.**
**Чак күренсә офык каны —**
**Көтә-көтә зарыкканмы —**
**Кемдер дәшә безне танып, ымлап.**

**Җир үзәге — үксез дала,**
**Ул далада учак яна,**
**Ул далада, җилдән кала, кемдер**
**Чорлар аша дәшә ала,**
**Ут торгыза, сөрән сала,**
**Һәм ашкына йөрәк — талган дөңгер[2].**

**Җан җепләрен өзә-тарта,**
**Кемдер дәшә туган якка,**
**Күк читеннән көлеп карый Тәңре.**
**Кайсы җәяү, кайсы атта —**
**Җиде яугир яудан кайта —**
**Җидесендә җиде ятның гаме.**

[1] Өтүкән инкүлеге - географик атама
[2] Дөнгер — бәрмә уен коралы, барабан

Йолдыз МИҢНУЛЛИНА *–шагыйрә; «Күк тирмәсе» исемле китап авторы. Казанда яши.*

## 2

*Илле халык идем, инде илем кая?*
*Мин кемгә илләр яулыйм?*

Күлтәгин истәлеге, Зур язма,
9нчы шигырь

**Күк белән Җир арасында**
**Үз иркемнән чапкан яумы?**
**Беләзегем ертып карыйм —**
**Каным саумы?**
**Бер ят шаумы күкрәгемдә,**
**тояк тавышымы?**
**Югалуыммы бу? Үз-үземә**
**Кайтып барышыммы?**

**Күк белән Җир арасында**
**Бүген мин кемнең колы?**
**Соң көчемне йомшак тынлы**
**Табгач[3] җиле йолкыды.**
**Җиргә ятып тыңлап карыйм —**
**Кайда ул — кайтыр далам?**
**Кем дә дәшми, яңагыма**
**Туң сабаклар кадала.**

**Кем дә дәшми үз телемдә —**
**Бүлгәләнде телем-телем**
**Күк белән Җир арасында**
**Минем илем, синең илең...**
**Кысык күзле җилләр генә,**
**Әрсез гадәтенә каршы,**
**Урап уза каганымның**
**Җиргә авыш кабер ташын.**

## 3

*Коралланган гаскәр кудымы сине,*
*сөңгеләр белән килеп куркыттылармы?*
*Изге Өтүкән ешлыгыннан, халкым, син*
*үзең киттең.*

Күлтәгин истәлеге,Зур язма,
23нче шигырь

**Иске сүздә шулай калган:**
**Тәңрегә тиң Бумын каган[4],**
**Ат сулышын тойганнарны,**
**Утта кылыч койганнарны,**
**Тимердән тир сыкканнарны,**
**Азау теше чыкканнарны**
**Барлап дала үзәгендә,**
**Оран салган:**
**Алда — кояш туган якта —**
**Тезе барлар — тез чүксен.**
**Кояш туктап торган чатта**
**Күзе барлар — яшь түксен.**
**Артта — кояш качкан җирдә —**
**Башы барлар — баш исен,**
**Ат җитәрдәй һәр тарафта**
**Яңгырасын**
**Төрки исем!**

[3] Табгач - кытайларның борынгы атамасы
[4] Бумын каган - I Төрки каганлыгының илбашы

**Дала йоткан вак кавемнәр**
**Бер каганга ил булсын,**
**Саклаучыгыз — Умай-ана[5],**
**Яклаучыгыз — җил булсын.**

**Элгәредән шулай калган:**
**Ил тупласа алып[6] каган,**
**Куе юкны тук итсә,**
**Уе мутны юк итсә,**
**Ялангачны киендерсә,**
**Мал-туарга тиендерсә —**
**Шулай булса, безнең халык,**
**Татлы сүзгә хәйран калып,**
**Чаптар атын читкә бора,**
**Дошман белән киңәш кора —**
**Сөйгән яры тол була,**
**Оланнары кол була.**

**Чордан чорга төрк будуны[7],**
**Юлдаш җилгә карышып,**
**Дин үзгәртә. Җилкәсенә**
**Баса Тәңре каргышы.**

**4**

*Бәкләр халкының тугрысызлыгы, табгач халкының коткысы аркасында, абыйлы-энеләләрне үзара талаштырып, табгач халкы төркиләрнең илен җимерде.*

Күлтәгин истәлеге, Зур язма, 6нчы шигырь

**Сезнең йола кыргыйрак шул,**
**Кануннарыгыз өтек —**
**Дәртле чагың узып бара**
**Тәхеткә чират көтеп.**
**Юкса син бит агаңнардан**
**Күпкә зирәк, белемле —**
**Илгә бүген синдәй каган**
**Кирәгерәк түгелме?**
**Тыңла сүзем, табгач[8] халкы**
**Бер дә юкка өйрәтми,**
**Сиңа – Кояш оланына –**
**Чират көтү кирәкме?**
**Тиңсез Тәгин[9], сүзем тыңла,**
**Ефәк күлмәк киярсең,**
**Горур башың, күп дигәндә,**
**Бер Тәңрегә иярсең.**
**Иярлә дә бүз атыңны,**
**Чиру тупла сак кына —**
**Үз хакыңа түгел, Тәгин,**
**Бөек илең хакына.**

**Ятлар беркөн көчең сизсә,**
**Яу атларын чигәрә,**
**Һәм хак гыйлем өйрәтүче**
**Остазларын җибәрә.**

[5] Умай-ана–төркиләрдә кешегә илаһи көч бирүче алиһә
[6] Алып — каһарман, батыр
[7] Төрк бодуны — төрки халык
[8] Табгач - кытайларның борынгы атамасы
[9] Тәгин –тәхет варисы, каган улы

### 5

*Төрки бәкләр исемнәреннән баш тартты, табгач җирендә, табгач исеме алып, табгач каганына буйсынды. Илле ел үз акылларын, көчен аңа бирде.*

Күлтәгин истәлеге, Зур язма, 7-8нче шигырь

**Бәрелеште ага-эне —**
**Тәңре үпкән улы синме**
**Атабызның? —**
**Ук очырткан кебек уйнап,**
**Тараттылар дала буйлап**
**Хатабызны.**

**Каганыннан ятим калып,**
**Йола алыштырган халык —**
**Бакчы, безме?**
**Илдән, телдән аерырлык**
**Күк каргышы ничә еллык —**
**Меңме, йөзме?**

**Елтыр күлмәген сәдәпләп,**
**Үз исемен җуйган бәкләр**
**Безнең ишме? —**
**Табгач ул баш игәннәрнең**
**Озынайта тезгеннәрен,**
**Ләкин чишми.**

**Табгач ул яу чапканнарның**
**Затлы итә арканнарын,**
**Ныклы итә.**
**Тик бер кызса, баба каны**
**Бүректәге ир баланы**
**Котлык[10] итә.**

**Котлык итә, һич буйсынмас**
**Алып итә.**
**Ике буын коллыктан соң**
**Халык итә.**

### 6

*Өстә төркиләрнең Тәңресе төрки халык юкка чыкмасын, халык булсын дигән.*

Күлтәгин истәлеге, Зур язма, 10-11нче шигырь

**Җир белән Күк арасында**
**Син бүген кемнең колы? —**
**Умай-ана ыңгыраша**
**Туфрак туңы аркылы.**
**Син кемгә илләр яулыйсың? —**
**Ике кулың — кара кан.**
**Тәңре сине ат ялыннан**
**Ир-ат[11] итеп яраткан.**

[10] Котлык - Кытай дәүләтенә каршы баш күтәрүне оештыручы, II төрки каганат житәкчесе
[11] Ир-ат - атлы сугышчы

Җир белән Күк арасында
Һава кан кебек куе,
Каш өстенә кулым куям —
Ул анда кемнең туе?
Күтәрелә татлы төтен —
Утлары толым-толым —
Тояк эзе чуарлаган
Табгач-Өтүкән юлын.

Өтүкәндә утлар яна,
Оран сала оланнар —
Әй, сез, ирен читен тешләп,
Тимер тәмен тойганнар!
Ишетегез, ялчы түгел
Табгачка төрки халык —
Котлык алып гаскәр җыя
Өтүкәндә туктальп.

Котлык алып гаскәр җыя,
Ат сулышыннан җебеп,
Тетри дала, бәйрәм көткән
Үсмер күңеле кебек.
Җир белән Күк арасында
Куе томан аркылы
Орынгандай итә таңда
Йөземә Тәңре кулы.

7

Өтүкән җирендә ут яна,
Туфракта сутелә тамырлар.
Кайт кына — учыңа яшергән
Борынгы үчеңнән танырлар.
Юрама югалган эзләрдән
Вакытның хөкеме хаклымы? —
Кайт та сал кытыршы үләнгә
Җил алган яңагың калкымын.

Чатырлар чатында ут яна,
Туфракка елыша үләннәр.
Ут яксаң, илереп чакыра
Каныңны югалтып үлгәннәр.
Чакыра кылычтан үткәннәр,
Үлемнең күзләрен үпкәннәр.
Алар да кайчандыр, ут йотып,
Кемнедер көткәннәр, көткәннәр.

Алар да кайчандыр бу җиргә
Син булып кайтуга ышанган,
Ул шуңа төшеңдә тилерткән
Күк асты иленә охшаган.
Ул шуңа бугазны каерып
Ургыган көй булып уяна.
Кемгәдер чак рәнҗеп көткәндәй
Өтүкән җирендә ут яна.



Фирүзә
Җамалетдинова

# ХИКӘЯЛӘР

## Яралы күгәрчен

Ул, ачкычларын шалтыр-шолтыр китереп, өенен тимер ишеген ачып керде. Борынына ялгызлык исе килеп бәрелде. Монысын ир аера белә иде... Дөньядагы бер генә искә дә охшамаган шул ул.

Йорт ияләре белән исәнләште. Җавап кайтаручы булмады. Өйдә гүя тынлык яши иде. Тынычсыз тынлык иде бу. Хатирәләр яши иде.

Ир, киемнәрен салган арада, дивардагы фоторәсемнәргә күз төшерде. Аңа елмаеп карап торган сурәтләр фатир эчен тулыландырып җибәргәндәй тоелды.

— Кызым! — дип эндәште ул шыпырт кына һәм үзенә елмаеп карап торган фоторәсемне бармак очлары белән сыйпады. Кызының тавышын ишеткәндәй булды. Күз алдында әллә ниләр бутала башлады: кешеләр, юллар, машиналар... һәм ап-ак күгәрчен.

Мизгелләр! Бөтен хыялларыңны үзгәртеп, кирегә борып куярга да сәләтле шул алар. Алга карап барган җиреңнән капма-каршы якка, кирегә таба юл алганыңны сизми дә каласың...

Мизгел эчендә булды ул хәл дә. Руль артына утырып, тигез генә җилдереп барган шәпкә, әллә нинди көч машинаны читкә алып атты. Монысын ул аңышмый да калды кебек. Күзен ачканда, кызы белән икесе дә йөзтүбән саклану каешларына эленеп торалар иде.

— Хәзер, хәзер, кызым, курыкма, яме, — дип сөйләнде ир. — Хәзер үзем ычкындырам мин сине... Курыкма түлке...

Ул башта үзен коллыктан коткарды да кызын сыңар кулы белән тоткан көенчә каешын ычкындырды һәм ачык тәрәзәдән иплән кенә чыгарып җиргә бастырды. Аның артыннан үзе үрмәләде.

Куркудан катып, аптырап калган бала, өч тәгәрмәче өскә әйләнеп яткан машинага төбәлеп, кинәт елап җибәрде. Дүртенче тәгәрмәч юл буендагы каенлык янәшәсенә үк барып ауган иде. Ир кул аркасы белән кызның күз яшьләрен сөртте. Бала әтисенең бармакларын чытырдатып кысты да нибары бер җөмлә әйтте:

— Әтием, әйдә Казанга, әнием янына җәяүләп кайтып китик... — Һәм

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА —*язучы; «Толымлы ай», «Догалы корт», «Еллар кәрваны» исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

ул, коңгырт күзләрен әтисенә юнәлтеп, тагын да кычкырыбрак елый башлады.

— Кайтырбыз, кызым, кайтырбыз, — дип сөйләнде ир, баланы юатырга теләп. — Тик син курыкма, яме...

Хәлнең шактый кискенләшкәнен тоеп, аны бераз йомшарту йөзеннән, ул бу нәни җан иясен алдарга мәҗбүр иде. Ышанычлы дустын — машинасын ничек юл кырыенда ташлап китеп булсын соң? Хәер, бик үк ышанычлы да булып чыкмады әле — ир шулай уйлады. Ул багажнигыннан башларына бөҗралар тагылган «буксир»ны тартып чыгарды, аны бамперның элмәгенә үк эләктереп куйды. «Мөгаен, рәтләп тә булмас инде моны» дип фикер йөртте.

Еракта-еракта таң кыелып килә, аның офыклардагы сүрән яктылыгы һәлакәтле юлга таралып-таралып төшә, кызның битендәге күз яшьләре энҗе чык бөртекләредәй җем-җем итеп ялтырап-ялтырап куя иде.

Ни дип шушындый зур юлга алып чыгып китте соң әле ул кызын? Әйе, Мәскәү күрсәтәсе килде. Укырга бара бит инде бу көздә. Мәктәптә укытучы сочинение яздырмый калмас. Бәлки әле, телдән генә дә сөйләтер. Әти-әниләрегез белән кайларда булдыгыз, дияр. Минем әтием безнең белән яшәми, дип басып торсынмы ул? Юк-юк, Мәскәүне булса да күрсәтеп әйләнер. Ничә еллар буена зур юлларда йөргән кешегә ни тора инде башкалага барып кайтуы. Аның каравы кызының да күңеле булыр...

— Яхшы карап йөрт, бала гына әле ул, алып чыгып киттем дигәч тә, дөньяңны онытма, — диде хатыны кырку гына. Кызын үзе китерде ул әтисе янына. Хәер, кыз әтисе өчен дә хөрмә төше кебек үзәктәге, кадерле зат шул... Шуны гомергә аңламады хатыны. Аннан, исәпләргә салсаң, ул Җир шарын ничә кабат әйләнеп чыгарлык юл үтте икән? Күптер, күптер...

Һәм менә ярты юлга килеп җиткәнче үк, алар кире борылдылар. Яхшы кешеләр очраса да, машинаны төзәтеп-тәртипләп юлга чыгарып куйсалар да, аңа ышаныч аз иде. Хәер, «буксир»ның кирәге чыкмады чыгуын...

— Язмаган булган, күрәсең, — дип кабатлады ир шыпырт кына. Бу аның гел әйтә торган җөмләсе иде. Ул барып җитмәгән берәр урын бар микән Рәсәй илендә? Хәтта якындагы чит илләргә дә барыштыра бит. Ә терәлеп торган Мәскәүгә җитеп булмады. Язмаган диме тагын ни дисең инде?

Ир шушы җөмләне беренче кат әйткән мәлен исенә төшерде. Бәлки әле, ул чакта ук телгә кертәсе калмагандыр? Әйткән сүз үрчемле була, ди бит. Бер үрчи башласа, таракан күк бөтен дөньяңны басып ала, ди.

Ул язылышу тантанасын күз алдына китерде. Таныш, җанга якын йөзләрне кабат хәтерендә барлап чыкты.

— Юныс, нишлисең син, Юныс?! — дигәннәрен ишетте. Кемдер сызгырды да бугай әле...

Тик балдакны ул кәләшенең атсыз бармагына киертеп өлгергән иде инде. Кәләше дә, елмаеп, сул кулын сузып торуын белде.

— Уң кулга кидерт! — дип кычкырды кайсыдыр.

Тик соңрак искәрде шул... Икесенең дә йөрәген ниндидер ят, салкын бер уй чеметеп үткән иде инде. Янадан балдакны салдырып уң кулга кидертү мәленең рәхәте дә, яме дә качкан иде.

Шунда ул беренче тапкыр эчтән генә: «Язмаган күрәсең...» — дип әйтеп куйды кебек.

Кояш инде сөнге буе күтәрелгән. Кабинага да аның җылы нурлары үтеп кергәндәй тоела. Җәйнең көзләргә авышкан чоры үз хасиятләре белән яши: алтын буявын бөтен җиһанга тарата. Басуларда инде игеннәрне көшелләргә салып яталар. Мондый чорны машина йөртүчеләр аеруча ярата, чөнки алай-болай юлда туктап калырга туры килсә, комбайнчылар да, тракторчылар да ярдәмнәреннән ташламый.

Бер тапкыр ул кышын батып калган иде шулай. Ничектер жир катканчы ук кар явып китте. Ир машинасы белән төзелешкә кирпеч илткән иде. Көн аяз, юллар коры булганга жайлы гына керделәр, шуна чыгу турында уйламады да. Төзүчеләр кирпечләрне бушатып бетергәнче, жепшек кар бөтен юлларны томалап куйды. Тәгәрмәчләр бер урында әйләнеп тик тора, машина бер карыш та алга китә алмады. Ул иске костюмын тәгәрмәч астына ташлап карады, тик тәгәрмәч аны кире әйләндереп чөеп кенә атты. Аннан иске халатлары тәгәрмәч астына төште. Берсенен дә файдасы булмады. Ахырда жүнле кешеләр, дөресрәге, бер тракторчы очрап, тарттырып чыгарырга туры килде.

— Әти! Күгәрчен! Ак күгәрчен!

Ир үзе дә ерактан ук күреп килә иде: ул тормозга басып тизлекне киметте. Ак күгәрчен, сынар канатын салындырып, юл кырыенда ук утырып тора. Кыз кабинадан сикереп төште дә, нәни кулларын уйнаткалап, күгәрченгә үрелде. Кош башта канатларын жиргә суга-суга талпынып карады, аннан, үзенә сузылган кулларның жылысын тоепмы, әллә артык барырга хәле юклыктанмы, йомгактай йомарланды. Башын кыегайтып-кыегайтып, әле кызга, әле анын әтисенә текәлде. Үзе кузгалмады да. Анын канаты сынык, сынар күзе чукылган иде.

— Туй күгәрчене бу, кызым! — диде ир, балага таба борылып.

— Туй! Нигә сон ул үзе генә?

— Алар, мөгаен, бер-берсен югалтканнардыр, кызым.

— Югалтканнар? Күктә дә югалтышырга мөмкин микән?

Кыз бу жөмләне нәкъ олы кешеләрчә итеп әйтте. Ир кызын андый ук тирән уйлар уйларга сәләтле дип башына да китергәне юк иде. Шунлыктан ул, тәмам сүзсез калып, кызга күз сирпеп алды да, чүгәләгән жиреннән кузгалып, машина ишеген ачты:

— Утыр, кызым!

Кыз, ак күгәрченне күкрәгенә кысып, әтисенә ялварулы карашын төбәде:

— Үзебез белән алыйк, әтием!

— Алабыз, әлбәттә. Аны дәваларга кирәк. Оча да алмый бит мескен.

Ир язылышу тантанасыннан сон учларыннан нәкъ шундый ап-ак күгәрченнәр очырып жибәрүләрен исенә төшерде. Ничек тантаналы төс керткәннәр иде алар туйга! Бөтен урамны яктыртып жибәргәннәр иде. Ул чакта күгәрчен язмышы турында кем генә уйласын икән сон?! Мәхәббәт куенынннан очып күккә күтәреләләр дә жиргә ничек килеп төшкәннәрен дә белмиләрдер, күрәсен, бахырлар.

— Әтием, анын канатын кем сындырган?

— Давылдыр, мөгаен.

Кыз кошнын бер якка салынып торган сынык канатын сыйпап-сыйпап куйды.

— Әтием, анын күзен кем чукыган?

— Жилдер, мөгаен.

— Жилнен томшыгы юк анын. Чукый да белми. — Кыз әтисенә үпкәле караш ташлады. Үзе сөйләнде: — Без сине дәваларбыз, кошчык. Минем әле шәһәрдә әнием дә бар. Табиб ул. Күзләренә дару сөртер, канатларына да...

Ир, рульне кысып тоткан көенчә, юлны йотып барган машинасыннан бер мизгелгә аерылып, кызы ягына борылды. «Бәхетле парлар кулыннан очкан кошчык түгелдер шул бу», — дип уйлап куйды. Бәхетле булырга язмаса, кош көенчә дә берни кыла алмыйсыңдыр... «Язмаса...»

Ир янә бәхетле чакларын күз алдына китерде. Берәү дә шулхәтле чыгымнар күтәреп, аерылышырга дип өйләнешмидер. Ә менә язмаса...

Туйдан соң алар Юныснын туган авылына кайттылар. Әниләре улының бәхетенә куанып елады да елады. Үзе кәстрүл тутырып итле аш салды. Токмач басарга әзерләнде. Яшь килен, таска тутырып, мунчага керләр уарга китте.

Кыш яшь киленнән аяк астына гүя ап-ак мендәр салган. Талгын гына җепшек кар ява. Бакча артындагы мунчага гүя мамык мендәрләргә баса-баса гына атлады ул. Аяклары йомшак, тантаналы рәхәтлектән иркәләнде. Нәзек кер баулары калынаеп, Яңа ел гирляндасына охшап калган, ап-ак агач ботаклары юанаеп киткән иде. Авылда кышның да үз яме шул!

Юныс анын хәлен белештереп кереп-чыгып йөрде. Кечкенә тәрәзәдән сүрән генә яктылык төшкән төссез, аулак мунчада чибәр хатынын кочагына алып, иреннәреннән үпте. Сабынлы куллары белән хатын да иренең битләреннән сыпырды.

Икенче әйләнеп керүендә, хатыны ике кулы белән мунча идәнен сыпыра иде. Ире кергәч тә күтәрелеп карамады.

— Югалттым бугай, — диде ул, еларга җитешеп.

— Нәрсәне?

— Балдакны югалттым... Шылтырап шунда гына төшеп киткәндәй тоелды...

— Борчылма бер дә, табарбыз... — Юныс үзе дә идәнгә иелде. Су ләгәннәрен күчерде, чүмечләрне урыныннан кузгатты. Эзли-эзли тәмам күздән язгандай тоелды. Ләүкә асларына кереп китте. Идән ярыкларын актарды. Балдак табылмады. Ул тураеп басты да хатынын кочып алды: — Димәк, язмаган... — дип куйды. — Әйдә, борчылма, яңасын алырбыз...

— Әниләргә әйтмә, белми калсалар яхшырак булыр...

— Килештек, — диде ир, хатынын янә кочагына сыендырып.

Алар югалту каршында икесе дә чарасыз иде. Югалырга дигән югала икән инде ул...

— Әтием, анын, бәлки, ашыйсы киләдер. Әйдә, ипи ваклап бирик без аңа.

— Бераздан тукталып ял итеп алырбыз, кызым. Шунда ашатырбыз без аны. Аз гына түз, яме.

Кыз, ризалашуын белгертеп, башын селкеде.

Ир тагын уйларына бирелде.

...Шуннан чып-чын тормыш башланып китте. Бик озак эзли торгач, бер тулай торактан вакытлыча тору өчен фатир таптылар. Тугыз квадрат метрлы гына булса да, эштән соң кайтып ятарга агач башлы бер караваты, утырып ашарга өстәл-урындыклары бар иде. Түгәрәк тормыш, мәхәббәт бар иде кебек. Тик акча юк иде... Тик акча кирәк иде...

— Әйдә минем балдакны ломбардка тапшырыйк, барыбер ялгызы шкафта ямансулап тик ята, — диде ир беркөнне.

Хатын бераз уйларына батып, тәрәзәгә төбәлеп торса да килеште. Акчасын сөенә-сөенә тоттылар. Хәер, кире барып алырга исә янә мөмкинлекләре булмады. Шул көе ике балдактан берәү дә калмады.

— Димәк, язмаган, — дип юатты ир үзен.

Тик акча һаман кирәк иде. Күбрәк кирәк иде...

Хатынының күз карашы аңа табын янында үтергеч тәэсир ясый, ул үзен убыр авыздай хис итә иде. Әйе, белә, дулап түшәмнән туфрак коя торган хатын түгел инде ул түгелен, әйтәсен карашлары белән генә әйтә.

— Акчалы эш эзләргә!

Ир бу сүзләрне атна буена, айлар буена кабатлады. Тик эше бар, акчасы гаиләне нибары шушы халәттә яшәтерлек кенә иде.

Беркөнне ир урекпәрвәр күнеленә юаныч булырлык эш табып кайтты. Бер шәхси оешмада аны дальнобойщик итеп алабыз диделәр. Әлбәттә,

беренче чиратта акчасы кызыктырды, чөнки моннан да төшемлерәк эшне ул күпме эзләсә дә таба алмас иде.

— Димәк, өйдә торырга язмаган, — диде дә, озын «КамАЗ»га прицеп тагып, товар төяп, Себер якларына чыгып китте.

Көн-төн барды ул, атналар барды. Алда тәрәзәләр һәм юллар иде. Тәрәзә һәм юллар аның бөтен тормышы иде. Тормышының мәгънәсе иде...

Эш җанлы күнелен басу өчен дә акча кирәк иде шул. Хатыны каршында үзен ир заты итеп санар өчен бердәнбер юл шушыдыр мөгаен...

— Әтием, күгәрченнен дә, минем дә ашыйсым килә.

Ир сискәнеп китте. Күпме килә сон ул шулай уйларга бирелеп?! Гомеренә бер тапкыр кызын олы юлга алып чыгып китте дә, игътибарын уйларына юнәлтеп, һаман үзе турында гына кайгыртып бара түгелме?

Ир, машинаны юл читенәрәк чыгарып, тормозга басты. Кыз машинадан сикереп төште дә күгәрченне чирәмгә куйды. Күгәрчен сынар канатын җилпеп-җилпеп карады, оча алмады. Аннан, башын бер якка борып, сынар күзен кызга төбәде.

— Калдырмагыз мине, дип әйтә ул, әтием...

— Калдырмыйбыз, дип әйт, кызым...

— Син дә кызганасынмы аны, әтием?

— Кызганам, кызым...

Ир чирәмгә җәймә җәйде. Юлда ашарга алган тәм-томнарны чыгарып тезде. Кыз, ипи янчыгын чишеп, кош алдына ипи валчыклары салды. Күгәрчен сынар күзе белән ризык эзләп бер якка иелгән саен чирәмгә тәгәрәп китә, аннан торып янә валчыкларны чукыштыра иде.

Кызы янәшәсендә булу ирнең үзенә дә куәт кертеп җибәргәндәй тоелды. Күнеле тагын да нечкәреп китте.

Көн чалт аяз, күкләр шундый биек, анда берән-сәрән генә ак болытлар йөзә иде.

Ул кызына тутыкмас термостан чәй салып бирде. Кулына «Сникерс» конфеты тоттырды. Тик кыз чәен бер генә йотып куйды да һаман күгәрчен тирәсендә кайнашты. Әле учларына сыендырып күкрәгенә кысты, әле чирәмгә төшерде.

— Кыбырсык, усак яфрагы булдың инде тәмам, — дип елмайды әтисе, аның башыннан сыйпап. — Әйдә, чәенне эч тә, аннан кузгалабыз...

Ул үзен яна гына әти булган кешедәй хис итте. Менә ничек рәхәт икән ул үз баланны тиргәп алулары! Хәер, тиргәү дә түгел инде, әтилекне сиздереп эндәшү генә. Аерылышканга да өч, юк, дүрт ел икән бит инде. Күп нәрсә онытылган, дип уйлап куйды ир.

Алар янә җиңел машинага кереп утырдылар. Янә кузгалып киттеләр.

Күгәрчен, рәхмәт әйтергә теләпме, кызның кулын чукып алды.

Кыз «ай» дип кычкырып җибәрде. Әтисе көлде.

— Яратты бу сине, кызым, — диде.

Кыз да әтисенә кушылды. Машина эче шат авазларга күмелде. Күгәрчен дә гөлдер-гөлдер гөлдерәп куйды.

Аннан янә тынлык урнашты.

Машина үз юлы белән җилдерде. Ир гүя үз юлы белән китте.

«Яратам... Һаман яратам бит... Мәхәббәтне юк дигән булалар, бар икән шул ул, бар... Югыйсә онытырлык вакыт үткән бит инде. Ә мин һаман ерактагы бәхетемнең шәүләсе белән яшәп ятам түгелме?»

Ул аның шәмдәй төз гәүдәсен күз алдыннан үткәрде, очкындай карашлары белән очрашкандай булды. Югыйсә шул озын юлларда кемнәр генә очрамады! Акча хакына, җанын яки тәнен сатарга дип, юл чатына чыгучыларның күплегенә дә исләште.

«Саталар, сатылалар, – дип уйлады ул. – Мәхәббәтне дә, гаиләне дә, балаларны да акчага саталар. Шунысы сәер: җир йөзендә сатылмый торган бернәрсә дә юк, ахрысы. Һәммәсе сатыла! Бер белдерүсез дә сатыла...» Шул мәлдә аның кинәт бөтен тәне куырылгандай булды: үзе дә якыннарын, дөресрәге, гаиләсен сатты түгелме соң ул? Акчага алмаштырды бугай, аракыга сатты... Әллә хатыны анламадымы? Сабырлыгы житмәдеме? Хатын-кыз бик сәер зат бит ул: акчалы да буласы килә, мал табучының, үзен иркәләп, янында гына торуын да тели. Тик тормыш таләпләре нигәдер гел башкачарак икән шул.

Бу нисбәттән ирнең дә үз кануннары барлыкка килде: ир-ат акча табарга, ә хатын-кыз һәммәсенә сабырлык күрсәтергә тиеш...

Ә сабырлыгы сынса? Анысын ирнең уйлыйсы килми иде. Ул сыңар күзле күгәрченгә карап алды. Кош кызының итәгенә йомарланып утырган да сынар төртке күзен йомып йокыга талган. Сыңар канатлы, сыңар күзле булса да, күңеле катмаган, ана да наз кирәк, күрәсең.

– Әти, син күгәрченне яратасынмы?

– Яратам...

– Син аңа «Кэтикет» алып кайтырсыңмы?

– Аны мәчеләр генә ашый, кызым...

– Алайса, ипи ваклап бирербез...

«Сабырлык булса булыр икән кошта да», – дип уйлады ир. Хәер, яшьлегендә ул да илгизәк хисләрен йөгәнли алмагандыр, хәзер генә, сыңар канатсыз, күзсез калгач кына шундыйга әверелгәндер...

Сабыр итә белмәде шул хатыны да. Югыйсә яшьлек җуләрлеге аркасында бөтенесе. Ә яшьлек ялгыша! Ялгышырга яшьлеккә куш инде...

– Арыдыңмы, кызым?

Кыз, карашын күгәрчененнән кубарып, бармагын иреннәренә тидереп, әтисенә борылды:

– Т-с-с, йоклый ул.

– Синең йоклыйсың килмиме соң, кызым?

– Килә дә... Аннан күгәрчен итәгемнән егылып төшәр бит. Икенче канаты да имгәнер. Мин түзәрмен, әтием!..

– И багалмам минем!

Ир, елмаеп, сыңар кулы белән кызының чәчләреннән сыйпады. «Ничекләр сабыр бу бала. Әнисенә охшамаган... Нечкә күңелле. Кайлардан килгәндер аңа нечкә күңел? Шәһәрдә туып-үскән бала бит ул йолдыз санап үсми югыйсә, чәчәкләрнең исе барлыгын да белми, төсләренә дә ушы китми. Аларны күрми дә диярлек. Шәһәр төтене эченнән ничек йолдыз күренсен ди инде? Димәк, үземә охшаган... Кан тартадыр шул...» Бу сүзләрне ул, әлбәттә, кычкырып әйтмәде.

Хатыны ерак юллардан озын-озак чакрымнар аша үтеп кайтуын бер дә сөенеп көтеп тормады кебек. Кем белә, әллә көткәндер дә... Көтеп кенә бетерә алмагандыр...

Турыдан-туры өйгә кайтып керә алмады шул, бу хәлне гадәткә әверелдерде. Хәер, ул эшләгән оешманың гадәти тәртибе шундый иде.

Оешма ишеге төбендә рейстан кайтып төшүчеләрне карга көтүедәй бердәм каршы алучылар күп булды. Дуслар инде. Авызлары – колакта, колаклары еракта иде.

Ир, шул мизгелләрне күзаллап, үзалдына елмаеп куйды. Машина оешма ишеге төбенә якынлашуга, төркем, тәмәкеләрен җиргә ташлап, шуны аяклары белән изә-изә шаулаша башлый һәм борчаклардай сибелеп китә, аннан кабат бер әйләнә булып кысыла иде. Ир беренче мәртәбә рейстан кайтуга шуңа төшенде: мунчалар ягылган, тавыгын-савытын дигәндәй сумкага тутырып чыгасын да, шушы төркемгә иярәсең... Һәм ул иярде.

— Кайнар ләүкәләрдә жебеп, ял итеп, нерв күзәнәкләрен тәртипкә китерергә кирәк, — диделәр чөнки дуслары.

— Бәлки, кирәктер дә, — дип кабатлады ир. Ул бу мәлдә дусларының тәкъдимен кире кагарлык халәттә түгел, артык арыган иде шул.

Юлда ниндидер бурлар төн уртасында черем итеп кенә алырга дип тукталгач, аның ярты товарын бушатып киткәннәр иде. Дөрес, ерак китәргә өлгермәгәннәр. Милиция постында машинасын калдырып, шунда милиция чакыртып, артларыннан тиз куып життеләр. Ул бу хәлне шушы тирәдә тукталган машиналы товар ташучыларга сөйләде.

— Ай-һай, дөрес эшләдең микән, бу юллардан алар сине кабат үткәрмәячәкләр бит, — дип, жанына шом төшерделәр шунда.

Ирнең бу мәлдә түбәсеннән пар күтәрелде.

Талчыккан сынын, каешланып каткан өс-башын менә хәзер үк каядыр ташлап калдырасы килә, дәвамлы тоташ юллар аны тәмам кешелектән чыгарган. Мондый хәлдә үзе булып калырга Алыпларның да көче житмәс иде, мөгаен.

Озын юлларга бик озакка чыгып китте шул ул. Инде менә, ниһаять, исән-сау кайттым, диясе килә иде. Өйдә аны хатыны белән кызы көтә. Күнеленең сынар канаты алар ягына талпынып караган иде дә сон, сынар канат белән ничек очып булсын инде?

Ул хатынының төннәр буена керфек какмый чыгуын да белә. Менә кайтыр, менә кайтыр, дип көтүен дә белми түгел. Тик озын юлларны һич тоткарлыксыз үтеп була, хатынын уйлаган мәлдә коштай очып барганын үзе дә сизми кала, ә кайтып житкәч кыенрак...

— Сине көтми ул, хатын-кыз акча көтә, — диләр аңа дуслары.

Ирнең сүз озайтасы килми, сабыр гына төркемгә иярә.

— Теге дөньяда сират күпере аша да үтәсе бар. Кылдан нечкә, диләр аны. Хатын янына кайту сират янында пүчтәк кенә, — дип көлделәр төркемдәшләре. — Кайтабыз бит әле барыбыз да...

Оекбашларын табып кия алмый торган ир затларының бу рәвешле хатыннарын санга сукмый сөйләшүе кайчак аның ачуын да кабарта, йөзләренә берне кундырасы килеп китә, тик ниндидер көч аны үзенә буйсындырып тотып кала. Ул үзе болай ук түгел бит әле югыйсә. Еш кына ялт иттереп идәндәге паласларның тузанын суыртып куя, аяк киемнәрен кремлап, караштырып кына тора.

Нибары бер көнгә соңлабрак кайта ул — бөтен гөнаһысы менә шушы. Нибары бер көнгә!

Бусагадан атлап керүе була, хатынының күз яшьләре тәгәрәп төшә. Ул күз яшьләренә бик ышана, хәтта курка да.

«Хатын-кыз күз яшьләре аша теләсә нинди ялганга ышандыра ала. Хатын-кызның бу хәйләсенә бер генә ир-атның да төшенгәне юк әле», — диләр дуслары. Белеп әйтәләрме алар моны, юкмы? Нигәдер күз яшьләрен сөртәсе килеп үрелгән кулларын ул, шушы жөмләләрне хәтерләп, кире төшерә. Алар да хаклыдыр, дип уйлый.

Әлбәттә, ир бераз кызмача була. Әлбәттә, янынннан да саф, хуш исләр генә аңкып тормый.

— Мин сине үз гомеремә бер генә көн булса да аек күрә алырмынмы, юкмы? — ди хатыны.

Ир аптырып китә. Хатынының күзләренә карап тора. Ничек инде? «Айлар буена юлларда йөрепме» дип фикер йөртә. Юлда исереп йөрү мөмкинме? Аек көенчә дә нинди генә хәлләргә юлыкмыйсың... Ярый караклар сагалаячак, дигәннәре дөрес булып чыкмады. Барыбер шул тирәгә якынлаша башласа, йөрәге төшеп киткәндәй тоела, тәмам йокы басса да, милиция постына барып житкәнче машинасын туктатмаска тырыша.

— Аек чагынны күрерменме берәр? — дип кабатлый хатыны.

— Күрмәссен, сөеклем, анысын юллар күрде, алар шаһит, — ди ул, бер тамчы да акланасы килмичә.

«Минем айлар буена аракы түгел, чәй дә эчә алмаган чакларым күбрәк, анысын ул белергә дә теләми», — дип үртәлә үзе эчтән генә.

Хатыны анын саен ярсый:

— Алкаш бит син! Алкаш белән үткән гомерем жәл, — дип сулкылдый-сулкылдый, мендәренә үк каплана...

— Әтием, син күгәрченне сагынырсыңмы?

— Сагынырмын, кызым...

— Син безнең янга килерсеңме?

— Килермен, кызым...

— Аннары безнең белән яшәрсеңме?

— Белмим, кызым...

Бала күзләрен тутырып-тутырып әтисенә карап тора. «Ничек көчле бит ул минем әтием», — дип уйлый булса кирәк. Машина белән капланганда да бер жәрәхәтләнгән жире булмады бит. Куркып бераз елап алды инде алуын. Әтисе янәшәсендә ул, мөгаен, бөтенләй курыкмаска да өйрәнер иде әле.

Бер тапкыр ул шулай бер көнгә генә түгел, ике көнгә сонлап кайтты. Куркып кына иртүк өй ишеген ачып керде. Гадәттәгечә, шыпырт кына:

— Кызым! — дип эндәште. Шулай эндәшкәндә, кызы кай арада уяна, йөгереп килеп муеныннан ук кочып ала торган иде. Ә ул аны күтәргән көенчә битләреннән үбә-үбә иснәде. Һай, татлы иде сабыеның исе! Дөньядагы бер генә искә дә алыштырышлы түгел иде шул. Тик бу юлы тавыш-тын ишетелмәде.

— Кызым! — дип кабатлады ул янә, аяк киемнәрен сала-сала. Өйдә тынлык хужа иде. Ир курткасын салып та тормыйча түр якка үтте. Йокы бүлмәсенә кереп әйләнде. Кеше заты күренмәде. Аптырап, хатынының кесә телефонына басты.

— Сез кайда соң? — дип сорады ул, карлыккан тавышын көчәйтә төшеп.

— Киттек без, — диде хатыны.

— Кайда киттегез?

— Анысы мөһим түгел. Бөтенләйгә киттек... Оныт син безне... Юк дип сана...

Ир, ни дияргә дә белмичә, тәмам аптырап калды. Кинәт бөтен тәне калтырана башлады.

— Ничек була инде бу?

— ...

Хатын телефонын сүндерде.

Кичен аны кабат дуслары эзләп тапты. Подъезд баскычына чүмәшеп, ярты төнгәчә сыра чөмерделәр. Йокылы-уяулы көннәр шулай бер-бер артлы агып китә торды. Янә юлга кузгалырга вакыт житте. Һәр киткәнендә ул, мондый хәлләрне башка кабатламам, хатыным белән кызымны рәнжетмәм, дип антлар эчә. Бу рейстан исән-аман кайтсам, тормышымны өр-яңадан башлармын, дип үз-үзенә сүз бирә иде.

Инде менә жанын әрнүле хисләр бөтереп алды. «Нишләдем мин, нишләдем?» — дип, үкенечле газаплар эчендә адашып калды. «Югалтулар бик тиз икән ул», — дип көенде. Инде менә шактый гомерләр үтсә дә, хатыны бер генә жөмлә белән жавап кайтара: «Бер киселгән икмәк кире ябышмый», — ди.

Иргә нигәдер ябышыр кебек тоела. Чөнки ул юлларда төрле кешеләр белән очраша. Бөтенесе белән дә гаилә хәлләре турында сөйләшә. Бар

шундый очраклар. Ябышкан очраклар бар. Кемнәрдер ун елдан соң янадан кушылганнар. Үз каныбыз, дип куаныша-куаныша оныкларын үстереп яталар. Кемнәрдер алты-җиде елдан соң... Ирнең дә менә шундый язмышка ышанасы килә. Үзенә шушы тәкъдирне юрап яши. Бер генә хатын-кыз затына да күнеле ятмый шул аның. Күз алдына һаман үз хатыны килеп баса. Кызы елмаеп карап тора.

Инде аны хәзер оешма ишеге төбендә көтеп торучылар да юк, күбесен эштән җибәрделәр, кайберсе башка оешмага күченде. Хәзер инде ул үзе дә яшьлек юләрлеге белән яшәми, тормышка ачыграк күз белән карарга тырыша, чөнки бик тә, бик тә ераклашкан бәхетен кире кайтарасы килә. Тик...

— Әтием, син аккошны җәллисеңме?

— Күгәрченне дип әйт, кызым...

— Ак күгәрченне...

— Җәллим, кызым...

— Ә мине?

Ир аптырап кызына карап алды.

— Ә мине? — дип кабатлады бала.

— Синең бит канатың сынмаган, — диде ир.

Кыз авызын бүселдерде. Ир үзе әйткән сүздән үзе үк куркып куйды. «Хәер, минем балам да сыңар канатлы түгелме соң? Үзем дә сыңар канат белән очарга талпынып ятам түгелме? Хатыным да, сыңар канатына ышанып, күкләр катына җитәргә омтыламы?.. Тик сыңар канат белән кайларга барып булсын соң? Ул монысын беләме икән?»

Аның күз каршыннан сыңар күзле кешеләр үтеп китте. Кызы, хатыны... Авылда сугыштан сыңар күз белән кайтучы картлар бар иде ул үскәндә. Нигәдер шуларны исенә төшерде. Ул күзләрдән тетрәндергеч тирән фаҗига карап тора иде бит...

— Әтием, дәваласак, ул оча алачакмы?

— Белмим, кызым...

— Ә әнием беләме?

— Мөгаен, беләдер... Әниең врач бит, кызым...

— Ул очсын иде, әтием...

Ир, башын борып, ак күгәрченгә күз төшереп алды. Ул, сынык канатын салындырып, борынын кызының итәгенә төртеп, тирән йокыга талган иде.

* * *

Юлларны йота-йота машина алга чаба. Ярата шул ул бу юлларны. Аларсыз бер минут та яши алмас кебек тоела. Шуларны яраттырган өчен, хатынына ул рәхмәтләр укый-укый бара. «Әгәр башка кәсепкә керешкән булсам?» — дип, үз-үзенә сорау биреп караганда да бөтен тәне калтыранып китә. Кирәкми икән шул аңа башка кәсеп. Тик аның очасы килә. Сыңар канат белән талпынып тору очуга керми икән шул. Очар өчен кешеләргә дә ике канатлы булу кирәк икән.

Ир, моннан алты-җиде ел элек кызына сыенып утырган кошны хәтерендә яңартып, юксыну өермәсе эчендә калды. Кайларда икән ул кош хәзер? Аны дәвалаган иде бит хатыны. Һәм кызы белән икәүләп алар кошны ирнең үзенә китергәннәр иде. Кош, подъезд төбенә чыккач, көнбагыш чүпләде, кызы белән бергә бер атналап кунак булды.

— Кайдан алып кайтсагыз, шунда илтеп куегыз, — диде хатыны.

Ир, рейска киткәндә, машина кабинасына йомшак сөлге җәеп, кошны чыгарып утыртты. Кызы елый-елый кул болгап калды. Ир аны нәкъ үзләре алып кайткан җиргә төшереп калдырды. Кош канатларын җилпеп-җилпеп

торды да, әйләнә ясый-ясый, һавага күтәрелде һәм ерактагы кошлар төркеменә таба очып китте.

Ир рейстан бер-ике көндә үк әйләнде. Машинасы белән йорт ишегалдына килеп туктады. Подъезд ишеге төбендә бөрешеп утырган ак күгәрченне күреп иманеп китте: кош ерак чакрымнар үтеп, кире әйләнеп кайткан иде.

Сынар күзле күгәрчен, башын як-якка борып, һаман кызны эзләде. Ир шул көнне үк аны кызына илтә китте. Кошларга да җан җылысы кирәк икән шул.

Инде күпме еллар узган моңа. Ул юллардан кайтып төшүгә, башлап кызына шылтырата. Тегесенең юньләп аралашасы да килми кебек. Хатыныннан:

— Нигә ул минем белән кирле-мырлы сөйләшә? — дип сорый.

— Минем белән дә шулай сөйләшә ул. Үсмерлек чорына керде кызың, — ди тегесе.

«Әти юклык менә нишләтә, — дип уйлый ир. — Бу юлысы кайтам да соңгы кабат һәммәсен әйтеп салам... Нигә син үзеңне генә уйлыйсың, бала бит икебезнеке дә. Киселгән икмәк ябышмый, имеш. Бала хакына булса да, ябышсын иде бит... Аннан, мин сине генә яратам, бердәнберем... Һаман яратам...»

Ир карашын офыкларга төбәде. Еракта-еракта оя-оя кошлар төркеме очып бара иде. Кошларның да япа-ялгыз очасылары килмидер шул...

## Нәфес җиңүе

Көтмәгәндә... Бер сүздән башланды һәммәсе дә...

— Безгә аерылышырга кирәк, әтисе, — диде хатын күгәрчен гөрләведәй тавыш белән...

Ир гәзит караштырып диванда ята иде. Гәзите идәнгә үк шуып төште.

— Бу ни диюең? Ничек инде, тиктомалдан?..

Ирнең йөзе агарып китте. Диванга торып ук утырды.

Талчыктыргыч эштән соң алар шулай, залга кереп, икәүләп ял итәргә яраталар. Ир — диванда, хатын кәнәфидә иркенәеп телевизор карыйлар. Шунда экран аша тыныч кына дөнья хәлләрен күзәтәләр. Аннан хатын хезмәттәшләреннән ишеткән, үлгәнне дә терелтеп аякка бастырырлык рецептлар, аларны төнәтү ысуллары турында сөйли башлый. Бик тәфсилләп, үз-үзенә ышанып бәян итә ул аларны һәм, җәлт кенә кухняга чыгып, газ плитәсенә ут элдерә дә туп-тулы чәйнеген утырта.

— Кичә җиләкле яфракларың бик тәмле булды. Андый чәй бавырны чистарта дисеңме әле? — дип сорый ир.

— Бүген дә шунысын пешерермен, — ди хатын.

Икесенең дә бик озак, мәңге-мәңге яшисе килә. Аерым түгел, әлбәттә, гел бергә, гел шулай икәү...

Бүген ул хатынын танымады... «Ни булды икән бу бичәгә?» — дип уйлады.

«Бичә» дигән сүзне дә ул, бик озак еллар элек, эшендәге башкорт якларыннан килгән егеттән эләктереп кайтты. Ошатты да шулай эндәшә башлады. Хатыны да сүзне ачык күңел белән кабул итте. Колакка каты бәрелми сыман ничектер...

«Аерылышырга кирәк...», имеш...

Ир — үткен фикерле кеше, ләкин барыбер әлеге сүзнең җеп очын тотып ала алмады. «Ничек теленә керде икән бу галәмәт? Белеп лыгырдыймы ул? Сәбәпсез, тик торганда кайсы шайтаны котыртты икән соң минем бичәне?» — дип баш ватты.

— Безгә аерылышырга кирәк, — дип кабатлады хатын тирән тынычлык аша.

Иренен үзеннән гайре беркая китмәсенә чын-чынлап ышанган хатын-кыз гына мондый тынычлыкны саклый аладыр, мөгаен...

Ир дәшмәде. Ул, бөтен күнеле белән кызыксынып, сүзнен дәвамын көтә иде. Хатын да сүзсез генә сораулы карашын иргә төбәде.

— Син хәл иттенме инде? — Ир жөмләсен тирән шикләнү аша әйтте.

— Кирәк булгач... Син дә ризадыр ич...

Ир тагын тынып калды. Ниндидер куркыныч көткәндәй, йөрәк тибеше ешайды.

Хатынга да анын кинәт кенә күз төпләре зәнгәрләнеп киткәндәй тоелды.

Юлда кайтканда гына иргә бер танышы очрады.

— Туйдым ялгызлыктан, — дип куйды ул, сүз иярә сүз чыгып.

— Таныш-белешләрен арасында гаилә жылысына елышырдай берәр зат юкмы сон? — дип сорады ир.

— Беләсенме, — диде танышы, — кешеләр хәзер гел бүтән ич. Алар бер-берсенә бер генә тамчы да ышанмыйлар. Йә фатир югалтудан куркалар, йә жыйган байлыкларын чит кешегә исраф итүдән. Чөнки элеккечә ирләргә хатын булырга торучылар да, хатыннарга ир булырга теләүчеләр дә бик аз. Шуна ялгызлык ирләр өчен хатынны, хатыннар өчен ирне алыштыра да бугай...

Икесе дә сүзсез генә күзгә-күз карашып басып тордылар. Ир танышына ни дип әйтергә дә белмәде. Чөнки ялгызлыкнын ни икәнен анлаган-тойган кеше түгел иде шул ул. Юкка гына, кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә, димиләрдер... Танышы дәвам итте:

— Ялгызлыкны ярата башлыйсын бит ул аннары... Чын-чынлап яратасын... Шундый итеп яратасын ки... Хәер... ирекне кем генә сөйми икән?!

Алар кайчандыр бергә эшләгәннәр иде. Иренен әллә ни мөһим булмаган сәбәп белән анын өенә дә килгәне бар. Хәер, күп нәрсә хәтер иләгеннән иләнеп очып беткән, бары тик танышынын түшәмдәге ялгыз лампочкасына бармак калынлыгы булып утырган куе тузан гына күз алдында калган. Ул чакта ук түшәмнән төшкән сүрән ут анын тормышына сыек кына яктылык сирпеп азаплана иде бугай...

«Бугай...» — дип, теләмичә генә иреннәрен кыймылдатты ул.

Ир юл буена уйланып кайтты. Әгәр дә ялгызлык шулкадәр үк яман нәрсә булса, аерылышучылар көннән-көн артмас иде бит... Димәк, бик үк афәт нәмәрсә дә түгелдер әле...

...Һәм менә сина, мә!

— Сөмбелә килеп киткән иде... — диде хатын, жөмләсен төгәлләп бетермәстән.

— Болай гынамы?

— Аерылышуыбыз кирәк, ди.

Иренен янә кашы жыерылды.

— Кемгә?

— Кияүгә фатир бирмәкчеләр икән. Пропискадагы кешеләр саны житми ди.

— Шуннан нәрсә?

Газ өстендә сыбызгылы чәйнек сызгырды. Хатын кухняга юнәлде. Бөтен дөньяга пар бөркеп кайнап яткан чәйнеген сүндерде дә янә ире янына чыкты. Төнәтмә ясарга жыенганын да онытткан иде инде ул.

Хатын алай ук бер дә китап укымаган кеше түгел үзе. Китапларда да, киноларда да төрле катлаулы хәлләрнен юктан гына килеп чыгуын да белә ул. Әнисе дә әбисеннән эләктереп калган Коръән сүзләрен һаман-һаман искә төшереп кенә торыр иде, мәрхүмә. «Хатын-кыз һич сәбәпсез

иреннән аерыла алмый. Әгәр дә бер сәбәпсез аерылышуны таләп итә икән, җәннәтнең исен дә күрмәячәк», — ди иде.

Сәбәп бармы мона менә хәзер, әллә юк тамы? Хәер, балалар сорагач, ничектер ярдәм итәргә кирәктер бит инде. Юк-юк, әни кеше башкача уйлый алмый, уйларга тиеш тә түгел кебек тоела аңа. Яктылык — кояш янында, яхшылык — ана янында, диләр бит...

Ул, йомшак кына басып, кәнәфигә килеп утырды.

— Шуннан нәрсә? — диде ир канәгатьсез тавыш белән.

— Шуннан шул... Безгә аерылышырга кирәк диләр... Һәм мине үзләренә пропискага кертмәкчеләр...

— Заманча, һәммәсе дә! — дип куйды ир һәм эчтән генә дәвам итте: «туйдырды тәмам заманасы да...»

Гаиләсе эчендә кыйммәтләрнең җимерелә баруын үз күзләре белән күреп тору ирне чыгырыннан чыгарды.

— Безне катыштырмыйча гына булмый микән соң? — дип куйды.

— Булмый диләр бит...

Хатынга ирне ничек тә күндерергә кирәк иде. Әлбәттә, ризалатыр инде ул аны бер... Ир — имән, хатын — колмак, аны сарган да башыннан игән, ди...

— Кирәк булгач соң...

Икенче көнне аларга кызлары эштән кайтышлый, кичке якта кагылды.

— Уйладыгызмы, безне ашыктыралар, — диде ул.

— Уйламадык, — диде әтисе. — Кырык ел элек уйлаганбыз бит инде...

— Кәгазь бит ул, әти, фиктивный развод, — диде кызы. — Анда ни дип язсалар да, барыбер түгелме сезгә... Кырык ел яшәгәнсез бит әле... Сандык төбеннән алып бирәр караганыгыз булдымы шуны?..

— Мин риза түгел, — диде ир. — Картаймышымда мондый уеннарда катнашып йөри алмыйм. Сәхнә артисты булганым юк әлегә...

— Катнашып дип инде... Анда безгә нишләргә кирәк соң, кызым? — дип сорады хатын.

Кыз гаҗәпләнгән кыяфәт чыгарып бер карап алды да боерулы тонда:

— Судка гариза бирергә кирәк, — дип куйды.

Әллә нинди шомлы булып ишетелде бу сүз хатынга. Иренә күтәрелеп карады. Аның йөзендәге котсыз уйчанлык билгеләрен күреп, ул бераз каушап та калды. Тамчы елмаю чаткылары чыкмый бит йөзенә. Мөмкинме уенны шулкадәр чынга алу?

— Әйе, судка, — дип кабатлады кызлары. — Чөнки суд кына аерырга хокуклы. Аннан әни син безгә пропискага керәсең дә, эш тәмам дигән сүз...

— Мин каламмы? — дип борчылып сорады ир.

— Кәгазьдә бит ул, әти. Шуңа исең китте инде тәмам.

— Кәгазьдә, имеш... — дип сөйләнде ир һәм, җанына тынычлык эзләргә теләгәндәй, кухня ягына юнәлде.

* * *

Судка алар икәү бергә барырга чыктылар. Икесе бер сукмактан сөйләшми генә атладылар.

Көн җилләп тора. Җил вакыт-вакыт, даладагы дүнгәләкләрне куып йөргәндәй, икесен бергә этеп йөгертеп бара һәм өермә эчендә калдырып болгатып ала. Рәхимсез чәнечкеле җил чеметеп-чеметеп узган саен битләрен пәлтә якалары белән каплап, алар, кыш суыгына каршы тормакчы булып, артка карый-карый, һаман алга баралар. Интегеп атлыйлар. Мондыйда кеше өйдән чыгамы? Юлыннан сабарсын бит...

Ә алда ни көтә? Икесенең берсе дә моны белми. Чөнки ни гомер яшәп, хөкем каршына басканнары булмаган икән шул... Бик бәхетле яшәлгән кебек бит югыйсә... Икесе дә шул хакта уйлыйлар...

«Хатыннар камырны изәләр кичтән, унмаса – күрәләр мичтән, – дип фикерли ир... – Бер нәфсесенә баш була белмәде бу бичә. Һай нәфселе булды да соң!» Келәм кирәк, дип башлаган иде кайчандыр... Келәм юк чакларда, әлбәттә. Хезмәт хакын бер тәнкәлекләр белән биргәннәр иде бервакыт.

«Менә, бичә, мин сина акча келәме алып кайттым», – дип төргәк-төргәк берлекләрне идәнгә сипкән иде ул. Идән кәгазь акчалар белән тулды шул чакта. И көлгәннәр иде дә соң шунда рәхәтләнеп. Хәтта башка бер төрле келәм дә кирәкмәс кебек тоелган иде.

Тик барыбер үзенекен итте бичә, барыбер алдырды келәмне. Аннан башта көмеш алкаларга да риза хатынга тора-бара бриллиантлары кирәк булды. Чәшке тунга кызыкты, аннан чит илләргә чыгып китте, машина дип желеккә төште. Боларын шулай тиеш дип кабул итте бит инде ул. Ә хатынының үз гомеренә кимендә ике эштә эшләгән ире турында уйлаганы бердәнбер төнәтмәгә кайтып кала түгелме?.. Хәер, ризасызлык күрсәтүе түгел, шушы тормышка күнеккән иде бит инде...

Аның аяклары карыша... Гомернең салмак кына, тыныч кына үз көенә агуы рәхәт булган лабаса... Бүгенге көне сәер хәсрәтле сер белән тулгандай тоела.

«Житмәсә житмәс икән бу балаларга да... Без алып биргәндә яшәп яталар бит әле үзләре. Исәпләшмәсәләр исәпләшмәсләр икән ата-ана белән...» Уй уйлаганда да сулышы буыла, күкрәк читлеген нидер кыскан кебек була.

Хатынның башында да пәрәвезгә эләккән чебендәй уйлар безелдәшә: «Балаларга кирәк бит. Баласы суга төшәр, анасы утка төшәр, ди. Утка төшми хәлең юк... Ике бүлмәдә дүрт жан ничек сыешып яшәп бетсеннәр соң?

Әллә ни сорамыйлар ич алар бездән... Кешеләр әнә гомер буена артистлана. Өрлек кебек таза ирләр, бит алмаларында тук тормыш төсе тупырдап торган сау хатыннар – һәммәсе инвалид булып өйдә утыра. Ирле-хатынлы эшкә чыгып киткәндә, күршеләрне уятмаска тырышып, шыпырт кына, ачкычларны шалтыратмыйча гына ишек биклибез икәүләп. Ишетә күрмәсеннәр, имеш, берүк... Кешеләргә хәрәм килешә шул. «Хәләл акчага сатып алгач, хәрәм булмый ул», – ди күршеләре Самат. Бәлки әле, ул хаклыдыр да...»

Хатын, кашлары жыерылган, иреннәреннән кан качкан, күзләре кысылган иренә күз төшереп алган саен, эчтән генә сискәнеп китә. «Менә барырбыз да кайтырбыз әле... Аннан тагын бер кат таныклыкның янасын яздырып алырбыз», – дип уйлый.

Ир һаман тирә-юньдәге йортларның көпә-көндез ут янып торган тәрәзәләренә текәлә. «Кешеләрдә әле ут яна. Кешеләрдә тормыш бар...» дип фикерли булса кирәк... Әллә еракларда калган бәхетле, мәхәббәтле чорларны хәтерендә янартып барамы ул?

* * *

Бөек төзелешләр чорына эләкте аларның яшьлеге. Авыл балаларын аждаһа кебек суырып кына алды яңа шәһәр. Яшьлек шул, андагы билдән саз ерып йөрешле юлсызлыгына да, йорт-жирсезлеккә дә – һәммәсенә риза булдылар. Чөнки шәһәр әле төзелмәгән, ә ул төзеләчәк, чөнки бәхет әле табылмаган, ә ул алда иде...

Шәһәргә сыенып яшәп яткан, мич ягып өен жылыткан, ипи салган, мич түбәнә чуен тутырып итле борчак ашы куеп, муллыкта гомер кичергән авылга да шәһәр ыгы-зыгысы килеп керде. Төзүче булып эшкә кергән Сабирны оешмадан Гарәфетдин агайларга фатирга урнаштырдылар.

Гарәфетдин агай – мал врачы, ат җигеп авылдан авылга йөри. Сизелерсизелмәс бөкресен күзе күрмәгәнгәме, үзен гел яшь егетләрчә тота, һаман кызлар турында сөйләшә иде. Аның шушы шуклыгы Сабирга аеруча ошады.

Ул бераз төшереп йөрергә ярата. Кызарып, янып торган битләрен сыпырып куя да еш кына Сабирга мыек астыннан гына елмаеп сүз ката.

– Тәк... тәк... Синең кебек егетләргә миннән үрнәк алырга кирәк, туганым, – ди.

Ятимлекнең бөтен кыенын ашаган Сабир, аның һәр сүзенә колак салырга тырыша. Ул көр күңелле, тәбәнәк буйлы Гарәфетдин агайны үз әтисенә охшатыбрак ярата кебек.

Агайның әле ике буй җиткән кызы да бар. Чибәрлекләре чәчрәп тормаса да, әнкәләренә охшаганнар, тыйнак кына, басынкы гына кызлар алар.

Сабирга нурлы карашларын түгеп, өмет белән карыйлар...

Әлбәттә, Гарәфетдин агай да аңа үз кызларын мактый. Сабирга өйләнергә вакыт җиткәнен ассызыклап әйтеп кенә тора.

– Минем кызларга күңелең төшмәсә, авылда бер чибәргә өйләндерәм мин сине, – ди.

Сабир белә: авылда чибәрләр күп. Алар егет яныннан үткәндә һич тә тигез суламыйлар... Аның үзенең дә, гүзәлкәйләр яныннан узганда, өйләнер матди мөмкинлеге булмаганга уфтанып куйган чаклары булыштыра...

Гарәфетдин агай моны сизеп тора: ул егетне кергән бер йортта мактый. Ә мал врачы кагылмаган йорт авылда сирәк. Аларында, гадәттә, карт-коры, ятим карчыклар гына яши.

Ә беркөнне ул салган баштан авыл клубына килеп керде. Анда берничә кыз спектакльгә әзерләнеп репетиция ясап яталар иде.

Шаян Гарәфетдин агайның керә үтүе кызларга һәрвакыт ошый. Шаярышып, көлешеп, бер шаулашып алырга җай чыга.

– Безгә бер чибәр егет кирәк, Гарәфетдин агай, әйдә шул чибәр егет булып уйна әле, – диде аңа кызларның берсе.

– Чибәр егет кирәк дисез инде алайса... Тәк, тәк...

– Бик кирәк, Гарәфетдин агай.

– Тәк... тәк... Мин табам сезгә чибәр егетне...

Ул, каз оясы чаклы колакчынлы бүреген салып, башын кашып торды.

– Кирәк дисәгез, хәзер мин аны шушында алып килеп тә бастырам, – диде аннары. – Минем өемдә яши ул чибәр егет... Тәк... тәк...

– Килмәс шул, Гарәфетдин агай, бик горур күренә егетегез, – диде кызларның кайсыдыр.

Агай бәхәскә үтә дә һәвәс кеше. Бәхәс аның өчен җан азыгы.

– Әйдәгез, бәхәсләшәбез алайса, тәк... тәк... Бер яртыдан...

– Алып килә алмасагыз?

– Ул чакта мин сезгә бер яртылык акча бирермен... тәк... тәк... чәйгә...

Кызлар көлешә-көлешә риза булдылар.

Гарәфетдин агай шыпан-шыпан өенә юнәлде.

Ул кайтканда, Сабир төзелеш оешмасын урап кайтырга җыенып ята иде. Агай егеттән кай якларга табан юл тотуын сораштырды. Моңарчы булмаган хәл егеттә бераз сәерсенү тойгылары да уятты. Болай гына да түгел, агай егет белән бергә урамга ук чыкты, һәм, аңа ияреп, урам буйлап атлады.

Менә алар клуб янына килеп җиттеләр. Гарәфетдин агай тынычсызлана башлады.

– Әйдә клубка кереп чыгыйк әле, тәк... тәк... – диде ул, егеткә күтәрелеп карамыйча гына.

– Минем анда эшем юк бит, ни дип керим соң? – Егет сораулы карашын агайга төбәде.

— Китапханәгә керәбез, — диде агай. — Бер эш бар... Тәк... тәк...

Егеттә дә клубның бер почмагына урнашкан китапханәне күрәсе килү теләге уянып китте.

Монарчы Гарәфетдин агайның китап укыганын күргәне булмаса да, ул «китап» дигән сүзгә алданып, берсүзсез ризалашты.

Ишектән керүгә, Сабир китапханәдәге кызларның сәерсенеп елмаешуларын күреп алды.

— Син оттың Гарәфетдин абзый, — диде шунда кызларның берсе.

Егет бу мәлдә Гарәфетдин агайның ниндидер бер шуклык майтаруын сизгән кебек булды. Әмма хәлне кызларга сиздермәскә тырышты, шуңа ул теләнә килгән бер китапны сорап алды. Ашыга-ашыга битләрен актарыштырды. Аннан:

— Иртәгә килеп алырмын, ерак куймагыз, — дип, тиз-тиз чыгып китте.

Кичен агай өйгә шактый кызмача кайтты.

— Син күрдеңме анда безнең чибәрләрне? — дип ыржайды ул.

Егет елмайды. Чөнки ул, чынлап та, арадан берсен — гүзәлләрдән гүзәлен күреп алган иде...

Аның ай тик кашлары, ай нурларыдай керфекләре, елмаю килешкән якты йөзе егетне тәмам әсир итте. Әйтерсең ул шул мәлдән тоташ нурдан торган башка бер планетада яши башлады...

Кызның һәр сүзе колагына, юк, йөрәгенә назлы җилдәй бәрелә иде...

Тик егет теге хәлдән соң бераз унайсызлану кичерә: юлында кызлар очраса, алар эчтән генә пырхылдап көлеп җибәрәләрдер сыман иде. Хәтта тәрәзәдән берәр кыз күренсә, ул да егеттән көлеп каладыр кебек тоелды. Шунадырмы, күңеленнән отылу мизгелләрен көлкегә санап, елмаеп үткәреп җибәрсә дә, бу авылда озакламаска карар итте. Барыбер дә үзен күкләргә күтәрерлек мәхәббәте белән табыштырган Гарәфетдин агайга, яшьлеген сындырган шушы кечкенә генә авылга ул чиксез рәхмәтле иде.

...Һәм үзе яшисе тулай торакка китапханәдә очраклы очраткан чибәрне — сатучы кызны да алып китте. Кыз да аны мәңге-мәңге яратырга вәгъдә бирде...

* * *

«Тормыш юлы мәхәббәтсез башланмаган да кебек, уйлап карасаң. Балалар үскән. Һәммәсенең үз тормышы бар. Оныклар әби, бабай дип өзелеп тора.

Фатирлар алынган... Кошлар да үз оясын үзе туздырмый. Һаман йон булса да эләктереп кайту ягын карыйлар. Нишли бу бичә, ә? Нинди нәфсе бу аңарда?»

Ир, шулай уйлый-уйлый, хатыны артыннан атлый.

Алар икәүләп судка баралар...

Хатын да уйлый...

«Хөкемдарлар каршысында авыз ачып торсаң, балаларны фатирсыз калдыруың да бик мөмкин... Эчә диярмен. Әллә дөрес түгелме? Әллә түгәме?! Ярый мин эләккән аңа һәммәсенә түзәргә... Хәзергеләр булса түзәрләр иде, бар...»

Ул хәтта дуңгәләктәй өертеп йөрткән җилгә дә игътибар итми. Кай якка куса, шунда барырга риза кебек тоела... Ә җил вакыт-вакыт урыныннан купкандай котырынып-котырынып ала. Этә дә чеметә, тузгый да өшетә...

«Балаларны тәрбияләштеме? Атасыз балалар кебек үстеләр... Үз гомерено бер мәртәбә җыелышларына барганы булмады. Өйгә эшләрен эшләштеме? Көндәлекләрен дә ачып карамады. Әле дә укыдылар инде алар...»

Хатын тирән итеп сулыш алды.

«Суыткыч шыр буш. Мин алып кайтканны утырып ашарга булдыра тагын... Өемә килсәләр, хөкемдарларга да ачып күрсәтә алам бит мин аны. Үзенә һаман тәмле кирәк... Гомергә сумка күтәрмәде... Һай, мин дә яшәгәнмен икән ир белән...»

Хатын, үзе дә сизмәстән, иренә ерткычлар күзе белән текәлде. Мәкер, нәфрәт тулы карашны ире, әлбәттә, күрмәде. Күрсә дә аңламас иде әле ул тиз генә...

«Берәр тапкыр балаларга кием алганы булдымы? Каникулларында берәр мәртәбә театрга алып барсын иде, ичмасам! Әле дә үстеләр инде...»

Юлда хәлсезләнеп яткан кар бөртекләрен итек очлары белән очыртып, канализация торбалары өстендә бөрешеп яткан маэмайлар яныннан үтеп, һаман үз юлы белән барды хатын... Башы тулы уй. Шуңа ул аларның берсен дә күрми... Уйларын гына күрә кебек тоела...

«Ни алып кисәм дә көнләште... Алып бирмәве бер хәл, эшләп тапканың белән ярап булмады...»

Җил кайчак аның уйларын өзә. Хатын йотлыга-йотлыга, артына борылып, тирән итеп сулыш ала. Аннан арт белән бара башлый. Иренә карамый гына атлый.

«Бер җылы сүз ишеттемме? Хәер, хәзерге ирләр тумыштан тупаслар, аларда кайдан хис булсын соң?»

Шулкадәр дә яман ир белән торганына хатын гаҗәпкә калды. Ничек монарчы бер кат та бу хакта уйлап карамаган икән соң ул?

Дымлы кар бөртекләре аның ирен читләренә кунды, салкын җил пәлтә эчләренә үк кереп эреде, гүя кыш хатынны салкын сулышы белән әфсенли иде... Тик хатын әфсенгә бирешмәде.

«Гомер әрәм үткән...» дигән нәтиҗә чыгарды ул. Тик ул боларның берсен дә чынбарлыкта иренә сиздерергә теләми, бөтенесен дә уен итеп кенә күрсәтәсе килә иде.

Ир дә дәшмәде.

Ул балачагын күз алдына китерде. Әти-әнисе, үзе көтү көткән кин болыннар, утын кискән-ярган ишегалды, мунчага су ташулар исенә төште.

«Ә бит безнең балалар боларның берсен дә эшләмәде. Безнең әнкәйләр баланы тормышка әзерләгәннәр, ә без һаман аларга тормыш төзеп бирәбезме? Дөресме бу?

Балаларга яхшы булсын дип эшләгән эшләр һәрчак яхшы булмаска да мөмкин бит әле... Ничек аңламый шуны бу бичә?»

Урамда исә буран дулады. Салкын буран үз юлы белән бөтен дөньяны себереп бара, кешеләрне бар дип тә белми иде...

* * *

Судта хатын соңгы җөмләне әйтте: «Мин боларның бөтенесенә түзеп яшәргә тиешме?»

Ирнең хатыны сөйләгәннәрдән колаклары салынып төште.

«Без менә ничек үзгәргәнбез! Кешеләр тора-бара бер-берсенә якынаеп бетәләр, ә без һаман ераклашканбыз түгелме? Әллә арага фатир кердеме соң? Нәфсе мәхәббәттән дә көчлерәкме әллә? Мәңге-мәңге яратырга сүз биргән сылу шушымы ул? Әллә аны алыштырып куйганнармы?»

Ул бары тик шулай гына уйлый ала иде.

Җил иссә, агачка агач та бәрелми калмыйдыр шул... Тормыш булгач булгандыр...

Хатын үткән-беткәннәрне җепкә тезгәндәй тезде дә тезде. Берсен дә

төшереп калдырмады. Анын бөтен вөҗүденә тулган салкын нәфрәт гүя галәбәле залны басып китте. Мона чыдап торышлы түгел иде. Ирнен күз аллары карангыланды, шул мәлдә ул үз-үзен кулга алырга кирәклеген аңлады.

Иргә дә соңгы сүзне әйтергә мөмкинлек бирделәр.

– Бинауат, – диде ул, шактый дәшми торгач.

– Соңгы сүзегез шушымы Сезнен? – дип сорады хөкемдар.

– Соңгысы менә шул: (ул хатынына текәлде) мин синең икенче иреннең миннән бәхетлерәк булуын телим...

Хөкемдар йөзеннән борчылу карангылыгы саркылган бичара кыяфәтле иргә шаккатып карап торды. Гүя анын йөзенә «Шундый тәрбияле ирләр дә ярамый бит, ә» дигән җөмлә язылган иде.

Ир нигәдер бу мәлдә Гарәфетдин агайны, анын басынкы гына ике кызын күз алдына китерде... Ник икәнен үзе дә аңламады...

«Тәк... тәк...», – дип кабатлады ул эчтән генә...

* * *

Ир хатынын көтеп тормады. Җәһәт-җәһәт атлап, залдан чыгып китте. Тышта буран да басылган, кич дөм караңгы иде. Ул, ниндидер яктылык күрергә теләгәндәй, тәмәкесен кабызып җибәрде... Сүрән генә янса да, тәмәке уты гына булса да, ут иде әле ул... Кай тарафка төбәлгәнен белмичә аптырап торган ир гүя еракка-еракка китәсе юлны шәйләде...

Ә хөкемне аларга Аллаһы Тәгалә үзе чыгарды. Ничек кенә бер-берсенә якынаерга теләсәләр дә, соңгы сүзләр әйтелгән иде инде...

## Себердә

Тәпиләрен тимер рельсларга кыйный-кыйный, авыр сыннарын тигез хәрәкәткә буйсындырып, поездлар бер-бер артлы үтеп кенә тора. Кырыгарниллешәр вагон тагылган товар эшелоннары узган саен, шәһәр, яудан исән калган сугышчыдай, сөенечле тынлыкка чума.

Чөнки бу хәл теләсә кемнең күңеленә шом салырлык булып тоела. Өйләр менә-менә ишелеп төшәр кебек: караватлар сазга эләккәндәй әле тетрәп, әле тибрәлеп куя.

Юлда ук без мондагы сазлыклы җирләрнең тотрыксызлыгын сизеп киллек. Тик юллар кайда да юлдыр инде ул. Алар мосафирларны алга табан әйди.

Без үзебез дә шушы тимер юллардан үтеп, ерак Себернең караңгы урманнары уртасындагы кайнар күлләрен эзләп шушы тарафларга килеп чыктык.

Поезд тәрәзәсеннән карап барган мәлләр искә төшсә, бераз шомлы булып китә: бөтен тирә-як бушлык һәм сазлыклар. Алар, поезд белән бер-берсен куыша-куыша, һаман каядыр йөгерәләр. Елтыр күзле сазлыклар кайчакта бу тарафтагы һәммә нәрсәне йотып куйганнардыр да инде безнең поездны гына көтеп торалардыр кебек тоела. Тик сазлыклар беркемгә дә тими икән. Монда да кешеләр яши икән.

Без килгән шәһәр Ук дип атала. Хәер, шәһәр дисәң дә инде, монда агач йортлар күбрәк һәм без аны үзебезчә «авыл» дип атыйбыз. Янәшәдә генә Ук елгасы да агып ята, ди, монысын без фатирларга урнашып алгач кына ишеттек.

Авыл кешеләренә:

– Бу атаманың ни аңлатканын беләсезме? – дип сорау бирдек.

Әлбәттә, белми иде җирле халык. Алар үзләренең нәсел-нәсәпләрен дә, кай тарафлардан килеп утырганнарын да, бу төбәкнең зур тарихын да онытканнар, бу хакта артыгын кызыксынырга да теләкләре юк иде сыман.

Тик безгә бик тә якын иде шул бу атама. Ул безне тирән тарихыбызга бәйли, шушы кинлекләрдә меньяшәр наратларның ябалдашларына йөз текәп, жир өстендә горур басып йөргән Күчем ханнарны, табигатькә береккән затлы халыкны искә төшерә.

Без фатир төшкән йортта гел хатын-кызлар гына тора икән: Анна карчык, анын кызы Лена, оныгы Олеся. Тагын берәү — өч яшьләр тирәсендәге курчак кебек тәти, Маша исемле кызчык та бар иде әле анда. Монысы Анна карчыкның улының баласы икән.

Анна карчык татар кешеләрен фатиргa кертергә атлыгып тора.

— Бик чиста халык, анакаем, корымга баткан бөтен кәстрүлләремне ялтыратып бетерделәр, — ди.

Чөнки монда килгән кешеләргә ул аш-су әзерләргә үзенең табак-савытларын биреп тора. Ашарга утыргач: «Пычак кирәк иде», — дип татарча үзара сөйләшкәнне ишетсә дә, хәзер, бер литрлы пыяла банкадан алып, үзенекен суза. Фатирында һаман татарлар яшәгәч, безнең телне дә шактый аңлый башлаган инде.

Анна түти үзе һәр көнне чиркәүгә йөри. Аякларын көчкә генә сөйрәп атласа да, бер дә калмаска тырыша. Гыйбадәт кылу белән бергә бушлай ашаталар да, ди.

Алар үзләре өйдә ашарга пешермиләр дә диярлек. Кибеттән һәр көнне колбаса алып кайталар да, шуны ипи белән ашап куеп та тук булалар. Тик нәни кызчык кына бу ризыкка үрелеп тә карамый. Табын әзерләвебезне күрде исә, ул безнең тирәдә әвәрә килә. Әлбәттә, аны түргә үк утыртып, хуш исле итле аш салып бирәбез. Сабый бит инде, салганны ашап та бетермичә торып та китә. Төн уртасында Машенька һаман елап уяна. Безнең белән бергә ризык жыеп ятса да:

— Минем ашыйсым килә, — дип өзелеп-өзелеп елый башлый.

Лена ана тиз генә печенье кертеп тоттыра. Аннан һәр көнне иртән ул бездән:

— Йоклый алдыгызмы? — дип сорый. — Йокларга бирмәде инде, балакай... Бәхетсез бала төнлә елый, диләр бит.

Без, ашап-эчеп алгач, кайнар күлгә юл тотабыз. Аны алар үзләре «чокыр» дип кенә йөртәләр. Кайнар чокыр нарат урманы эчендә бөтен тирә-юньгә пар бөркеп, рәхәтлектән шаулап кайнап ята. Кешеләрнең үзен кай тарафлардан эзләп килүләренә карамастан, һәммәсенә сәламәтлек бүләк итә. Авырулар монда, бәлки, шифа табармын, дип килсә, саулар, чирләмәскә язсын, дип юл саба. Кайнар күлнең уртасына төшеп сузылып чалкан ятасың да, кайнар дулкында тибрәлә-тибрәлә зәп-зәңгәр күкләргә төбәләсең. Минем моңарчы мондый жете зәңгәрлекне беркайда да күргәнем юк икән бит. Күкләр биек-биек, чиксез биекләр. Хәтта болытлар да төпсез зәңгәрлектә күльяулыгы кадәрле генә күренәләр. Кайчандыр бу жирләрдә Күчем ханның Гөлсифәре дә, яраткан хатыны Сүзге бикәләр дә, нәкъ минем кебек, чиксез гүзәллеккә төбәлеп, шулай соклану аша рәхәтлек кичергәннәрдер. Чөнки кайнар күлләр бөтен Себер буйлап сибелгән бит. Бай шул ул Себер киңлекләре!

Суда кешеләр артыгын сөйләшмәскә тырышалар. Унбиш-егерме минутка сузылган дәвалану сеансында бөтенесе дә тыелып тора шул. Ә ярда... Монда үзеңне бака базына эләккәндәй тоясың... Хәтта татарча жырлап жибәрүчеләр дә очрый. Бер ир-ат, киенгәндә, гел безнең тирәгә туры килә. Ул һаман:

Без алай да итмәгән,
Без болай да итмәгән.
Нигә куркырга кешедән,
Урлап Себер китмәгән, –

дип, бик якында торучылар ишетерлек итеп кенә жыр суза.

Гадәттә, кешеләр ярда, жанга якын туган телне ишетеп, бер-берсеннән сорашып алалар:
— Сез кайдан?
— Казакъстаннан.
— Сез кайдан?
— Свердлаудан.
— Сез кайдан?
— Татарстаннан...
— Ә пес Сепер татарлары...
Кыскасы, кай тарафларда гына яшәми безнең халык һәм кайлардан гына килмиләр монда.

Анна карчык белеп әйтә:
— Сәламәтлек татарларга күбрәк кирәк, ахрысы, — ди.

Минем үземне дә бик гажәпләндерә шушы хәл: бер чакырусыз дөньяның бар почмакларыннан татарлар жыелсын әле... Шуңа да жирле халык бу күлне «Татар чокыры» дип тә атый.

Кайчакта Лена Анна түтине дә безгә ияртеп жибәрмәкче була.
— Кешеләр сәламәтлек эзләп кайлардан кадәрле киләләр, ә син ятасың шунда төртенеп, — ди.

Кызы күлгә кыстый башлады исә, Анна карчык күтәрелеп бәрелә:
— Анакаем, синең аркада һәммәсе дә. Синең бәхетсезлеген житте минем башыма, — ди. — Каенанаң бозган бозымны су ничек дәваласын? Чиркәү дә дәвалый алганы юк әле аны...

Карчык бер кызган көенчә өйдән үк чыгып китә.
— Ул үзе дә дөньяның бер бәхетсезе инде, һаман бәхетсезлеген миннән күрә... Яшьли ятим калган. Кияүгә чыгып ике ел да яшәмәгән, әти үлеп киткән. Абый белән икебезне берүзе үстергән... Хәзерге тормышын кара инде... Мин ялгыз, кызым әтисез, абый үлде, аның баласы тома ятим... Шушы да булдымы бәхет? — ди Лена әнисен жәлләп.

Анна түти безнең белән бармады, әлбәттә. Без кичке күлгә тагын үзебез генә төшеп киттек. Артык сонга да каласы килми, ни дисәң дә, Себер бит ул: вак черки явы астында калып, елый-елый кашынып кайткан чаклар да булыштыра.

Без, мәңге тынгы белмәс поезд юлы аша чыгып, куе урман эченә кереп киттек. Юл тулы халык, башларына мунча сөлгесе урап, башмак йә галошларын чаштор-чыштыр китереп, сәгать теледәй әкрен генә бер көйгә чайкалып кайтып бара. Күл ягына атлаучылар да әз түгел. Башлары күккә тигән наратлардан бөтен жиһанга хуш ис тарала. Әчкелтем чәер исе күзләргә каләр кергәндәй тоела.
— Икебезнең колач житә микән, син ничек уйлыйсың? — дим мин иремә юан бер агач янына тукталып.
— Әйдә, колачлап карыйбыз...

Имәнгә ябышып ук кулларыбызны бер-беребезгә сузсак та житмәде шул колачыбыз... Наратлар да шундый, түбәләре күккә тия язса да, һәммәсе төптән үк юан монда.
— Могаен, Себер ханнары утырткан агачлардыр болар.
— Могаен... Күпме калалар төзегәннәр... Төмән, Тубыл, Чимги, Ук... Шушы тирәдәгеләре генә бит әле... Меңьяшәр урман үстерү берни тормаган инде аларга.
— «Төмән» «гаскәр» дигән сүзме әле? — дип сорап куя ирем. — Атлы гаскәрләр турында барадыр инде сүз. Атсыз татар ничек булсын инде ул?
— Могаен...

Монда тарих тәгәрмәченең бик тирән эзләре калган шул.

Без кайтып кергәндә, өйнең алгы ягында ниндидер ят ир белән яшь һәм бик тә чибәр хатын күренде.

– Тагын фатир төшүчеләрме? – дип сорадым мин Ленадан.

– Юк. Монысы ирем. Үзенең себеркесе белән... – диде ул, шыпырт кына, телендәге авазлар тибрәнешеннән сүзләренең йөрәк әрнүе аша әйтелүен чамалау бер дә кыен түгел иде. – Шунын белән чыгып киткәненә ике ел узды инде менә...

– Чакырган идегезме?

– Кем чакырсын соң аларны? Товар сатарга кайтканнар, имеш. Торырга урын юк, ди бит. Ике-өч көнгә генә, ди. Ничек куып чыгарасың инде? Мин куар идем дә, кызның атасы бит әле ул. Мин синең янына кайтмадым, кызым янына кайттым, ди. Югыйсә себеркесе кызы белән бер яшьтә... Анарда кызы кайгысы бар микән соң, шулай булгач?..

Мин Ленаның бәхетсезлегенең тирәнлеген шушы мәлдә генә тоя алдым кебек. Менә ни өчен өйдә, квартирага кергән ир-атлар алдында, яшьлеген югалтса да, сылулыгын җуймаган сынын күрсәтеп, көпә-көндез коену костюмыннан йөри икән ул... Көн эссе бит, дигән була, бичаракай... Челләдә кемгә эссе түгел инде, берәү дә өйдә чишенеп ташламый лабаса... Тагын өч бүлмәсендә дә кешеләр яши бит әле. Барыбыз бергә егермедән артыкка җыелабыздыр без.

Ире кайткач та, нигәдер бик тиз киенеп куйды югыйсә.

– Кызы янында инде аның хәзер, япь-яшь әнә... Калганын уйласа, китмәс тә иде ул... Шул себеркегә алыштырды бит инде үз баласын.

Бүлмәгә шулчак Анна түти килеп керде дә Ленага ачулы карашын төбәде. Аннан:

– Горурлыгын да юк инде синең, анакаем, һаман әтрәк-әләм җыеп ятмасаң, – дип чәпчеп алды. Үзе, шифоньерны ачып, кара өстенә ала-кола сызыклар төшкән яулыгын тартып чыгарды һәм чәчләрен сыпырыштырып җибәрде дә шуны бәйли-бәйли ишек ягына юнәлде: – Чиркәүгә киттем мин, анакаем, сиңа бераз акыл сорап гыйбадәт кылырмын... – Анна карчык чыгып киттем дигәндә генә, юлыннан бүленеп кирегә борылды һәм, иконалы почмакка төбәлеп: – Син аның шифоньердагы шакмаклы күлмәген үзенә биреп җибәрергә онытма, эзе булмасын монда... Һаман шуңа карый-карый кыйшаерсың тагын син дә, анакаем... – диде.

Лена дәшмәде. Анна карчык та җавап көтми иде кебек, үз юлы белән китеп барды.

– Әнкәй аңламый инде ул минем хәлне, – диде Лена. – Берәр нәрсә, булса хәзер «анакаем» ди башлый. Аның үзенең ире үлгән дә киткән. Сагынганда бер карарга да юк бит инде ул... Ә мин яратам бит аны. Иблис икәнен белә торып яратам. Янындагы кыздан көнләшми дип уйлыйсынмы әллә? Ничек кенә көнләшәм әле. Яшьлегеннән дә көнләшәм хәтта... Бүген үк пычак белән кадар идем, хәлемнән килсә... Тик... Әле бит абыйның кызын үстерәсем бар. Әнкәйне күреп торасын, бик карт инде ул. Үз кызым да мәктәпне генә тәмамлый. Аларны ничек хәсрәткә саласың ди?

Лена шушы бай һәм бәхетле Себер җирендә бәхетсезлеге белән яшәп ята микәнни, дип уйлап куйдым мин. Һаман ачык йөзле, яп-якты елмаю тулы күзләрен күргән кеше ничек болай уйлый алсын соң аның турында?

– Кем каргышлары төшкәндер безгә? Ерак бабайлар, мөгаен, кеше хакына кергәннәрдер инде, кичерелмәс гөнаһ кылганнардыр... – ди ул үзе дә, аптырап. – Күршеләрдә дә шундый ук хәлләр. Бөтен посёлокка бер бәхетле кеше табалмассың.

– Ярар, болары гына баш бетәрлек кайгы түгел әле. Аяк-кулыгыз хәрәкәтләнә, күзләрегез күрә. Әнә күл буена төшеп карагыз: анда кайберәүләрне суга кулларында күтәреп төшереп салалар.

Мин иртән коеныргa баргач күргән хәлне искә төшердем дә, Ленаны юату өчен, тиз-тиз генә сөйләп тә ташладым. Киемнәрне янәшә чишенсәк тә, сорашырга кыенсындым: алар ниндидер башка телдә аралаштылар. Югыйсә Ленаны юатыр өчен күбрәк тә сөйләргә тырышыр идем кебек.

— Лена Ивановна!— дип кычкырдылар урам яктан.

Лена тәрәзәне ачты:

— Кем сорый анда?

— Фатирыгызда урын юкмы?

— Юк шул, бер йорт аша урыннар бар, анда барыгыз...

Лена үзе дә мосафирлар артыннан чыгып китте. Мин, чәй куеп җибәрергә теләп, су флягасын ачтым, чүмечем, шалтыр-шолтыр килеп, төпкә үк төшеп бәрелде, савыт бушаган иде.

— Чәй куярга бер кашык су да калмаган, — дидем иремә.

— Әйдә, икәүләп күңеллерәк тә булыр...

Фляга тагылган ике тәгәрмәчле арбага мин дә иярдем.

Без, иске бараклар, ямьшәеп җиргә иңә язган йортлар арасыннан үтеп, колонка янына барабыз. Юан-юан карамалар, имәннәр астында бик мескен кыяфәттә үлем көткән картлардай бөкшәеп утырган колонка ул. Ямь-яшел яфраклар баш өстендә шыбыр-шыбыр килә. Җил аларны бер селкетеп алмак булып куәтләнеп исә дә тына, исә дә тына. Бу йортларның да үз тарихы бардыр инде.

— Өсләренә урман авып тора, ә бер җүнле йорт юк бу посёлокта, — ди ирем, күзәтеп бара торгач.

— Йорт салырга ирләр калмаган бит монда, кайсы хуҗалыкны алма — хатын-кызлар, кайсының ире төрмәдә, кайсы, гаиләсен ташлап, шәһәрдән үк күчеп киткән.

Мин Лена сөйләгәннәрне бәян итә-итә барам. Хәер, алай гына да түгел, танышлар шактый очрады ич. Сүз иярә сүз чыгып, кемнең кайда фатир төшүен, хуҗаларының кемнәр булуын сорашмый калган юк. Алар да бездән шул хакта сораштыралар. Бу, күрәсең, ияләнелгән гадәт инде.

— Югыйсә ерак тарихларда, Ермак гаскәрләре басып кергәндә, мондагы калаларның капкаларына кадәр алтыннан булган, дип язалар бит. Казаклар, байлык күреп, тәмам һушсыз калганнар, диләр.

— Ермаклар, Борис Годуновлар һәммәсе ерак тарихта инде... Димәк, өметләре акланмаган...

Без суны өйгә алып кайтып житкергәнче, шушы посёлокның яшәргә тырышмавы хакында сөйләштек. Югыйсә май айларыннан башлап, күпме халык фатир төшә монда. Хаклары да бер дә арзан түгел. Тик бер генә тамчы да алга китеш күренми шул. Кыйшайган түбәләр, җиргә ингән йортлар...

Хәер, посёлокка терәлеп үк утырган бишәр катлы йортлардан торган шәһәрнең үзеннән дә искелек исе аңкып тора. Кибетләр яныннан узганда, исләнгән балык яки тавык исеннән борыныңны тотып узарга мәҗбүр буласың. Вокзал тирәләрендә, урамнарда сагыз, тәмәке каплары, буш сыра шешәләре аунап ята һәм үзәктә ары китүчегә дә, бире үтүчегә дә Ленин бабай, уң кулын алга сузып, юл күрсәтеп тора. Аның да плащ якаларына, итек башларына куе тузан утырган. Алга сузылган кулына эре-эре каргалар кунып ял итә.

— Су кайтардыгызмы? Әйбәт булган, — дип каршы алды безне Лена. — Машенька су сорый.

Ул, без фляганы эчкә кертеп куйганчы ук, чүмеч белән батырып алып, кызчыкка су узды.

— Әнисе янына барып килдем әле, — диде аннан, авыр сулап.

— Кайда соң аның әнисе?

Лена тагын да тирәнрәк итеп тын алды да:

— Җүләрләр йортында, — дип җавап бирде. — Бала тапканда акылдан язды. Машенька әнисе барын белми дә. Мина «әни» ди, күреп торасыз инде.

— Аллам сакласын! Нинди хәсрәт! — дип әйтеп куйдым мин, Лена өчен чын күнелемнән борчылып. Югыйсә яхшы күнелле хатын ул. Ташламаган бит абыйсының баласын, авыр чакта үзенә алган... Төн йокыларыннан бүленеп, ул аның бар йомышын үти, кочагында тибрәтеп йоклата.

— Хәсрәт көтмәгәндә килә икән ул. Бик авыр тапкан шул. Ярый Машенька сау-сәламәт туды.

Лена туктаусыз сөйләде дә сөйләде. Аның бөтен вөҗүденнән әрнү ташый, күнеленнән ятимлек ачысының тамырлары актарыла иде.

— Абыйны бик ярата иде бит әнием, поезд астында калды шул ул гаиләсендәге хәлләрдән соң. Әллә күрмәгән инде, әллә язмышы шул булган.

— Бәлки, терелеп тә китәр әле киленегез. Күлгә алып төшеп карагыз сез аны. Күпме кеше килә бит, сәламәтлек эзләп...

— Берәр могҗиза булса гына инде... Бер дә өметләндермиләр шул табиблар. Ул бит үзенең баласы барлыгын да белми, бичара. Бер тамчы да хәтере кайтмады. — Лена бераз тын торды. Ниләрдер уйлап, ниләрнедер күз алдыннан үткәреп карады кебек. Аннан: — Күл суы нигәдер безгә бер дә ярдәм итми шул, — дип куйды.

— Кем нәрсәгә ышана инде, — дидем мин чарасыздан.

Анна карчык та житен чәчкәседәй зәңгәр күзле, ак күбәләк кебек җиңел Машеньканы үлеп ярата. Чәчләрен көнгә әллә ничә кат тарап, матур итеп тасмалар тагып җибәрә. Әбисе эшне йомгаклаганчы, Машенька аның кочагына кереп бетеп, иркәләнеп, сабыр гына басып тора. Тик таракны урынына куеп өлгергәнче, кызчык, нәни бармакларын дерелдәтеп, ак купшы бантларны йолкып та ала.

— Кызларга матурлык кирәк, анакаем, беләсеңме син шуны?

Машенька аны тыңлап бетерми, әлбәттә, урамга йөгерә.

— Анакаем, үземә охшаган бу бала, бәхетле булса гына ярар иде, — ди карчык, идәндә ятып калган бантларны җыя-җыя. — Шулай дип көн дә гыйбадәт кылам. Аллаһының көче житә югыйсә. Христос ярдәменнән ташламаса иде.

Без шулай бер өйдә яши-яши тәмам үз кешеләргә әйләнеп бетәбез. Гади халыкка күкләр аяз булса, ил-көннәр тыныч торса, тагын ни кирәк инде? Гади халык дин дә, тел дә бүлми шул ул. Без үзебез белән әнине дә алып килдек. Ул намаз укый. Анна түти ана намазлык итеп тотарга чип-чиста ап-ак җәймәсен бирде:

— Анакаем, сезнең дин өчен арулык кирәк бит, — диде.

...Газ өстенә чәй куеп җибәрдем дә үзебез яшәгән бүлмәгә таба атладым. Чөнки күл күбрәк ятып ял иткәнне ярата. Аяк атларлык та хәл калмый, бөтен тән үзалдына тирләп чыга. Кешеләр дә, хуҗалар да шушы тәртипкә канәгать булып яшәп торалар. Һәр җирдә дә урын гел җәелгән көе кала бирә.

Безнең бүлмә янәшәсендә Лена Машенька белән йоклый. Баланы көндезен дә бер йоклатып ала.

Ачык ишеккә игътибар итсәм, бу юлы бүлмә буш, караватка җете розалардан гына торган өр-яңа җәймәләр җәелгән. Сокланып микән, кызу-кызу атлап килгән җирдән бераз әкренәя төштем. Хәер, мин дә хатын-кыз бит, мине генә Ходай кызыксыну дигән хистән мәхрүм итмәс инде.

— Ай-яй-яй! — дидем мин, матурлык йоткан күземне түгәрәкләндереп. Артымнан Лена да кереп килә икән:

– Тегеләргә бирдем әле бүлмәмне. Себеркесе, сәләмәгә батып ята, дип сөйләп йөрмәсен, – диде ул.

Мин, әлбәттә, елмаеп кына куйдым. Ни дип әйтергә дә сүз тапмадым. Белер-белмәс кешенең йөрәк ярасына кагылып куярсың да, Аллам сакласын, олы рәнжеш алырсың тагын.

Болай да үзен хужа итеп, әнә ничек, таш сын күк башын югары тотып йөри бит көндәше.

Үзенең бәхетсезлегe, ялгызлыгы сыенган ятагын да ул шушы көндәше белән бүлешергә әзер. Нинди кин күңелле хатын бу Лена?!

Анна карчык еш кына уфтанып та куештыра:

– Анакаем, мин Аллаһыдан һәм дә Христостан курыктым шул, каты бәгырьле итеп үстерә алмадым балаларымны, – ди. – Ә бит кешеләр каты бәгырьле, менә гөл кебек бала багып, ялт итеп яшәп яткан жиреннән ирен алып чыгып киттеләр, – ди.

Чынлап та, каты бәгырьле бугай шул кешеләр...

Без кичен су буена соңрак төштек. Түбәләре күккә ашкан наратларга хозурланып йөри торгач, вакыт үткән дә киткән шул. Сизми дә калганбыз. Бу кадәрле серле урманнар тагын кайларда бар икән? Агачлар шаулавы да шомлы, ерак гасырлар аша атлы гаскәрләрнең тояк тавышыдай ишетелә... Сукмактан әз генә читкә китсәң, мизгел эчендә адашырга да мөмкинсең. Ә бит әле татлы кара жиләкләре, әле бармак башы кадәрле чем-кара шомыртлы тәлгәшләре, әле мәмрәп пешкән кыргый кура жиләкләре һаман эчкәрәк дәшә, кызыктыра-кызыктыра сыйлый. Мондагы табигать тә чит итми шул безне.

Жирле халык (кем белгән кемнәрдер инде алар?) бу урманнар ышыгына атна ахырында ял итәргә жыела. Урман юлы кырыйлап чатырлар корып, учаклар ягып жибәрәләр. Урман һавасын шашлык төтене катыш сыра, аракы исе басып китә. Сүгенү сүзләре борчактай сибелә, сугышып та куештыралар. Кайчакта, төнлә атышканнар икән, кайсыларындыр больницага озатканнар икән, дигән хәбәрләр дә ишетелгәли.

Фатирларда яшәүче халык аларга читтән генә караштырып, сабыр гына үтеп-сүтеп йөри. Ни дисәң дә, хәзер бу жирләрнең хужасы алар бит.

Әнә черкиләре дә үз итеп кенә тәнгә сарыла. Аяклар шешеп чыга.

– Черкиләре дә шифалы анын, әйдә талап калсыннар, – дип шаярталар өлкәнрәкләр. Кем белгән инде? Бәлки, шифалыдыр да шул...

Черкиләргә игътибар итмәскә тырышып, зәп-зәңгәр күкләргә төбәләсең. Ә алар төпсез дингез кебек. Күкләр биек, бик тә биекләр. Болытлар безгә ерактан-ерактан карап торалар. Алар, мөгаен, шушы төбәктә яралганнардыр... Алар, мөгаен, шушы жирләрнең тарихын хәтерлиләрдер... Аларнын, мөгаен, Кучем ханны да күргәннәре бардыр әле... Себер-йорт өчен шәһит киткән олуг ханны үз Ватанында кемнәрдер хәтерләргә яки ниләрдер хәтерләтергә тиештер бит. Сүзгә бикәнә дә... Бәлки, шул чорларның кайнар йөрәкле халкы рухын саклап, шундый зәһәр кышларда да бер тамчы туңуны белмичә, мәңгелек күкләргә карап көлеп ятадыр әле ул шифалы күлләр...

Халык үз хәтереннән ераклашкан саен, болытлар да биеккәрәк ашалардыр. Хәтерсез кешеләр куркынычтыр чөнки... Алар үз балаларын да танымыйлардыр. Кош дип атып төшерүләре дә бар ич...

Мин, тын гына, ялантәпи, ташлы, чүпле ярга баса-баса, жир куенынннан кайнап чыккан кайнар күлгә төшеп яттым. Биектә-биектә зәп-зәңгәр күк, күл өстендә әрфия канатлы ап-ак болытлар туктап калган... Янымда ирем һәм дә әнием... Никадәр рәхәт бу дөнья, никадәр гүзәл ул! Бай ул, якты ул... Һәм ул миңа менә шушы көенчә кирәк тә...

## Кояшлы keләмнәр

Бу язмыш дигәнең ничекләр төрле холыктагы кешеләрне бергә, хәтта бер гаиләгә җыя ала икән соң? Үзе кызык, үзе сәер дә... Мин моны Сәмия апаны һәм аның кызы Гөлназа апаны яхшы белгәнгә әйтәм. Менә алар, мин белгәннән бирле, бергә яшиләр үзләре. Һәм бергә дә яшәмиләр кебек...

Сәмия апа, кызы хакында сүз чыкса:

— Тумыштан җүләр, — дип уфтана.

Ул үзе шәһәребезнең бик зур сәүдә базасында җитәкчелектә эшли. Бу дөньяда табып булмый торган нидер бар икән, аны сез Сәмия апага гына әйтегез, чөнки җир өстенең һәммә байлыгы аның кулында.

Менә кибетләрдән затлы келәм табу мөмкинме? Таптың ди бик... Ә Сәмия апаларның ике бүлмәле фатирларының берсе келәм белән шыплап тула язган. Төргәк-төргәк итеп, аслы-өсле, утын әрдәнәседәй өеп куйганнар хәтта. Бүлмәдә Гөлназа апаның диванына гына урын калган. Келәмнәр генә түгел, бәллүр вазалары, савытлары, хәтта көмеш кашыклары да чиксез күп Сәмия апаларның. Алары да шушы келәмнәр янәшәсендәге шкафка аслы-өсле өеп куелган. Мин өйләренә кергәндә, бу хәзинәне кайчакта үзем дә бик кызыксынып күзәтәм. Келәмнәренә күзем төшсә, «Их, идәнгә берәрсен генә туздырып җәеп җибәрәсе иде дә соң шуларның» дим. Күз явын алырлык бит һәммәсе. Чөнки бер керүемдә, Сәмия апа аларны миңа сүтеп-туздырып та күрсәтте. Идәннең буеннан-буена җитәрлек могҗизаны җәеп җибәрүгә, тәрәзәләргә ябышып торган һәммә кояш нуры шуның вак-вак бизәкләре эченә кереп тулды. Кояш үзе дә шунда төшеп чумды кебек, чөнки андагы бизәкләр ялтыра, ялтыра, һаман ялтыра бардылар. Өй эче дә нурланып киткәндәй тоелды. Кояшка кушылып, Сәмия апа да елмайды.

Келәмнәрнең озак еллар бер халәттә ятканлыктан кинәт кенә турая алмый интеккән чит-читләрен ул йомшак куллары белән, иркәли-иркәли, кат-кат сыпырды, барыбер алар әле язылып китәргә ашыкмадылар.

— Һай, җаным, һинд келәмнәре алай ук көйсез түгел, монысы кытайныкы шул... — дип сөйләнде ул. — Һинд келәмнәре менә ничек юка гына бит алар. Тотып кара әле, аерма сизәсеңме?

— Әйе шул, юка шул, Сәмия апа...

И шуларны төргәгеннән сүткәндә аның кичергән күңел халәтен тойсагыз иде сез! Оҗмахка эләккән дип белерсең, билләһи. Хәер, ялгыш әйтәм, оҗмах бер дә кызыктырмый шул аны. Чәчләрен бөдрәләтеп җыеп куйган прическасын бозмаска тырышып, бармакларын тидерер-тидермәс кенә башын сыпырыштырып алгалаганда, аның көязлеге бөтен кыяфәтенә бәреп чыга. Тук тормыш шулай итәдер инде кешене... Ул хәтта комачкызыл иреннәрен бөрә төшеп кенә көлеп җибәрә. Затлы келәмнәр өстендә якты елмаюын тибрәтеп байлыктан горурланган мәлендә, буяулы озын тырнаклары күкрәкләре тирәсендә уйнап кына тора.

— Бөтенесе дә матур, искиткеч матурлар, — дим мин, Сәмия апаның күңелен күрергә тырышып. — Их, бездә булсын иде шуларның берәрсе, гел җәеп кенә тотар идек, бер дә алмас идек идәннән...

Гөлназа апа нигәдер, әйткәнемне ошатмыйчамы, миңа күз кырые белән генә карап ала.

— Кыйбат шул алар, сеңлем, директорлар, җитәкчеләр генә җәя мондыйларны... — ди Сәмия апа.

— Шулайдыр шул...

— Сиңа ник кирәк инде алар, тузан җитмәгән мәллә өеңдә? — дип сорау бирә миңа Гөлназа апа, китап укып яткан җиреннән бүленеп. — Син балачагага түгел, әниеңә дә кирәкми әле болар. Юкка кызыкмасаң иде.

Ул үзе китабын каршыннан бер миллиметрга да читкәрәк алмый, шунда ук укуын дәвам итә.

— Белмим инде... Матурлар бит... Бизәкләренә карап торуы да ничектер күнелле...

— Җуләргә игътибар итмә, зинһар, ана бернәрсә дә кирәкми. Ишәк алга тарта, койрыгы артка тарта, диләрме әле. Менә мин чиләнәм шуңа булсын дия-дия. — Сәмия апа кызарынып-бүртенеп чыга. Аның тагын озак итеп, күп итеп әйтәсе килгәне сизелеп тора, тик ул, телен тешләп, сүзләрен йотып җибәрә.

Гөлназа апа ирен чите белән генә елмаеп куя да янадан китабына каплана. Миңа бу өйдәге хәлләр бераз сәеррәк булып тоела.

Икенче бер кергәнемдә, Сәмия апа, шкафны тәмам бушатып бетереп, бәллүр вазаларын күрсәтеп чыкты. Чынлап та, һәммәсенә тузан утырган иде. Ул аларны учлары белән генә сыпырып алды да алдыма сәйләннәрне җепкә тезгәндәй тезә барды. Күбесе чит илләрдә эшләнгән икән. Хаклары да адәм башлары җитмәслек, ди. Хәер, мине аларның затлы пыяладан ясалулары түгел, әйләнә-тирәләренә төшкән рәсем-бизәкләре кызыктырды. Ничекләр пыялага шулкадәр дә нәфис итеп уеп бетереп була икән соң?

Бер керүемдә шулай, үзем дә сизмәстән сорап куйдым:

— Нишләп бер дә кулланмыйсыз соң сез аларны? — дидем.

Ул чакта да Гөлназа апа диванда гарәп язуы белән язылган китабын караштырып ята иде:

— Байлар саран һәм комсыз була алар, үскәнем, — дип җавап бирде ул. Үз әнисе хакында мондый сүзләр әйтүенә мин аптырап киттем.

Сәмия апа кызына күзенең агы белән генә карап алды да:

— Юарга җайсыз бит аларны, бизәк уйган сырларына пычрак утыра, — дип куйды. — Менә шушы исәргә бирнәгә дип җыям инде. — Ул кызы ягына ымлады. Үзе һаман:

— Юмартлык ярлы итә дә инде кешене, саран, имеш, — дип сөйләнде. Мин Гөлназа апаны алырга килгән егетне күз алдыма китердем:

«Әкәләле имән авачак икән монын өстенә, — дип уйлап куйдым, дөресрәге, әнием сүзләрен исемә төшердем. — Ни дисәң дә, бирнәле кыз бирнәле кыз инде ул...»

Ә саранлыкка килгәндә, мин Гөлназа апа сүзләрендә дә хаклык бардыр дип фикер йөрттем, чөнки бу өйгә туганнары килгән чакка әллә ничә тапкыр эләктем, берсендә дә Сәмия апа аларны нигәдер чәй куеп эчертмәде.

Мин үзем дә, чынын әйткәндә, монда затлы келәмнәр, бәллүр вазалар карарга дип түгел, ана белән кызның сәерлекләреннән күнелдән генә булса да рәхәтләнеп көлеп, бер ял итеп чыгар өчен керәм. Аннан алар икесе дә әдәп кагыйдәләренә бик буйсынмыйчарак сөйләшәләр. Кычкырып уйлыйлар, дисәң инде... Шулайдыр, чөнки икесенең дә уйлаган уйлары телләрендә. Әни әйтмешли, йолдызлары йолдызга туры килмидер инде, күрәсең. Кызык аларда шулай да.

Әйткәнемчә, үзләре икесе дә гаҗәп әйбәт кешеләр югыйсә. Тирә-күршеләргә бер генә яманлыклары да тигәне юк. Безнең подъездда яшәүчеләр Сәмия апаны гади, ихлас булганы өчен, акчалы кешеләр бай булганы өчен яраталар. Кирәк әйберләрен гел аның аша юллыйлар. Ул эштән кайтканда, күршеләрдән кем генә очраса да, тукталып сөйләшеп торырга вакыт таба, хәлләрен сораша, бала-чагаларының исәнлекләре, тормышлары белән кызыксына. Хәтта мине күрсә дә, кулларын җәеп кочып алырга дип көтеп тора:

— Дәресләрең күп булган, ахрысы, арыганың йөзеңә чыккан, балакаем, — ди һәм чәчләремнән сыйпап куя.

– Арыдым шул, Сәмия апа.

– Кичен кереп чык, яме, мин сиңа бәллүр кувшин күрсәтермен.

– Керермен, Сәмия апа.

Үзләренчә тормыш кичереп яталар алар икәүләп. Сәмия апа бәллүр вазалар, келәмнәр җыярга ярата, ә кызы китап укый. Безнең йортка каршы гына шәһәр китапханәсе. Гөлназа апа яшәгәнне белеп салып куйганнар диярсең. Мәдрәсәдән кайтышлый ук ул шунда керә. Үзе институтта да гыйлем җыя. Ничек икесенә дә өлгерәдер?!

Әнә шулай күнелле итеп яшәп торганда, Сәмия апа нигәдер күңелсезләнеп йөри башлады. Ул инде урамда да еш күренми. Кибеткә-мазарга чыкса да, тиз генә кереп китү җаен карый иде. Анарда ниндидер яман бер авыру тапканнар икән, дип сөйләделәр. Үзе бу хакта берни дә сиздермәде. Больницадан больницага йөреп кыш чыкты ул. Һәм һич көтмәгәндә, көннәрнең язга авышкан ярсулы бер мәлендә, тиз генә үлеп тә китте.

Гөлназа апаның хәле никадәр авыр булса да, хәсрәтне дин кушканча, сабырлык белән күтәрергә тырышты: әнкәсе рухына көн-төн дога кылды.

Ул әле әнкәсенең өчесендә, аш үткәргәндә берничә дә кагылмады, ә җидесендә, Сәмия апа исталеге итеп, туганнарының һәммәсенә бүләк өләште. Ул көнне алар фатирыннан затлы келәмне иңнәренә салып чыккан ирләргә карап туганнары күплеген бөтен йорт күрде, хатын-кызларның ябылып бетмәгән сумкалары авызыннан бәллүр вазалар, савытлар җемелдәшеп тора иде.

Подъезддагылар:

– Үзем тапкан мал түгел, атайныкы җәл түгел, – дип пошынып калсалар да, Гөлназа апа беркемне дә ишетергә теләмәде.

– Туктале, Гөлназа, син бөтенесен дә таратма әле, яшисең бар бит әле үзеннән дә, – дип, бер апа ана каршы төшәргә дә җыенып карады.

– Җитә әле анда, – дип кенә җавап бирде ул, почмак якта төреп куелган келәмнәргә күрсәтеп.

Икенче керүемдә аларыннан да җилләр искән иде инде.

Ул көнне без икәүләп бушап калган шкафларны тузаннан арындырдык, суны кат-кат алыштырып кына тордык. Идәннәрне юып чыгаргач, Гөлназа апа тәрәзәләрне киереп ачып куйды. Урамнан бу өй өчен шулкадәр дә тансык шомырт исе катыш саф һава ургылып керде. Кояш алтын нурларын ялангач идәндә биетте. Әллә кояш үзе дә шунда яшәргә дип төшеп җитте микән – бөтен дөнья яп-якты нурга күмелде. Өйдә чынлап та рәхәт иде...

Әлбәттә, Гөлназа апага алай ук рәхәт булмагандыр, ни дисәң дә, әнисе юк бит янәшәсендә. Хәер, мина да вакыт-вакыт монда нидер җитмәгән сыман тоелды. Җитми иде шул. Сәмия апа җитми иде. Аның баласы өчен җанын бирердәй булып борчылуы сагындырган иде. Бу өй ул барында күңеллерәк иде бит.

Шулкадәрле бирнәне очырып кына җибәргәч, киявенә ни дип җавап бирер икән бу, Гөлназа апа, дип уйлап куйдым мин.

Тик еллар бер-бер артлы җилеп кенә үтсәләр дә, кияү буласы кеше күренмәде. Шөкер, Гөлназа апага беркем алдында да җавап тотарга туры килмәде.

– Ничек яшәрсең инде? – диючеләргә, ул һаман:

– Мина Аллаһы үзе биреп тора җитәрлек итеп, – дип җаваплады. – Ашка чакыралар, абыстай санап, хәер китерәләр, һәммәсенә дога кылып яшим. Җитмәгәндә җитмәгән көе дә торып була. Байлык дип капланырга ярамый. Байлык күнелдә ул.

Итәгенә Коръән китабын куеп, ул мина салмак кына шулай дип сөйләде.

Ә туганнары ана башкача бер кат та килмәделәр кебек. Әллә теге келәмнәр белән алар өенә дә Гөлназа апа әйткән саранлык һәм дә комсызлык таралды микән? Кем белә инде?.. Бәлки әле, Гөлназа апа үзе дә, әнием булып күзләремә көн дә саранлык белән комсызлык карап тормасын әле, дип өләшеп бетергәндер дә аларны. Үзе бик тә яхшы кеше иде бит ул Сәмия апа. Гөлназа апа да әнисен бик ярата иде шул.

Гөлназа апа шунын кадәр авыр йөктән исән-имин котылуына сөенеп бетә алмады, хәер, байлык турында уйлап ул беркайчан да көчен сарыф итмәде кебек. Янә бер кат:

— Бу дөньяларда ин сөймәгән нәрсәм — тузан. Әйт әле, өем ялт итеп торамы? — дип, миннән сүзләренә мөһер суктырды.

— Ялт итеп тора, бер бөртек тә тузан калмаган, Гөлназа апа, — дидем, аны куәтләп.

Житмәсә, шул сөйләшүебезнен икенче көнендә аларнын өен су бастырдылар. Өстәге каттагыларнын торбасы тишелгән һәм су беренче каткача бөтен фатирларнын да түшәмнәреннән ташкындай аккан иде. Мин шунда, Сәмия апанын төргәк-төргәк келәмнәрен күз алдыма китереп, жинел сулап куйдым. Нишләп бетәр иде Гөлназа апа алар белән? Ә болай диван асларына качып калган тузаннар гына юешләнгәндер, бәлки... Шунын аркасында подъездыбыздагы кайбер гаиләләр судларга бирешеп, бер-берсе белән талашып-ачуланышып беттеләр. Гөлназа апа беркемгә дә үпкә белдермәде. «Буласы булган, буявы унган» диде дә куйды. «Ремонт кирәк иде барыбер» дип тә өстәде.

Ул әнисе бакыйлыкка күченгәч, рәтләп кием дә алып кимәде диярлек. Кеше арасына чыкканда, аны танымыйсын да, киенә дә белә үзе. Чиста, пөхтә йөри, сирәк кенә булса да күлмәкләрен өстенә килешле итеп тектерә.

Ә менә өйдә минем Гөлназа апаны ямау салынган халаттан да күргәнем булды.

— Исраф, ярамый, — дип анлатты ул монысын.

* * *

Әллә ничек кенә бүген комсызлык арткан заманда, нишләптер мин ихлас елмаю аша искә төшердем бу гаиләне.

Нигә язмыш төрле холыклы кешеләрне бергә жыя икән? Хәер, дингез ярындагы төрле-төрле төстәге ташларны күргәнегез бармы сезнен? Беришләре бик вак, кайберләре бик эре була, арада уртачалары да бар. Әмма алар бер-берсенә тамчы да охшамаганнар. Өсләренә дулкын ябырылган саен, ташлар бер-берсенә ныграк бәреләләр. Шулай тәмам шомарып бетәләр. Тик төсләрен барыбер үзгәртмиләр.

Әйтегезче, шул ташлардан башка ярлар яр булыр идеме икән? Әгәр дә алар дулкын бәргән саен төсләрен үзгәртеп ятсалар, аякны кисеп керерлек үткен дә булсалар, һәммәсенә кызыгып, ялантәпи өсләренә баса-баса, дингез ярыннан кемнәр генә ташлар жыеп йөрер иде икән?.. Мин үзем дә бу эшкә алынмас идем кебек хәтта.

## Йөк

Ул чамасыз авыр йөк күтәреп бара. Гомере буена. Хәер, уйлап баксан, гомере дә нибары бер тотам гына. Тик бөкрене ташлап булмаган кебек, йөген дә ташлый алмый. Көн үткән саен, ул арта, зурая, авырая гына бара... Аны тау кадәрле дию генә дә аз инде. Мәнгелек кебек тоелган дөньянын үзе кадәрледер ул. Ин куркынычы шул: юк итеп тә, башкалар арбасына аударып та булмый. Еш кына уйлый: бу рәвешле гомер азагына ничекләр барып житәрсен? Үзе саный:

— Бер адым... Ике адым... Өч адым... Бер көн... Ике көн... Өч көн...

Шулай теге хәерсез көннән бирле үзе дә үлемгә табан барадыр кебек тоела. Юк-юк, әлегә зиратка гына бара ул...

Күзен йомды исә, һаман шуны сизә: йөге йөрәгенә ябышкандай була. Төшендә һәрвакыт каршысына балачак дусты йөгереп килә:

— Авырмы? — дип сорый.

Ир дәшми. Чөнки ул аны селкетә дә алмый, имеш. Эчтән генә «авыр, бик авыр» дип уйлый.

— Миңа да авыр, — ди яшьтәше Рияз. — Җитмәсә, сул як күкрәгемнән кан саркый.

Куркынып күзләрен ачып җибәрә ир. Йөрәге кагуына чыдый алмыйча торып ук утыра. Кан басымыннан кызарган күзләрен уа-уа, ишегалдына чыгып китә. Гел күрә торган бер үк төш күз алдына килә.

— Их, бергәләп тәгәрәтер идек бит дөньясын, — ди ир, тавык тәпиедәй кытыршыланып каткан кулларын яза-яза. — Мине гафу итсәң иде син, Рияз, ялгыш бит... Балалык белән...

Ул, башын күтәреп, як-ягына карана. Беркем дә юк икән. Тагын үз-үзе белән очрашкан икән. Үз-үзе белән. Һәм тынлык белән сөйләшә икән... Тынлык утлы да, уклы да була ала икән. Утлары көйдерә, уклары җәрәхәтли икән. Ул тагын зиратта, Рияз кабере янында басып тора икән. Менә ул, яшелгә буяп, аңа, җәйгә килешле итеп, өр-яңа чардуган кордыртты. Ташын да алыштырды быел. Искесен зират хуҗаларына илтеп тапшырды. Тик барыбер җиңеллек килмәде.

— Туганыңмы? — дип сорады күрше кабер янында басып торучы агай.

Салават җавап бирмәде. Агай янына юнәлде. Агай каршысындагы ике кабер ташының берсенә «Үтте дә китте гомерем...» дип язылган иде.

— Монысы минем кабер, — диде агай. — Ә язулысында хатыным ята. — Ул янәшәсендәге кабергә төртеп күрсәтте. Агайның чәчен уйнак җил җилбер-җилбер җилбердәтте. Кабер өстендәге гөлләр күзләрен ача төшеп карадылар.

Салаватка әллә ничек шомлы булып китте. Башыннан «Үлмәгән кеше чардуган кордыртмаса соң...» дигән уй йөгереп үтте. Агай гүя аның уйларын укыды.

— Бер килгән, бер китәсе... Минем үземне дә хатыным үлгән көнне җирләделәр инде, — диде ул. — Хәзер болай гына йөрим җир өстендә... Җан чыкканын көтеп кенә...

Салават сискәнеп куйды. Ничек була инде ул шулай?

— Аны сез үтердегезме? — дип сораганын сизми дә калды. Соравы башына барып җиткәч кенә, унайсызланып йөзен җыерды.

— Үтермәдем, — диде агай. — Аллаһы үзе хәл итте. Иң газиз кешемне мин ничек үтерә алыйм?

— Алайса, үлем турында мондый сөйләшү нигә?

Агай дәшми торды. Тирән итеп сулыш алды.

— Ялгызлыкның киләчәге дә, өмете дә юк икән аның, туган. Каберләрнең дә. Монда хатирәләр генә яши. Һәм тынлык... Ә син яңабаштан мәрмәр таш куеп йөрисең... — Ул, пышылдап кына сөйләнә-сөйләнә, Салаватны гаепләргә теләгәндәй, күз кырые белән генә аңа карап алды.

— Тегесе мәрмәр түгел иде аның, шуңа алыштырдым... Сез тере кеше дә... үзегезне кайгыртып йөрисез бит әле...

— Ә син ялгышасың. Хәер, мин дә ялгышам. Без икебез дә ялгыш уйлыйбыз...— диде ул. Аннан, кисәк кабергә арты белән борылып, башы белән генә ерак офыкка ымлады. — Зиратның әнә теге башында минем бабай ята. Аның өстендә йоп-йомры елга ташы тора. Искерми дә, череми дә. Урлаучы да юк. Ничек куйсак, шул көенчә һаман.

— Мөмкинлек булмагандыр инде... — диде Салават, читкә карап.

— Әманәте шундый. Мин үлгәч, кем рәшәткә тота, кем таш куя, дип сүз озайтып йөрмәгез, елганың иң матур урыныннан иң йомры ташны сайлап алып, шундагы көмеш суда юыгыз да баш очыма алып менеп утыртыгыз, диде. Зират кин күңелле бит ул. Кеше аермый. Баймы, ярлымы, яхшымы, яманмы — барысын да сыйдыра...

— Акыллы карт булган, ә! — дип кушылды ир.

— Борынгылар туганлык мөнәсәбәтләренә хилафлык китермәскә тырышканнар. Ташны сатып алып була, ә туганлыкны — ай-һай... Каберләрнең киләчәге юк ич инде барыбер, зиратның яшәгәнен кайда күргәнең бар синең, җә? Һәр җирдә үле тынлык әнә. Тынлыгы да шомлы. Куркыныч, — дип, кулын селтәп китәргә борылды агай. Аннан, янә сүзен дәвам итә-итә, алга атлады. Атлый торгач, алар ниндидер сәер һәйкәлләр тезелешеп торган каберлекләргә килеп чыктылар. Мәрмәр ташларына тулы гәүдәле, шома битле, пеләш башлы япь-яшь кешеләрнең сурәтләре ябыштырылган иде.

— Ташларның да авыры белән бастырганнар, чыгып йөри күрмәсеннәр дигәннәрдер, мөгаен.

Салават дәшмәде. Агай сүзне икенче юнәлешкә борды:

— Кешеләрнең җир өстендә юанычы берәү генә: үлгәннәр хакында «ул туган-тумачасы, нәсел-нәсәбе янында ята» диләр. Кадерле кешем янында ятасым килә минем дә... — дип сөйләнде.

Салават аңа иярде. Алар һаман биек-биек һәйкәлләрдәй сыннар куелган каберләр яныннан үттеләр. Кайсының бронза, кайсының көмеш язулары кубарылган, каерылган иде.

— Үлгәч тә тынгылык юк. Һай бу байлыкны! Зиратларга да үтеп керде каһәр... Ярый җир астына төшалмый бу адәм балалары. Аста һәммәсенә ике аршын тигез бүленгән... Тигезлек аста гына... — Агай тукталып калды. Аннан: — Нәселемә бай булырга язмасын, дип телә, — диде Салаватка, борылып. — Әнә минем бабай елга ташы астында тып-тыныч ята... Безгә дә тыныч... Аңа да җиңел... Рәхмәт укыйбыз үзенә...

* * *

«Ташлар да гомерлек түгел, ә ялгышлар гомерлек», — дип уйлады Салават. Әнә ич гомер буена артыннан сөйрәлеп килә. Йөк булып иңнәренә баса, яшәүнең бер мәгънәсен калдырмый. Хәтта туган авылында, үзең туган йортта яшәп булмый башлый. Аны яхшы ук белгән затлар да «Салаватка зират җене кагылган икән» дип гайбәт тараталар. Аңа шикләнеп карыйлар һәм гомере буена аңардан читләшәләр. Авылдашлары бигрәк тә...

Авылдан читкә китәсе малай түгел иде ул да. Нигә китәргә ди? Шәһәр үзе авылга терәлеп торгандамы? Алар авылы белән шәһәрне мәңге аерып булмас җепләр бәйләгән. Эшкә кешеләр шунда йөриләр. Хәтта зират та уртак. Ике араны автобуслар, таксилар, җиңел машиналар тоташтырган. Тик яшәү рухы икесендә ике төрле. Кешеләр, авылда иркен сулап була, ичмасам, диләр. Салават анда да иркен сулый алмый шул. «Бөкресе» ирек бирми...

Ул янә, тәмәкесен иреннәренә кысып, подъезд төбенә чыгып басты. Һәр чыккан саен, хәйран калып күккә карап тора ул. Бу юлы да зәңгәрлеккә төбәлеп, күзләренә бер гомерлек күкләр авырлыгын җыеп алды гүя. Кургаш болытлар агылалар да агылалар. Салават аларның һаман туган авылы ягына таба гына агылганнарын күрде.

Болытлар шул якка таба хәрәкәт итә башлады исә, янә карашларын җиргә төби ул. Болытлар да рәхәтлек бирми шул аңа. Ир кинәт үзе дә сизмәстән озын юлларга төбәлде. Энҗесен югалткан кешедәй, күзләре белән нидер

эзләде. Тәмәкесен кабызып җибәрде. Эчтәге ялкынның тышка төтене генә чыга иде гүя. Шәһәрнең биек-биек йортларында көпә-көндез тәрәзә саен утлар җемелдәшә. «Мәзәк инде бу шәһәр халкы» дип уйлады ул.

Җирдә әнә меньяшәр имән үсеп утыра. Арырак... Тукта, бу ни бу?..

Аның ишек төбенә җәелгән таш плитәләргә күзе төште. Алар ана кабер ташлары булып күренделәр. Әйтерсең зираты белән алып килгәннәр дә аның ишек төбенә бушатканнар, һәм җәеп куйганнар. Якын барырга куркып, шактый басып торды ир. Бу мәлдә аның нибары бер әйбергә – акылга зәгыйфьләнеп китмәвенә генә ышанасы килә иде. Ни гомерләр шул ташлардан куркып яшәде бит ул. Кинәт, күңелен өшетеп, һавада нидер гөрселдәде. Салаватның башы әйләнеп китте. Тәмәкесе бармак арасыннан шуып кына җиргә төште дә бөҗра-бөҗра төтенен өскә таба үрләтте. Аны аягы белән басып сүндерде ир, аннан ирексездән ташларга таба атлады.

Якынайган саен, кабер ташлары да эреләнә барды. Алар инде кабер озынлыгы гына булып күренмиләр, берсе-берсе чакрымнарга сузылгандай тоелды. Тиз генә кулларын, чәчләрен тотып карады. «Исәрләнгәнмен икән тәки» диде ул, үзенә ишетелерлек итеп. Җитмәсә, ташларның һәрберсенең бер башы түгәрәкләп эшләнгән булып чыкты. Ул инде кабер ташларындагы язуларны укый башлаган иде. «Тимеров Тимур...» Ир бар ихласын салып укырга тырышса да, беркемне дә исенә төшерә алмады. Ул зиратта сөйләшеп торган агайны хәтерләде. Бабасының өстендә йомры елга ташы дидеме әле? Карашлары йомры таш эзләде. Тик андый таш юк иде. Шуннан башкасы янына юнәлде. «Рәхимов Ри... Рияз...» Салават теле көрмәкләнгәнен тойды, аның башы да галәмәт каты әйләнә иде. Караңгы күкләре, кургаш болытлары һәм кабер ташлары белән бергә тагын әллә ниләр кушыла-кушыла, дөнья кинәт агып китте. «Ычкынганмын» дип уйларга өлгергән арада, ул кабер ташлары өстенә килеп тә төште.

«Ашыгыч ярдәм!, Ашыгыч ярдәм!» – дип шаулашкан кешеләрне ир төштә генә күргәндәй булды. Күзен ачарга тырышкан мәлдә, аклык эчендә аккоштай бер җан иясе, җирдән кубарылып, болытларга таба йөзеп бара иде. Аның: «Мин Рияз!, Мин Рияз!» – дип кычкырганын Салават ап-ачык ишетте. Бераздан ул, гап-гади күрше малаена әверелеп, тагын аның янына төште:

– Сиңа авырмы? – дип сорады.

– Авыр, бик авыр, – диде Салават.

– Ике кешелек йөкне берүзең күтәрү ничек авыр булмасын?! Миңа миңа да бик авыр... – диде дә канлы күкрәген сул кулы белән каплап, янә томан эчендә эреп юкка да чыкты.

* * *

– Ычкынган кешеләр бар инде бу дөньяда, – диде табиб.

Салават яңа күзен генә ачкан иде. Ак халатлы затның сөйләшүен ишетеп, өнсез калды. «Сүз минем турыда булса кирәк... «Сары йорт» дигәннәре шулдыр, күрәсең...» дип уйлады.

– Егетне әрәм итә язганнар бит, – диде табиб, Салаватка карап. Аннан үз юлы белән чыгып та китте.

Салават үзенең больницада булуын аңлап алды. Палатадагыларны күзәтеп, берара сүзсез торды. Кемнең, өскә күтәртеп, аягына герләр элеп куелган, кемнең кулы урап бәйләнгән иде.

– Травмотология бүлегенә эләктегез сез кичә, башыгыз белән ташка бәрелгәнсез, – диде күрше караватта селкенмичә дә ятучы бер агай.

Салават башын тотып карады. Аңа бинт уралган иде. Салаватның эченә җылы йөгерде. Каш ярылып, күз чыкмаган, төзәлер, диде ул эчтән генә. Ин мөһиме, акыл шөрепләренә зыян килмәгән.

Ул арада табиб янә әйләнеп керде. Салаватның башын тотып карады.

— Ычкынган кешеләр бар ла дөньяда, — диде ул, елмаеп. — Анда сезнең подъезд каршысына кабер ташлары түшәп куйганнар диме? «Ашыгыч ярдәм»дәгеләр әйтә... Берәрсе зиратта эшлиме әллә?

Салават беркавым уйланып торды, аннан икенче катта яшәүче Русланны кинәт исенә төшерде:

— Эшли икән шул. Әйе шул. Шул Руслан эшедер, мөгаен, — диде ул, үзалдына елмаеп. Бу мәлдә кинәт хәле җинеләеп киткәнне тойды.

— Уколга барырсыз хәзер, — диде табиб, чыгып киткәндә. — Температурагыз төшмәгән әлегә. Күбрәк ятарга тырышыгыз...

* * *

Больница аңа үз гомере хакында да уйлану мөмкинлеген бирде. Аның әлегәчә үзе турында фикер йөртергә вакыты да булмаган икән.

Буш хыялларга алданып, күзгә күренми генә гомер дә үтеп бара түгелме? Менә аңардан ни кала бу якты дөньяга. Улы кала. Андрей исемле. Үлгәч, ул атасын искә алырмы? Атасы рухына дога кыла белмәс инде. Үзе дә, өенә туганнарын чакырып, әти-әнисе рухына хәер-дога ирештерә алмады. Хатыны Маринага бер әйтеп караган иде дә, тегесе каршы килде. «Йортта бер генә дин булырга тиеш», — диде. Дөрес, ата-бабаларының каберләрен караштырып тора торуын. Рияз белән бер тирәдәрәк яталар алар...

Әтисенең сеңлесенә барып аш үткәрмәкче булды бер тапкыр. Тегесе: «Синең үз өең бар бит, нишләп миндә үткәрергә җыенасың әле? Йортыңа дога керер дип куркасың мәллә?» — дип каршы төште.

Ә Марина аның язмышы иде. Авылдашы Гөлнарага мәхәббәте бөре көенчә күнел түрендә кипте. Юк, кипте, дию дөрес булмас, ул иң авыр мизгелләрдә һаман үзен сиздереп торучан ярага әверелде. Риязның сеңлесе иде ул. Дөньяда мондый мәхәббәт яралырга тиеш түгел иде. Ул кызның күзенә ничек карамак кирәк? Караган саен, ул газапка ничек түзмәк кирәк? Болай булырга тиеш түгел иде. Салават шулай хәл итте.

Гомер аңа гел алдадыр кебек тоелды. Тизрәк иртә тусын, тизрәк кич житсен, дип, алданылган икән лә. Үлемгә нибары бер адым икән. Ул мәхәббәтеннән ераклашкан, бәхетен тапмаган, әле яшәргә дә өлгермәгән бер зат икән — больница караватында ятканда шулар аның жанын өтте... Риязның рәнжеше төшкәндер инде, дип, үзенчә нәтиҗә ясады аннан.

* * *

Балачакның шундый көннәре була: бөтен җиһан чалт аяз. Авыл тирәли жылы яктылык, борчак басуы өстендә рәшә тибрәлеп тора. Кырда — иксез-чиксез киңлектә — тук кузаклардан сыгылып, бер кыр яшел борчак өлгерә. Кузакларның сутланып тулышкан мәле малайлар өчен Сабантуй бәйрәменнән бер дә ким түгел. Иртәнге җир салкынын суырган тыгыз тәнле кузакларның ялангач корсакка тиеп, тәнне кытыклый-кытыклый күлмәк эчендә шыбырдашуларын тагын кемнең ишеткәне бар икән? Аяк атлаган саен, күлмәк эчендә чи борчак шыгыр-шыгыр кузгала. Алардан тәнгә кыр салкыны үрли. Корсактан җир исе, уныш исе, борчаклы җәй исе килә. Аяклар үзеннән-үзе авылга элдерә. Кырлар каравылчысы күргәләгәнче, тиз кайтырга кирәк шулай.

Малайларның керфек очларына кагылып диярлек күбәләкләр очып үтә. Аларның әрфия канатлары кояш яктысында елкылдашып тибрәләләр.

— Син беләсеңме, кешеләрнең җаны күбәләк булып кайта да менә шулай дога сорап очып йөри, — ди Салават.

– Юкны сөйләмә, жан ничек күбәләк эченә сыйсын? Ул бит зур. Минем кадәрле, – ди кайсыдыр.

– Зур, зур, – дип тәкрарлый Салават, – миңа әби шулай әйтте, беләсең килсә.

Бәхәсләшә торгач, тагын да тизрәк кайтып җителә шул.

... Менә хәзер дә малайлар, бергәләп, елга буенда борчакны бер өемгә бушатырлар да җиргә сузылып ятарлар. Аннан бармак очлары белән генә таза тәнле борчакларның кузакларын каерырлар. Тыгыз кузакның эчке ягын иреннәргә тидергән көенчә, борчагын теш белән эләктереп, ләззәтләнә-ләззәтләнә чәйнәп йотып җибәрерләр. Авыздан сулар килерлек...

Тик әллә ни булды ул көнне. Һич көтмәгәндә нәрсәдер гөрселдәде. Аннан тагын. Тау башына кунган рәшәләр, кинәт шуышып, җиргә төшеп яткандай булды. Бер мизгелгә кояш сүнде. Көтмәгәндә аттылармы шулай?.. Һәммәсенең бу тавыштан котлары очкан иде. Малайларның корсактагы борчаклары кинәт җиргә коелды. Алар, өнсез калып, авылга таба йөгерделәр. Тик берәү – Рияз гына йөгерә алмады... Аның күкрәгеннән кызыл тасма сузылып төште...

– Салават, атма, – дип кычкырды ул көлә-көлә, малайның каршыга мылтык күтәреп килүен ерактан ук күреп.

Салават та көлде. Көлә-көлә килде. Ул бу мылтыкның атасын үзе дә белми иде шул. Әтисенең аудан кайткач та элеп куйган мылтыгын тиз генә эләктерде дә малайларга каршы йөгерде. Шуны аларга күрсәтер өчен, борчакка да бармый калды хәтта. Мактанасы килә иде. Тик... әллә нишләп атты бу мылтык... Риязга атты...

* * *

Шуннан аңа тау кадәрле бөкре үсеп чыккандай булды. Үзе каядыр артта, күренеп тә тормый, үзе яшәргә дә ирек бирми. Бу авыр йөген малай булып та, олпат ир-егет булып та күтәрә ул. Тик күтәргән саен авырая гына бара. Бу хакта Маринасы да белми хәтта. Хәер, адәм баласы бу дөньяда япа-ялгызы шул. Газаплары да аның берүзенеке генә. Аларны кешеләр белән бүлешеп булса икән лә соң... «Гөлнара, син генә аңлыйсың мине, матурым, – дип кабатлый ул. – Тик куркак бер затка әвереллдем шул мин, гафу ит, зинһар! Сөюемнән качтым... Синнән качтым...»

Салават сискәнеп китте. Җир өстендә гомере буена кешеләрдән качып йөри түгелме ул? Кешеләр шул аны берничек тә аңлый алмыйлар. Гаепли генә беләләр.

Кайчакта Рияз урынына үз улын куеп карый да кан тамырлары тартыша башлаганны тоя. Аннан Риязның әти-әнисен күз алдына китерә. Шуннан ул үзен дә үлгән итеп күрә... Һәм коточкыч бер халәт кичерә...

Менә Риязга янәдән яңа таш куйдыртты. Кабере дә ялт итеп тора. Тик... тузан утырмасын сырларына, сөртештереп торырга кирәк, дип уйлый ул, яман уйларыннан арынырга теләп, һәм зиратка юнәлә.

* * *

Салават больницадан кайтканда, бер төркем ирләр подъезд ишеге төбендәге кабер ташларын машинага төяп яталар иде.

– Бик вакытлы эләктен, күрше, булыш әйдә, – дип каршы алды аны икенче катта яшәүче Руслан. – Подъезддагылар жалу язган. Карт-коры инде. Кире зиратка илттерәләр менә, – диде ул, ашыга-ашыга.

– Таш таш инде. Нәрсәсе бардыр шулхәтле. Машинаны хет чистага куяр идек, – дип кушылды бер яшь кенә егет.

– Син ник алып кайттың соң боларны монда? – дип сорады Салават.

– Курыкма, урламадым, – дип авызын ерды Руслан. – Зиратта списать ителгән ташлар алар. Янасын куялар, искесен алып китүче юк. Кая илтәсең аларны? Бер склад тулып яталар шунда. Хет кирәкле эшкә ярарлар дип уйлаган идем. Сазга машина куйганчы. Өстенә асфальт салырга була. Ә халык әллә нинди бит бездә. Кайсыларыдыр һушын югалтып егылган, ди, имеш.

– Анда бер йомры елга ташы да бар иде...

– Калды ул шунда, бер эшкә ярамый ич ул. Яраганнарын алып кайттым менә. Тик кешеләргә барыбер ярап булмый.

– Зират бик изге урын бит ул, – диде Салават, ана каршы төшеп. – Әрвахларның рухы монә шатланыр дип уйлыйсыңмы әллә?

– Үлгәч, барыбер инде ул. Бу ташларны бәкләр, ханнар төрбәсеннән дип белдең мәллә син? Алары да юк инде аның хәзер. Чиркәү нигезләренә салып калдырганнар. Гәжитләр шулай яза. Укыганың юк мәллә бер дә. Музейларга алучы да күренми ич боларны.

– Алмасалар да, аларның урыны бары тик зиратта гына.

– Зиратта урын юк, дип торам бит мин сина. Ташларны жыяр вакыт житте. Тик кая? Беркемгә дә кирәкми ич алар...

– Нишләп кирәкмәсен? Туганнарына әйтергә иде, алар хәл итсен...

Ир кычкырып көлде дә кулын селтәде. Аннан дәвам итте:

– Беләсең килсә, ике-өч елдан ул зиратның эзе дә калмаячак. Жире әллә кайчан сатып алынган. Зур йортлар калкып чыгачак анда. Планын безгә китерделәр инде. Ә зират урынына туры килгән жирдә яшьләр өчен күңел ачу комплексы булачак. Мондый гади таш түгел, мәрмәрләрен дә чыгарып кына атачаклар әле елгага, күрерсең менә.

Салават кабер өстендәге гап-гади йомры ташны күз алдына китерде. Бөтен каберләр дә табигыйлектән аерылмаса, мондый күңелсез хәл килеп чыгар иде микән? Ничек акыллы булган бу карт, дип уйлады.

Әйе, кабер ташлары жансыз. Ул ташлар берничек тә яшәүгә өмет уята алмыйлар. Ничек кенә кыйммәтле булсалар да... Каберләр дә... Үлемнең дә киләчәге юк. Кешеләр бит ташларда түгел, йөрәкләрдә яши. Тик һәркем инген жирендә мәңге тыныч ятарга тиештер бит инде. Аны борчып тору ярамыйдыр, дип үзенчә нәтижә дә ясады, зиратта очраган агайны исенә төшереп.

Руслан сөйләде дә сөйләде. Салават дәшмәде. Тынлап та бетермичә, сагаеп кына өенә таба атлады. Күз алдыннан әрфия канатлы күбәләкләр йөзеп үтте. Алар, кешеләрдән куркышып, әллә кая биеккә-биеккә юл алдылар...

Ташларга кагылырга һәм алардан аерылырга намусы кушмый иде аның. Чөнки ул ташлар арасына аның жан жәрәхәте яшеренгән иде. Үлемгә булган нәфрәте яшеренгән иде. Яшәүгә булган омтылышы һәм яшьлек мәхәббәте яшеренгән иде. Шушы сөю көче аны жир асты турында уйлый башлауга, Ходайның рәхмәте белән һаман биеккә, караңгы күкләргә күтәреп ала. Һәм үз-үзен югалтып бетерергә һич ирек бирми. Кургаш болытлар агыла да агыла... Яшәү белән үлем арасында басып торган зат өчен һичнәрсәнең әһәмияте калмаган бер мизгелдә якты рәшә булып уйнап ала ул сөю. Шуннан аны янә сагыш баса: «Эх, Риязның йөрәгенә тигән ядрә минем жаныма ук эләккән бугай шул, каһәр», – дип пышылдый. Эх!..



Розалина
Шаһиева

# АНА ТЕЛЕ – ГҮЗӘЛЛЕК...

## Халык җыры

Нинди бишекләрдә тирбәлмәгән,
Нинди моңлы авазлардан
яңгырамаган –
Ераклардан килгән елга суы сыман –
ярсып, тынып,
күкрәкләрдән – күктә йолдыз йөрешедәй –
серен ачып, күңелен ачып,
аваз салган бу дөньяга:
– Мин бар! – диеп.
Яңгыр кебек – хистән туган,
Күктән төшкән,
Пар канатлы моң агымы –
Халык җыры.
Күпме күңелләрне уятасың,
Җырлатасың, моңлатасың –
Гаҗәп тылсым! Нинди ырым!
Минем җырым!

## Әрем

Әрем изеп учта, иснәдем...
Нинди таныш хисле авазлар!
Балачактан – кичке намазлар,
Кайнар нарат, черки, лабазлар,
Әйтерсең лә, мин бер баһадир –
Иксез-чиксез илдә бәхетем...
Яшел күлләр, дала-тәхетем, –
Алып китте әрем-чеметем!...
Зур илләрдә гигант агачлар,
Чәчкәләре кавын зурлыгы..,
Ләкин әрем исе булырдай –
Юк хикмәте, адәм хурлыгы!

Розалина ШАҺИЕВА – *шагыйрә, сәнгать белгече; «Кара мәрҗән», «Ниса» һ.б. шигырь китаплары авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Әче әрем кергән каннарга —
Дәвалаучы, терелтүче тәм...
Озайтучы кеше гомерен —
Мәңгелеккә — меңъеллык үлән.

***

Үз телеңдә сөйлә, сабый,
Ана теле — гүзәллек.
Бу тел белән дөньяларны,
Диңгезләрне гизәрлек.
Ата—баба тудырган тел —
Ана сөтедәй газиз.
Үс, чынык, үрләрне яула,
Баесын мирасыбыз.
Дөнья киң, телләр, гадәтләр —
Барсы да синең өчен.
Йөр милләтләр бакчасында
Күбәләк кебек очып!..

***

«Шигырь үлде» — ди кайберәүләр
Яңа заманнар җитте...
Көнбатыштагы шаукымнар
Безгә дә килеп җитте...
Юк, халкымның, теле, коты,
Зәвыге һәм заманы —
Шигырьгә төйнәлеп калган,
Үзгәртеп булмый аны.
Тумаган шигъри назымнар
«рекламага», «өндәүгә»
Кайда анда җан тетрәтү, —
Мәңгелек хисләр кайда?!
Гомер буе шигырь — гигант,
Булып алыш — яу аты,
Күпме буын, адәмнәрне,
Йокысыннан уятты.
Юк, татар шигырьсез, җырсыз
Яши алмас беркайчан...
Җырлар,
　　дала кояшыдай,
Янган күкрәген ачып!

## Әллүки

Нинди хиссез бушлык бу йөрәктә...
Ахры талаганнар кодрәтне...
Гомер буе җыйган байлыгымны
Тартып алды кайсы мөртәте?
Күңел җәүһәрләрен җую —
Авыр халәт...
Яратканны, ышанганны гел.
Соңгы өметемне тартып алды
бүген — мин үстергән асыл гөл.
Инде миңа бары чатка чыгып,
«Әллүки»не калды еларга!
Сагынганга, егылганга ярдәм —
Кылә икән бары Ходайдан.

## Васыять

Каберемне тирән казымагыз...
Яңгырны тоярлык булсын...
Көтү кайтышының тыпылдавын
Ишетерлек булсын.
Сандугачларның мәхәббәт
Ярсулары ишетелерлек булсын!
Нәни балаларның йөгереп узуларын
Ишетерлек булсын!
Яңа үскән чәчкәне
берәү таптаса, гарьләнеп,
Ул адәмне иманга китерерлек булсын.
Каберемне
тирән казымагыз...
Күккә карап, шигырь җырлаганда
Ишетерлек булсын!

***

Ах, көяз дәү-дәү агачлар, –
Әйтерсең, син җәннәттә!
Кайтып китәр идем өйгә –
Оныгымны сулга салып,
Биштәремне уң якка...
Мәтәлдем, чит җанвар сыман,
Бөтерелдем, чайкалдым...
Онытып узган – үткәнне
Шәрә таякка калдым...
Килде миңа тәмугълардай, –
Иң соңгы нечкә газап –
Әйтерсең лә. Ватаным юк,
Туган-үскән җир харап!
Шундый бәлага тарганда
Төшкә керде Казаным!!
Көттердең, дип күкрәгемә –
Алсу чәчәк кадады.
Сикереп киттем чәнчүдән,
Күзләрдән очты очкын...
Терелдем мизгел эчендә,
Канатлар китте очып! –

Фәрит Гыйльми

# САЛАВАТ КҮПЕРЕ

Мина алар еллар пәрдәсе аша карап тора. Тыныч кына. Нәрсәгәдер бераз моңайгандай итеп...

Зәңгәр күк. Зәңгәр күл. Ап-ак төнбоеклар.

Якты күк. Якты күл. Ап-ак төнбоеклар...

Кай арада ачылырга өлгерде алар?

Тузанлы юл. Бөкре бабай. Капчыклы кыз... Картайган авыл. Тузган скрипка. Камчылы казак. Кай арада күңелгә килде әле алар?

Мин авыл башында торам. Таныш чирәмнәр. Изге истәлекләр. Барысы да кадерле миңа. Яңа гына яңгыр явып үткән. Җирдән пар күтәрелә. Түгәрәк күл өстеннән өскә таба салават күпере сузылган. Аңладым — миндә балачакның бер истәлеге, таң җилләре исеп куеп, кояшның беренче нурлары уяткан төнбоек чәчәге кебек ачыла... Мина моңсу-моңсу. Үземне ниндидер буш дөньяга эләккән кебек сизәм... Биектән, салават күпере өстеннән, малай чагыма барам кебек.

... Алар — кәрлә каен агачы шикелле бөкрәйгән, аркасына скрипка белән капчык аскан карт һәм бер чандыр кыз өйдән өйгә йөриләр. Урамны йөреп чыккач, авыл башындагы яланда туктап, озак итеп ял итәләр. (Йөреп чыгу, дигәннән, хәзер алар урамны бик тиз әйләнәләр. Сәбәбе — безнең авылга аклар керде. Аларның солдатлары яши торган йортларга хәерчеләрне кертмиләр). Без, малайлар, авылда болар кебек хәер эстәп көн күрүчеләрне күп беләбез, күп күрәбез. Ни өчендер алар бездә артык кызыксындыру тудырмый. Ә боларны күрсәк, безнең малайлар йөрәге ярсыбрак тибә башлый. Менә алар авыл башында. Тынычрак булсын, диптер инде, ялан буйлап бераз барып, уйсулыкка юнәләләр. Безгә хәзер качып торуның кирәге юк. Кулларны артка куеп, мосафирларга таба юнәләбез. Барып җитәрәк, аяклар ирексездән туктап кала. Безнең йөрәкләрдә барлык хисләр — аларны кызгану да, кызыксыну, хөрмәт итү дә бергә кушылып беткән. Бернинди сәбәпсез, тәк дуамал алар янына барып бассак, ул хисләр ничектер чайпалып китәр кебек. Алар янына бару өчен җай эзлибез... Кесәдән рогаткаларны суырып чыгарабыз. Кулда — таш. Кая атарга? Тирә-якта — чирәм дә чирәм. Безнең баш очында — эссе июнь кояшы. Аның кайнар нурларыннан бөтен табигать әлсерәгән. Ә-ә, менә безгә мишень! Аларны әлсерәтүче кояшмы әле ул?

— Малайлар, кояшка таш ыргытмагыз!

Ниһаять, безгә алар янына барырга җай чыкты.

— Без болай гына. Шаярып.

— Кояш белән шаярмыйлар.

Әхмәт бабайга без әллә бар, әллә юк. Кулын каш өстенә куйган да Иманлек урманы юлы буйлап авылга якынаеп килүче бер төркем акларны күзәтә. Ә аның оныгы Айсылу башын түбән игән дә тырышып-тырышып үлән йолка, аннары аларны кире чирәм арасына тезеп чыга.

— Безнең янда сезгә тоз сипмәгәннәрдер бит, кәҗә бәтиләре. Сикергәләп йөрер өчен башка урын таба алмадыгызмы?

— Скегипкәнне бег уйнап җибәр әле, Әхмәт бабай?

Мәнге сакау, Пирук баш кушаматлы югары оч малае шулай диде дә оялып безнең арага кереп качты.

— Кич килегез сез аны тынларга, оланнар. Хәзер анын тамагы бетә. Күрәсез ич, көн нинди кызу.

Димәк, безнең бүген дә юл унмады. Күпме генә көтсәк тә, уйнамаячак ул. Гадәте шундый. Йә шундук сыздырып җибәрә, йә бөтенләй уйнамый. Ялыну, ялындыруны жене сөйми.

— Кызым, син кайт, булмаса. Мин зиратка кагылып әтиеннең каберен карап кайтыйм.

Без Айсылуны өенә кадәр озатабыз да кире яланга йөгерәбез. Бу эсседә яланда да кызык юк. Хәтта кош-корт булып кош-корт тынып калган. Исәеп килүче каз бәбкәләре аналарының канаты астына борын төрткәннәр. Аларның жимен чыпчыклар чүпли. Бар тарафта, күз күреме жирдә рәшә уйный. Безнең әрсез күнелләр шуларга иярә. Тотынабыз кыр буйлап йөгерергә. Рәшә йөгерә, без куабыз. Ул кача, юк була, без яна дулкын сайлыйбыз, инде эләктердек, кочаклап кыстык дигәндә, теге тагын күккә инә. Шул рәвешчә, Арыслан байның арыш басуына житкәнбез. Арыслан бай — бик дини, кырыс, усал кеше. Әмма анын безнең күкрәк турысына житеп килүче арыш басуы шулкадәр йомшак, тәмле исле, ямь-яшел булып елкылдап, жем-жем килеп, безнең күзләрне яндыра, үзенә, үзенең дә иң уртасына чакыра иде. Үзебез куркабыз, үзебез иген дингезе эченә керәбез. Дөрес, бик дөрес әйтә малайлар. Зурлар өчен генә анын һәр әйбере изге икән. Менә ич, Арыслан бай арышының башка кешеләрнекеннән бер артыклыгы да юк! Яшел арышны мендәр итә-итә, рәхәтләнеп качышлы уйнап туярга өлгермибез, таныш тавыш янгырый.

— Малайлар, икмәкне таптамагыз!

— Без аны чынлап таптамыйбыз бит, Әхмәт бабай, шаярып кына.

— Икмәк белән шаярмыйлар. Исегездә тотыгыз: бик тиз ялкынга әйләнә ул.

— Арыслан бай күрсәме?

— Ул күрмәсә дә.

Без уйга калабыз. Күп йөрүдән, фәкыйрьлек, михнәттән, мөгаен, акылы кирегә китә башлагандыр Әхмәт бабайның! Ничек итеп бу яшел арыш ялкынга әйләнсен?

Кич житкәч, Әхмәт бабай, скрипкасын күтәреп, читән буендагы эскәмиягә чыгып утыра. Озак көттереп тормый. Скрипкасының кылын черки елаган тавыш чыгартып тарткалап куя да, башын кыек салып, уйнап җибәрә. Хәзер кичләрен көтү кайтмый инде (аклар бар малны жыеп, каядыр куып алып киттеләр), шуна күрә халык урамга иртә чыга. Карт-корылар әкрен генә Әхмәт бабайны урап алалар. Әбиләрнең яшьле күзләре баеп баручы кояшның өй түбәсенә, биек тупыл агачына эләгеп калган сонгы нурларына текәлгән. Нинди дер анлашылмас көч мине ихата эченә тарта. Өйалды баскычларында олы кешеләр сыман уйланып Айсылу утыра. Ябык, нечкә беләкләрен чалыштырып күкрәгенә куйган. Зур, кара күзләре әллә ничек карыйлар — анламыйм.

— Әссәламегаләйкем, күрше?

Жавап юк...

— Икегезгә бик авырдыр, Айсылу. Иртәгә мин дә сезгә булышыйммы?

— Минем хәер сорашасым килми.

Күлмәк жинем белән анын күз яшьләрен сөртәм. Минем дә күнелемә әче төер утыра. Без генә түгел, Әхмәт бабайның скрипкасы да елый икән ич. Дөнья буш, буш, Әхмәт бабайларның ихатасы кебек. Ә урамда — кешеләр. Башларын игәннәр.

Үземнең көчсезлегемнән, Айсылуга тырнак очы хәтле генә дә ярдәм итә алмавымнан бәгырем телгәләнә. Ә ярдәм итәргә бик тә кирәк! Чөнки мин — малай кеше. Әни дә әйтә: «Айсылу авылда иң бәхетсез бала. Ятимәләргә игелек кылсаң, савабын арта. Тәмугта янмыйсың!» Күлмәк жиннәрем белән анын күз яшьләрен тагын сөртәм. Ул күтәрелеп мина карый. Чем-кара, жемелдәп торган күзләре болай да ярсыган күнелне янә тузгытып ташлыйлар.

Алар мина өмет, ышаныч, олылау белән, бик тә үз итеп, якын итеп карыйлар. Анын кулларын үземнең учыма алам. Оялудан, тагын әллә ниләрдән — һич

аңламыйм, тәнем кызыша, яна башлый. Зиһенемдә мең төрле сүзләр бөтерелеп йөри. Мондый вакытларда сүз башларга кирәк! Ниндидер сихри көч мина шулай куша.

— Айсылу?

Җавап юк. Ул, бер йомгакка әверелеп, бөтенләй кечерәеп калган. Сулкылдаган вакытларында гына ябык калак сөякләре бер күтәрелеп, бер төшеп алалар.

— Айсылу, иртәгә сезгә булышыйм инде, ә? Бергә-бергә җинелрәк булыр.

— Кирәкми, Бәдретдин. Малай кешегә хәер сорашырга һич ярамый. Син, зинһар, көчле, әйбәт кеше булып үс, яме. Хәер эстәгән малай көчле булып үсә алмый ул.

— Айсылу, мин булышам гына ич.

— Алай да ярамый, Бәдретдин. Хәерче — кызганыч, мескен кеше. Мескен малай батыр булып үсалмый. Ризамы, мин сине скрипкада уйнарга өйрәтәм?

— Риза.

Әйттем бит, сүз башларга кирәк, дип! Айсылу күзгә күренеп тынычланды. Язылды. Мина таба күчебрәк утырды.

— Бәдретдин, бер сер әйтсәм, кешегә чишмәссеңме?

— Чишмәм, Айсылу.

— Ант ит.

— Әпекәем, туры кояш, алдасам — баскан урынымда җир йотсын! Бер кешегә дә әйтмәм!

— Әхмәт бабайга да, диген.

— Әхмәт бабайга да. Алдасам — җир йотсын! — Айсылу пышылдауга күчте.— Төшемдә гел әниемне күрәм. Үзе янына читкә чакыра. Ә мин карышам, үзен авылга дәшәм. Дөрес эшлим бит, Бәдретдин?

— Әйе шул! Берүк ризалык бирә күрмә!

— Ант итәм, Бәдретдин, бабайны, сине ташлап, беркая да китмим!

Айсылуның мина шундый зур сер, ышаныч белдерүеннән үсенеп, горурланып киттем. Әмма куркытып, шөбһәләндереп тә алды. Айсылуның әнисе, әтисе белән бергә читкә, акча юнәтергә киткәч, тиф дигән зәһәр чирдән вафат булган, әтисе авылга кайткач, гүр иясе булган. Нигә чакыра икән инде әнисе Айсылуны үз янына? Кирәкми, кирәкми! Берүк кызый ризалык бирә күрмәсен!

— Айсылу, ант итәм, мин дә сине ташлап беркая да китмәм!

Айсылуның иреннәре калтырана, нидер пышылдый. Күзләреннән минем кул аркасына кайнар күз яшьләре тама. Кабаланып, күлмәк җинем белән йөзен каплыйм. Яшь тамчыларына ияреп, кара күзләре таммасын! Минем вагъдә шатлыгыннан мөлдерәмә тулган ич алар!

Әхмәт бабай да башлаган көен уйнап бетерә алмады. Атлы казаклар кешеләрне куып тараттылар. Әхмәт бабай скрипкасын күтәреп өйгә керде.

— Бабай, икмәк ничек ялкынга әйләнә соң ул?

— Уйлап кара. Теләсән, бөтен авылны да һавага менгезеп куярга була.

Мин шаккаттым. Күз маңгайга сикерде.

— Ничек?!

— Моның өчен үзенә ялкын булырга кирәк!

Икенче көнне Айсылу хәер сорашырга чыкмады. Әхмәт бабай да, авырыйм, дип, өйдә калды. Без, Айсылу белән икәү, аның скрипкасын алдык та яланга киттек. Айсылу мине скрипкада уйнарга өйрәтеп маташты. Тик, аны ничегрәк тотарга кирәклегеннән башка, бернәрсә дә өйрәнеп кала алмадым.

Көн җиләсләнеп китте. Минем уң колак ягында, Калатау өстендә авыр, кара зәңгәр болытлар күренде.

— Айсылу, күр әле теге болытны, гел атлы казак инде.

— Ә урман өстендәгесе — партизан.

— Әй, чынлап та. Ул урманда кызыл партизаннар яши икән, дип сөйлиләр. Тизрәк безнең авылга да килсеннәр иде алар.

Күк күкрәү тавышлары якында гына ишетелсәләр дә, болытлар безнең авыл турысына ук килеп җитмәделәр. Түгәрәк күл ягына таба борылдылар. Яңадан кояш чыкты.

— Бәдретдин, салават күпере! Яшеле мина!

Их, мин аның калыкканын ничек күрмәгәнмен. Ә менә хәзер Айсылу миннән бәхетлерәк. Салават күперен беренче булып күргән кеше бәхетле була, диләр бит.

— Ә ни өчен яшеле сина?

— Шуны да белмисеңмени?

— Шуны да белмим.

— Тыңла. Яшел төс — яшәү төсе ул. Яшел ялан, яшел уҗым. Алардан кешегә бернинди зыян килми. Зәңгәр төс — диңгез төсе. Суга батып үләчәксең. Сары — авыру төсе. Кызыл булса — янып үлү.

— Бигрәк инде син, Айсылу, сүзеңдә гел үлү дә үлү.

— Шуңа күрә яшел төсне көтеп алдым ич. Аның турында гына сөйләшик, Бәдретдин, яме.

— Аннары тагын скрипка турында, әйе бит.

Өйгә кайткач, ашарга гына утырган идем, урамда мылтык аткан, әллә нәрсәләр шартлаган тавышлар ишетелде. Әни барыбызны да өй базына куып төшерде... Барыбер чыктым баздан. Нидер сизенгәндәй, урамга ук чыктым. Әхмәт бабайларның өе дөрләп яна. Аны аклар урап алганнар да беркемне өйгә якын китермиләр.

Кайсыларыдыр арбага мәетләр ташый. Ә урамда кешеләр, кешеләр... Башларын игәннәр. Әхмәт бабай скрипка уйнагандагы кебек. Күзләрендә яшь. Күзләрендә тагын әллә ни, анысын мин аңламыйм. Әнинең кемнәрнедер каргый-каргый ачынып елавыннан төшенеп алдым — янып торган өй эчендә Әхмәт бабай калган икән. Аклар өй эченнән аны чыгармыйча торалар икән... Кинәт халык тагын шаулаша башлады.

— Җәмәгать, ул сабыйның ни гаебе бар? Мөселман зиратына аерым күмәргә кирәк аны.

Аклар арасыннан курчак кебек кечкенә бер гәүдә алып чыктылар. Айсылу гәүдәсен.

...Икенче көнне Айсылу кабере өстенә аларның ындырыннан табып алган скрипканы илтеп куйдым. Жил искәндә хәзер инде кыллар еламыйлар. Кыллар өзелгән.

Әхмәт бабайларда яшеренеп яткан разведчик-партизаннарның гәүдәләрен Түгәрәк күл ягына алып китеп күмгәннәр. Иртәнчәк авылны сугышып алган партизаннар белән авыл кешеләре Әхмәт бабайның гәүдәсен озак эзләделәр, ләкин таба алмадылар.

Якты күк. Якты күл. Ап-ак төнбоеклар! Кай арада ачылдылар соң әле алар?

Яңа гына яңгыр явып үткән... Әйләнә-тирәмдә чалбар балакларын сызганган малайлар, тузган чәчле кечкенә кызлар яңгыр суын чәчрәтеп йөгерешәләр. Менә бер кыз таеп егылды да, бөтен көченә яңгыратып кычкырып җибәрде:

— Малайлар, салават күпере! Яшеле минә!

*1967*

Рауль
Мирхәйдәров

# КАРГА КҮЗЕН КАРГА ЧУКЫМЫЙ

170 ел элек Ф.М. Достоевский Рәсәйдәге теләсә нинди реформа түрәләр санын арттыру белән генә тәгәлләнәчәк, дип язган иде. Аның сүзләре хак булып чыкты, ләкин ул да бүгенге кадәресен алдан күрәзәли алмагандыр. Соңгы егерме ел эчендә Яңа Рәсәйдә чиновниклар саны, СССРдагы белән чагыштырып караганда, өч тапкыр артты. Өч тапкыр! Бу әле унбиш союздаш республиканың СССР составыннан аерылып чыгуын исәпкә алган хәлдә. Елга ике тапкыр балалап, 10-15әр бала китерүче дуңгызлар да, дөньяны басып алган күселәр ыруы да бу кадәр үрчем бирергә сәләтле түгел. Хәер, безнең халык коточкыч югары эш хакы алып эшләгән һәм һәртөрле бонусларга ия булган бу күселәр өеренә дә түзәр иде. Шоферлары белән бер комплектта кулланылучы, чиновникның үзен генә түгел, ә аның гаиләсен дә көне-төне йөртеп торучы махсус автомобильләр, гади кешеләргә керергә ярамый торган махсус ашханәләрдәге махсус әбәтләр — боларын без, гади халык, шактый авыр күзаллыйбыз инде. Сүз уңаеннан: әлеге дә баягы ашханәләр ашханә дип атала гына, чынында исә алар чып-чын рестораннарны хәтерләтә. Әмма югары катлам вәкилләре өчен шунысы белән уңайлы алар — монда 100 сумга тулы әбәт (салаттан башлап, десерт, чәй-кофены да исәпкә алып) ашарга мөмкин. Без, гап-гади Рәсәй халкы, Мәскәү кофейняларында гадәти кофены 160-250 сумга алып эчкәндә, монда — 100 сумга менә дигән тулы әбәт! Шуннан соң хакимиятнең «чиновник» категориясенә кергән сөекле ул-кызларына мөнәсәбәтен аңлатып торырга кирәк түгелдер инде, шәт?! Ә инде «халыкка хезмәт итүче»ләр өеренә отпусклар һәм отпускнойларның аерым бер исәп белән түләнүен, махсус пенсияләренең нинди нульләрдән торуын да сөйли башласаң, алар хезмәт иткән мескен халыкка инфаркт булуы ихтимал.

Күптән түгел генә үземә тагын бер ачыш ясадым, сезнең белән дә бүлешми кала алмыйм. Йөзләгән профессия вәкилләре, меңләгән оешмаларның профсоюзлары юк. Рәсәйдәге барлык төзү объектлары да колбиләүчелек чорындагы кебек эшли. Мондагы эшче көчләрнең хокукларын яклау, гомумән, каралмаган. Бездә ул профсоюзлар, иманым камил, әле ун елдан соң да булмаячак, юкса нәкъ менә алар хокукый дәүләтнең төп күрсәткече булып тора бит! Ә менә Рәсәйнең югары дәүләт структураларында эшләүчеләр өчен профсоюзлар каралган. Һәм бу профсоюзлар түрәләрнең, аларның хатыннарының һәм балаларының җаннары ни тели, шуны юнәтә ала: иң шәп лагерьларда ял итүне дә, диңгезгә сәяхәтне дә, кышын балакайларны Аурупада ял иттереп кайтуны да. Түрәләрне аңгыра дип уйлаучылар бик нык ялгыша, безгә — гади халыкка да алардан үрнәк аласы иде бу эштә!

Әмма халыкның алга таба да үз җилкәсендә бу йөкне йөртергә теләмәвенең

сәбәбе бүтән. Бу юлларны язганда, бер өер чиновникларның: «Нинди сәбәп ул тагын?» — дип үкерүен ишеткәндәй булам. Халык җилкәсеннән төшәргә теләмәсләр бит инде! Ачыктан-ачык әйтәм: без аларның элеккеге заманда яшәгән затлы ханымнарның будуарларын хәтерләткән зиннәтле кабинетларда утыруына да, гади кеше аяк басарга тиеш булмаган, иң шәп белгечләрдән генә торган шифаханә-санаторийларда дәвалануына да, елына ничә кат чит илләргә ялга баруына да (тәҗрибә туплар өчен, дип атала бу аларның катлаулы телендә) түзәр идек. Иң чыгырдан чыгарганы бу түгел. Иң чыгырдан чыгарганы: әлеге ташламаларга карамастан, күбесе әле оялмыйча урлаша да! Һәм әле ничек кенә урлаша, үзенә генә түгел, ә балалары, оныкларына, аларның оныкларының оныкларына җитәрлек итеп, әллә ничә дистә елны исәптә тотып! Шива атлы алиһәгә, әллә ничә кулы була торып та, безнең чиновникларга кадәр үсәсе дә үсәсе әле! Менә ни өчен халык аларга мәңге түзмәячәк, чыбыркыдан куркып, йә, киресенчә, тәмле-татлы вәгъдәләргә алданып тагын бераз түзсә генә инде. Тик бу очракта ул үзе дә әллә ни озакка чыдамаячак. Уйлап карагыз әле: без булмасак, чиновниклар да юкка чыгачак. Эшчеләр, профсоюзлары булмаса да, барыбер киләчәк турында уйлыйлар инде, үз киләчәкләре хакында булмаса, балаларының язмышы турында. Ышандыра алам: халыкның карашында арыганлык һәм сагыш кына, моңарчы барысына да риза булып, чыдап яшәүчеләрнең дә күзләрендә куркыныч очкыннар бии. Фәкыйрьнең җуяр әйберсе аз аның.

Әгәр әлеге дә баягы әрәмтамакларның санын кыскартып булса, илнең бюджетына да җиңеллек килер, ришвәтләр дә кимер иде. Олы һәм кече бизнес та иркен сулыш алыр иде, бәлки. Юкса ришвәт алучының кем булуы да билгеле, бу хакта көн-төн телевизордан сөйләп торалар — губернатор үзе, аның урынбасарлары, шәһәр мэры, мэрның яраннары... Бу башкисәрләр өере, Саша Белый бригадасыннан да болайрак кыланып, берөзлексез үз бизнесын булдырырга омтылучыларны кысрыклыйлар, көпә-көндез акыртып талыйлар, җир сатып кесәләрен кабарталар, кыскасы, Аллаһы Тәгалә вазифаларын үз өстенә алып, барына да хуҗа булырга омтылалар. Безнең дәүләт эшлеклеләренең кыланмышларын сөйли башласаң, өч көн тоташ башка бер эш тә эшләмәскә, бары сөйләп утырырга гына кирәк. Җинаять эше ачылган меңләгән җитәкчегә берәр данә хулиган, кесә карагы, йорт талаучы да туры килми хәтта. Урлашучы, талаучылар бүген — барысы да җитәкчеләр, асылда, «өстә» утыручы җитәкчеләр. Рәсәйдә соңгы 20 ел эчендә карак статусы бик үсте: бу статусны йөртүчеләргә депутатлар, министрлар, сенаторлар, ректорлар, генераллар, банкирлар, корпорация директорлары, баш табиблар һәм башка шундый «затлы» әфәнде-ханымнар плеядасы керә хәзер. Замана каракларына элеккеге карак исемен йөртүчеләр көнләшеп карыйлар, мондый тәвәккәллеккә һәм осталыкка өйрәнәседер әле аларга.

Егерме елдан артык милли идея эзлибез без, егерме елдан артык коррупциягә юридик аңлатма бирә алмыйбыз, шуңа чиновникларны да авызлыклый алмыйбыз. Башына тай типмәгән кем генә үзенә каршы закон язар икән?! Миңа калса, Рәсәйгә теләсә нинди милли идея, система, идарә итү ысулы килешәчәк: монархия булсынмы ул, социализммы, капитализммы, парламентаризммы, хәтта диктаторлык режимы булса да ярый. Рәсәйгә теләсә нинди партия ярап тора, чөнки алар барысы да бер төрле, максат-бурычлары да әллә ни аерылмый. Аларның төп бурычы — хакимияткә яраклаша белү, ә төп омтылышы — сезнең белән безнең кара тиребез сеңгән ипи телемен бүлгәндә читтә калмау. Барыбыз да белгән В.С. Черномырдин әйткәнчә, нинди генә партия төзесәк тә — КПСС

килеп чыга. Рәсәйгә, минем уйлавымча, теләсә кайсы конституция дә ярый, берәрсенекен файдаланып өчен алып торсак та була хәтта. Ул конституцияне 99,9 процент рәсәйле барыбер белми, берәрсенең кайчан да булса конституция тарафыннан яклануы шулай ук икеле. Бу кәгазьдәге конституция, димәк, 0,1 процент тәшкил итүче рәсәйле чиновникка үз мәнфәгатьләрен кайгыртыр өчен генә кирәк булып чыга. Рәсәйдәге рухи кыйммәтләрне дә, материаль кыйммәтләрне дә чиновникларның комсызлыгы, белдексезлеге, «кул кулны юа» әйтеме буенча эш йөртүе юкка чыгара. Шуңа да хакимият, йә аның тирәсендә бөтерелүчеләр арасында ничә дистә еллар буена бер үк йөзләрне күрәбез. Сирәк кенә йөзләр алышынса да, ахыр чиктә «иске йөз» урынына аның улы, кияве, туганнан-туганы, сөяркәсе килгән булып чыга.

Рәсәйнең төп бәласе америкалылар да, «Әл-Каида» да, мөҗаһитләр дә, мөселман дөньясы да, яһүдләр дә, татарлар да, чеченнар да түгел. Рәсәйнең күп гасырлык иң зур бәласе — түрәләр. Хакимиятне тота белмәү, демократия һәм азатлык төшенчәләрен дөрес аңламау нәтиҗәсендә, алар бөек Рәсәй империясен җимерделәр. Чиновник-партократлар шул ук сәбәпләр аркасында СССРны таркаттылар. Бүгенге түрәләр инде яңа Рәсәйне дә һәлакәткә илтәләр. Янә таркала калса, бу илне кабат торгызу, белмим, мөмкин булыр микән: аны патша вакытында да, СССР чорында да телемләп-телемләп чиновниклар үзләренә бүлеп алып бетерде инде.

Бүген бишенче колонна яһүдләр мәкере һәм дөньякүләм яшерен көч турында сөйләп торуның кирәге юк. Рәсәйдә моннан саллырак көч бар — түрәләр интернационалы. Ничек инде үзең утырган ботакка туктаусыз чабарга мөмкин дип аптырыйбыз. Аптырарга кирәкми, аларның чикнең теге ягында запас аэродромнары бар: чит ил банкларында бездән талап җыйган акчалары ята, чит илләрдә аларны ташпулатлар, яхталар, иң шәп уку йортларында укучы балалары көтеп тора. Лондонда гына да мондыйлар 400 меңләп, Ниццада исә — 200 мең. Болар XXII гасырга хәтле җитәрлек итеп туенган инде. Гадәттә, түрәләрнең, җинаятьчеләрнеке кебек үк, милләте юк диләр. Әмма бүген җинаятьчеләрне дә этник яктан аерып карап була, ә түрәләр — һаман интернационалда, алар без моңарчы белгән теләсә кайсы масон ложаларыннан да бердәмрәк бүген. Рәсәйдә милли идея табыла калса да, ул инде ярдәм итмәячәк. Рәсәй упкын читендә тора дип уйлаучыларның күңелен бөтенләй төшерә алам: Рәсәй упкынга убылды инде, ул хәзер иң-иң төптә. Пугачевск, Сагра, Кандопогадагы хәлләр, Мәскәүдәге даими конфликтлар шуны күрсәтә. Самолётлар дөмегә, космодромнарда ракеталар шартлый, башбаштаклык арты башбаштаклык — без бу сазлыктан Рәсәй түрәләренең аппетитын тыеп кына котыла алабыз. Төп милли идея нәкъ менә шуннан гыйбарәт хәзер.

Калганы — икенчел. Күптән түгел чиновникларның эш хакын икеләтә арттырдылар. Әбәт бәясе арткангадыр инде.

Бер Рәсәй түрәсенең зиннәтле тормышыннан мисал китермичә уза алмыйм. Ниццада Мәскәү өлкәсенең финанс җитәкчесе Алексей Кузнецовны кулга алдылар. Әллә 92 миллиард урлаган ул, әллә 37 миллиард «кына», ничек кенә булмасын, бу саннарның икесе дә гади эш хакына яшәүче рәсәйлене хуштан яздырырлык. Алексей Кузнецовны берничә ел элек кызының туенда ук кулга алырга кирәк иде. Бу туй турында газета-журналлар чаң какты, телевизордан Кузнецов сараеның йөзләгән бүлмәле затлы интерьерларын да күрсәттеләр хәтта.

Казна акчасын урлап дан казанган Кузнецов иптәшнең кызын кияүгә бирү безгә 5 миллион долларга төшкән булып чыкты, җәмәгать! Бер кунакны сыйларга гына да 20 мең доллар акча тотылган! Ирексездән «пир во время

чумы» гыйбарәсен искә төшерерсең! Сүз уңаеннан: Кузнецовның йорты (сарае) үзе Архангельскта урнашкан — парклар, оранжереялар, буалар белән уратып алынган, аны кеше күзеннән биш метр биеклегендәге дивар саклый. Эчендә исә — алтын йөгертелгән люстралар, башка зиннәтле корылмалар, сарайны махсус чакыртылган атаклы итальян дизайнерлары эшләгән. Болар һәммәсе ярты миллиард долларга төшкән!

Ә бит Кузнецов Мәскәү өлкәсендәге иң югары административ чин да түгел, аннан югарыда утыручылар бер дистәләп. Алар, үзләренең хәлләре мөшкелрәк булса, Кузнецовка майлырак калҗаны алып кабарга рөхсәт итәр иделәрме? Ә сезнең белән безнең җилкәбезгә мондый Кузнецовлар меңнәрчә бит!

Кузнецов кызының туенда яңа Рәсәйнең бөтен түрәләре рәхәтләнеп күңел ачкан. Зиннәт яратуы белән дан тоткан Людовик XIV сарайлары һәм бакчалары белән тиңләшерлек бу байлыкның таланган байлык булуын алар белмәделәр микәнни? Императорлар белән патшалар да бу кадәр азынмаган бездә заманында! Шул ук депутатлар, сенаторлар, прокурорлар, министрлар, погонлы туганнарыбыз нинди хисле тостлар яудырган иде ул чакта Кузнецов атлы ата карак һәм аның гаиләсе исәнлегенә. Телләре дә корып төшмәгән, намуслары да тыныч кына йокымсырый биргән. Карга күзен карга чукымый ди, шулай да бер Рәсәй күге өчен бу кадәр козгын инде артык күп тоелмыймы сезгә?

Хәтта Брежнев заманында, Үзбәкстанда Шәрәф Рәшидов җитәкчелек иткәндә дә, партиянең югары постларында утыручы түрәләр, бигрәк тә прокуратура, МВД, КГБ хезмәткәрләре шикле адәмнәргә, бигрәк тә малкуарларга мәҗлескә, туйга йөрми иде. Рисвай ителеп, икенче көнне үк эштән куылачагың көн кебек ачык. КПССның Партконтроль дигән бик кырыс бер бүлеге булып, аның хезмәткәрләре партия эшлекләренең мораль-этик һәм керем ягын да бик җентекле күзәтү астында тоталар иде. Казна акчасын талап, оялмыйча, бөтен илгә шаулатып затлы мәҗлес уздырырга берәүнең дә башына килмәс иде ул заманда.

Хәер, без Кузнецов кебекләрнең урланган миллиардларына инде ияләшеп өлгердек. Иртән берсен кулга алалар, кичкә икенче берәвен «җинаять составы юк» (нинди матур һәм сак гыйбарә!) дип чыгарып җибәрәләр... Кайсының ни эшләгәнен, нәрсә белән тотылганын да хәтердә калдырырлык түгел. Алексей Кузнецовны кулга алганда, аңарда төрле кешеләр исеменә теркәлгән, аның фотосы ябыштырылган дистәләгән паспорт тапканнар. Гади генә паспортлар да түгел, ә дипломатларга һәм дәүләт хезмәтендәгеләргә махсус бирелә торганнарны, ягъни бу ата карак үзенә чит илләрдә дә хөрмәт күрсәтүләрен теләгән. Ә хәзер уйлап карагыз: андый паспортлар вокзал каршында гына сатылмый, алар санаулы, һәм Россия федерациясенең Чит ил эшләре министрлыгында теркәлеп, органнар тарафыннан даими тикшерелеп торалар. Аларның барысында да чып-чын имзалар тора һәм бу имзаларны дәүләт органнарының махсус бүлекләрендә эшләүче кешеләр куйган. Алар нәрсә — алларына нәрсә кертеп салсалар, шуңа кул куялармыни?! Башкаладагы яшерен казиноларны «түбәләп» торучы Мәскәү прокурорларына бернинди җил-давыл тимәгәндәй, бу паспорт ясаучы осталарны да бернинди җәза көтмәячәк, әлбәттә. Эшне прокуратурага тапшырсалар да, «җинаять составы» тапмаячаклар.

Минем Мәскәү өлкәсенең губернаторы, генерал-полковник Борис әфәнде Громовка мөрәҗәгать итәсем килә: кул астыгызда эшләгән Кузнецов әфәнденең күп еллар дәвамында дәүләт казнасын талап ятканлыгын сез соң ничек сизмәдегез? Бу хәл ачыклангач та, ник соң сез тыныч кына Федерация Советында утыруыгызны дәвам итәсез,

дәүләт каршында нинди олы хезмәт күрсәттегез сез, анда әлегерлек? Ә, бәлки, коллегагыз, Курск өлкәсенең элеккеге губернаторы, Федерация Советының элеккеге спикеры, үзе җитәкләгән Курск өлкәсендә мөмкин булган бөтен нәрсәне үзләштереп киткән Егор Строев кебек, тәҗрибә уртаклашырга уйлыйсыздыр? Урлашу серләренә яшьрәкләрне өйрәтергә? Строевтан үрнәк алмагыз, Борис әфәнде!

Егор Строев хәтта кызын да сенатор итеп куюга иреште, ә майор киявен генерал дәрәҗәсенә күтәрде. Тылсымчы дими кем дисең инде шундый кешене! Газеталарда спикерның караңгы эшләре турында язгалый башлагач, аны тыныч кына ялга озаттылар. Инде Рәсәйдә гадәткә кергәнчә, «җинаять составы юк» дигән карарга килде органнар. Гаугадан соң бераз вакыт узгач, Егор Строев янә Федерация Советына кайтты, бу юлы инде — сенатор вазифасында. «82 яшегездә нигә кабат дәүләт хезмәтенә әйләнеп кайттыгыз?» — дип сорагач, ул, күзен дә йоммыйча: «Тәҗрибә уртаклашырга», — дип җавап бирде. Нинди тәҗрибәгә өйрәтер икән ул яшьрәк чиновникларны, ничек уйлыйсыз? Курск өлкәсенең әле таларлыгы калдымы икән? Бәлки, Борис әфәнде, сез дә Мәскәү өлкәсе казнасының төбенә төшү серләрен уртаклашырга ниятлисездер? Бер Кузнецов кына да андагы 92 миллиардны кесәсенә алып салганда, сез, мөгаен, әле хәзергедән күпкә самимирәк булгансыздыр?

---

## РӘСӘЙ КОНСТИТУЦИЯСЕ ҺӘМ МИЛЕК

Күптән түгел атаклы икътисадчы Евгений Гонтмахерның «Рәсәй дәүләте юк ул» («Российского государства не существует») дигән мәкаләсенә тап булдым. Яшерен-батырын түгел, либераль икътисад һәм аның тарафдарлары беркайчан да күңелемә якын булмады. Илнең хәзерге икътисади хәле — Б.Н. Ельцин һәм аның командасы кабул иткән әнә шул либераль реформаларның нәтиҗәсе, монда шәрехләп тору артыктыр. Әлеге либераль юлдан бара торгач килеп терәлгәнлегебез бүген һәркемгә дә аермачык күренәдер. Шагыйрь Л.Завальнюк әйткәнчә: «И не жаль то, что было, жалко, время прошло». Шагыйрь, билгеле, реформаларны күздә тотып әйтмәгән, әмма безнең хәзерге икътисади хәлебезне аның күрәзәчел гыйбарәсе бик әйбәт сурәтли. Минем үземә М.Делягин, С.Глазьев, Е.Бунич, Н.Кричевский, В.Иноземцев кебек икътисадчылар якынрак.

Югарыда искә алынган мәкалә кискен исем-атамышы белән җәлеп итте. Җитмәсә, Евгений Гонтмахер — иҗтимагый проблемаларны өйрәнүче галимнәрнең берсе. Бу аның фикеренә колак салыр өчен тагын бер этәргеч булды. Язучы һәм гражданин буларак, мине дә шул ук проблемалар борчый бит.

Евгений Гонтмахер белән бәхәсләшергә җыенмыйм, аның мәкаләсе бик вакытлы һәм урынлы, ул безнең җәмгыятьнең күз иярмәс тизлектә кайсы упкынга таба тәгәрәвен күрсәтер өчен язган. Һәм язма авторы үз максатына ирешкән дә, мин ул чыгарган нәтиҗәләр белән тулысынча килешәм. Хәер, башка берәүнең мәкаләсен сөйләп утыру — килешә торган эш түгел, әлбәттә, әмма шулай да, илебездәге икътисадны һәм дөнья базарындагы вәзгыятьне тамгалар өчен, Гонтмахер кулланган кайбер өр-яңа терминнарны «үзләштерергә» җөрьәт иттем. Һәм — кайбер саннарны да. Ник икәнен тора-бара аңларсыз.

Көнбатышта дәүләтнең үз-үзен тәэмин итә алу-алмавын билгеләүче термин буларак кулланылышка кереп киткән «Falied states» төшенчәсе

соңгы арада бездә дә популярлашып китте. Аны төрлечә тәрҗемә итәргә мөмкин: «барып чыкмаган дәүләт», «банкротлыкка чыккан дәүләт» һ.б. Гадәттә, мисалга Сомали, Гаити, Зимбабве, Әфганстан, Гыйрак кебек илләрне китерәләр. Без әле бу исемлеккә кертелмәгән, ләкин эш бит исемлектә теркәлү-теркәлмәүдә генә түгел...

Чит илләрдә җәмгыятьтәге байлыкның бүленешен әлеге җәмгыятьнең һәр берәмлеген күздә тотып исәплиләр. Аерым бер гаилә туплаган байлык (welth) — банкка салынган акчалар, акцияләр, күчемсез милек — барысы да керә бу исәпкә. Рәсәй исә үзендә тупланган мөлкәтне бүлү мәсьәләсендә иң гаделсез дәүләт буларак «дан казанган». 1 процент бай рәсәйлеләр катламына ил туплаган барлык мөлкәт, активларның 71 проценты туры килә. Америка һәм Аурупа буржуйларын телебезгә тилчә чыкканчы яманлаган чакларыбызны оныттык, ахрысы, бүген инде әлеге дә баягы «каһәр буржуйлык» буенча алардан да уздырабыз. Алай гына да түгел, дөньядагы барлык рекордларны узып киттек! Чагыштыру өчен: Һиндстанда бу күрсәткеч 49 процентны тәшкил итсә, Африкада — 44, АКШда — 37, Кытай белән Аурупада — 32, Япониядә нибары 17 процентны тәшкил итә!!!

Рәсәй дөньяда тагын бер төр хурлыклы күрсәткечләр буенча да — лидер. 10 процент бай рәсәйле Рәсәй мөлкәтенең 87,6 процентына хуҗа. 90 процент гади рәсәйлегә исә йөнтәс куллы чиновниклар һәм аларның яраннары үчлап өлгермәгән 12,4 процент кала. Нинди тигезлек, гаделлек турында сөйләргә мөмкин монда?! Нәкъ менә шушы күрсәткечләр Рәсәйнең «үз-үзен тәэмин итә алмаучы», «бөлгенлеккә төшкән» дәүләт булуын билгели дә инде. Хокукый җәмгыять һәм аның демократиясе турында нинди сүз алып барырга була монда?! Бу хәтта феодал җәмгыять кысаларына да керми, ә колбиләүчелек чорына кайткандай тәэсир калдыра. Совет чорын искә төшереп тору кирәкмәстер, 12,4 процент кына тәтегән гражданнар алай тынычрак йоклар. Хәер, ул 12,4 процент та, нигездә, приватизацияләнгән фатирлар бәһасеннән гыйбарәт, асылда, гади халыкка ил мөлкәтенең 5 проценты тәтесә дә — бу инде уңыш.

Рәсәй гражданнары — коточкыч гаделсезлек корбаннары. Моның сәбәбе нәрсәдә соң? Беренче чиратта — Рәсәй Конституциясенең үз гражданнары хокукын яклауны күздә тотып төзелмәгән булуында. Аны югарыда искә алынган либерал сәясәтчеләр бары тик үз мәнфәгатьләрен кайгыртып һәм үзләрен яклар өчен генә төзегән.

Бездәге либераль икътисад халык хокукларын якларга сәләтле булмаган һәм халык тарафыннан кабул ителмәгән приватизация белән төгәлләнде һәм җәмгыятьтә моңарчы күзәтелмәгән иҗтимагый тигезсезлекне китереп чыгарды. Ирекле эшмәкәрлек төшенчәсе төшенчә генә булып калып, илебезне олигархлар, кемнеңдер акча янчыгын калынайтып торучы, махсус булдырылган бер көнлек фирмалар, сату-алу өлкәсендә курыкмыйча, ачыктан-ачык диярлек эш итүче караклар, ялган продукция чыгару һәм аны тарату белән шөгыльләнүче яңа камырдан әвәләнгән оятсыз «сәүдәгәрләр» басты. Наркотиклар сатуга корылган «күләгәдәге эшмәкәрлек» 300 процент керем китерсә, ялган дарулар, медицина препаратлары сатудан алган керем 3 000 процентны тәшкил итә. Мондый галәми масштабтагы процентлар һәм бәяләрне исәпкә алсак, «күләгәдәге эшмәкәрләр» не мәңге авызлыклап булмаячагы көн кебек ачык. Үлем җәзасы кертеп карасаң гына инде...

Шулай итеп, дәүләтнең табыш-мөлкәте әллә ни зур булмаган бер җинаятьчел төркем кулына кереп бара. Тик шунысы ачык: бу төркемнең юлы Рәсәйнеке белән бер түгел. Аларның юлы — бөтенләй башка тарафка. Аларның Көнбатышта шәхси «аэродромнары» бар, балалары чит илнең иң шәп уку йортларында белем эсти. Һәрбер чираттагы эре дәүләт эшлеклесе,

постын калдырганда, гади рәсәйленең аңына да сыймаслык олы мөлкәт хуҗасы булып китеп баруын дәвам итә.

Без Б.Н. Ельцин файдасына төзелгән Конституция буенча яшәп ятабыз, аны безнең мәнфәгатьләрне кайгыртырга тиешле документ дип исәплибез. Ә либераллар белән дәүләт казнасын талаучылар шәхси милек турында инде әлек үк кайгыртып куйганнар, Рәсәй Конституциясендә бу хакта акка кара белән менә болай дип язылган: «Шәхси милек хокукы закон тарафыннан яклана». Дәүләтнекеме бу милек, җәмгыятьнекеме — бу хакта ләм-мим. Әйе, милек дәүләт тарафыннан якланырга тиеш, әмма бу очракта үз көчең һәм талантың белән тапкан мөлкәт турында сүз барырга тиештер. Ә бездә — киресенчә. Сүз, гадәттә, урлап, еш кына талап җыелган акча һәм мал-мөлкәт турында бара: ришвәт тә керә монда, откатлар, рейдерлык та...

Чит илләрнең конституцияләрендә милек һәм гражданнар хокуклары мәсьәләсе ничек куелган соң дип кызыксына калдым. Таларга ияләшкән Рәсәй чиновниклары һәм элитасы еш кына андагы законнарга ишарә ясый бит.

Мисал өчен, Италияне алыйк. Анда акка кара белән болай дип язылган: «Шәхси милек закон тарафыннан таныла һәм гарантияләнә, закон аны булдыру һәм файдалану ысулларын билгели һәм социаль функциясен һәм һәркем дә файдалана алуын тәэмин итү максатында аның чикләрен дә билгели».

Алмания (Германия) Конституциясендә дә аермачык язып куелган — «Милек җаваплылык йөкли. Аннан файдалану гомум мәнфәгатькә дә хезмәт итәргә тиеш».

Испания — «Дәүләт байлыгының иясе кем булуга карамастан, аның бөтен төрләре дә гомум мәнфәгатькә хезмәт итә».

Япония — «Гомум милек хокукы, иҗтимагый мәнфәгатькә каршы килмәсен өчен, закон тарафыннан билгеләнә».

Төркия — «Милеккә ия булу хокукын тормышка ашыру гомум мәнфәгатьләргә каршы килергә тиеш түгел».

Болардан кала да безгә кулай күп Конституцияләр бар һәм аларның берсе генә дә Рәсәйнеке кебек үз халкын фәкыйрьлеккә дучар итәрлек итеп язылмаган. Башка илләрнең Конституцияләре белән таныш кешеләр, кайсына гына тукталмасыннар, бизнесның җәмгыять һәм дәүләт алдындагы социаль җаваплылыгы хакындагы анык кагыйдәләргә юлыгачак. Аларда закон төрлечә шәрехләргә урын калырдай итеп язылмаган. Безнең Конституциягә дә аныклык кертергә вакыт.

Рәсәйне ялган товар белән тутырдылар. Бу безнең чиновникларның башбаштаклыгы, коррупция баткаклыгына чумган булуы белән генә аңлатыла ала. Кремль диварлары артында утыручылардан башлап, муниципаль берәмлекләргәчә — барысы да ришвәт ала, барысы да халыкны талый һәм алдый. Юкса депутатларга һәм дәүләт аппаратында утыручы башка түрәләргә ул кадәр мал-мөлкәт ничек килер иде?!

Матбугат чаралары да тулаем диярлек шул ук урланган акчага сатып алынган. Журналистлар, редакторларның авызын томалыйлар да, тегеләре, аермачык күренеп торган башбаштаклыкларга да күз йомып, халык аңына коррупция белән көрәшүнең мөмкин булмаган файдасыз бер эш икәнлеген сеңдерүне дәвам итәләр. Юк, җәмәгать, кирәк көрәшергә! Без нибары үз хокукларыбызны, мөмкинлекләребезне генә белмибез, асылда, коррупция белән көрәшүнең йөзләгән законлы юлы бар. Шуларның берничәсен генә атап узам.

Халык белән түрәләр — барысы да бертигез кешеләр, шулай булгач, алар өчен аерым төрмәләр төзү нигә кирәк? Әмма юк, бездә дәүләт акчасын талап тотылган чиновникларның, хокук саклау органнары хезмәткәрләренең «утыру» урыннары аерым. Шартлар да икенче аларга. Нигә әле алар бер

капчык урланган бәрәңге өчен төрмәгә тыгып куелган гап-гади кешеләр белән бергә уртак зонада утыра алмый?! Уртак зона турындагы уй, бәлки, күбесен айнытып җибәрер иде, анда алар үзләре хезмәт иткән гап-гади халык вәкилләре белән очрашу бәхетенә дә ирешер иделәр. Әгәр хакимият үз халкы белән бербөтен булырга омтыла һәм үз гражданнарының тантана итүен бер генә тапкыр булса да күрергә тели икән, иң әшәке җинаятьләр, иң кычкыртып талаулар өчен үлем җәзасын кайтарып карасын — күрер иде «түбән катлам»ның ни дәрәҗәдә үзләреннән гарык булуын. Әмма мондый хәлнең Рәсәйдә гомергә булачагы юк, чөнки илебезнең ата бурлары барысы да югарыда — күн кәнәфиләрдә утыра.

Әле яңарак кына язган бер мәкаләмдә мондый фикер белдергән идем: «Рәсәйгә, минем уйлавымча, теләсә кайсы Конституция дә ярый, берәрсенекен прокатка алып торсак та була хәтта. Ул Конституцияне 99,9 процент рәсәйле барыбер белми, берәрсенең кайчан да булса Конституция тарафыннан яклануы, шулай ук, икеле. Бу кәгазьдәге Конституция, димәк, 0,1 процент тәшкил итүче чиновник-рәсәйлегә үз мәнфәгатьләрен кайгыртыр өчен генә кирәк булып чыга». Файдаланыр өчен берәр илнең Конституциясен алып тору мөмкинлеге булса, мин Италиянекен сайлар идем, чөнки нәкъ менә аларныкында дәүләт белән шәхси милекчеләр арасындагы мөнәсәбәтләр анык билгеләнгән. Ни генә дисәң дә, бу — Конституциянең төп маддәсе. Калганнары бөтенләй кирәкми димим, ләкин нәкъ менә шушысы дәүләтнең сәламәтлеген һәм яши алуын гарантияли. Казнасында җилләр искән, үзе исә хәер сорап чатка чыгып баскан дәүләтнең киләчәге юк икәнлеге көн кебек ачык. Аның юлы бер генә — Сомали, Гаити, Зимбабве кебек хәерче дәүләтләр рәтенә барып кушылу.

Әле бөтенләй соң булганчы, ах-ух килмичә, сабыр һәм тыныч кына, СССР Җинаять кодексындагы бер бик мөһим маддәне кире кайтарасы иде — хак юл белән табылмаган мал-мөлкәтне конфискацияләүне әйтүем. Ул заманда шәхси милек турында закон юк иде, әмма алда искә алынган маддә бик күпләрне авызлыклап торырга ярдәм иткән икән. Бу маддәне законнар тупланмасыннан әллә халык алып ташларга кушкан дип уйлыйсызмы? Кемнәргәдер бик уңайсыз булганга алып ташланган бит инде ул, көн кебек ачык. Караклар, малбасарлар юлыннан ул киртәне кемнәр теләвенчә, кемнәрнең кулы алып ташлаганын ачыклау да комачауламас иде.

Нигә әле безне тупикка китергән Конституцияне тикшерү буенча референдум уздырмаска ди?! Нигә халыкка аның җитешсез якларын ачыктан-ачык әйтеп күрсәтмәскә? «Ельцинча капитализм»ны үз җилкәсендә татып караган халык бүген инде үз Конституциясенә башкача, күпкә җитдирәк карар иде дип уйлыйм мин.

Рәсәй Конституциясе белән танышкач, бердәнбер шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: Рәсәй бизнесының дәүләт каршында да, җәмгыять каршында да бернинди җаваплылыгы һәм бурычлары юк икән. Ә бәла була калганда, дәүләткә сыенырга йөгереп килеп җитә бит алар.

Ике генә мисал китерәм. Бу мисалларны халыктан яшереп торуның инде хаҗәте юк. Беренчесе — җитәкчеләренең мәгънәсезлеге һәм комсызлыгы аркасында Саян-Шушенск ГЭСын һәлак иттеләр, ә ул халык акчасына төзелгән гигантларның берсе иде. Гадел приватизацияләнгән очракта, әлеге гигантның эшчәнлегеннән Рәсәйнең һәрбер гражданинына сизелерлек өлеш чыга алыр һәм бүгенге Рәсәй гражданнары электр энергиясен шактый кулайрак бәһагә куллану бәхетенә ия булыр иде. ГЭСны төзекләндерүгә һәм торгызуга 4 ел дәвамында санап бетергесез дәүләт акчасы тотылды, әмма бу процессның әле азагы-чиге күренми. Бүгенге су басулар чорында ГЭСның гомумән җимерелү куркынычы да бар, бу очракта төзекләндерүне дә башкарып чыга алмаган хуҗалар инде дәүләт

кесәсеннән компенсация алачаклар һәм җиңел сулаячаклар.

Икенче мисал. Рәсәйнең барлык эре банклары һәм җитештерүчеләре, үзләренең саранлыгы һәм караклыгы аркасында барлыкка килгән ике дефолтны да (1998нче, 2008нче еллар) артык югалтуларсыз, исән-имин генә кичеп чыктылар. Дәүләт аларны саклап калу өчен коточкыч акчалар сарыф итте. Бу суммага Рәсәйне аякка бастырырга мөмкин иде — яңа юллар, хастаханәләр, аэропортлар, торак йортлар, заводлар төзеп. Ә бит илнең резерв фонды — эшмәкәрләр һәм югары катламнарның шәхси хисабында яткан акча түгел, ул безнең тир түгеп алган акчаларыбыз.

Күптән түгел генә бер гап-гади урыс мужигы белән сөйләшеп тордым. Кызы грекка кияүгә чыгып, Афинага китеп төпләнгән моның. Әлеге агай илебезнең икътисад министрыннан акыллырак фикер йөртте: «Менә грекларны гына алыйк, алар да, безнең кебек, дефолт кичерделәр, ләкин 20 ел буе җир җимертеп яшәделәр дә. Аякка бастылар, торак-йортлар төзеделәр, машиналар алдылар, балаларына менә дигән белем бирделәр... Көндезге өчкә кадәр эшләп, уноченче, ундүртенче, унбишенче, ә кайберәүләре хәтта уналтынчы хезмәт хакын да алып яшәделәр, дини бәйрәмнәрдә, хезмәт хакына өстәп, дүрт бонус та түләнде әле үзләренә. Аурупа стандартлары буенча уртача эш хакы алдылар, бу 2 мең евро тирәсе, пенсияләре дә Аурупаның уртача стандартына тәңгәл. Моңа өстәп — бушлай белем алу һәм дәвалану хокукы. Ә безгә, Рәсәйнең гап-гади гражданнарына, 2008 елгы резерв фондында алты йөз миллиард доллар акчабыз була торып, бу нигъмәттән берни тәтемәде. Алты йөз миллиард соңгы тиененәчә туймас тамак олигархлар, паразит-банкирларны күтәрүгә тотылып бетте. Алар бу акчаны, әлбәттә инде, илдә калдырмадылар, хакимият исә моңа күз йомды, аңлашыла да, аның үзенә дә өлеш начар чыкмагандыр. Фантастик сумма бит — уйлап карасаң!»

Мондый мисаллар — санап бетергесез. Бюджеттан таланган акчага корылган чиновниклар бизнесы үзенең һәр югалтуын безнең кесәдән чыгарып каплый. Киләсе елга, мәсәлән, утка бәя күтәрергә уйлыйлар, шактый кырыс лимитлар да каралган. Шөкер, әлегә һаваны бушка сулыйбыз, ләкин безнең түрәләр аңа да түләү кертергә бик мөмкиннәр. Менә бүгенге көннең бер анекдоты: «Рәсәйдә ике генә төрле закон бар: аның берсе — «тыярга», икенчесе «гражданнар мөстәкыйль рәвештә түләргә тиеш» дип атала». Конституция тулы бер ил гражданнарының түгел, ә аерым бер катламнарның гына хокукларын яклауга юнәлтелгән икән, әлеге ике катгый кагыйдә үзгәрешсез калачак.

Бүген Рәсәйнең тышкы бурычы тулаем эчке продуктның (ТЭП) 30 процентын тәшкил итә. Бездәге монополизацияне, коррупцияне исәпкә алган хәлдә, яңа резерв фондының акчаларын чит ил кыйммәтле кәгазьләренә күчерергә һич ярамый, алар, өлешчә генә булса да, барыбер шул ук олигархлар һәм түрәләр кулында бит. Дөньяны яңа депрессия дулкыны яулап ала калса, бу акчалар бер көн эчендә кыйммәтен җуячак, ә барлыкка килгән яңа бурычлар илне упкынга батырачак. Әгәр дәүләт казнасында өстәмә акча бар икән, аны илнең эчке капиталын үстерү өчен тотарга кирәк: әйбәт белгечләр тәрбияләү булсынмы ул, пенсия һәм эш хакларын арттырумы; иң мөһиме — кешеләргә тотылсын. Юкса дәүләт акчасы читкә очты дип кайгырган мужик, югарыда утырган сәясәтчеләргә нәфрәте соң чиккәчә кабарудан, йә эчәргә сабышачак, йә нинди дә булса этлек уйлап табачак һәм аны гамәлгә ашырырга да күп сорап тормас. Чөнки аның бу дәүләттә югалтыр нәрсәсе юк инде...

# ЗАМАНЧАЛЫК

## ДАНИЛ САЛИХОВ ДРАМАТУРГИЯСЕНЕҢ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

1980 елларда татар драматургиясенә килгән иҗатчылар Аманулла (Әмир Камалиев), Фәүзия Бәйрәмова, Фәнәвил Галиев, Мансур Гыйләҗев, Хәбир Ибраһимов, Гафур Каюмов, Мәдинә Маликова, Юныс Сафиуллин, Рәдиф Сәгъди, Зөлфәт Хәким, Эсфир Яһудин һ.б. арасында үз иҗат йөзе белән аерылып торган Данил Хәбибрахман улы Салихов та бар иде. Аны драматург буларак таныткан беренче әсәре — «Туй күлмәгем — соңгы бүләгем» драмасы 1987 елда языла һәм К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында куела. Аннары шул ук театрда бер-бер артлы «Яшьлек хатам — йөрәк ярам» (1989) драмасы һәм «Бәйрәмгалинең сыер тышавы» (1991) исемле комедиясе, Әлмәт татар драма театрында «Хатын түгел — аждаһа» (1992) дип аталган сатирик комедиясе, «Чукрак» исемле трагедиясе (1998), «Алла каргаган йорт» (1996, язылган елы — 1990), «Узып барышлый» (2001, театрда куелган елы — 2003), «Баязит» (2010) дигән драмалары, Минзәлә татар дәүләт театрында «Өзелгән йөзем» (2005) һ.б. сәхнәләштерелә. Чаллы татар дәүләт яшьләр театры, Уфаның «Нур» татар дәүләт театры, Туймазы татар дәүләт театры, Оренбург дәүләт драма театры, Сибай башкорт дәүләт театрлары да аның пьесаларына еш мөрәҗәгать итә.

Драматургның иҗат мирасында хәзерге көндә дүрт дистәгә якын сәхнә әсәре бар. Сан ягыннан гына түгел, жанр төрлелеге җәһәтеннән дә, тематикасы белән дә бай мирас. Аның бер өлешен язучы дүрт җыентыкта туплап бирде инде («Яшьлек хатам — йөрәк ярам», 1998; «Узып барышлый», 2002; «Гыйлаҗ тәрәзәләре», 2004; «Таш сандык», 2008). Алар Д.Салиховны бүгенге татар драматургиясенең иң актив һәм нәтиҗәле авторларыннан берсе итеп бәяләргә мөмкинлек бирә. Д.Салихов, асылда, бүгенгебез турында яза, халкыбыз тормышында туган проблемаларны игътибар үзәгенә куя, замандашларының төрледән-төрле һәм үзенчәлекле образларын сурәтли. Драматург заман проблемаларына сизгер. Милләт язмышы, кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтләрендә урын алган, торган саен ныгый барган мәрхәмәтсезлек, гаделсезлек, битарафлык, кешелекне упкынга сөйри торган эчкечелек, байлык артыннан куып, кешелек сыйфатларын җуя бару, аерата яшь буынга янаучы наркомания, узгандагы һәм хәзер дә еш күзәтелгән сугыш афәтләре, гаилә мөнәсәбәтләренең бозыла баруы һ.б. кебек кимчелекләрне фаш итүче ситуация һәм образлар аның әсәрләренең үзәгендә тора.

Менә аның «Яшьлек хатам — йөрәк ярам» дип аталган психологик драмасы. Беренче карашка сурәтләнгән вакыйга артык катлаулы түгел: эчкечелекнең шәхесне фаҗигагә алып килүе. Бу проблема байтак авторларның игътибар үзәгендә. Әмма әсәрләрдә еш кына аракы белән мавыгуны фаш итү, кире кагу төп вакыйгаларга өстәмә рәвештә кертелә. Ә бу драмада исә ул төп сюжет сызыгын тәшкил итә. Әхмәт исемле архитектор аракы белән «дуслаша». Нәтиҗә

— гаять аяныч. Яраткан хатыны Гөлəндəм аны ташлап китə. Бəхетсез ирне эчпошыргыч ялгызлык, ямьсез тормыш, өметсезлек билəп ала. Яшəүнен яме калмаган. Күршелəре Сəлах бабай белəн Галимə карчык анын хəленə керергə, һəрничек ярдəм итəргə тырышалар, əмма файдасыз. Ир бары тик кешелектəн чыккан исерекбаш Əбүзəр һəм бомж-сукбай хəленə төшкəн сəрхүш хатын Сəхия белəн генə уртак тел таба ала. Бу өч «дус» вакыт-вакыт бу юлнын фаҗигагə алып баруын таныйлар да. Сəхия бер айныган вакытында менə нəрсə ди: «Урамда трамвай-троллейбустагы кешелəрне күреп көнлəшəм. Кайсы бала күтəргəн, кайсы житəклəгəн, кайсысынын хатыннары ирлəрен култыклаган. Нидер алалар, нидер эшлилəр. Əбез... Шуларга карыйм да, асылынасы килгəн чакларым да еш була. Хəзер алар жылы өйлəренə кайтып кайнар аш ашыйлар, жылы ятакта балаларын назлыйлар, ир куенында иркəлəнəлəр. Əбез... айнырга куркып йөрибез». Əхмəт тə анын белəн килешə: «Шулай шул, айныгач, башка төрле уйлар килə. Эчеп исергəч, онытыласын», — ди ул.

Əйе, бу чирдəн котылу бик авыр шул, анар бирелү генə ансат. Монын өчен ныклы ихтыяр көче кирəк. Шулай да Əхмəт үзендə аракы белəн арасын өзəрлек көч таба, тəртипле тормышка кайта, яраткан хатынын эзлəп таба. Лəкин сон инде: Гөлəндəм асрамага бала алган, язмыш тарафыннан кыерсытылган, ирлеген жуйган Харун белəн тормыш корган, үзен аларга багышлаган. Ул, гəрчə яратса да, Əхмəткə кире кайтмый...

Сонгы еллар драматургиясендə үткəндə илебездə хөкем сөргəн совет системасын тəнкыйть итү, ана алмашка килгəн кыргый капитализм тəртиплəрен фашлау ачык бер төс алды. Бу темага Д.Салихов «Алла каргаган йорт» (1990), Т. Миннуллин «Бажа мал түгел, кəжə туган түгел» (1992), Зөлфəт Хəким «Жүлəрлəр йорты» (1995), Ф.Бəйрəмова «Вакыйга жүлəрлəр йортында бара» (1998), «Безне онытмагыз» (1998) һ.б кебек пьесалар яздылар. «Алла каргаган йорт» драмасында ситуация бик оригиналь корылган: эре бер оешманын директоры Айрат Харисович Галин, кылган жинаятьлəре өчен төрмəгə утыртуларыннан качып, жүлəрлəр ята торган больницага кереп ята. Үзе телəп мондый аферага барганда ул остаханəнен баш табибы, əшнəсе Риваль Якубовичка таяна. Лəкин анын ышанычы акланмый. Алай гына да түгел, ул бик нык алдана. Риваль Якубович — əшнəлек ярдəмендə күплəрне үзенə каратып бетергəн оятсыз һəм намуссыз кеше. Ул директордан ришвəт алып кына калмый, ə анын яшь һəм чибəр хатыны Зилə Саматовнаны үзенə сөяркə итəргə тырыша. Яшергəн бөтен байлыгыннан колак каккан Айрат Харисовичны нормаль яшəешкə кайтудан тəмам мəхрүм итеп, жүлəрлəр арасында калдыра. Лəкин үзен бик акыллыга санап йөргəн бозык һəм мəрхəмəтсез бу адəмне төп башына утыртырлык икенче берəү табыла. Ул — Зилə Саматовна, бүгенге вəзгыятьнен бөтен пычраклыкларын үзлəштереп алган, алдап-юмалап иренен бөтен байлыгын кулына төшергəн һəм карт иренен гомерлеккə жүлəрлəр йортында калуына төп сəбəпче булган хатын.

Байлык дигəндə жинаять эшлəүдəн дə баш тартмаган кешелəр жəмгыятен сурəтлəгəн драма реаль картиналарнын төгəл эшлəнүе, тормышчын интригаларнын оста үрелеп бирелүе белəн жəлеп итə. Анда бүгенге яшəешебездə урын алган кыргый мөнəсəбəтлəр, алда исемнəре аталган персонажлар ярдəмендə күрсəтелсə, кешелексез, мəрхəмəтсез мөнəсəбəтлəрнен кичəгедəн килгəн чыганаклары да шактый анык гəүдəлəнə. Шəхес культы еллары жəллады, ерткычлык, бəгырьсезлек «һөнəре» канына сенгəнлек бүген дə һəрчак сизелеп торган Кадыйр, анын дəвамчысы Дубиналы Адəм, Ватан сугышы инвалиды, Сталинга тугрылыклы булам, шунын белəн кешелəргə файда китерəм дип ышанган Садрый, инде сабыйлар акылы кергəн Исмай кебеклəр гаять тəэсирле образ-характерлар булып калка.

Д.Салихов икенче төр драмаларында бүгенге торшышта яшьлəрнен үзара мөнəсəбəтлəрендəге катлаулыклар, вакыты белəн туа торган фаҗигале хəллəрне сурəтли. «Туй күлмəгем — сонгы бүлəгем» драмасында бу — сөйгəн егете артыннан шəһəргə килгəн, аяк киемнəре тегү фабрикасына эшкə урнашкан Сəрия исемле

саф күңелле, риясыз кызны, аның бәхетсез язмышын тасвирлау. «Өрәк» дип аталган драмада — наркоманлык юлына баскан Илдусның мәктәп директоры әнисе ярдәмендә бер гөнаһсыз, намуслы, әле генә армия хезмәтен тәмамлап кайткан Хафиз исемле егетне төрмәгә кертүе вакыйгасы. Ул мәктәпләр тормышында урын алган күз буяу, хөкем органнарындагы ялган, мафия кебек җинаятчел оешмаларның канат җәюе кебек сыйфатлар белән бәйләп сурәтләнә. «Язмыш» драмасында — Әфганстан сугышыннан сукыраеп кайткан Нәсимнең бу дөньядан китәргә теләп үз-үзенә кул салырга уйлавы, сөйгәненең һәм якыннарының ярдәме белән нормаль тормышка кайтуы хәлләре. «Әни буласым килә» мелодрамасында балаларга тиешле мөнәсәбәтнең изгелеге, яшь буынны тарбияләүгә җаваплы караунын мөһим икәнен алга сөргән ситуацияне гаять үзенчәлекле итеп, шартлы алымнардан уңышлы төстә файдаланып бирү.

Д.Салихов драмаларының күпчелеге реалистик стильдә язылган. Аларда тормышчанлыкка тугрылык өстенлек итә. Ләкин драматургка ситуацияләрне оештыруда, образлар системасын бирүдә шартлы алымнарга, метафорик гомумиләштерүләргә мөрәҗәгать итеп язу да ят түгел. Мәсәлән, «Ак күгәрчен» дип аталган драма тулысынча шартлы-мифологик алымга корылган. Эшкуар Ибраһимның мәңгелеккә күчүе вакытында кичергәннәре, инде мәрхүм әти-әнисе, кайбер туганнары, хатыны, туарга тиеш булып та тумыйча калган балалары, исән вакыттагы дусларының рухлары белән аралашуы дин кануннары, дини ышануларга нигезләнгән хәлләр ярдәмендә җанландырыла. Кешенең җирдәге тормышы намуслы яшәешкә нигезләнеп корылганда гына бакый дөньяда аның рухы рәхәтлек кичерәчәк, мәңгелектә ул үз урынын табачак дигән фикер бик тә үзенчәлекле төстә раслана. Кыскасы, Д.Салихов ситуацияләрне бүгенге тормышыбыздан ала, ул — заман язучысы. Ләкин драматург кайбер әсәрләрендә үткәнгә дә мөрәҗәгать итә. Җәмгыятебез тормышындагы, халкыбыз язмышындагы хәлләрне узгандагы тарихи вакыйгалар белән органик бәйләнештә карый. Шундый әсәрләрдән берсе — «Чукрак» драмасы (1995). «Данил Салихов, тарихи дөреслекне эзли-эзли, Октябрь инкыйлабы көннәренә кайтып төшә һәм «Чукрак» исемле трагик драмасын иҗат итә», — дип яза Аяз Гыйләҗев үзенең бер мәкаләсендә. Драмада автор совет хакимиятенең башлангыч чорындагы буталчык, караңгыямьсез вакыйгаларны сурәтли. Ул вакыйгаларда аерым кешеләрнең, беренче чиратта, саф күңелле, күңеле изгелек белән тулы шәхесләрнең фаҗигаләре ничек барлыкка килүен күрсәтә. Совет хакимиятенең еш кына мәгънәсез күрсәтмәләренә Нуриәхмәт кебекләрнең ихластан ышанып алдануларын, ә Арслан шикелләрнең оста итеп болганчык суда балык тотуларын, иң әшәке теләкләрен канәгатьләндерүләрен тормышчан, җанлы картиналарда гәүдәләндерә. Үзәк каһарманнарның да, ярдәмче персонажларның да характер үзенчәлеге, шул нигездә оешкан язмыш сызыгы да оста сурәтләнгән. Шулар ярдәмендә гади хезмәт иясенең дә, зыялы дин әһелләренең дә фаҗигале язмышы ачык булып гәүдәләнә. Вакыйгалар үзәгендә Арслан кебек ерткыч, интриган кешеләрнең торуы революцион көрәш вакытында туган фаҗигаләрнең нигезендә ята. Төп фикер ачык: совет идеологиясе һәм хакимияте тарафыннан җибәрелгән хаталар һәм гаделсезлекләр бик күп кеше өчен бәхетсезлек китерә: Гөлйөзем һәм Нуриәхмәтләрнең фаҗигале язмышы, Батыржан, Галимҗан кебекләрнең надан фанатиклыгы һәм коллык психологиясенә нигезләнеп яшәүләре...

Драма әсәрләренең нигезендә конфликт ята дигән кагыйдәне беләбез. Ләкин сәнгать һәр очракта да бер генә кысаларга ябышып ятмый. Язучы хыялы чиксез. Д.Салихов иҗатында да шуны күрергә мөмкин. «Көттереп килгән яңгыр» әсәрен автор публицистик драма дип атаган. Анда ачык күренеп торган конфликт юк. Хакимият башлыгы Нурфатихның тормышы гадәти борчулардан, көндәлек мәшәкатьләрдән тора. Аның бар яшәеше авыл хуҗалыгын уңышлы алып баруга, урып-җыюны вакытында үткәреп, сезонны уңышлы тәмамлауга буйсындырылган. Нурфатих — яхшы җитәкче, кешеләргә мәрхәмәтле, алар белән үзенә тиң итеп сөйләшә белә. Кечкенә малай Илнур белән кечкенә булып, бандитлар белән

аларча каты итеп аралаша-сөйләшә белә. Гәрчә драмада вакыйгаларны тотып торучы үзәк конфликт булмаса да укучы һәм тамашачы алдына нык характерлы, халык белән тиешенчә идарә итә белә торган акыллы житәкче образы килеп баса.

Д.Салихов комедия өлкәсендә дә яратып эшли. Алда атап үтелгән дүрт жыентыгына 28 әсәр кертелгән, шуларның яртысы, ягъни 14-е — комедия. Монда бу жанрның сатирик комедия, музыкаль комедия, лирик комедия, мажаралы комедия кебек төрле формалары бар. Комедияләрендә дә автор материалны замана күренешләреннән һәм кешеләренең эш-гамәлләреннән ала. Бүгенге кешеләрнең яшәү рәвешендәге, характер үзенчәлекләрендәге кимчелекләр, үз-үзләрен тотуларындагы гайре табигый кыланышлар аның комедияләрендә фаш ителә, тәнкыйтьләнә, кире кагыла.

Менә колхозның алдынгы комбайнчысы Бәйрәмгалине («Бәйрәмгалинең сыер тышавы» исемле сатирик комедия), имеш, яхшы эшләгәне өчен Америкага жибәрәләр. Аны жыйнаулашып озату вакытында колхозның никадәр «алдынгы» булуы да, коммунизмга барабыз дип «тырышкан» халыкның аң дәрәжәсе дә, колхоз житәкчесе Карабаш Шалканбашовичның «унганлыгы һәм булганлыгы да» сатирик яссылыкта, бик тапкыр сүз көрәштерүләр ярдәмендә ачыла. Бәйрәмгалинең Америкадагы мажараларында никадәр «анлы-булдыклы булуы», «патриотлыгы» сурәтләнә. Алдынгы хезмәте өчен Америкага жибәрелү «бәхетен» татыган колхоз рәисе Шульдери Михайлин характеры белән дә, белеме ягыннан да Бәйрәмгалигә бик пар булып чыга. Совет жәмгыятендә хөкем сөргән мәгънәсезлекләр аркасында ачлы-туклы яшәргә мәжбүр булган бу ике бәндә Америка разведчикларының да көлкеле эш-гамәлләр кылуына сәбәпче булып чыга. «Бәйрәмгалинең сыер тышавы» комедиясе үзенең төп пафосы һәм максаты белән совет жәмгыятенең кимчелекләреннән көлү булып яңгырый.

Д.Салихов үз комедияләрендә кешеләрдәге байлыкка омтылу, дәрәжәгә кызыгу, бер-береннән көнләшү, сөйгән кешенә, гаиләгә хыянәт итү, мәрхәмәтсезлек, жаһиллек, куштанлану кебек начар гадәтләрне, кимчелекләрне фаш итүне, тәнкыйтьләүне төп максат итеп куя. Боларның барысын да ул жәмгыятьтәге шартлар белән, бүгенге тормышыбызда урын алган катлаулы вәзгыять, кимчелекләр белән ныклы бәйләнештә карый. Шуңа күрә дә аның әсәрләре ижтимагый эчтәлекле, социаль пафослы. Боларга ирешү өчен драматург тирән эчтәлекле ситуацияләр тудыра белә. Мәгънәле юмор, үткен сатира, халыкчан тапкыр тел, сурәтләү алымнарына байлык аның драмаларына да, комедияләренә дә хас. Әлбәттә, бу зур ижат турында теләкләр дә әйтергә мөмкин. Кайбер пьесалар жентекле тәнкыйди анализга лаек, аерым сораулар тудырган моментларны ачыклау соралып тора. Мәсәлән, кайбер драмаларның исемнәре бик үк уңышлы түгел. «Гыйлаж тәрәзәләре», «Көттереп килгән янгыр», «Өзелгән йөзем» атамалары пьесаларның асыл эчтәлеген тулы ачмый, «Яшьлек хатам — йөрәк ярам» дигән исем дә бик абстракт, драманың эчтәлегенә туры ук килеп бетми. Мондый житешсезлекләрне тагын да күрсәтергә мөмкин. Әмма иң мөһиме Данил Салиховның киң тармаклы, житди драматургиясе бар һәм ул татар сәхнә әдәбиятында үзенә лаеклы урын алып тора. Драматургтан яна әсәрләр көтеп калабыз.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН**

# ҖЫРГА БИРДӘ БАР КӨЧЕН

*Тагын көрәшергә булсын –*
*Хушлашмый китәм.*
*Искә алып, бер җырларсыз –*
*Җыр бүләк итәм.*
Г.Зәйнашева

Республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген хатын-кызлардан беренче булып 1991 елда шагыйрә Гөлшат Зәйнашева алды. Ул вакытларда ук инде Гөлшат җыр сәнгатендә иң популяр автор буларак танылган иде. Әлеге дәрәҗәле бүләкне дә ана «Илле җыр» исемле китабы китерде.



Тел-әдәбиятыбыз, мәдәният-сәнгатебез кебек рухи кыйммәтләрнең саега, төссезләнә баруы һәм бүгенге чынбарлыгыбызда дәүләтнең тотрыксыз милли сәясәте ярдәмендә аларның бетүгә юл тотуы шартларында, Гөлшат Зәйнашева кимәлендәге җыр остасының иҗаты милләттәшләребез күнелендә өмет чаткылары дөрләтүче, анын рух байлыгын саклаучы таяныч булып кала. Бу — бик анлаешлы һәм мантыйкка сыешлы күренеш. Милләтебезнең язмышы әдәбиятыбыз, телебез, сәнгатебезнең сыйфатына бәйләнгән бит.

Шактый озын гомер кичердем, ләкин Гөлшат дәрәҗәсендә җырга гашыйк, бу сәнгатькә риясыз хезмәт иткән бүтән берәүне белмим әле.

Гөлшат — минем институт буенча сыйныфташым, һөнәрем буенча хезмәттәшем; көнкүрештә исә шатлык-куанычларны, кайгы-борчуларны уртаклашып, якыннан аралашып, кинәшләшеп яшәгән дустым иде. Бик күп җырларының язылу тарихын беләм. Ләкин бу мәкаләдә мин анын беркем махсус тукталмаган, балалар өчен язган җырлары турында сөйләүне мәгъкуль күрәм. Ник дигәндә, бу өлкәдә без Гөлшат белән рухи туганнар идек, чөнки мин озак еллар балалар өчен тапшырулар редакциясендә эшләдем.

Кешенең матурлыкны тоюы, музыка дип аталган гүзәл дөньяга сукмагы сабый чагында ук ишеткән бишек җырларыннан шытым ала. Үсә төшкәч, ул нәниләр өчен язылган җырлар дөньясына аяк баса. Аннары мәктәп җырлары дөньясына керә. Бу җырлар бит матур көй тынлап ләззәтләнү өчен генә түгел, тәрбияви максатны күздә тотып, нинди дер сабак, гыйбрәт алу өчен дә языла. Хезмәт сөяргә, өлкәннәрне хөрмәт итәргә, тырышып укырга, тәртипле булырга өйрәтәләр. Гөлшат күнелендә җырлар язу теләге дә шушы изге максатларны кечкенә дусларының анына сендерү, җанын тәртиптә тоту гадәтләренә күнектерү ниятеннән туа иде дип беләм. Моны ул үгет-нәсихәт белән түгел, ә бәлки тормыштан гыйбрәтле мисаллар китереп, ышандырырлык итеп раслап күрсәтә белә иде. Әйе, балаларга адресланган шигырьләрен дә, җырларын да Гөлшат яшь буында әхлакый сыйфатлар тәрбияләү зарурлыгын күздә тотып язды. Менә, мәсәлән, «Шырпы уенчык түгел» дигән шигырендә бер малайның, әнисе сүзенә колак салмыйча, шырпы кабызып уйнап кулын пешерүе, «Конфет» дигән шигырендәге кызның конфетларны күп ашавы

нәтиҗәсендә, үсмичә, конфет кадәр генә булып калуы сурәтләнә. Бу мисаллар нәни дусларыбызны начар гадәтләрдән арынырга кирәклегенә ышандыралар.

Гөлшатның табигать серләрен аңлау, тере дөньяның гүзәллеген күрү өчен күзләрне башкача ача торган шигырьләре дә ифрат тәэсирле. Бу җәһәттән «Иртәнге җыр» дип исемләнгәненә тукталасым килә.

*Таңны мактап, талларда*
*Кошлар канат кактылар,*
*Тамчы гөлләр, тирбәнеп,*
*Алкаларын тактылар.*
*Күбәләкләр, уянып,*
*Канатларын җилпеде,*
*Коңгызлар җемелдәвек*
*Матур күлмәген киде.*
*Чәчәкләр чык суында*
*Коенып юындылар,*
*Бал кортлары, безелдәп,*
*Чәчәкләргә кундылар.*
*Син дә, матур сеңелем,*
*Татлы йокыңнан уян,*
*Җәйге таңның яменә,*
*Гүзәллегенә куан.*
*Уян, сеңелем, күзең ач,*
*Җәйге иртә нурында.*
*Кояш чыкты алланып,*
*Синең тәрәз турында.*

Табигатьнең йокыдан уянуын сурәтләгән бу шигырь рәссам кулы белән генә тудырып була торган үзгә бер картинаны җанландыра. Шигырьдә тирән фәлсәфә дә, ясалма чагыштырулар да юк. Гап-гади сүзләрдә табигатьнең уяну мизгеле, байлыгы һәм матурлыгы чагылыш тапкан. Аларның укучылар күңелендә урын алуы да менә шушы гадилектәдер, мөгаен.

...Бүгенгедәй хәтерлим әле. Мин радиода эшли башлаган 1950 нче елларда дип әйтим инде, республикабызда дан тоткан бу оешма кайнап торган казанны хәтерләтә иде. Репетиция бүлмәсеннән дә, тавыш яздыру студиясеннән дә җырлар, төрле музыка коралларында уйнаган тылсымлы аһәңнәр яңгырый. Радиога композиторлар, шагыйрьләр сукмагы өзелеп тормый. Алар яңа җырларын тәкъдим итәләр. Өлкән композиторларыбыз Салих абый Сәйдәшев, Мансур абый Мозаффаров, Заһит абый Хәбибуллин, Александр Ключарев, Җәүдәт Фәйзи, әлегә яшь композиторлар дип йөртелүче Мирсәет Яруллин, Бату Мөлеков, Фасил Әхмәтов, Фәтхрахман Әхмәдиевләр, шагыйрьләрдән Әхмәт Ерикәй, Шәйхи Маннур, Сибгат Хәким кебек танылган әдипләр, сәнгать әһелләре килә. Араларында яшь шагыйрьләр Мәхмүт Хөсәен, Гөлшат Зәйнашева да була. Алар килгән саен, яңа җырлары, шигырьләре белән шатландыралар. Радионың музыкаль репертуары көн саен диярлек яңа җырлар белән баеп тора. Ләкин балалар өчен җырлар юк диярлек. Без, әлбәттә инде, төрле темаларга җырлар язуын үтенеп, Гөлшатка мөрәҗәгать итәбез. Ул дөньяга балалар күзе аша карый белә, балалар теле белән сурәтләү осталыгына ия, редакция алдына куелган таләпләрне дә аңлый. Шулай әкренләп мәктәп, пионер оешмалары тормышын яктырткан, походларда, сәяхәтләрдә йөрергә чакырган, туган ягыбызның табигатен күзәтергә, аның матурлыгы, байлыклары белән горурлана белергә өйрәткән, тәртипле, тәүфыйклы булып үсәргә өндәгән җырлар туа башлый. Балалар җырларыннан торган концертлар яңгырый. Җыр өйрәтүләр, табышмак-концертлар пәйда була. Ләкин радио дигән тылсымлы дөнья матур җырлар тыңлагыз дип әйтеп, балаларның күңелен күтәрү белән генә һич тә чикләнә алмый. Ул яшь буынны гүзәллек дөньясына алып кереп, рухи яктан тәрбияләргә бурычлы. Шул максатны күздә тотып, редакция музыканы ничек тыңларга һәм ничек аңларга

дигән концерт-әнгәмәләр оештыра. Аларны исә музыка укытучылары, сәнгать белгечләре әзерли. Болар барысы да балаларның зәвыгын тәрбияләү өчен эшләнә. Бу тапшыруларның мәгънәсен тирәнәйтүдә, тәэсир көчен арттыруда Гөлшат иҗатының роле зур булды. Аның җырлары репертуарыбызны баетты гына түгел, матурлыкны тою хисе, зәвык тәрбияләп, чын музыканы такмаклардан аерырга өйрәтте.

Бу иҗатның бәясен аңлау өчен Гөлшатның берничә җырына тукталып үтәм.

Композитор Фасил Әхмәтов язган «Спортчылар җыры»н алыйк. Ул күп еллар дәвамында эфирда уңыш белән барган «Олимпия» дигән тапшыруны башлап җибәрүче, аның тематикасына юнәлеш бирүче җыр булып яңгырады.

*Белмибез ару-талуны,*
*Укыйбыз зур дәрт белән.*
*Авырмыйбыз, чөнки яшьтән*
*Дуслаштык спорт белән.*
*Корыч чыныккан шикелле*
*Ялкында, утта,*
*Үсәбез чыныгып шулай*
*Спортта, спортта.*

Ә менә Мәсгут Имашевның батырлыкка мәдхия булырдай «Газинур отряды» дигән җырыннан юллар:

*Газинур исемен йөртә, бу — безнең отряд,*
*Батырларга тиң булыйк, дип, тибә яшь йөрәк.*
*Кызыл байрак, кызыл байрак*
*Безнең кулларда,*
*Лаек булып үс, пионер,*
*Газинурларга.*

Бу җырның максаты һәм әһәмияте турында өстәп аңлатма бирү таләп ителми. Курку белмәс, көчле рухлы ил сакчылары, патриотлар булып үсәргә омтылыш уятуын җыр үзе әйтә. Гөлшатның һәр җыры шулай гади генә тел белән бөек изге максатны тулысынча җиткерә ала. Шуңа күрә, яшь буын күңеленә юлны тиз таба.

Көен Фәтхрахман Әхмәдиев язган «Кояш гомере» дигән җырын искә төшерик әле. Радиодан беренче яңгыратуга ук балалар аны үз итте, тиз отып алды. Һәм ул мәктәп кичәләрендә, пионер сборларында, бәйрәмнәрдә башкарыла торган иң популяр җырга әверелде. Хәзер дә ул, әниләргә мәхәббәт гимны булып, һәр тантанада башкарылмый калмый.

*Бер кыз бала җыр чыгарган,*
*Багышлап әнисенә.*
*Икәү бергә җырлыйк диеп,*
*Өйрәткән энесенә.*
*Кояш, кояш, мәңге балкый,*
*Мәңге нур сибә,*
*Кояш гомере телим мин,*
*Әнием, сиңа.*

Моннан да гадирәк, моннан да үтемлерәк итеп әниләрне сөендерү мөмкинме икән?

Бу җырны да, Гөлшатның башка җырларын да әле бик күп буын балалары җырлап үсәрләр дигән уйда мин. Чөнки алар балачак иленә онытылмаслык булып керделәр, һәм хәзер музыкаль тәрбиягә юнәлеш бирүче компас ролен үтәп яңгырыйлар. Матурлыкны тоя белүче, зәвыклы кешеләр булып үсәргә ярдәм итәләр. Моны без зур горурлык белән Гөлшат дөньясы, Гөлшат бүләге дип атыйбыз.

Гөлшат Зәйнашеваның милләтебезгә хезмәт итүдәге тагын бер изге гамәленә

тукталасым килә. Анысы да минем күңелемә бик якын һәм кадерле. Ул бит жырга, музыкага булган мәхәббәтен үзенен кызы Асиягә дә йоктыра алды. Асия консерваториядә укып музыкаль белем алды. Мин радиода эшләгән беренче елларда туган телебездә жырлаучы балалар юк дәрәжәсендә иде. Хор коллективлары турында сөйләргә дә юк инде. Балалар жырларын артистлар башкаруында гына яңгыратырга мәжбүр идек.

Радио каршында кечкенә генә балалар хоры оештыру ихтыяжы туды. Гөлшат белән сөйләштек тә, житәкче итеп Асияне чакырдык. Ул мәктәпләрдән туган телебездә сөйләшә белүче, музыка яратучы дусларын жыйды. Алар репетиция бүлмәсенен буш торган чакларында жырлар өйрәнә башладылар. Тиздән радиодан ургылып чыккан саф чишмә чылтыравын хәтерләткән балалар жырлары яңгырый башлады. «Укырга, укырга», «Күңелле безнен шәһәр» һәм башка күп жырлар минем колагымда әле дә яңгырап торалар. Сонрак Асия Зәйнашева «Айсылу» балалар ансамблен оештырып эшли башлады. Композитор Гөлнара Беляева белән бергәләп, Гөлшат сүзләренә язылган жырлар циклы дөнья күрде. Телевидение режиссеры Нурания Жамали тырышлыгы белән ул жырлар экранга чыкты.

Ул чакта шагыйрә Гөлшат Зәйнашева белән композитор Гөлнара Беляева ижат иткән илледән артык жыр телевидение компаниясенен фондын баетты, һәм шул жырларны туплаган жыентык *(Гөлнара Беляева, Гөлшат Зәйнашева. Көмеш тавышлар. Казан, 2008)* басылып чыкты. Болар да Гөлшат ижаты, Гөлшат эшчәнлегенен гаять әһәмиятле бер истәлеге.

Кеше күңеле бит ул — очына чыгып, чигенә барып житә алмаслык катламнардан тора. Гөлшат үзенен жырлары, шигырьләре белән шушы серле дөньяга юл ярды, укучылары, тынлаучыларына шул юлны яктыртып, маяк булып торды һәм беркайчан да халкы, яшәеш алдындагы изге бурычы, үзенен нинди мәдәни мирас калдырырга тиешлеге турында онытмады.

*Нәрсә калдырам мин, китсәм*
*Бу якты дөньяга, дим.*
*Яктыртыр өчен тагын да*
*Ни кылдым мин аңар, дим.*
*Гашыйк булып бу дөньяга*
*Тик жырлап үтте гомер.*
*Кемнәр моңлы, шулар гына*
*Хәлемне белсә белер.*
*Жырладым илемне мактап,*
*Жырга бирдем бар көчем,*
*Илемнең — күгә, халкымның*
*Күңеле яктырсын өчен.*
*Үзем китсәм, калыр моңлы*
*Жырым кинәт бүленеп,*
*Туган як каеннарының*
*Яфрагына эленеп.*

Жырлары анын бөтен вөжүден билаүче, яшәешен бизәүче байлыгы булды. Искермәс, тутыкмас шушы хәзинәне халкына мирас итеп калдырды. Гөлшат әни, дәү әни, өлкән дәү әни булгач та, балалар дөньясыннан, шигърият дөньясыннан читләшмәде. Бакыйлыкка күчкәч тә милләтебез күңелендә яшәп калды. Жырлары-шигырьләре аша аны һәрдаим янябызда тоябыз. Телебез, сәнгатебез, милләтебезне саклап калу юлында жырчы шагыйрә ижатташ дуслары белән янәшә атлый.

**Нәсимә ӘХМӘТЖАНОВА**

# ҖЫРЛАНМАГАН ӘЛЕ БЕЗНЕҢ ҖЫР

Адәм баласы гомере буена җырдан аерылмый. Җырлап яши, җыр белән күнелен юата. Ана да үзенең сабыен бишек җырын көйләп йоклата. Авылда радио булмаган заманнарда да җыр, музыка тыңлап үскән ир-егетләрнең берсе буларак, минем күңелемдә ул елларның якты хатирәләре саклана. Сугыш бетәр-бетмәс елларда һәм аннан соңгы чорда салкын авыл клубында Рәшит Ваһапов, Зифа Басыйрова җырлавын, Мохтар Әхмәдиев, Оркыя Ибраһимова, Фәйзи Садыйковның баянда уйнавын, Фәйзи Биккининнын кечкенә гармуннарда сыздыруын күреп, тыңлап үстем. Артистлар безнең Арча районының Урта Аты авылына еш килделәр. Чөнки без Татарстан радиосының шефлыгында идек. Инде ял көннәрендә авылның бүрек артеле бухгалтериясенә җыелып, батарея белән эшли торган радиоалгычтан татарча концерт тыңлый идек. Гөлсем Сөләйманова башкаруындагы җырларны авыл халкы бик озак күңелендә саклады.

Гомумән, безнең татар җырлары моңлы булулары белән бергә, аларның туу тарихы да кызыклы. Бу уңайдан үземнең кайбер фикерләрем, күзәтүләрем, тарихи язма чыганаклар тупланган мәгълүматларым белән уртаклашырга телим. Ник дигәндә, халык җырлары онытылыбрак барган, сәхнәләрдә, концертларда, радио, телевидение тапшыруларында сирәгрәк яңгыраган заманда бу хакта сөйләшү зыянга булмас. Әмма без соңгы вакытта моңга сусадык. Ә моңсыз җырны тыңлыйсы килми...

Җыр китапларындагы һәм халык көйләре дип аталган җырларның авторлары барлыгы турында кайчан да булса бер уйлап караганыгыз бармы сезнең? Татар халык көе дигәч, кайберләренең җыр текстын кем язганлыгын беләбез, ә көен — юк. Халык җырларының сүзләре буыннан-буынга күчеп камилләшкән. Кемнәрдер көй чыгарган, башлап җырлаганыннан халыкка таралган. Вакыт үтү белән алар күңел кылларын тибрәтерлек хәлгә килгән, моңга баеган, халкыбызның рухи хәзинәсенә әйләнгән. Кайбер җырларның беренчел текстлары да үзгәргән, халык аларга заман төсмере салган. Мәсәлән, «Сарман» көе башта «Авыл көе» дип аталган. Аны төрле сүзләргә җырлаганнар. Баштагы вариантлары хәзергесеннән шактый аерылып тора. Бу көй 1938 елда «Сарман» дип атала башлый. Аны радиодан беренчеләрдән булып Усман Әлмиев башкарган. «Сарман» көенең Арча районында тууы мәгълүм.

«Идел» җырының бик популяр булып китүенә без җырчы Зифа Басыйрова белән баянчы Оркыя Ибраһимовага рәхмәтле. Аны Оркыя Ибраһимова гастрольдән кайтканда пароходта җырлап баручы бер кыздан ишетеп кала. Ул аны Зифа Басыйровага уйнап күрсәтә. Күп тә үтми, Зифа радиодан шушы җырны җырлый. Ана «Су буйлап» дигән исем бирәләр. Шуннан соң җырның берничә варианты туа. «Озын су өсте», «Идел», «Су юлы» исемнәре белән җырлана. Оркыя Ибраһимова кызның исемен дә, кайдан икәнлеген дә сорамаган.

Еллар узу белән башка кайбер көйләрнең дә исемнәре үзгәргән. Мәсәлән, Александр Ключарев «Көзге ачы җилләрдә» җырының урыс-япон сугышы чорында ук җырлануын искә ала. Бу җыр беренче бөтендөнья сугышы вакытында туган диючеләр дә бар. Башта ул «Окоп көе» исемен йөрткән. «Шөгер» көе — «Гүзәлем», «Хәмдия» — «Шакир солдат», «Озату» — «Ялкын», «Арча» — «Җырламыйм мин җырларымны» исеме белән аталган. А.Ключарев «Әллүки», «Зиләйлүк», «Бөдрә тал», «Мәдинәкәй», «Сәгать чылбыры», «Сандугач», «Иске

кара урман», «Кызыл төлке» көйләренең борынгы заманнарда чыгарылуы турында яза.

Элек «Сәгадәтбану» көе бик популяр булган. Мирхәйдәр Фәйзи шундый исем белән драма әсәре яза. Режиссер Вәли Мортазин-Иманский драматургка аны «Галиябану»га алыштырырга киңәш иткән һәм «Галиябану» жыры халык арасында киң таралып китә.

Озак вакыт күп кенә җырчыларның репертуарыннан төшмәгән «Ай, былбылым» көенең дә тарихы кызыклы. Бу җыр үткән гасырның унынчы елларында иң популяр җырларның берсе була. Аны Камил Мотыйгый чит илдән өйрәнеп кайткан.

Халык көйләре Тукайның да күңел кылларын тибрәткән. Ул аларның кайберләренә үзе дә шигырьләр язган. Мәсәлән, «Әллүки», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», «Туган тел» көйләре аның шигырьләренә җырлана. «Ашказар» җырының барлыкка килүен ул болай дип аңлата: бер кызның кияве Ашказар елгасы суында батып үлә. Кызлар бергә җыелгач, килен алардан кияве истәлегенә җыр чыгаруларын сорый. Шулвакыт бер кыз җыр сузып җибәрә. Тик җыр киленгә ошамый. Шуннан соң ул үзе җырлый. Бу «Ашказар» көе була, ди Тукай.

Кайбер җырлар шулкадәр популярлашып китә ки, аларның музыкасын һәм шигырен кем язганлыгы да онытыла. Халык җыры дисәләр дә, тарих кайбер көйләрнең авторы исемен саклый. «Уракчы кыз» көен кайсыбыз гына белми, кайсыбыз гына тыңлап, яки җырлап үсмәгән?! Александр Ключаревның 1936 елда басылып чыккан «Татар халык җырлары» китабында ул халык җыры дип атала. Җәүдәт Фәйзи дә бер язмасында «Совет дәүләтенең беренче елларында ук җырлана башлаган «Уракчы кызы» заманыбыз халык иҗатының классик үрнәге булып саналырга хаклы», — ди. Бу көйнең сүзләрен 1922 елда Нәкый Исәнбәт язган. Халык шул ук елларда аны көйгә салган, ди композитор Ж.Фәйзи. Күп еллардан соң гына бу көйнең авторы — халык музыканты Хәбибулла Ибраһимов икәнлеге беленә.

Заманында халык арасында киң таралган «Вәгъдә» җыры да башта күп еллар буена татар халык җыры дип йөртелде. Ул «Егет моңы», «Чишмә буенда» исемнәре белән дә җырлана. Аның да авторы бар икән ләбаса! Ул — элеккеге Бондюг районының Псәй авылы (хәзер Менделеев районы) клубы мөдире Зиннур Мөхәммәтдинов. Әхмәт Рәшитов сүзләренә җырлана торган «Зәңгәр күлмәк» җыры кайбер җыр китапларына татар халык көе дип кергән, аның да авторы табылды. Ул — Ильяс Зиннуров.

Җыр турында сөйләгәндә шундый сораулар туул бик табигый: башта көй туганмы, әллә җыр текстымы? Шагыйрь сүзләрен билгесез автор көйгә салганмы? Гадәттә, бигрәк тә хәзерге заманда, композитор көй язу өчен шигырь эзли һәм шулай уртак иҗат җимеше булып җыр туа. Әмма көйгә шигырь язылган очраклар да күп. Әхмәт Фәйзи «Аккош», «Умырзая», Зыя Мансур «Яшьлек», Әхмәт Ерикәй «Берсе алма, берсе хөрмә», «Сәрвиназ», Сибгат Хәким «Фазыл чишмәсе», Гөлшат Зәйнашева «Иртә дә генә торам...» көйләренә шигырьләр язганнар.

Тик миңа иң аянычы — халык җырлары онытылып бара. Совет власте елларында иҗат иткән мәшһүр композиторларыбызның да, һәвәскәр композиторлар дип йөртелгән һәм берсеннән-берсе матур җырлар язган талантлы егет-кызларыбызның да җырлары сирәк яңгырый. Концерт залларында, Мәдәният сарайларында, радио, телевидениедә бер-бер артлы игезәк, бер-берсеннән һич тә аерып булмый торган җырлар сибелә. Ник әле без халык җырларына шулкадәр битараф соң? Татар музыка сәнгатендә якты эз калдырган атаклы композиторларыбызның җыр-көйләрен аларны искә алу кичәләрендә генә ишетәбез?

Дөрес, телевидение бөтенләй үк онытып бетерми әле. «Татарстан — яңа гасыр» каналында «Җырлыйк әле!», «Оныта алмыйм», «Татар халык җырлары» тапшыруларын карагач, халык җырларын үз иткән җырчыларыбыз да бар икән әле дип сөенеп куясың. Ләкин тулаем җыр сәнгате турында сүз алып барабыз икән, турысын әйтик, тамашачы еш кына үзебезнең милли җырларыбызны тыңлау-ишетүдән мәхрүм.

Элек филармониянең сәнгать советында артистның җыр репертуарын

энәсеннән жебенә кадәр тикшерәләр иде. Ләкин мин андый цензура кертү ягында түгел. Шулай да жырга карата таләпчәнлек булырга тиеш. Атаклы жырчыбыз Габдулла Рәхимкулов белән бер очрашу вакытында аның сөйләгәне хәтердә калган. Үзбәкстанга гастрольгә баргач, бер концертта аннан бер жыр (исеме хәтердә калмаган) башкаруны сораганнар. Г.Рәхимкулов программага кермәгән көйне жырларга ярамаганлыгын белсә дә, тәвәккәлләп шул жырны башкара. Күңел түреннән ургылып чаккан моңлы тавышы белән жырны жырлап бетерүгә, халык, урыныннан торып артистны алкышларга кумә. Ни кызганыч, Казанга кайткач, Габдулла Рәхимкуловка репертуарга кермәгән жыр башкарганы өчен нык кына эләгә.

«Татарстан-яңа гасыр» каналының жыр сәнгатен күз уңында тотуы — мактауга лаек. «Безгә нинди жыр кирәк?» дигән тапшыру да әзерләп күрсәтте. Бик кызыклы һәм житди сөйләшү булды ул. Тик безгә нинди жыр кирәк, дигән сорауга анык кына жавап ишетелмәде. «Татар жыры үсештәме?» дигән сорау куелды. Монда фикерләр икегә аерылды. Сәхнәдән, радиодан яки телевидениедән яңгыраган көй, жырларны исәпкә алсаң, сан ягы, һичшиксез, үсештә. Ә жыр сәнгатенең бүгенге хәлен күздән кичерсәк, ул үсми, торгынлык кичерә. Тапшыруда катнашучылар жырчыга музыка белеме кирәк, шунсыз тамашачы күнеленә үтеп кереп булмый, дигән фикер әйттеләр. Талантың, жырга, музыкага сәләтең, һәвәслегең юк икән, ике, өч консерватория тәмамласаң да, тамашачының тирән ихтирамын казана алмыйсың. Монда күп нәрсә жырчының башкару осталыгына һәм нинди жыр сайлап алуына бәйле. Сәхнәгә чыгып берничә жыр жырлап керү — кыен эш түгел, ә менә чын жырчы булып танылу — ай-һай авыр!

Татарстан телевидениесендә «Мәйдан» дигән яңа канал эшли башлады.

Кайвакытта матур жыр тыңлыйсы килеп шул канал кнопкасына басам. Берсеннән берсе күңелгә ятышсыз жырлар яңгырый. Ник без шулкадәр талымсыз икән? Ник тамашачыны ихтирам итмибез икән? Башыңны стенага бәрсәң дә аларны бер-берсеннән аерып булмый. Сирәк-мирәк кенә халык жырлары, танылган композиторларыбызның көй-жырлары яңгырап куя. «Яратам сине генә», «Мин синең белән», «Бергә чакның кадерен белик», «Мәхәббәтне саклагыз», «Яратмаган булыр идем», «Сине сагына күңел», «Юлларыңда синең адашмам», «Ул — мәхәббәт», «Синнән башка яшәү юк миңа», «Шулмы сөю?», «Бердәнберемә», «Алтын бөртегем», «Бирмә мине беркемгә дә», «Бәхет гөлем», «Кара, иркәм, күзләремә», «Сөеклемә» кебек төче мәхәббәт жырларыннан гына торамыни соң безнең жыр сәнгате?!

Татар эстрадасында үз урынын тапкан, тамашачының тирән ихтирамын казанган кайбер жырчыларыбызның да шушы сукмакка кереп барулары ягъни игезәк жырлар белән мавыгуларына шаккатам.

Безнең искиткеч матур тавышлы жырчыларыбыз, өлкән буынга алмашка килерлек егет һәм кызларыбыз бар гына түгел, күп алар. Бу жырчылар халык күңеленә кереп калырлармы? Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Рәшит Ваһапов, Галия Гафиятуллина, Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Габдулла Рәхимкулов һәм башка кайбер танылган жырчыларыбыз халык жырларын, татар музыка сәнгатенең йөзен билгеләгән композиторларыбызның көйләрен жырлап халыкның тирән ихтирамын, мәхәббәтен казандылар.

«Татарстан-яңа гасыр» каналының «Ретро-концерт» программасында Гөлзада Сафиуллина башкаруында жырлар тапшырылды. Гөлзаданы элек тә тыңлаган бар. Соңгы вакытта ул телевидение экраннарында һәм концерт залларында бик күренми. Әмма жырчы үзенең көчле тавышы, моңлы жырлары белән күңел кылларын тибрәтеп жибәрде.

Кайвакытта тамашачыны хөрмәт итү дә житеп бетми. Мин барыннан да бигрәк фонограмма белән жырлауны күздә тотам. Бу хакта дәшми калыйм мәллә дип тә уйлаган идем. Законы булмагач, сөйләүдән файда юк, дим. Урыс эстрадасының танылган жырчысы Елена Ваенганың матбугатта ясаган белдерүеннән соң тагын бер бу хакта искә төшерү зыянга булмас дидем. Кешеләр артистның үз тавышын

ишетермен, үзен күрермен, ничек жырлаганын карармын дип акча түләп концертка килә. Ә артист егетебез яки кызыбыз сәхнә артында магнитофонны хутка жибәреп, тамашачы каршына чыгып, микрофонын тотып «жыр суза». Е.Ваенга хөкүмәт житәкчесе янына кереп, фонограммага жырлауны тыеп, моны законлаштыру турында әйтергә теләвен белдергән. Керә алгандырмы, юктырмы, анысын ачыклый алмадым. Әмма мәсьәләне шулай куюы игътибарга лаек.

Мона бу һәр артистның үз эше дип кенә карарга ярамый. Мәдәният министрлыгы, филармония фонограмма белән жырлау мәсьәләсендә нинди караштa торадыр, әйтә алмыйм. Әмма урыс эстрадасында хәзер жыр конкурсларында фонограммага жырларга рөхсәт ителми. Конкурс премияләре югары профессионализм өчен биреләчәк. Шулай да, концертларда фонограммага жырлау дигән ачу китергеч, эч пошыргыч «тамаша» төрләргә дә барып житкән, ахрысы, ниһаять, Дәүләт Думасына Закон проекты кертелгән. Концертларда фонограмма файдаланылуы турында тамашачыга хәбәр ителмәсә, жырчыга зур күләмдә штраф салынырга мөмкин.

Магнитофонны ачып куеп, сәхнәгә киенеп-ясанып чыгып басу өчен әллә ни зур талант кирәкми. Ә менә тамашачы күнеленә хуш килерлек жыр сайлап алу һәм аны бөтен сәләтенне биреп, зур осталык белән башкару — артистның тамашачы алдындагы жаваплылыгын, ана карата ихтирамын билгели торган сыйфат. Әлбәттә, матур жыр сайлап алу жинел эш түгел. Совет заманындагы кебек, һәр жырны, һәр көйне яки бүтән музыкаль әсәрне композиторлар берлегендә тынлап фикер алышу кебек тәртипләр юк инде хәзер. Композиторларыбыз жыр язып, аны тамашачы кабул итсен өчен шактый күп тир һәм көч түккән. Гомәр ага Бәшировның «Жидегән чишмә» жырының ничек тууы турында сөйләгәне истә. Сара апа Садыйкова жырны язучының үзенә уйнап, жырлап күрсәткән. Гомәр ага композиторның хәтере калыр дип тормаган, турысын әйткән. «Сара, — дигән ул, — чын жыр булып житмәгән бит әле бу, иренмичә генә тагын бер тапкыр йөрәгең аша үткәреп кара». Сара апа башта үпкәләгән, аннары төзәтмәләр, үзгәрешләр керткән. Тагын Гомәр ага янына килгән. Тагын уйнап, жырлап күрсәткән. «Сара, — дигән язучы, — менә безненчә «Жидегән чишмә» килеп чыккан. Рәхмәт!».

Жырчының жырга талымсызлыгында без — тамашачылар үзебез дә гаепле. Артистларны мактый-мактый үсендереп бетердек, ахрысы. Каян килеп чыкты әле бу сәхнәгә аяк баскан һәр жырчыны «йолдыз» дип атау? Шуның өстенә тагын «уникаль тавышлы», «алтын тавышлы» жырчы дигән купшы сүзләр белән артист халкын бөтенләй масайтып жибәрдек.

Артистларны йолдызларга тиңләү гадәте безгә урыс эстрадасыннан йоккан. Бер иязләнеп-күнегеп киткәч, «йолдыз», «сәхнә йолдызы», «эстрада йолдызы» дигән сүзләрне кызганмыйбыз. Әгәр дә артистка ихтирамыбызны, хөрмәтебезне, мәхәббәтебезне, соклануыбызны белдерәсебез килә икән, аны олылау өчен башка сүзләр беткәнмени? Танылган, күренекле, мәшһүр кебек сүзләр ник ошамый? Ләкин даһи түгел. Кайвакытта телебездән бу сүз дә ычкынып китә. Кемгә булса да даһи дип әйтү — бүтән мондый шәхес юк дигән сүз. Әгәр дә без Рудольф Нуриев даһи биюче, Михаил Ломоносов даһи галим, Петр Чайковский даһи композитор, Федор Шаляпин даһи жырчы дибез икән, бу шәхесләр мона лаек һәм аларга бүтән беркем дә тиңләшә алмый. Билгеле, бу даһиларны уздыручы да бардыр, алардан яхшы биюче яки жырчы, композитор һәм галим дә бардыр, әмма боларның даһилыгы талантлары белән инде исбат ителгән. Фикеремне аңлату өчен шундый бер мисал китереп үтим. Шахмат тарихы унбиш дөнья чемпионын белә. Аларның һәркайсы заманында бөек, мәшһүр, атаклы шахматчы дип аталып йөртелгән. Ләкин шулар арасыннан бер генә шахматчы даһи исемен йөрткән. Ул — урыс шахматчысы Александр Алехин.

Инде дә безнең «сәхнә йолдызлары» тамашачы алдына чыгып бер-бер артлы игезәк жырларны жырлый башласалар, ни хәл итәсең? Халык жырларын, хөрмәтле композиторларыбызның безгә мирас итеп калдырган көйләрен ник онытттык соң әле, дияргә генә кала. Әлбәттә, яна жыр, көй язудан беркем дә беркемне тыймый. Син менә шушы көйне өйрән, шушы жырны жырла, дип жырчыга акыл өйрәтүдән дә

файда юк. Әмма син тормышынны җыр сәнгатенә багышлагансың икән, тамашачы алдында җаваплылыгың турында онытма. Халык онны көрпәдән аера белә. Билгеле, тамашачының да төрлесе бар. Ләкин ул теләсә нинди җыр тыңларга риза түгел, без еш кына концерт залларында моңлы, матур көйләр тыңларга зар-интизар булып утырабыз икән, концертны алып баручы сәхнәдә халкыбызның яраткан җырчысы дип белдереп тә, яраткан җырчыбыз халык күңеленә барып җитми торган җырлар башкара икән, безнең җыр чишмәсе шулкадәр үк саекты микәнни соң, дигән сорау куярга хакыбыз бар. Кайберәүләр кемгә нинди җыр ошый инде, гел халык җырларын гына җырламаслар, дияр. Ләкин пәри башка, җен башка дигәндәй, җырчы егет һәм кыз җыр белән җырның аермасын аңларга тиеш. Аңламый икән, ул беркайчан да чын җырчы булып таныла алмый. Кабатлап әйтәм: мәшһүр җырчыларыбыз халык җырларын, композиторларыбызның популяр җырларын җырлап, милләтебезнең олы ихтирамын яуладылар.

Җырчының кемлеге — аның сәхнәгә чыгып нинди көй башкаруы белән генә бәяләнми, үз-үзен тотышы да, киеме дә бик мөһим. Кара костюм-чалбар киеп, ак күлмәк һәм бантик белән, сәхнәгә елмаеп-көлеп чыгып баскан Рәшит Ваһапов күз алдымда тора. Артистның сәхнәгә чыгуына тамашачының иң элек күзе аның киеменә төшә. Хәзер кайбер җырчылар джинси чалбардан, майкадан гына тамашачы алдына чыгып басуны бернигә дә санамый. Ир-ат җырчыларның костюм-чалбар, галстук алырлык кына акчалары бардыр, ләбаса. Хәерчелек итәктән тарткан заманнарда да артистлар сәхнәгә матур итеп киенеп чыктылар, авылның салкын, рәтләп ягылмаган клубларында җырлап-биеп концерт бирделәр.

Кайвакытта телевизорда җырчының тавышы ишетелә, үзе күренми, аннары килеп чыга. Ул йә урманда, йә пляжда җырлап йөри, йә аның түшәктә җырлап ятканын, машина эчендә җырлап утырганын күрәсең. Минем җырчының нинди көй җырларга кирәклеген өйрәтүем түгел. Ләкин ул беренче чиратта тамашачы өчен җырлавын онытмасын иде.

Җырланмаган әле безнең җыр, җырланмаган. Һаман җырлыйсы килә. Безгә чын татар җыры, чын татар моңы кирәк. Тукаебыз әйтмешли чын, безнеңчә матур, милли көй кирәк. Каян нинди җыр табыйм икән, дип аптырап йөрисе юк. Безнең дистәләгән җыр китапларыбыз бар. Кайберләрен генә искә төшерәм: «Җырлар», «Халык җырлый», «Җырлыйк әле», «Җырларыбыз», «Татар халык җырлары, «Яңа җырлар», «Яраткан җырлар», «Сез яраткан җырлар», «Лирик җырлар», «Җырлыйк та, биик тә», «Күңел моңнары», «Җырлыйк, дуслар, бергәләп»... Бу кадәр җыр байлыгы тагын кайсы халыкта, кайсы милләттә бар?!

**Мөнир АБДУЛЛИН**

Нурихан
Фәттах

# ЧЕТЕРЕКЛЕ БУЛДЫ БЕЗНЕҢ ЗАМАН

ИСТӘЛЕКЛӘР

## Боҗра кысылу

Хрущев урынына Брежнев килгәч без тагын өметләнеп яңалык көтә башладык. Баштагы елларда чыннан да кайбер яңалыклар булды. Халыкның тенкәсенә тигән кукурузның дәрәҗәсе төште. Кукуруз игү мәҗбүри саналмый башлады. 1980 елга коммунизм төзү планы да телгә алынмый башлады. Ит-сөт житештерү буенча Американы куып житеп узып китү турындагы өндәмәләр дә юкка чыкты. Ләкин төп юнәлеш үзгәрешсез калды. Милли мәсьәләдә бигрәк тә.

Бу чорны хәзер торгынлык чоры дип атыйлар. Торгынлык ул бөтен ил буенча экономикада, культурада, социаль-ижтимагый тормышта.

Милли мәсьәләдә Брежнев чорында торгынлык түгел, террор чоры булды дип әйтергә мөмкин. Мыштым террор, тавыш-тынсыз террор.

Урам чатларында, багана башларындагы көн-төн кычкырып утыра торган репродукторлар алып куелды. Хәзер һич югы урамнарда тавыш кимеде. Шуның белән бергә йортлардагы, урамдагы татарча язулар юкка чыга башлады. Бәйрәм вакытларында лозунглар, плакатлар, өндәмәләр элек татарча да языла иде. Хәзер бары русча гына язылды, газета витриналарына татарча газеталар бөтенләй диярлек ябыштырылмады. Һәр төрле белдерүләр, чакыру кәгазьләре русча басылды. Хрущев заманыннан калган татарча берән-сәрән ясле-бакчалар юк булды. Казанда бер-ике татар мәктәбе калды, аның берсе — интернат мәктәп. Анда авыл балаларын гына алдылар. Казанның үзендә, Дербышка поселогында 106нчы мәктәп калды. Ләкин ул яртылаш татар, яртылаш русча мәктәп. Миссионер Ильминский методы белән төзелгән «дуслык» мәктәбе. Минем малай белән кыз шунда укыдылар. Аларның кызганыч, мескен хәле тулысынча минем күз алдында үтте. Житмешенче елларда минем малай укыган татар классында егермеләп бала булды, соңыннан кызым Чулпан укыганда унга-унбергә калды. Бу мәктәптәге татар класслары бары директорның, укытучыларның тырышлыгы белән, аннан соң инженер Энгель Зәйнуллин батырлыгы белән генә исән калды. Энгель поселок урамнарындагы һәр татар фатирына кереп, ата-аналар белән сөйләшеп йөрде, үгетләп йөрде, кемнең, кайда баласы барлыгын белеп торды. Һәр жан өчен, һәр бала өчен көрәш барды. Ана туктаусыз аяк чалдылар. Ленин районында торучы Тәүфыйк Әйди, малае мәктәп яшенә житкәч, Энгель кебек үк активлык күрсәтеп карый. Үзләре янындагы рус мәктәбе житәкчеләре белән, райбашкарма вәкилләре белән сөйләшеп, якындагы рус мәктәбендә татар классы ачтырмакчы була. Мәктәптә дә, райбашкармада да каршы килмиләр, чөнки каршы килергә законы юк. Законы

*Ахыры. Башы 7нче санда*

исә шундый: ата-аналар теләге белән ачарга була. Тәүфикъ үзләре тирәсендә йөреп, егермедән артык бала «жыя». Ләкин татар классын барыбер ачтыра алмый. Күпчелек ата-ана курка. Тәүфикъ сүзенә түгел, коткычылар сүзенә колак сала. Аннан соң, мәктәпкә баргач, андагы укытучылар тегеләрне төрлечә алдап, кире борып жибәрәләр. Дербышкада да балаларын татар классына бирергә килүчеләргә завуч Татьяна Федоровна: «Класс тулды, башка алмыйбыз», дип борып жибәрә торган булган.

Райбашкарма кешеләре бернинди практик ярдәм күрсәтмиләр. Аларның үзләренең коты алынган. Законын закон да, милләтчелектә гаепләп куярлар, уен эш түгел. Беркемнең дә милләтче исемен тактырасы килми.

Бик озак азаплангач, нерв авыруына сабыша башлагач, әлеге уеннан кире кайтырга мәжбүр була Тәүфикъ. Бер көнне ул миңа килеп озак кына зарланып, «эчен бушатып» утырды. Кыяфәте бик мескен, бик кызганыч иде. Ир уртасы кеше. Жылады.

Икенче бер танышым — Жәгъфәр дигән завод художнигы, (хәзергечә әйтсәк, дизайнер) үзенең кызын Дербышкадагы татар классына әллә каян, Әмитау ягыннан йөртте. Кызы Ләйсән безнең Чулпан белән бергә укыды. Сүз иярә сүз чыгып, Жәгъфәр бер әйтеп куйды: «Черек күл» вәкиле моны кызын татарча укытуы өчен гаепләп маташкан. Ник татарга бирден дип гаепләде, диде. Жыелышларда, жәмәгать урыннарында татарча сөйләшү бетте, хәтта Язучылар союзында да жыелышлар русча алып барыла башлады. Татар әдәбияты турында татар язучысы русча сөйләргә тиеш булды. Билгеле, беркайда андый закон, кагыйдә игълан ителмәде. Ләкин шундый тәртип керде. Язучылар жыелышында, секция утырышларында татарча сөйләшүдән тыючы булмады булуын, шулай да төрле хәл булды: 1975 нче елда ахрысы, Казан курчак театрында драматург Юныс Әминовның адашы икенче Юныс Әминовның нииндидер пьесасы буенча куелган татарча спектакльне тикшерү булды. Тикшерергә мине дә чакырдылар. Директор бүлмәсендә утырабыз. Беренче сүзне миңа бирделәр. Татарча сөйли генә башлаган идем, шулчакны культура министры урынбасары авызга суккан кебек тупас кына «Говорите по русски», диде. Мин тынып калдым. Шуннан башка сүз сөйли алмадым, ахрысы. Культура министры урынбасары ул чакта Ринат Харис иде. Кайчандыр «Яшь Ленинчы»да, Язучылар союзы идарәсенә жаваплы эшләрдә эшләгән кеше, татар шагыйре.

Ул елларны мин ничектер урамга чыкмаска, кеше белән аралашмаска тырыштым. Шулай да эш-йомыш белән редакцияләргә дә, магазинга-фәләнгә дә барырга туры килде. Берничә мәртәбә автобус-троллейбуста шундый күңелсез хәлгә юлыктым. Берәр авыл хатыны, йә булмаса авыл агае онытылып китеп таныш дусты белән татарча сөйләшергә тотына. Артык кычкырып та түгел. Шулай да якындагы кешеләр ишетерлек итеп. Шунда берәр рус кешесе тупас кына боларның авызын томалый: «Надоели своим тарабаром», ди яисә татарча сөйләшүне турыдан-туры туктатуны таләп итә. Мондый тәртип яратучы гадәттә таза гәүдәле, тупас, оятсыз йөзле кеше була. Ике мәртәбә мин шундый хатын-кыз белән очраштым. Дөресрәге, шундый хатын-кызның «тәртип» урнаштыруына юлыктым. Бер мәртәбә өч-дүрт яшьлек улыбыз белән хатын трамвайда барганда бер рус хатыны ана ябышкан: «Почему с ребенком разговариваеш по-татарски?!» — дип. Хатын, «ул бит минем бала», дип нәрсәдер мыгырданган, ахрысы. «Курыктым» — диде. Бервакыт иртәнге якта «Детский мир»га барып чыктым. Кеше күп түгел. Минем алда сатучы кыз янына кыска сакал-мыеклы бер татар агае килде дә, «кызым» дип сатучыдан татарча нидер сорый башлады. Кыз нидер аңлатты. Шул чакны каяндыр спортсменнарча таза бер иптәш килеп житте. Башында кара эшләпә, аркасында яшел капчык. Турист сыман киенгән. Килде дә, сатучыны кыздыра башлады. «Нишләп татарча сөйләшәсең?» — ди. Мин тораташтай каттым да калдым. Хәтта магазинда. Хәтта карт кеше белән. Димәк, ярамый. Ник?! Нәрсә соң бу, ә?! Нинди стройда, нинди илдә яшибез соң без? Кая килеп чыктык?

Шунын өчен революция ясаганнармени унжиденче елда? Шунын өчен кан койганнармени бетмәс-төкәнмәс сугышларда безнекеләр? Үзе өчен генә түгел, уртак ил өчен, рус өчен дә кан койганнар ләбаса! Хәтта патшалар да тыймаганнар, тыя алмаганнар урамдагы татар кешесен үз телендә сөйләшүдән.

Брежневтан соң Андропов килде. Без тагын өметләндек. Дөресен әйткәндә, ана өмет әлләни зур булмады. «Черек күл»нен атасы Андроповнын кыяфәте үк миһербанлы түгел иде. Күз карашы усал, кансыз. Кылган эшләре аннан ким түгел. Шулай да аның беренче сүзен көттек, яналык көттек. Беренче сүзеннән үк милли мәсьәләдә томанлы итеп сөйләде Андропов. Томанлы булса да, төп мәгънә аңлашылды — вак милләтләр бер-берсенә якынаялар гына түгел, бер-берсенә кушылырга да тиеш. Барысы да аңлашылды. Хәзер инде киләчәккә бернинди өмет юк. Якынайту гына түгел, кушу.

Күп тә үтмәде, куша башладылар. Шәһәрнең ничектер исән калган язулары бөтенләй юкка чыкты, мәктәпләр... Бу юлы инде авыл мәктәпләре дә тулысынча русчага күчәргә тиеш иде. Иң элек ваграк халыкларнын мәктәпләре ябылган. Татарстан белән Башкортстандагы милли мәктәпләрне күчерү бер елгамы, ике елгамы кичектерелгән диделәр. Имеш, безнекеләр әзер булмаган — укытучылар житмәгәнме, фәләнме.

1983 елда мин Ессентукига су эчәргә бардым. Шунда тарихчы Сәләм Алишев белән очраштык. Ул анда төрле милләт кешеләре белән аралашкан, мәктәп хәлләрен сорашкан. Мәктәпкә карата, телгә карата миндә хәзер аллергия. Мин бу турыда тыныч кына тынлый алмыйм. Мәктәп турында, тел турында күнелле хәбәр булмаячагын белгәнгә күрә, мин ничек тә ана кагылмаска тырышам! Сәләмнен, күрәсен, минеке кебек авызы пешмәгән. Украин кешесе әйткән, вузлардан украин телендәге барлык дәреслекләрне жыеп алдылар, уку русчага күчте, дигән.

Элек аларда институтларда да украинча уку бар иде. Кабардин кешесе әйткән, барлык мәктәпләр русчага күчерелде, дигән. Безнен күрше Мари республикасында инде күптән авыл мәктәпләре дә русчага күчеп беткәннәр иде. 1980 елда «Дружба народов»та бер мари язучысы хәтта язып чыкты: марича яза торган кырыктан яшьрәк язучы юк, дип. Менә шулай, божра кысылганнан-кысыла барды. Яшисе, эшлисе килми. Еш кына күнел төшенкелегенә бирелеп, кара көеп, үз алдына кайгырасын.

## «Ябылуда»

Бәләкәй чакта, өйдә беркем дә юк чагында, сизмәсләр әле дип уйлап, Нәсимнәр кар базындагы сөтнен өстен ашаганым бар. Бөтенләй түгел, кая ул! Сөткә бармагынны тыгасын да, бармак башына сыланган тәмле каймакны ялап куясын. Бәләкәй чакта, бик ачыккач, шулай ук сизмәсләр әле дип уйлап, тияргә ярамаган ипинең берәр кырыен кисеп, сындырып ашаганым бар. Бәләкәй чакта, шулай ук, колхозга да әзме-күпме зыян салганым бар. Колхоз бакчасына кыярга, шалкан ише нәрсәләргә кергәнем бар. Аннан соң качып-посып борчак жиренә кереп, яшел борчак ашыйдыр идек. Бер көнне Зәйкәт белән икәүләп Уразыларның житкән борчагын суктык. Уразы — безнен авыл түгел, безнен колхоз түгел. Борчак жирләре безнең әрәмә янында гына. Борчак өлгергән. Басуны саклыйлар, шулай да кичкә таба капчык күтәрдек тә, киттек куак арасыннан чыгып, ялт-йолт каранып, кипкән салам борчагын йолкыйбыз да, үзебезнең якка алып чыгып сугабыз. Биш-алты кило булдымы икән, күбрәк булдымы икән — капчык төбенә салып алып кайттык. Үзебез күтәрә алган кадәр. Авыр гына булды. Менә сина кышлык азык. Соңыннан ишетелде, Уразы каравылчылары күршедә, әрәмә арасында дөпе-дөпе килеп борчак сукканны ишеткәннәр, эзләгәннәр — таба алмаганнар. Шулай тоттырмадык.

Безнен шулай ук яна арыш жирендә кесә тутырып уылган арыш-бодай алып кайткан да бар. Анда да тотылмадык. Чикләвек өлгергәч, күрше Вәрәшнен чикләвек әрәмәсеннән чикләвек жыйган бар. Вәрәшләр дә күршеләрдән чикләвек әрәмәсен

саклыйлар иде. Үз кешеләренә аерым көн биреп җыйдыралар. Анда да безне тота алмадылар.

Шундыйрак шуклыклар булгалады. Сугыш елларында мондый шуклык өчен бишәр-алтышар ел, унар ел бирәләр иде. Без менә тотылмадык һәм шунын белән төрмәдән котылып калдык. Ул еллардагы закон-тәртип күзлегеннән чыгып караганда, күпмедер дәрәҗәдә мин — дезертир, гадел хөкемнән качып йөрүче.

Тоттырмадым. Тоттырмаска беркем өйрәтмәде, беркем котыртмады. Тормыш, табигать үзе өйрәтте. Адәм булып тугач, ашарга-эчәргә кирәк булган. Адәм булып тугач, дөнья кирәк-ярагы ашау-эчү белән генә дә бетми икән. Аң кергәч, күз күреме кинәйгәч, шул ук тормыш, табигать кушуына буйсынып без милләт, тел, әдәбият, культура дигән төшенчәләрен үзләштердек. Безнен дә башкалар кебек үз телебезне, культурабызны үстерәсебез, башкалар кебек кешечә, «милләтчә» яшисебез килә башлады. Университетта чакта еш кына без бәхәсләшеп киттек, киләчәк турында, милләтне үстерү, баету турында сүзләр алып бардык. Колхоз басуыннан бер кесә яшел кузак алып кайту яисә күршеләр әрәмәсеннән чикләвек җыеп алу чынлыкта баш китәрлек җинаять булмаган кебек, үз телен, культуран турында кайгырту, фикердәшләрен, яшьтәшләрен белән җыйнаулашып сөйләшү, бәхәсләшү дә җинаять түгел дип исәпләдек без.

Ләкин без ялгышканбыз икән. Бик нык ялгышканбыз. Бер кесә урылган арыш, бодай өчен төрмәдән котылып калсак та, үсә төшкәч без аннан котыла алмадык. Биш-алты ел урынына безне мәңгелек «төрмәгә» ябып куйдылар.

Бәхеткә каршы дип әйтимме, мин ябылуда бары утыз ел гына булдым. Кимендә утыз ел. 1985 елга кадәр.

Мин эзәрлекләүнен кайчан башланганын да төгәл генә әйтә алмыйм, шул Чистайдан, Казанда эшкә керүдән «явыз ният белән» баш тартудан башланды булса кирәк. Ә власть вәкиленен ин беренче килүен, мине тикшереп, күзәтеп килүен яхшы хәтерлим.

«Аккош күле»ндә, урман эчендә торып яткан чак. Яңа ел житә. Кыш көне урманда күнелсез. Әледән-әле шәһәргә барасын, дусларны, танышларны күрәсе килә. Мин шулай итәм дә. Берәр атна өйдә утырам да, шәһәргә чыгып китәм. Шунда бер уй килде. Яңа елны, ягъни 57нче елны бездә, урманда, дачада уздырырга кирәк. Таныш-белешләргә әйткәләдем. Алар бик теләп риза булдылар. Урманда, аулакта җыелып бер күнел ачу ни тора! Барысы да яшьләр, кызлар-егетләр. Егермеләп кеше җыелды.

31 декабрьдә кичкә таба кунаклар җыела башлады. Барысы да шат, күтәренке күнелле. Сихри урман эченә киләләр. Мин каршы алып торам. Шаулашып исәнләшәләр, шаян сүзләр әйткәлибез. Очрашу-күрешү ыгы-зыгысында ниндидер ят кеше чалынып калды. Озын буйлы, янында кызы да бар. Җегет белән кыз. Минем боларны беркайчан күргәнем юк. Минем берәр танышка ияреп килде микәнни соң? Ләкин без теләсә нинди таныш-белешне ияртеп килергә сөйләшмәгән идек. Күнелдә шик туды, «Сез кем белән килдегез», — дидем шулай да боларга. Нидер җавап бирде дә, түргә узды. Төпченеп, бәйләнеп тормадым. Ерактан кунак булып килгән икән, ничек куалап чыгарасын кешене? Безнең белән ашадылар-эчтеләр болар, җырладылар, биеделәр дигәндәй.

Ул вакытта мин бу турыда ничектер онытТым. Бары соңыннан гына, шундый ук шикле, ят кешеләр тирә-якта еш чуала башлагач кына искә төшердем. Тегеләр кешесе булган бу.

Житмешенче еллар башы. Тарихи трагедия язу уе белән хыялланып йөрим. Пьеса язып караган юк. Шулай да язасы, дөнья шаулатасы килә. Батулла «коткысына» бирелеп, курчак театры өчен «Энжеле үрдәк» дип аталган пьеса язган идем, Сара апа Садыйкова музыка язды. Уңышлы гына барды. Татар өчен трагик чорлар күп булган. Якынрагы, анлашылганрагы — Казанның алынуы, ханлыкның юкка чыгуы. Ләкин бу турыда язу түгел, уйлавы да куркыныч. Шул турыда язганны сизсәләр, икенче көнне үк алып китәчәкләр. Ин кулае — монгол яулары чоры. Болгарның харап булуы. «Кол Гали» трагедиясе шундый жирлектә туа башлады. Трагедиянең әүвәлге

вариантын шигырь белән яздым. Кол Галигә, гомумән элекке татар әдәбиятына иярү дә бар монда, Шекспир трагедияләренә дә иярү бар. Бездә бит әдәбият ин элек шигырь формасында булган.

Үземчә язып бетердем. Ләкин кемгә дә булса укып күрсәтергә йөрәгем житми. Беренчедән, минем үзем өчен яна жанр, икенчедән — тарих турында. Ин әһәмиятлесе шул, ахрысы. Ул елларда без Габдулла абый Шамуков белән дуслашып киткән идек. Бу болай булды. Габдулла абый Сөембикә манарасы турында зур гына мәкалә язган да, шуны «Казан утлары»на тапшырган. Мәкаләне шул килеш басарлык түгел, теле авыр, жөмләсе дә буталчык. Моны мина тел-стиль ягыннан эшкәртергә тәкъдим иттеләр. Мин бик теләп риза булдым. Шул чакны бер сөйләшү истә калган. Авторнын исем-фамилиясеннән сон анын РСФСРнын, ТАССРнын, БАССРнын... атказанган артист дигән исем-дәрәжәсе тезелеп киткән. «Габдулла абый, сезнен исемегез болай да укучыга таныш. Исемнәрне язып тормыйк» — дидем мин мона. «Юк, — диде бу, бу исемнәрне мин үземне данлау өчен язмыйм, — диде. — Әгәр мине юк итәргә исәпләсәләр, ин элек минем дәрәжәле исемнәрне юк итәргә кирәк булачак.» Кыскасы, бу дәрәжәле исемнәр үзен саклап калыр дип уйлаган Габдулла абый.

Мәкалә басылып чыкты. Габдулла абыйны алып китмәделәр, редакторга да берни булмады. Шулай да колакка чалынып калды. Атаклы артист Габдулла Шамуковны бик озак күтәрмәделәр. Театрда СССРнын халык артисты дигән исемгә ин элек, әлбәттә, ул лаек иде. Ана түгел, башка иптәшкә бирделәр. Бары үләренә бер ел кала, 1980 елда гына ана бу исем бирелде. Мондый тоткарлауга киртә булып, әлеге Сөембикә турындагы мәкалә сәбәпче булган, имеш.

Нindидер бер жыелышта, мин тәнәфестә буфетта тамак ялгаган арада, Габдулла абыйны очраттым да, ана «Кол Гали» трагедиясен язуым турында әйттем. Каршы килмәсәгез, сезгә укып карар идем, дидем. Габдулла абый риза булды. Кайчан күрешү, сөйләшү турында килештек. Без буфетта сөйләшкәндә якында гына черек күл «кошы» — кыска буйлы башкорт күзгә чалынып калды.

Берүзе бер өстәл янында ашап утыра. Халык алдында Габдулла Шамуков белән Нурихан Фәттахнын очрашып сөйләшүе зур жинаять иде, әлбәттә. Шулай да мин мона игътибар итмәдем.

Билгеләнгән көнгә, кичке сәгать алтыга беренче мәртәбә Габдулла абыйнын квартирасына киттем. Таптым, куркып кына звонокка бастым. Ишекне бик тиз ачтылар. Өстенә өй халаты киеп алган Габдулла абый шаулатып исәнлек-саулык алды, түргә чакырды, кыяр-кыймас кына ишектән кердем. Ләкин түргә үк үтеп булмый. Ишек төбендә нindидер ир кеше. Таза гына, аксыл йөзле, исерек сыман. Габдулла абый моны чыгарып жибәрмәкче була. «Бар әле, бар!» — дип кулын селти, ишеккә күрсәтә. Күпмедер азаплангач, чыгарып жибәрде бу моны.

Түзәлмәдем, сорарга мәжбүр булдым. «Кем сон, бу, Габдулла абый?» — дидем. «Кем белсен аны» — ди хужа. Әлерәк кенә килеп керде. «Шушы подъезда торам», ди, күргәнем дә, белгәнем дә юк!» — ди Габдулла абый. «Ник кергән сон ул шулай да?» — димен. «Минә малаемны урыс мәктәбенә биргән идем, татар мәктәпләре юк» — дип башны катыра, — диде Габдулла абый.

Ул кичне мин Габдулла абыйга кычкырып «Кол Гали» трагедиясен укыдым. Пьеса турында ниләр сөйләшкәнбездер — истә калмаган. Бары минә шул исерек булып кыланган, туп-туры кеше квартирына басып кергән иптәш хәтергә уелып калган да, анын йөзе, кыланышлары, уелып калган.

Көзге салкын иртә. Октябрьнен унбише. 1963 ел. Иртән иртүк торып магазинга киттем. Ипи алырга. Күпмедер чират торып, сәгать сигезләргә кайтып керсәм, капка төбендә аксыл төстәге искерәк «Волга» машинасы тора.

Янында майор погонлы юантык кына, таза гына бер кеше белән шоферы тора. Капка бикле, хатын укуга киткән. Өйдә башка беркем юк. Мине көтеп торалар болар. Майор үзенен кем икәнлеген әйтте. «Комитет госбезопасности»дан, ди. Мине алырга килгәннәр.

Мине. Алырга килгәннәр. Черек күлдән. Аңлап житә алмадым. Каушап төштем. Калтыранган куллар белән капканы ачтым, ишегалдына кердем. Шулай да кергәндә әйттем, ашамаган әле, чәй эчеп алыйм, дидем. Ярар, диде майор. Машинасы янында торып калды. Өйгә кермәде.

Өйдә иң элек мин үземнең кысан гына язу бүлмәсенә кердем, соңгы сүзләрне язып калдырырга булдым. «Мине Черек күлгә алып киттеләр. Кайта алмасам, улымны сакла. Сау бул» — шундыйрак сүзләр яздым. Улым да, инәкәй дә ул вакытта Яңавылдалар иде. Чыннан да, кайта алмасам, аларны яңадан күрә алмасам, нинди үкенечле булачак! Ләкин үкенеп, кайгырып тора торган чак түгел. Чынлап та кайталмасам, үкенерлек нәрсәләр күп кала. Бөтен бер дөнья, тормыш, өй, эш-хыяллар өелеп калачак. Ышанасы килми. Ни өчен икәнлеген белергә тырышам.

Бу арада гына бернинди гаеп эш, кыек эш тә эшләмәдем. Юк-бар сөйләшеп тә йөрмәдем кебек. Черек күлнең нәрсә икәнен инде мин бик яхшы беләм. Иң тәэсирле сүзләр, иң яшерен сүзләр — Черек күл турында. Анда бер сүз, монда бер сүз ишетәсең. Андагы хәлләр турында ишеткәч, чәчләрең үрә тора. Күңел өши, бозга әйләнә. Мине инде ул елларда ук бәйләнчек бер уй эзерлекли башлаган иде. Минем еш кына үземне черек күл корбаннары урынында итеп күрә, тоя башладым. Никтер мин, һичшиксез, Черек күл базларында үләргә тиеш сыман тоелды. Төштә еш кына миннән сорау алалар, газаплыйлар, мыскыллыйлар.

Шул еллардамы, соңыннанракмы, Черек күл базларын, камераларын үз күзе белән күргән, күп нәрсәне үзе татыган Бәдәйли язмаларын укырга туры килде. Миннән соңгы буын кешеләренә истәлек булып калсын дип, Бәдәйли Тәуфикъ Әйдигә әйтеп калдырган булган. Шуннан бер җөмлә хәтердә калган. Гитлер концлагерьлары барлыкка килгәнче, концлагерь тәртипләре иң элек Казанда, Черек күлдә барлыкка килде, дигән. Кешене Черек күлдә мыскыл итүләр, җәзалаулар янында фашистларның җәберләре бала-чага уены гына булып тоелырга мөмкин, дигән.

Әйе, мин инде күп нәрсә ишетеп белә идем. Күңелемнән мин кайчан да булса Черек күлгә эләгүгә, андагы җәзаларга да әзер сыман идем. Карар да кабул иткән идем кебек: мин барыбер аларга берни сөйләмәячәкмен, бернигә җавап бирмәячәкмен. Мин барыбер үз фикеремдә калачакмын. Алар, әлбәттә, үтерәчәкләр. Кайчан һәм ничек үтерсәләр дә барыбер түгелмени?

Күңелгә шундыйрак уйлар килә торган иде. Тик шулай да мин менә шулай кисәк кенә, көтмәгәндә генә алып китәрләр дип башыма да китереп карамадым. Юл буе уйланып барам. Ник? Ни өчен? Юк, бернинди дә гаеп тапмыйм. Өйләргә, кешеләргә, юлга игътибар беләнрәк карыйм. Беренче мәртәбә күргән кебек карыйм. Майор белән шоферның үзара сөйләшеп алуларына игътибар итәм.

Килеп җиттек. Ишектән кердек, кечкенә тәрәзәле вахтер бүлмәсе яныннан узып киттек. Өченче катка мендек, озын коридор буйлап бардык та, сул яктагы 65нче бүлмәгә кердек. Бүлмәдә кара чәчле, чибәр кыяфәтле яшь кенә татар кешесе каршы алды. Кешечә, ягымлы сөйләшә. Бер дә мин күз алдына китергән кансыз палач түгел. Шулай да баштарак мин үземне шактый киеренке, усал һәм дорфа тоттым. Эндәшмим, яисә тупас-тупас җаваплар бирәм.

Бераздан бушандым, тынычландым сыман. Болар мине базга ябып куярга яисә анда җәзаларга чакырмаганнар икән. Болар, имеш, минем ярдәмгә мохтаҗ. Менә алар татарча язылган ниндидер прокламация кулга төшергәннәр. Шуның телен тикшерергә, кем язганын ачыкларга кирәк кирәк икән. Мин, имеш, телне яхшы беләм, «иптәшләр» мине тәкъдим иткәннәр. «Нурихан Фәттахтан башка моны тиешенчә анализлаучы кеше табылмас», — дигәннәр. Прокламациядә кемдер татарның, татар культурасының юкка чыга баруына өзгәләнә... Мисаллар китерә, Иван Грозныйларны, башка патшаларны искә ала.

Беренче көнне сәгать уникеләргә кадәр «прокламация» белән танышып утырдым. Шуннан соң чыгарып җибәрделәр. Икенче, өченче көнне тагын бардым. Атна буе

шунда йөрдем. «Прокламация»нен теленә жентекләп анализ ясадым, шуны язып бирдем. Мин боларның бары бер спектакль генә булуын бөтен күңелем белән сизеп тордым. Чыннан да бу шулай булып чыкты. Дүртенче көнне сөйләшүдә кара чәчле иптәш янына тагын икенче бер иптәш керде. Монысы өлкән яшьтәрәк, кыскарак буйлы. Башкортстаннан икән. Мин дә бит Башкортстаннан, янәсе без — якташлар.

Иң житди сөйләшү шунда булды. Болар мине шелтәли, үгетли башладылар. Мин, имеш, ультрамилләтче, җыелышларга йөрмим, рәсми иптәшләрне хөрмәт итмим, булмас нәрсәләр турында сөйләнеп йөрим. Юк-бар нәрсә белән йөргәнче, халыкка хезмәт итәргә, язарга кирәк. Күрәсең, алар да «халыкка хезмәт» турында сөйли алалар. Әйтерсең, мин халыкка хезмәткә каршы кеше. Минем бөтен уем-фикерем, бөтен эшем — халыкка хезмәт итү. Шуннан соң яшьрәге әйтеп салды — бу прокламацияне без инде күптән ачыкладык, язган кешесе дә билгеле. Без моны сина юри генә бирдек, диде. Менә син монда болай дип, тегеләй дип язасың... ди. Хәзер бу минем анализдан гаеп тапмакчы була. Түзмәдем, әйттем: мин аның кайбер фикерләре белән килешәм, дидем, ягъни «прокламация» язган кеше фикерләре белән.

Мин үземнең кайда, нинди бүлмәдә утыруымны онытып җибәрдем, ахрысы. Шулай да ул-бу булмады. Хәер, ул-бу булырга да тиеш түгел иде сыман. «Прокламация» тикшерү спектакль булгач, аның башкасы да спектакль булырга мөмкин бит әле.

Өченче килүдә, ахры, кара чәчлесе озак кына минем белән тел, әдәбият, тарих турында сөйләшеп утырды. Тел ничек үсә, кая бара, татар каян килә һ.б. Ул чакта нәрсә белсәм, барысын да сөйләдем. Белем ягы әле артык тирән түгел иде, шулай да кайбер нәрсәләрне инде дөрес сукалый идем.

Иң ахырда шул булды, киләчәктә ярдәм-фәлән кирәк булса, сине тагын чакырсак, килгәләп йөрерсеңме? «Юк, — дидем — минем бу йортка йөргәнемне иптәшләр күрсә, алар йөзенә ничек күренермен?» — дидем. Аерылышыр алдыннан бер кәгазьгә кул куярга куштылар. Укып тормадым, ләкин бик нык итеп әйттем: мин монда бернинди кәгазьгә кул куямаячакмын, дидем. Шуннан соң кыстаучы, үгетләүче булмады.

Кулдан язган анализны машинада басарга кирәк, диделәр. Бездә татарча машина юк, машинканны монда алып килмәссеңме, диделәр. Монысы хәтта миңа да шикле тоелды. Кем инде монда машинка күтәреп йөри?! Ярар, анализны алып кайтырмын, машинкада басып алып килермен дидем. Риза булдылар. Икенче көнне кулдан язылган, машинкада басылган текстны алып килгәч, кара чәчле чибәр иптәш дөньясын онытып укырга тотынды. Бик озаклап укыды. Юк, бернинди хата да, гаеп тә тапмады. Киткәндә ягымлы итеп озатып калды.

Утыз ел буена, ким дигәндә утыз ел буена алар минем язганнардан хата эзләделәр. Юк, тапмадылар...

*1988 ел, 17 июль*




*Һәр елны 15 октябрьдә Казанда Хәтер көне үткәрелә. Ул Ирек мәйданында башланып, Сөембикә манарасы янында җеназа намазы уку белән тәгәлләнә.*



*Тукай клубында Камал театры артистлары белән очрашу ядкәре. 1977 ел.*



*Әмирхан Еникинең каләм эзе Сарман районында да калды. 1983 ел.*



*Равил ул – чаңгыда да Шәрәфиев! 2004 ел.*



*Фәнис Яруллин һәм Нурсөя Үзбәкстанның Янгиюл авылындагы Сафияновлар гаиләсендә. 1977 ел.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Баулы

Баулы Казаннан 369 чакрымда, тимер юл станциясе Бөгелмәдән 35 чакрым ераклыкта урнашкан.

Ул хәзер ике өлештән тора: аның югары өлешен халык Ак буа дип, ә аскы өлешен Баулы дип атый. Уртак исемнәре Баулы, әлбәттә.

Олылар Баулы атамасының барлыкка килүен болай аңлата.

Борын-борын заманнарда бер күчмә кабилә ял итү, көч туплау өчен билгесез бер елга янына килеп чыга. Кабилә башлыгының малае тамагы кибеп ул елгадан су эчкән, ә судан бал тәме килгән. Бу сәер хәлнең серен ачарга ниятләп, елганың башланган урынына ук барганнар. Елга башында яшен суккан агач булып, аның эченә шөпшә оялаган, шушы оядагы баллы ширбәт елгага аккан икән. Нәтиҗәдә, Баллы елга исеме барлыкка килгән. Тора-бара атама Баулыга әйләнеп киткән.

Баулы уртасыннан кечкенә генә (элек ул зур булган) Баулы елгасы ага. Читләтеп Ык һәм Димскәй сулары үтеп китә.

Баулы янында Никкүчтем урманы бар. Бу тирәдә урманнар катнаш. Агачлардан имән, каен, юкә, чыршы, нарат, усак һәм чикләвек куаклары үсә.

Баулы соңгы елларда нык үзгәргән. Җир куенындагы нефть байлыгын чама белмичә чыгару табигатькә шактый зыян салган. Урманнарда каен агачлары сирәгәйгән. Елга-инешләр, чишмә-кизләүләр һәм күлләр пычранган.

Баулыда кешеләрнең ялын файдалы итеп үткәрү өчен бөтен унайлыклар тудырырга тырышалар. 1996 елның җәендә яна мәчет ачылган. Музей оештырылган. Анда Баулының тарихы белән танышырга була.

## Битләнгер (Аксыбы)

Битләнгер авылы Кукмара районында, район үзәге Кукмарадан 24 чакрым ераклыкта, җирле үзидарә советы үзәге Түбән Өскебаштан – 2, Гурьевка пристаненнән 19 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы тарихи белешмәләрдә шактый еш искә алына.

А.Артемьев җыеп чыгарган тарихи белешмәдән күренгәнчә, авыл Битләнгер (Акцыбова) формасында бирелгән. Өске суы ярына утырган бу авылда 55 хуҗалык булып, аларда 182 ир-ат һәм 176 хатын-кыз көн күргән, мәчет эшләгән. И.А.Износков җыеп чыгарган белешмәдән аңлашылганча, исемлектә авыл Битләнгер, Аксуфи, Акцибово, татарча Балтанир, Белтангир вариантлары белән күрсәтелгән. Өске суы ярына урнашкан бу авылда 185 ир-ат һәм 179 хатын-кыз көн иткән. Аксуфи атамасы

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

авылны беренче тапкыр нигезләгән шәхескә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән. 1898 елда басылып чыккан тарихи белешмәдә авыл Битләнгер (Аксебо – татарча ул Аксыбы булса кирәк: Ф.Г.) дип теркәлгән. К.П.Берстель бастырып чыгарган белешмәдә авыл Битләнгер (Акунбово) дип атала. Анда 634 татар кешесе яшәгән.

Битләнгер (Аксыбы) авылы халкы күршедәге Югары Тәкәнеш, Түбән Тәкәнеш, Урта Тәкәнеш, Югары Козгынчы, Түбән Козгынчы, Түбән Дусай, Тулбай, Олыяз, Иске Чәбья, Яна Чәбья, Шәмәк, Көмеш күл (Биләтле), Алгай, Өске, Сарбай (Каравыл), Югары Өскебаш (Казаклар), Түбән Өскебаш авыллары белән бергә 12-18 июньдә (иске стиль белән) Тукташ жыены үткәргән. Тукташ, күрәсен, бу зур жыеннын башлыгы булгандыр.

Өлкән буын сөйләвенә караганда, авыл болай оешкан.

Ике бертуган, абыйлы-энеле Аксуфый белән Янсуфый бәхет эзләп юлга чыга. Аларнын юллары бик озын һәм катлаулы була. Янсуфый хәзерге Кукмарадан ерак түгел генә бер аланлыкта тукталып төпләнеп калса да, Аксуфый юлын дәвам итә. Бик еракка китмичә генә, елга буендагы бер аланлыкка чыга һәм шунда төпләнеп кала. Үзе өчен алачык ясый, урман кисеп утын әзерли, жирне эшкәртеп бераз ашлык та чәчә. Елганын уң ягында чыга торган чишмәне чистарта, су юлын кинәйтә.

Озакламый монда берән-сәрән кешеләр дә килә башлый. Бу якларны ошатканнары шушында урнашып та кала. Бер-берсе белән уртак тел табып, үзара ярдәмләшеп матур гына яши башлыйлар. Алар арасында хөрмәткә лаек кеше Аксуфый була. Анын хөрмәтенә авылны Аксыбы дип атыйлар.

Авыл зураеп үсеп китә. Урмандагы агачлар киселгән һәм төпләнгән. Шулай итеп, ашлык чәчү өчен жир дә ачылган. Халык болан, пошн, куян аулаган. Тиреләреннән тун-бүрек теккәннәр. Тора-бара халык сыер, сарык кебек мал-туар да асрый башлаган.

Көннәрнен берендә күрше Өскебаш халкы Аксыбыга таба жирләрен арттыра башлый. Өскебашлар Аксыбы халкынын жирен ала икән дигән хәбәр тарала. Бу хәбәрне ишетүгә жиде хужалык, Галим исемле кешегә ияреп түбәнрәк, хәзерге күпер янына төшеп утыра. Ике авыл арасында бәрелеш тә булып ала. Сонрак бу урынга башка хужалыклар да төшеп утыра. Авылда Дөббәрүш исемле бик укымышлы кеше була. Ул халыкны да белемле итәргә тырыша. Алар гаиләдә жиде бала үсәләр һәм жидесе жиде авылга урнашалар. Ул вакытта ук инде укымышлы кешегә халык изге зат дип карый торган була. Жиде туган утырган 7 авылда да алар хөрмәтенә чишмәгә Изгеләр чишмәсе дип исем бирелә. Авылда бер чишмәне укымышлы Дөбәррүш хөрмәтенә Изге чишмә дип йөртәләр. Халык Аксуфыйга да изге зат дип караган. Әлеге чишмәне Аксуфый карап һәм чистартып торган. Хәзерге көндә чишмә өе манаралап эшләнгән һәм ай куелган. Чишмә күзе рәттән ургылып чыгучы ике чишмәне берләштерә. Суы бик шифалы диләр. Авыл халкынын күбесе авырганда суны шуннан эчә. Су алу өчен башка жирләрдән килүчеләр дә байтак.

Авыл зурайганнан-зурая. Күпердән өстә урнашкан халыкны Югары очлар, ә күпердән түбән утырганнарын Түбән очлар дип йөртәләр. Күпернен икенче ягына, тау башына да өйләр салына. Бу урын тау башында булганлыктан, халык теленә Атау дип кереп калган. Авыл ягыннан Өске инеше ага. Ул Югары Өскебаш авылы яныннан башланып, Югары Өскебаш, Түбән Өскебаш, Зур Өске һ.б. авылларны үтеп, Шия елгасына кушыла.

Хәзер халык телендә авыл атамасы ике төрле кулланыла: Битләнгер һәм Аксыбы. Битләнгер атамасы Бөтләнгер инешенә мөнәсәбәтле булса кирәк. Ләкин авыл халкы күнеленә Аксыбы атамасы якынрак. Сөйләм телендә авылны Аксыбы дип йөртәләр, ә Битләнгер атамасы рәсми документларда гына кулланыла.

## Бөгелмә

Бөгелмә шәһәре Казаннан 333 чакрым ераклыкта урнашкан. 1859 елда Бөгелмә елгасы ярына утырган Бөгелмәдә 620 хужалык исәпләнгән. Аларда 2460 ир-ат һәм 2181 хатын-кыз көн иткән. Шәһәрдә православие чиркәве, училище, хастаханә, элемтә станциясе, 5 завод булган, атна саен базар үткәрелгән.

В.П.Семенов наширлегендә басылып чыккан тарихи чыганактан күренгәнчә, Бөгелмә шәһәре урынында башта шушы исемне йөрткән татар авылы була. Бөгелмәнең шәһәр буларак салына башлавы 1741-45 елларга карый. Шәһәрнең әүвәлге халкын жир эше белән шөгыльләнүче солдатлар, ясаклы крестьяннар һәм сөргенгә жибәрелгән кешеләр тәшкил итә,

1781 елда Бөгелмә шәһәр статусы ала. Хәзерге вакытта ул республика карамагандагы шәһәр, Бөгелмә районының үзәге. Республиканың көньяк-көнчыгыш өлешенә, Зәй суы башланган урынга якын гына утырган.

Бөгелмә районы 1930 елда оештырылган.

Олылар сөйләвенә караганда, Бөгелмә шәһәренең атамасы бөгелеп аккан Бөгелмә елгасына нисбәтән барлыкка килгән. Элек шәһәр урынында шактый күп сазлыклар булган. Элек үзәк мәйданнарда базар эшләгән, базар урыны гел сазлыктан торган. Әле дә шәһәр урамнарының кайберләрендә асфальт жиргә инә. Аны ел саен күтәртеп, астына плитәләр куеп, янадан асфальт түшиләр.

Элек Бөгелмә елгасының суы саф һәм чиста булган, анда көмеш форель дип аталган балык үрчегән. Хәзер елга сай һәм пычрак, форель дә шәһәр гербында гына сакланган.

Бөек Ватан сугышына Бөгелмәдән 14844 кеше сугышка китә, шуларның 4475е үз гомерләрен Ватан өчен бирә. 1941 елның көзендә шәһәрдә 352нче укчы дивизия оештырыла. Генерал Ю.М.Прокофьев командалыгындагы дивизия Мәскәү стеналары янынннан башланган данлы сугыш юлын узган. Волоколамск өчен барган сугышларда төп сынауны узып, дивизия Мәскәү, Смоленск өлкәләрен, Белоруссия, Польшаны азат итүдә катнашып, сугышчан юлын Чехословакиядә тәмамлый.

Орша шәһәрен азат иткән өчен дивизиягә Орша исеме бирелә. Минскины азат иткән өчен Кызыл Байрак ордены, Днепрны уңышлы кичкән өчен Суворов ордены белән бүләкләнә. Шул вакыттан алып аны 352нче укчы Кызыл Байрак һәм Суворов орденлы Орша дивизиясе дип йөртәләр. Бөгелмәлеләр дивизиянең үткән данлы юлы турындагы ядкәрләрне кадерләп саклый. Шәһәрнең бер урамы Орша дивизиясе исемен йөртә. Шәһәрдәге 11нче мәктәптә 352нче укчы дивизиянең сугышчан дан музее бар.

Советлар Союзы Герое исеменә 8 бөгелмәле лаек булган. Араларында легендар Газинур Гафиятуллин да бар.

Бөгелмә иҗат белән шөгыльләнүче шәхесләргә дә бай. Журналист һәм язучы Роза Сәет кызы Хафизова да Бөгелмә шәһәрендә туып-үскән.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Р

**РӘХИМОВ** Җәмит Гата улы (13.1.1935, элекке Шөгер р-ны Иске Шөгер ав. — 27.12.1996, шунда ук җирләнгән), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1961). 1953 елдан Әлмәт шәһәрендә нефть эшкәртү пр-тиеләрендә оператор һәм электромонтёр булып эшли, 1959-60 та — «Заветы Ильича» исемле Лениногорск р-н г-тасында а.-х. һәм пром-ть бүлеге мөдире. Лениногорск нефть техникумын тәмамлагач (1970), скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсендә мастер, нефть эшкәртү пр-тиеләрендә инженер. Әдәбиятка 1950 елларда килә. «Алтын яткан җирләрдә» (1966), «Кобзарь — Тукай кунагы» (1968), «Якташларым» (1972), «Батырлык чакрымнары» (1976) исемле очерк җыентыклары хезмәт кешесе турында. «Девон хәбәрчесе» (1977), «Өлешемә тигән көмешем» (1978), «Тәвәккәл таш яра» (1981), «Кыядагы чәчәкләр» (1989), «Сагыш» (1991) повестьларының үзәгендә дә нефтьчеләрнең авыр хезмәте, катлаулы язмышлары бәян ителә. Бай тарихи материалларга нигезләнеп, психологик планда язылган «Батырша» (1992) романы 18 гасыр уртасында татар һәм башкорт халкының патша хөкүмәтенә каршы баш күтәрүе, аның җитәкчесе, милли азатлык хәрәкәте идеологы Абдулла Алиевның (Батыршаның) каһарманлыгы, шул чорның тормышы, халыкның гореф-гадәтләре, төрле катлаулы кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр турында. Бу роман 20 йөз татар милли әдәбиятының тарихи роман жанрында язылган күренекле әсәрләреннән берсе булып санала.

Әд.: Төхфәтуллин Р. Кыядагы чәчәкләр // Казан утлары. 1995. №1.

**РӘХИМОВ** Ринат Рәхим улы (17.3.1939, Арча р-ны Урта Сәрдә ав. — 16.8.1984, шунда ук җирләнгән), шагыйрь. Казан а.-х. ин-тын тәмамлагач (1962), Питрәч р-ны Ильич исем. колхозда агроном, 1965 тән рәис булып эшли. 1973-84 тә шул ук районның а.-х. идарәсендә баш агроном-мелиоратор, аннары мелиоратив берләшмәнең баш агрономы һәм соңрак аның рәисе. «Тормыш атомнары» (1964), «Сабан тургае» (1965), «Туган җирем» (1970), рус теленә тәрҗемәдә «Тепло земли» (1972) җыентыклары авторы. Иҗатының үзәгендә гражданлык лирикасы өстенлек итә. Шигырьләрендә авыл кешесенең хис-тойгыларын, табигать күренешләрен оста тасвирлый.

Әд.: Хәким С. Җир шагыйре // Казан утлары. 1971. № 9.

**РӘХИМОВА** Бикә (псевд., чын фам. һәм исеме Фәйзуллина Миннебикә Рәхмәтулла кызы) (10.4.1939, Әлки р-ны Чуаш Кичүе ав. — 9.3.2011, Казан, туган авылында җирләнгән), шагыйрә. Казан ун-тын тәмамлагач (1963), СССР Фәннәр Академиясенең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. 1968-73 елларда Әлмәт шәһ. яши. 1973 тән Казанның урта мәктәпләрендә татар теле укыта. 1980-94 тә Татарстан кит. нәшриятында әдәби басмалар мөхәррире вазифасын үти. «Сәрвиназ» (1986), «Ачыл, күңел!» (1989), «Иделләр казанында» (1999), «Мәрхәмәт» (2005), балалар өчен «Кырмыскалар өендә» (1991), «Урман радиосы» (1995), «Җайдак малай» (2007) исемле шигырь җыентыклары, «Бакый сагыш» (2009) дигән публицистика китабы авторы. Р.ның иҗаты фәлсәфи мотивларга, халыкның яшәеше турында лирик уйлануларга бай. ТРның Почёт грамотасы белән бүләкләнгән (1994). А.Алиш исем. ТР Язучылар берлеге пр. лауреаты (2009).

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**РӘХМӘНКОЛОВ** (Рәхмәнколый) Әхмәт (Шаһиәхмәт) Таҗетдин улы (1886, Оренбург губерниясе Троицк ш. — 1939 елдан соң), драматург. Троицкида атасы мәдрәсәсендә («Рәхмәнколый»), аннары Бохарада, Истанбулда укый, бер ел чамасы Троицкида рус телен өйрәнә. 1911 елдан тегермәндә эшли, сәүдә б-н шөгыльләнә.

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

1914 елдан Төркиядә сәүдәгәр Яушевнең сәүдә йорты вәкиле була; татар студентларының иҗтимагый хәрәкәтендә, «Тәгареф әл-Ислам» газетасын чыгаруда катнаша. Троицкига кайткач, 1917 елның мартында «Хөр милләт» газетасын редакцияли, 1920-22 елларда укытучылык итә. 1925-32 елларда Казанда, соңыннан Урта Азиядә. «Чыңгызхан» (Истанбул, 1914), «Упкын» (1925), «Боз астында дулкын» (1926; 2нче басма 1992), «Җиһан тетрәгәндә» (1926), «Кара күләгәләр» (1931) һ.б. татар һәм рус театрларында куелган пьесалар авторы. 1929 елда «Востоккино» студиясендә Р.ның «Упкын» пьесасы буенча «Комета» исемле фильм төшерелә (реж. В.Инкинижов). 1938 елда репрессияләнә; вафатыннан соң аклана.

Әд.: Сафиуллин Ю. Атылган йолдыз // Идел. 2000. № 39; Татар драматурглары: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2007.

**РӘХМӘТ** (Рәхмәтуллин) Бари (Габделбари) Сибгатулла улы (29.5.1897, Урал губ. Гурьев өязе (хәзерге Казахстан Респ-сы Гурьев өлк.) Жилая Коса ав. — 26.5.1957, Мәскәү, Казанда җирләнгән), шагыйрь. Башлангыч белемне туган авылы мәдрәсәсендә ала. 1919 елдан Казанда: «Кызыл Армия» г-тасында әдәбият бүлеге мөдире, бер үк вакытта, «Эш», «Эшче», «Кызыл Шәрекъ» г-таларында язышa, үзенең сатирик әсәрләрен бастыра. 1921 елдан янә үзенең туган якларына кайтып китә. 1932 дән кабат Казанда, 1939 га кадәр бухгалтер булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша, «Совет сугышчысы» г-тасында хәрби корреспондент була. Балалар өчен «Кем көчле?» (1949), «Нәниләр китабы» (1953), «Ин күнелле чак» (1957; 2 басма 1997), «Сабан туенда» (1953; русчага тәрҗемәсе «На Сабантуе», 1958), «Сөенеч» (1972), «Сара мәктәпкә бара» (2007) исемле шигырь җыентыклары авторы. Р.нең шигырьләре форма җыйнаклыгы, фикер һәм хисснең балалар рухына ярашлы, табигый, эмоциональ көчле янгырашлы булулары белән аерылып торалар.

Әд.: Кукушкин Р. Канатлы дөнья. К., 1984. 94-109 б.

**РӘХМӘТУЛЛИН** Салават Ибраһим улы (1.2.1942, Башкортстан АССРның Авыргазы р-ны Солтанморат а.), шагыйрь. Эстәрлетамак пед. ин-тын тәмамлагач (1965), Авыргазы р-ны урта мәктәпләрендә укытучы һәм уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли. 1982-84 тә Гафури р-ны Аккүл авылы мәдәният йорты директоры, 1987-92 дә Эстәрлетамак шәһ. №1 интернат-мәктәбендә тәрбияче. «Әйтелмәгән әйтер һүзләрем» (Уфа, 1978), «Күперзәр» (Уфа, 1985)» «Уяну» (Уфа, 1993), «Сулар үргә акса да...» (Уфа, 2001), «Очлытауда» (Уфа, 2004) исемле җыентыклар авторы. Шигырьләре эмоциональ һәм фәлсәфи янгырашлы, гражданлык мотивлары көчле. Балалар өчен дә күп яза: «Ямгыр, яу, яу!» (Уфа, 1981), «Быйыл мәктәпкә барам!» (Уфа, 1990), «Куян ник кыска койрыклы?» (Уфа, 2001) дигән җыентыклары бар. Балаларга атап язылган шигырьләре үзләренең җыйнаклыгы, образлы теле белән аерылып тора.

Әд.: Сафуанов С. Һәр бөртеге энже булсын // Тулпар. 1995. № 5.

**РӘХМӘТУЛЛИН** Шиһабетдин Габделгазиз улы (19 йөзнең 2нче яртысы — 20 йөз башы), тәрҗемәче, нашир. Казан губерниясе Ындырчы авылында мулла булып тора. Китап һәм фольклор чыганакларыннан алып балалар өчен «Дүрт дәрвиш хикайәте» (1900), «Әбугалисина» (1902), «Малик хикайәте» (1906) һ.б. легендалар һәм тарихи риваятьләрне тәрҗемә итә һәм җайлаштыра. Мәдрәсәләр өчен «Татарчарусча перевод» (1893) исемле дәреслек авторы. 1890-1900 елларда татар телендә еллык өстәл календаре чыгара.

Әсәр.: Самоучитель татарского языка русским и русского языка татарам. К., 1918.

Әд.: Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек. К., 2001.

**РӘХМӘТУЛЛИНА** Галимә (19 йөзнең 2нче яртысы — 20 йөз башы), язучы. Дидактик эчтәлекле «Аналарга ярдәм» (1903) исемле шигырьләр, «Иҗма ишеге» (1906) исемле дидактик хикәяләр җыентыклары авторы.

**РӘШИДИ** Габделгаллəм Габделбадиг угылы (1848, Чистай өязе, хәзерге Яңа Чишмә р-ны Чертуш а. — 19.11.1923), шагыйрь. Туган авылында, Кормаш авылында, Чистайда белем ала. Соңыннан укытучылык итә. 1890 елдан туган авылында мулла булып тора. 1905 елдан башлап иген игә, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1880 еллар ахырында шигырьләр яза башлый. 1905 елдан соң басылган 50 кечкенә күләмле шигъри җыентыклар авторы. Иҗатында юк-барга ышанучылар б-н көрәш темасын күтәрә («Яңа ишан», 1910; «Җинел көн итү», 1911), татарларның көндәлек тормышын тасвирлый («Мишәр туе», 1910; «Асрау кыз нәсыйхәте», 1911), фольклор образларына мөрәҗәгать итә («Сак-Сок хәлләре», 1911; «Сөембикә», 1912) һ.б. Татар халык җырларын туплап 9

жыентык бастыра (1913 елка кадәр чыгып килгән «Хикмәтле җырлар» сериясе).

Әд.: Татар әдипләренен һәм галимнәренен кульязмалары. К., 1968.

**РӘШИТ** (Рәшитов) Әхмәт Әхәт улы (25.3.1936, Буа р-ны Яна Чәчкап а.), шагыйрь, публицист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986), ТРнын атказ. сәнгать эшлеклесе (1995). 1957-58 елларда Казакъстан-Себер тимер юлынын Семипалатинск резервында өлкән конструктор булып эшли. Казан ун-тын тәмамлагач (1960), Апас район г-тасында әдәби хезмәткәр. 1961-96 да (бүленеп) ТАССР МС каршындагы радиотапшырулар һәм телевидение к-тында (1992 дән «Татарстан» ДТРК): башта Казан телестудиясендә балалар тапшырулары мөхәррире, сонрак 1968 кадәр Лениногорск шәһәр телевидениесендә өлкән мөхәррир. 1969 дан кабат Казанда: 1974 кадәр Татарстан радиосында әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире, 1990 нан өлкән мөхәррир. 1974-75 тә «Социалистик Татарстан» г-тасы хәбәрчесе, 1976-88 дә ТАССР Язучылар берлегенен Г.Тукай клубы директоры. Р.нен беренче шигырьләре 1952 дә «Чаян» ж-лында басылып чыга. Анын көчле гражданлык мотивлары белән аерылып торган «Минем шәҗәрәм» (1970) поэмасы җәмәгатьчелекнен игътибарын җәлеп итә. Буыннар дәвамлылыгы, заманнар бәйләнешы, киләчәккә инанганлык — Р. иҗатында төп темалар. «Сөембикә» (1987), «Колшәриф» (1990), «Мөхәммәдъяр» (1996), «Без — татарлар» (2003) поэмаларында алар тарихи хәтер җирлегендә хәл ителсә, «Авылдашлар» (1972), «Варислар» (1974) поэмаларында шагыйрь игътибарны үз заманынын тормыш материалына юнәлтә. «Хатирә» ( 1972), «Сәяхәтнамә» (1978), «Киек каз юлы» (1982; русчага тәрҗемәсе «Млечный Путь», М., 1983), «Йөрәк кынгыраулары» (1986), «Давыллар кайтавазы» (1990), «Тан илчесе» (1996), «Фидаиләр»(2003) җыентыкларында Р. дөньянын гүзәллегенә, тормыш-яшәешнен мәңгелегенә дан җырлый. «Кояшлы ил — бәхет иле» (1981) җыентыгы балаларга багышланган. Анын татар халкынын милли үзаны үсеше турында бәян ителгән «Иман янартканда» (1991) исемле публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләр җыентыгы җәмәгатьчелек арасында кин янгыраш тапты. Ул — популяр җыр текстлары авторы да. Р. казакъ һәм каракалпак классиклары Абай һәм Әҗинияз әсәрләрен, хәзерге заман шагыйрьләреннән Б.Исхаков, М.Әлимбаев, Р.Әхмәтова, Н.Furthermore Бобоглу, Ж.Аймурзаев шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итә. Р.нен әсәрләре рус, укр., белорус, латыш, казакъ, чуваш телләренә тәрҗемә ителгән. ТР Язучылар берлегенен Г.Исхакый исем. пр. лауреаты (1993).

Әсәр.: Ике гасыр арасында. К., 2002.

Әд.: Галиуллин Т. Тарих мизгелләре // Казан утлары. 1997. №8; Фәйзуллин Р. Яшәүгә ышаныч // Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т. 4; Мансуров З. «Мөмкин» белән «түгел» арасы // Казан утлары. 2006. № 3.

*Г.М.Габделхакова.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*


## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге документлар булу мәҗбүри:

1. Паспорт күчерелмәсе (титул, прописка бите).
2. Дәүләт пенсия страховкасынын страховка таныклыгы күчерелмәсе.
3. ИНН күчерелмәсе.
4. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
5. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп).

Илшат
Вәлиулла

# ТӘҮБӘЛЕ ЕЛЛАР, ТӘҮБӘЛЕ ЮЛЛАР...

*Әгүүзе билләәһи минәш шәйтаани раҗиим.*
*Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.*
*Әйт: «Ул Аллаһ – бер!*
*Аллаһ – мәңге булучы.*
*Ул тудырмады да һәм тумады да.*
*һәм һичбер нәрсә дә Аңа тиң булмады.*
Корьән. «Ихлас» сүрәсе, 1-4

*Сорау туа, башта уйлар кайный:*
*Тормыш юлым үткән дип ни хакка?!*
Рәзинә Мөхияр. «Тәүбә сонеталары»

Тышта әкрен генә ап-ак кар ява... Сурәтләре бер-берсен кабатламаучы миллионлаган-миллионлаган энҗе кар бөртекләреннән торучы ап-ак кар... Әйтерсең лә, аның һәр кешенең торышына катнашы бар. Бу бераз тәүбәгә охшаган. Бу бераз истигъфарга охшаган. Әйтерсең лә, бу – Күктән иңгән изге бер хәбәр, Аллаһның тын бер кичерүе... Ә җир йөзендә яшәгән, анда азмы-күпме гомер кичергән Аллаһ бәндәсенә тәүбә итәр өчен сәбәпләр аз түгелдер ул... Юк, аз түгелдер. Аның ихлас күңелдән үкенгән һәм чистарынуга, пакълануга омтылган көннәре-төннәре дә, еллары-мизгелләре дә аз түгелдер, бәлки... Кеше күңеле еш кына пакълыкка, сафлыкка омтылып яши, гомер итә.

Ә шулай да, уйласаң, кайда соң ул Аклык, Сафлык? Мәңгелек Бәхеткә илтүче хак-пакъ, изге сукмак-юллар? Кайсы рухи юлларда-магистральләрдә калган, гомер итә, алгысына, эзләнә икән безнең күңелләр? Әллә инде алар тормыш лабиринтларында адашып калып, яки кырыс тормыш җилләре белән алып кителеп, хак юлны таба алмыйча тын гына җәфаланалар микән?

Әгәр синең күңелең беркөнне аклык-пакълык халәтен югалткан икән, адашкан икән, әгәр ул үткән көннәрнең сәер авырлыгыннан котыла алмый интегә икән, җәфалана икән, әгәр ул өр-яңадан, яңа, гүзәл, саф тормыш башларга өметләнә-хыяллана икән – синең өчен олугъ тәүбә хисе дә кирәк түгелме соң? Мөмкиндер вә, шиксез, гаҗәеп мөһимдер дә... Кешеләрнең йөрәк түрендә бит кайчак хак үкенү хисе дә ачык кабына аладыр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәт (с.г.в.) үзенең бер хәдис-шәрифендә «Гөнаһларыннан тәүбә итүче мөселман гөнаһсыз мөселман кебек», дип белдергән. Аллаһ Сөбханәкә Тәгаләгә булган тәүбә һәм тирәнтен истигъфар хисләре... Сафлану, пакълану, күңелнең чистарынуга булган эчкерсез бер олуг омтылуы... Илаһи садәлеккә, беренче кат булгандай, янә бер кат кагылырга теләү, алгысу. Тормышыңны өр-яңадан башларга омтылу, өр-яңадан Хак юл буенча, Мәңгелек Бәхеткә, Мәңгелек Сәгадәткә илтүче юл буенча яшәүгә булган изге бер ымсыну...

Әдәбиятның үзендә тәүбәгә кагылышлы юллар яна омтылыш-хыяллар белән

тулы үзгәртеп кору елларында, мәсәлән, күренекле татар шагыйре Рәдиф Гаташта, авар шагыйре Рәсүл Гамзатовта ачык күренеп киткән иде. Бу, әйтерсең лә, үзе тәүбәгә ихлас омтылган (әйтик, Архипелаг ГУЛАГлар өчен, аударылган мәчет манаралары өчен) өметле бер чор иде!.. Бу хәтта аларның шигырьләрендә дә ачык чагылды түгелме:

*Ни генә әйтмә, Гаребтән җан гарык:*
*Аннан алган калып-өслүбем ярык...*
*Шуңа гел: — Хәйям! дим; кайтам Тукайга...*
*Кайтам, димәк, үзебезгә, без – Шәрекъ!*

(Рәдиф Гаташ. «Ни генә әйтмә, Гаребтән җан гарык...»)

Яки:

*Ты прости меня, горная родина,*
*Что тебе я служил не сполна.*
*Миллионы дорог мною пройдены,*
*А нужно была только одна.*

(Рәсүл Гамзатов. «Тәүбә»)

Тарихның аерым бер борылышында күңелләр өчен өр-яңа офыклар ачылганда һәркем, чыннан да, үткәндәге кайбер гамәлләре өчен, кайбер гөнаһлары өчен үзенчә гафу үтенәдер, үзенчә нәтиҗә ясыйдыр, үзенчә киләчәккә омтыладыр һәм, шиксез, бу табигыйдер дә. Ул үзенең юл башын янә искә төшерә, саф, гөнаһсыз үткәненә кайтып килә. Һәр адәм баласы да, Коръән Кәримдә әйтелгәнчә, Галәмгә саф-пакъ йөрәк белән туа бит, тик, кызганычка, сирәкләр генә шушы пакълыкны-сафлыкны саклап кала һәм Аллаһының яхшы, игелекле әҗерен ала («Әт-Тин»). Әйе, бу тәүбә хисләре гомерләре-иҗатлары да күбрәк өлеше социализм чорында үткән олырак буын язучылар өчен булды. Мондагы кимчелекләр безгә шактый яхшы ук аңлашыла: атеизм (дәһрилек), хәбәрдарлык һәм демократия җитеп бетмәү һ.б. Әмма, әмма... Тәүбә хисе ул, әйткәнемчә, һәрвакыт яңа икән. Ул һәр кеше, һәр буын искерми, янәшә һәм янарышта кала...

Чыннан да, мәсәлән, Рәдиф Гаташ буынынан аермалы буларак, алардан яшьрәк буын шагыйрьләрдә тәүбә хисләренә кагылышлы рәвештә нindирәк уйланулар табарга булыр иде? Аларның иҗатында соңгы еллардагы чор-вәзгыятькә карата, мәсәлән, ниндирәк шигъри юллар күрә алыр идек, һәм күреп уйлана һәм фикер йөртә алыр идек икән соң? Аларның яшәешләре дә, иҗатлары да шул гаҗәеп үзгәртеп корулар, демократик җилләр исә башлаган өметле дә, катлаулы да тарихи дәвердә шәкелләште бит. «Торгынлык» еллары адәм баласын тәүбә хисенә китергән кебек, «ирекле еллар» да кешедә тәүбә хисенә булган сусауны бетерә ала димени инде?!...

Әйе, җәмгыятькә чагыштырмача ирек килде һәм бу ирек башта зур нигъмәт, бәхет сыман тоелды. Әмма, әмма... Ирек әле ул җаваплылык та икән. Ул кешенең теләсә нәрсә эшләргә хакы бар дигән сүз түгел икән. Һич юк! Бәлки без бу турыда соңрак уйланганбыздыр, фикер йөрткәнбездер. Безгә күпмедер җаваплылык та җитеп бетмәде кебек? Ирек белән кеше күпмедер сайлау алдында кала, һәм әгәр ул үзенең сайлавында Аллаһ кушкан чикләрдән чыкса, мәсәлән, хәрамга керсә (әйтик, «ярамаган», «тыелган «җимешне татыса»), авырлыклар да, михнәтләр дә кичерә ала икән, һәм, Аллаһ кушса, соңрак үзенең Хуҗасына-Аллаһка тәүбәгә дә килә ала икән...

Әйе, чыннан да, үзгәртеп корулар кыргый капитализмга таба тәгәри башлагач, җәмгыятьтә кайбер уңай үзгәрешләр булуга карамастан (шәхси ирек, милли ирек, дин иреге...), андагы күп кенә рухи кыйммәтләр әкренләп «юыла башлады» кебек, рухи тормышны тәэмин итүче рухи баганалар да берәм-берәм ава, кыйшая башлады сыман: олыларга хөрмәт, рухи чисталык-пакълык, тугрылык, үзара миһербанлылык,

шәфкатьлелек, гаделлек һ.б... Монарчы күренмәгән өр-яңа вәсвәсәләр дә барлыкка килде.

*Безгә язган ике гасырның да*
*Үзгәрешле шундый күп юллары,*
*Меңгә тармакланган зур юллары –*
*Ак-карасы ике гасырның да, –*
(«Һәрбер гасырның үзгә матурлыгы»)

дип яза үзенә генә хас фәлсәфи биеклектә уйланып, «Кем биргән соң безгә очар канат?» исемле «Тәүбә сонеталары»нда шагыйрә Рәзинә Мөхияр (Казан утлары.– 2011.– №8). Бу шагыйрә ихлас күнелдән үз дәвере турында уйлана, үз заманы чикләрендә кешенең сыналуы, тәүбәгә килү моменты, рухи чистарынуы, рухи алгарышы турында фикер йөртә; бүгенге көндә адәм баласына чын мәгънәсендә котылу, дөрес-пакъ яшәү юллары эзләп алгысына.

Рәзинә Мөхияр инде күп кенә шигырь китаплары чыгарырга өлгерсә дә («Сиңа булсын жырым», «Шәмдәлләрдә утлар», «Учларымда утлы күмер», «Алиһә», «Тыңла мине», «Нәрсә булды миңа?», «Жидегән йолдыз», «Асылыма кайтам»), чагыштырмача бик үк күзгә бәрелеп торган шагыйрә дә түгел кебек. Әмма Рәзинә Мөхиярнең «Тәүбә сонеталары» үзләренең эчкерсезлеге, тәүхиде, бөек Хакыйкатьне күнелләребезгә янә бер кат искә төшерүе, үткән чорга аек бәя бирергә тырышуы белән дә игътибарга, шиксез, лаектыр. Шагыйрә, урта буын шагыйрьләрнең бер вәкиле буларак, үз заманының аңа гына хас булган кабатланмас, үзгәрешләр тулы жанлы атмосферасы турында уйлана, фикер йөртә, тикшерә, аңларга тели, нәтиҗәләр дә ясый...

Үткәннәргә әйләнеп карасаң, чыннан да бу елларда нинди генә вакыйгалар, вәзгыятьләр булып бетмәде икән. Ирек жәмгыятебезгә, әйтерсең лә язгы ташу булып бәреп керде. Шунамы, күпмедер дәрәҗәдә иректән «исерү», «баш әйләнү», күпмедер адашулар да, саташулар да булмый калмагандыр? Без, мәсәлән, үзебез ул елларда ничек итеп чикләүләрнең бетә, югала баруын күреп тордык бит. Тик ни өчендер ул күбрәк түбән нәрсәләргә кагыла иде кебек. Ул вакытта кешеләргә акыллы киңәш, дөресрәге аларга колак салу сәләте кирәк булгандыр?! Әмма, иң мөһиме, байтак адәм баласы тәүбәле елларда тәүбәле юлларга әйләнеп кайтты түгелме?!.

Әйе, ирек ул –жаваплылык та. Син хәзер барысын да «югарыдагылар»га сылтап калдыра алмыйсың. Син инде бүгенге көндә житәрлек ирекле кебек: урамда Аллаһ биргән вак яңгыр тамчылары тамганда яки ап-ак кар тәнкәләре чайкала-чайкала төшкәндә кая таба атларга синә: Галәмнәрнең Раббысы – Аллаһ йорты – мәчеткә табамы, әллә инде түбән, шикле ләззәтләр белән кызыктыручы-чакыручы төнге клубкамы? Сиңа – үзеңнең колына Аллаһ сайлау (һәм моның өчен тулысынча җавап бирү!) хокукы да биргән икән... Беркем дә сине Күк һәм жир арасында, бүгенге жәмгыятьтә котылу яки һәлак булу юлында көчләми һәм көчләргә дә теләми кебек.

*Ак-карадан торган бу дөньяда*
*Каралмыйча ничек яшисе? –*
*Ак сыйфатлар алып яшьнисе?!. –*
*Ымсындыргыч фаллар торса алда?! –*
(«Ак-карадан торган бу дөньяда...»)

дигәндә Р.Мөхияр күп кенә замандашларының күнелләрендә, калебләрендә кайнаган каршылыклы фикерләрен әйтеп бирә кебек. Әйе, шагыйрәнең фәлсәфи-рухи сораулары юкка гына түгел! Бүген дә кеше һәрдаим олы һәм гажәеп мөһим олуг сайлау алдында тора. Дөрес, бүгенге көндә мәчет манаралары киселми, дин эзәрлекләнми, әмма төрле кызыктыручы шикле ләззәтләр адәм баласын чакырып тора...

Әйе, ирек – әле ул сынау да: Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәт кылуда; яхшылыкта, явызлыкта; хәрам белән хәләлне сайлауда. Ә бүгенге дөньяда, җәмгыятьтә чикләүләр бетү белән бергә, бозыклык, рухсызлык, жансызлык та җитәрлек көчәя төште түгелме икән?!. Сүз дә юк, кемнең вәсвәсә кылуы ачык:

*Йокламыймы шайтан дигәннәре,*
*Караны да ап-ачык күрсәтә,*
*Аклыкларга каршы әсләтә,*
*Баш өстендә оча тилгәннәре...*

(«Ак-карадан торган бу дөньяда...»)

Иблис – кешенең ачык дошманы һәм ул кеше белән атабыз Адәм гыйләһиссәлам вә анабыз Һава ризаллаһү гәнһә чорыннан башлап аны туры юлдан яздыру өчен көрәш алып бара. Ул менә, белгәнебезчә, гөнаһларны зиннәтләп күрсәтү юлы белән ирешә. Адәм баласына кылган гөнаһлары һич тә гөнаһ булып тоелмый башлый, киресенчә, хәтта гүзәл бер гамәл булып күренә ала: «Караны да ап-ачык күрсәтә...» Изге Коръәннән өзек: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. (39) Иблис әйтте:

– Раббым, мине (тугры юлдан) яздырганыңа күрә, мин дә җир йөзендәгеләргә гөнаһларын ләззәтле вә гүзәл гамәл итеп күрсәтермен һәм юлдан яздырырмын, (40) Тугры колларыңнан калган барысын да, – диде.

Шулай боерды:

– Әнә шул юл – Минем тарафка тугры юл булыр. – Шөбһәсез, колларым өстеннән синең хакимиятең юк. Азгынлыкка батканнардан тыш. Хактыр ки, җәһәннәм алар өчен корылган урын» (Коръән. «Хиҗер», 39-43).

Мәңгелек җәннәтме әллә җәһәннәмме? – бу синең турыдан-туры шәхси сайлавыңнан тора икән. Иблис вәсвәсеннән Аллаһка сыгынып кына котылып була. Галәмнәрнең Раббысы, сине юктан бар итүче бөек Аллаһ-Әл-Халикъ һич тә корабың суга батканда гына искә төшерә торган Зат түгел икән бит. Аны күпкә алданрак искә төшерергә кирәк икән. Аңа даими сыгынып, буйсынып, эшләреңне Аңа тапшырып, Аңа дога кылып, Аны һәрдаим зикер итеп яшәү гаҗәп мөһим икән.

Чыннан да, бу җиһанда бер Аллаһтан башка кем коткара ала сине, өммәтеңне, милләтеңне, илеңне? Кем? Потлармы? Бөтен Галәмдә һәм җир өстендә бары тик башы вә ахыры булмаган Бер Аллаһ-Әл-Мәлик-Әл-Әүвәл һәм башка беркем дә түгел, ләбаса. Бары тик Бер Әл-Гаффарга (Кичерүче) гына чын мәгънәсендә тәүбәгә килергә мөмкин икән. Ул гына – Рахманлы-Рәхимле – Мәңгелек Зат үз колын югары кимәлдә кичерә ала. Шуңа күрә, мәсәлән, ялган потлардан арыну һәм, әйтик, Аллаһ коллары – кешеләрдән кумир тудырудан баш тарту бик мөһимдер. (Чөнки алар да синең кебек үк кешеләр, еш кына хаталанучан Аллаһ бәндәләре... Балчыктан, судан яратылган адәм баласы Аллаһ була алмый бит.)

Бер Әл-Коддүскә (Изге, Кимчелексез) генә гыйбадәт кылып, Аңа гына дога кылырга, ялварырга вә сыгынырга кала... Котылу юлына кагылышлы рәвештә шагыйрә болай ди:

*Аллаһыдан ярый Коръән иңгән,*
*Кешелек тә шуңа бик кинәнгән,*
*Аллаһ сүзе булса иң алдан.*

*Юлым якты, күңелем тыныч утә,*
*Аллаһ сүзе булса иң алдан,*
*Каралыклар миннән читкә китә.*

(«Ак-карадан торган бу дөньяда»)

Менә кайда икән ул кеше өчен чын мәгънәсендә Котылу юлы: Аллаһ юлында

гомер итү, яшәү, Аллаһ Китабы белән тынычлык табу... Дөньяда да, Ахирәттә дә чын мәгънәсендә бәхетле булу мөмкинлеге — шушындадыр ич.

Бу — үзгәртеп кору елларының уңай ягы, гүзәл җимеше дә иде бит: дин иреге, Әл-Хактан килгән Коръән Кәрим белән таныша алу мөмкинлеге... Чыннан да, җәмгыятькә дин-ышану иреге кайтты, хакыйкать, онытыла башлаган мәңгелек изге кыйммәтләр кайтты...

Җир өстендә, без, мәсәлән, күп кенә атаклы вә хөрмәтле фәлсәфәчеләрне, галимнәрне, язучыларны беләбез. Әлхәмдүлиллаһ, алар аз түгел. Әмма... аларның язган, иҗат иткән китапларында, алар никадәр даһи, акыллы булсалар да, без, барыбер, хата тапмыйча калмас идек бит. Ә Коръән Кәримдә исә бер генә хата да юк. Ни өчен? Чөнки беренчеләрен — Аллаһ коллары язган, ә Коръән Бердәнбер Яратучыбыздан-Әл-Ваахидтан иңгән Изге Китап.

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Коръәнгә ышанмаучыларга әйт: «Беләсезме, Коръән Аллаһтан иңдерелгән булып та, соңра сез иман китермәсәгез, миңа хәбәр бирегез. Коръәннән сукыр, вә анардан ерак булган кешедән дә адашканрак вә азгынрак кеше бармы?

Безнең кодрәтебезгә, вә берлегебезгә дәләләт иткән ачык вә көчле галәмәтләребезне бөтен галәм төзелешеннән кешеләргә күрсәтербез, вә кешеләрнең яратылышы Аллаһ эше икәнлеген үзләренең төзелешеннән күрсәтербез, хәтта ачыкланганга чаклы Аллаһ Тәгаләнең хаклыгы һәм бер икәнлеге, вә Коръән Аллаһ китабы, вә Мөхәммәт (с.г.в.) Аллаһның рәсүле икәнлеге ачыклангынчыга чаклы. Яки һәрнәрсәгә шаһит булырга синең Раббың җитмимме?» (Коръән. «Фуссиләт» («Аңлатылды») сүрәсе, 52-53).

Ләкин кадерен беләбезме соң без аның — ошбу котылу юлының — котылу Китабының? Югыйсә, Коръән Кәримдә — Аллаһ Сөбханәкә Тәгаләдән килгән барлык мәҗмугалар арасында бердәнбер бозылмыйча калган ошбу Изге Җыентыкта — күңелне борчыган барлык сорауларга да ачык җавап табарга булыр иде бит!

Икенче бер шигырьдә шагыйрә уйланып болай ди:

*Тагын бер көн китә тарих төпкеленә,*
*Бүгенге көн җирдә тагынниләр булды,*
*Күпме аналарның күңелләре тулды,*
*Күпме гамәл кылдык Аллаһ хөкеменә?*

(«Тагын бер көн китә тарих төпкеленә»)

Бүгенге үзенчәлекле заманда, хәзерге катлаулы вәзгыятьтә, бүгенге үзгәреш тулы елларда «Күпме гамәл кылдык Аллаһ хөкеменә?»— дип сорый шагыйрә... Ошбу зәңгәр яки йолдызлы биек күкләр астында Аллаһ хөкеменә кылмаган гамәл бушка гына икән бит. Бушка узган көннәр, гомер, тырышу, хезмәт, яшәеш, алгысу-хисләр!.. Мөхәммәт (с.г.в.) үзенең бер хәдисендә: «Аллаһ ризалыгы өчен кылынмаган гамәл бушка булган (һәлак булган) гамәл», дигән. Яшәешнең асыл мәгънәсе дә шушындадыр ич?!.

*Яшь вакытта гомер алда кебек:*
*Вакытның да кадерләре булмый,*
*Кеше өчен әҗерләре булмый,*
*Күпме вакыт үткән чәйнәп чүбек.*
*(...)*
*Уфтанасың таудан төшкән чакта,*
*Коры җилләр булса тик кочакта:*
*Тормыш юлым үткән дип ни хакка?! –*

(«Яшь вакытта гомер алда кебек...»)

ди шагыйрә уйга калып.

Бәлки үзгәртеп кору елларында күп нәрсә алышынгандыр?!. Әйткәнебезчә, соңгы дистә еллар гына да Җиргә күпме үзгәрешләр, матавыклар алып килде һәм алып килүен дәвам итә. Бу үзгәрешле елларда уңай яклар күп булса да, әмма... кайчак Вөҗдан, Намус, Иман күпмедер чигенделәр түгелме?! Алар урынына башка

кыйммәтләр — көчләү, талау, гаделсезлек, имансызлык та урын алырга тырышты түгелме?! Җәмгыятьтә женси азгынлык, бозыклык та көчәя төште түгелме?! (Хатын-кыз гаурәтен күрсәтеп йөрү кебек бозыклык таралды. Хәтта гомосексуализм кебек Аллаһы Тәгаләгә, сәламәт акылга, табигатькә каршы килүче күренеш тарала башлады. Аллаһы Тәгалә андый бозыклык кылучыларны (Лут кавемен), хәтта Бер Аллаһка ышанырга чакыруны да кирәк тапмаган). Әмма бит чыгу юлы да, һичшиксез, бар. Җәмгыять гел сәламәт булмаган атмосферада яши алмыйдыр?!.

Менә икенче бер шигырьдә мондый юлларга очрыйбыз:

*Яманлыклар, яман бер чир кебек,*
*Бик тиз йога, кирәкми тырышу.*
*Яхшылыкка кирәк әле тырмашу,*
*Күңелләрне пакълик без иң элек.*

(« Хәерлегә юрыйк бар эшләрне»)

Чыннан да, кеше күнеленә «яманлыклар бик тиз йога икән...»(Аллаһ Коръәндә кат-кат әйткәнчә, инсан өчен ан уяулыгы да бик мөһим.) Хәер, элек-электән хәмер һәм женси азгынлык халыкларны, милләтләрне юкка чыгару коралы булып саналган. (Мәсәлән, хәмер аркасында авырлыклар күргән Себер халыкларын искә төшерик.) Безгә үз динебезгә, борынгы рухи традицияләребезгә тугры калу мөһим икән. Ятларга иярү безнен өчен хәвефле. Бары тик Аллаһ чакырган туры юлга, һидаят юлына тугры калганда гына безне матур киләчәк көтә икән — шагыйрә шул турыда әйтергә тели түгелме?!. Замандашларын борчыган сорауларга ул түбәндәгечә җавап бирә:

*Изге эшләр белән күңелләрне пакълик,*
*Әхлаклылык, иман нурын яклыйк!*
*Яшәүләре булыр бит тынычрак.*

(«Хәерлегә юрыйк бар эшләрне...»)

Изге эшләр, әхлаклылык, иман нуры... — егерме беренче гасыр башында татар шагыйрәсе чакырган изге кыйммәтләр. Алар мең яки ике мең ел элек кебек актуаль, чөнки адәм баласы һәрвакыт искә төшерүгә мохтаҗ, диелә дини китапларда...

Әйе, безгә һәрбер чорда да, һәрбер заманда да соралган рухи үсеш, рухи алгарыш турында онытмаска, шиксез, кирәктер. Ә шулай да шагыйрә, үткән елларга әйләнеп карап, эчке бер тынычлык-ныклык тоя.

*Авыр булса булды күчешләре,*
*Җәмгыятьнең кискен кичешләре:*
*Безне нидер тотып торды кебек.*

*Читтән чиккә артык ташланмадык,*
*Безне нидер тотып торды кебек,*
*Шөкер, Аллаһ безне ташламады, –*

(«Һәрбер чорнын үзгә матурлыгы»)

ди ул үткәндәге ирек тә, сыналулар да алып килгән үзгәрешле елларга бер нәтиҗә ясап.

Димәк, Аллаһка ышаныч, Анын барлыгын тою да безне яклаган, саклаган икән. Үткәннәргә тыныч күңел белән әйләнеп карый алу инсан өчен ул үзе чын мәгънәсендә зур бәхет түгелмени?!.. Шагыйрә Рәзинә Мөхияр үзенен «Тәүбә сонеталары»нда гомумкешелек кыйммәтләрен раслый:

*Коръән барыр юлда маяк булса,*
*(Иманыңа кайту – ул зур җиңү)*
*Кеше дигән сүзгә лаек булсаң.*

(«Шайтан кер тәрле кыяфәткә»)

* * *

Соңгы елларда олы һәм урта буын гына түгел, ә әдәбиятка соңрак килгән яшьрәк буын шагыйрь һәм шагыйрәләре дә югарыда телгә алынган кыйммәтләр турында ешрак уйланырга мәҗбүр кебек. Мәсәлән, Р.Майорова, Л.Фәтхетдинова, Ф.Гыйләҗев, Э.Авзалова, Р.Сәлах һ.б. Болар бит аеруча сикәлтәле елларда үскән, формалашкан буын. Әйе, алар ирекле елларда үстеләр, шәкелләштеләр, әмма, бу ирекле елларның икенче ягы да бар иде бит... Шулай да, монда уңай яклар да ачык күзгә ташлана. Чөнки бу елларда рухи эзләнүләргә, рухи үсешкә өр-яңа мөмкинлекләр ачылды!..

Чыннан да, кешенең ихлас рухи эзләнүләре, рухи алгысулары, дөреслекне кабат-кабат эзләп табарга тырышулары (мәсәлән, экстенциализм, феноменология, детерминизм кебек кешеләр уйлап чыгарган фәлсәфәләр белән мавыгулар һ.б.) Аллаһ, дин, хакыйкать темасына китерми кала алмыйдыр. Әле XX йөзнең 90 нчы елларында япь-яшь шагыйрә (12 яшьлек!) Энже Авзалова ихлас күңелдән болай дип язган иде:

*Күзләремне төбим мәчетләргә,*
*Күңелемдә дога юллары.*
*Адашмаска тормыш сазлыгында,*
*Бир, Ходаем, иман нурлары.*

(«Авылымда мәчет янара»)

Яки:

*Газиз Аллам, нурларыңны*
*Кабул итсә һәрбер кеше –*
*Танымаслык булыр иде*
*Бу җир өсте.*
*(...)*
*Җир өстенә бәхет китер,*
*Иман китер, газиз Аллам.*

(«Күңелемдә иман нуры»)

Шагыйрәнең әдәбиятка бераз соңрак килгән яшьрәк замандашлары да асыл, төп Хакыйкатькә кагылышлы рәвештә уйланалар, үзләренә генә хас булган фәлсәфи биеклектән торып, үзләренчә фикер йөртергә омтылалар. Әйтик, яшьрәк шагыйрәбез Рәмилә Майорова бер шигырендә фәлсәфи уйланып олы нәтиҗәләр ясарга ашкына:

*Адым саен кисешә юл,*
*Адым саен бер сорау.*
*Һәр мизгел – Аллаһ рәхмәте,*
*Һәр мизгел – олы сынау...*

(«Адым саен кисешә юл...»)

Олы сынау... Сүз дә юк, яшьрәк буынның үз яшәешен Аллаһ Сынавы икәнен аңлау гаҗәеп мөһимдер. Бәлки, ул аларны бу катлаулы вәзгыятьтә кайбер ялгыш адымнар ясаудан саклап калыр, туры, хак юлдан тайпылудан коткарыр?!.

Дин темасына еш мөрәҗәгать итүче яшь шагыйрь Рифат Сәлах исә «Үләндәге чык» шигырендә кешенең Аллаһка гыйбадәтен образлы итеп сурәтли:

*Иртәнге намазга азан*
*Ишетелде таң белән.*
*Гыйбадәт, дога, күз яше –*
*Уянгандыр һәр үлән.*

*Тәһарәт алып кайтканда*
*Кала тик эзе генә.*
*Үз гыйбадәте янында*
*Һәркем дә үзе генә!*

Шигырьнең соңгы ике юлында, мөгаен, адәм баласының Аллаһ Тәгалә алдындагы ихласлыгы, эчкерсезлеге, җаваплылыгы турында сүз барадыр...

Әдәбиятта, мәдәнияттә киләчәккә таба дини мотивлар көчәя төшәр, күрәсең. Чөнки берданбер Хакыйкать кешегә якын, тансык икән. Кеше чагыштырмача, ялганга корылган, фундаменты комнан торган, тыштан матур, әмма эчтән черек хакыйкатьләр белән яши алмый икән. Ул Җәллали әл-Икрамга – Бөеклек, Камиллек вә Хөрмәтлелек Иясенә юл эзли, Аның кушканнарына колак сала. Чөнки Галәмнәр Раббысы кушканча яшәмәү бу дөньяда да, Ахирәттә дә бәхет китерә аламы соң?!..

Әйе, дин-ышанунын югары роле бәхәссез икән. Әйтик, үткән елларда татар халкының әйдаманнары булып еш кына язучылар, әдипләр, вакыт-вакыт сәясәтчеләр дә торды. (Мин әле шундый заманнарны хәтерлим: әгәр татар язучылары чакырса, урамнарга дистә меңләгән, ә бәлки, аннан да күбрәк халык чыгарга әзер иде.) Киләчәктә исә бу рольне инде имамнар, хәзрәтләр үтәр диган фикер дә бар. Ислам адәм баласын үз барлыгын тәэмин итеп торучы Дөреслеккә кайтарырга тели бит...

Дөрес, дини мотивлар белән бәйле шигырьләргә тирәнлек, фәлсәфилек, кинлек, тормышчанлык та житеп бетми кебек әле. Хәер, монда кайбер чыгармалар да бар. Мәсәлән, Габделнур Сәлимнең фәлсәфи эчтәлекле иҗаты – шуңа ачык мисал. Анарда тирәнтен язылган дини-фәлсәфи шигырьләрне күпләп табарга булыр иде. («Итәгать» китабы үзе ни тора.) Бу үзе, мөгаен, зур әдәби байлыгыбыздыр.

*...Аллам, дигәч, йөрәк китте*
*Төенчектәй чишелеп...*

*Сыйлансын ил! – Тоям илнең*
*Көйсезлектән көйгәнен.*
*Буш кул белән килмәдем ич:*
*Төенчектер – йөрәгем.*

(«Төенчек»)

Бу әле өйрәнелмәгән дөнья. Монда күбрәк декларация, дидактика хөкем сөрә кебек. Бездә Ислам дине белән бәйле әдәбият, мәдәният зур үсеш алмаган кебек әле. Әйтик, күршеләребез урысларда христианлык (носаралык) белән бәйле урыс әдәбияты гаҗәеп көчле (Л.Толстой, Ф.Достоевский). Урыс фәлсәфәчеләрендә дә (С.Соловьев), рәссамнар иҗатында да (М.Нестеров), фәлсәфи эчтәлекле нәфис фильмнарда да («Андрей Рублев») чагыла бу.

Без исә күтәрелеп кенә киләбез кебек. Күрәсең, бу якын-ерак киләчәк эшедер. Киләчәктә Аллаһ юлында эзләнүләр белән тулы, дини мотивлар белән сугарылган шигырьләрдә, проза, драма әсәрләрендә тирәнлек, фәлсәфилек, тормышчанлык шактый үсә төшәр дип уйларга ышаныч бар сыман.

* * *

...Тышта югарыдан әкрен генә явучы ап-ак кар кешеләрне тәүбәгә, пакълыкка чакыра төсле. Күңелләрнең чистарынуына, җаннарның сафлануына, рухларның уянуына... (Ап-ак кар, җирдәге чәчәкләр төсле үк, җиргә Күк энергиясен алып килә дип ишеткәнем дә бар.)

Тәүбәле елларда тәүбә юлларында кемне генә очратмассың икән син?! Күп алар. Тормышларын ашыгып яки сабыр гына төзәтергә омтылучылар, үткәндәге кайбер гамәлләре өчен хак үкенүчеләр, юлларын яктырак тарафка борырга омтылучылар,

ниһаять, хакыйкый кыйблаларын табарга, ачыкларга вә аңларга тырышучылар... Пәйгамбәребез Мөхәммәт (с.г.в.) көненә 70 (ә кайбер мәгълүматлар буенча 100) мәртәбә тәүбә иткән диләр, димәк, бу (тәүбәгә мохтаҗлык) һәр инсанга киләдер.

Гомумән, адәм баласының үткән гөнаһлары өчен тәүбәгә килергә омтылуы мөһим. Бик мөһим. Шуннан башка өр-яңа тормышка атлау мөмкинме икән ул?! Мөмкинме икән соң янәдән сафлыкка, пакълыкка кагыла алу?!... Янә бер кат саф мәхәббәткә, саф бәхеткә чын мәгънәсендә кагыла алу?!... Аллаһка, Хакыйкатькә таба чын мәгънәсендә житди тормыш башлый алу... Иң мөһиме: шиксез киләчәк Кыямәт Көнендә гамәл дәфтәренне уң яктан ала алу бәхетенә ирешү?!

Мәкаләне Рәзинә Мөхиярнең «Тәүбә сонеталары»ндагы замандашларына юнәлдерелгән түбәндәге шигъри юллар белән тәмамлыйсы килә:

*Савапларны күбрәк эшли алсак,*
*Яшәүләре булыр бит тынычрак.*
*Җир йөзеннән юылыр кер-пычрак.*

(«Хәерлегә юрыйк бар эшләрне...»)

Яки

*Уйландыра бик еш кайтып кабат-кабат,*
*Барысы өчен килер җавап тотар бер көн.*
*Кем бирер соң шунда безгә очар канат?!*

(«Тагын бер көн китә тарих төпкеленә»)

---

## Электрон почта да төпсез түгел

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар исә, жинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

**Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.**

**Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар жибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.**

Габдулла
Галиев

# ЙӨРӘК ЯРАСЫ

Тук...Тук...Өй алды ягыннан ишетелгән шул тавышка Камәрия карчык сискәнеп күзен ачты. Чү, кемдер шакый түгелме соң? Шакый бугай шул. Ул мендәрдән башын күтәреп, сагаеп кына пәрдә арасыннан тәрәзәгә күз төшерде.

Тышта — дөм караңгы, өстәвенә көзге җил исә, урам як бакчадагы чаган агачының коелып бетмәгән яфраклары карчыкның күнеленә хәвефле хәбәр салган төсле лепелдәшәләр иде.

Камәрия карчыкның йөрәге сулкылдап куйды. И-и, бу ялгыз яшәүче карчыкларның хәлләре! Башкаеңны кая куярга белмичә үткән көннәр. Куркудан һәр шомлы тавышка дерт-мерт килеп, йоклый алмый таң сызылганын гаҗизләнеп көтеп алган көзге озын төннәр... Ялгызлар хәлен ялгыз гомер кичерүче генә аңлыйдыр шул.

Тукылдау кабатланмагач, карчык тынычланган сыман булды да, яңадан урынына ятты. Әмма башы мендәргә тию белән теге тавыш яңадан кабатланды.

«Башка нәрсә булмас, хәерсез җил өй алды түбәсенең купкан тактасы белән шаярадыр, иртән берәр ир-атка әйтеп кактырып куярга кирәк булыр», — диде ул, үз алдына сөйләнеп.

Тук... Тук... Бу юлы тавыш ачыграк ишетелде, инде икеләнергә урын калмады.

Камәрия карчык урыныннан торып ут кабызды да стенадагы сәгатькә күз төшерде. Төнге бер тулып килә иде. «И Ходаем, үзең саклый күр, төн уртасында кайсысы йөри икән? Әллә күрше-күләнгә берәр хәл булдымы? Менә бит, гөнаһ шомлыгы, саңгырау колагым белән күпме вакыт ачмыйча тордым. И-и, бу картлык...

Әнә шулай сөйләнеп аягын кыштыр-кыштыр сөйрәп барган жиреннән ул кинәт туктап калды. Шәһәрдәге кызы Нәгыймәнең: «Кара аны, әнкәй, төннәрен ишегеңне ача күрмә. Әнә телевизордан ялгыз карт-корыны талап-үтереп чыкканнарын күрсәтеп кенә торалар», — дигән сүзе кылт итеп исенә төште. Шулай нишләргә белмичә икеләнеп торганда шакылдау тагын кабатланды. Юк, юк, ачмыйча ярамас. Кем белгән, берәрсе бик кирәккә шакыйдыр. Камәрия карчык күнелендәге шик-шөбһәсен җиңеп, өй алдындагы лампочканы кабызды да, йорт ишеген бераз кысыбрак ачып, калтыранган тавышын күтәребрәк, каушавын яшерергә тырышып, «Кайсыгыз ул? Кем шакый анда?» — дип сорады.

Тыштан, өй алды баскычында бераз таптанып алганнан соң: «Мин әле бу, оныгың Эдик», — дигән тавыш ишетелде.

— Идик?! Әстәгъфирулла, бу караңгы төндә нишләп йөрисең, балакаем? И Раббем, үзең сакла... Әллә берәр хәл булдымы?

— Кергәч сөйләшербез. Салкын монда, өшетә, тизрәк ач ишекне! — Камәрия карчык өй алды баскычыннан төште дә, ишек бигән шалтыратып ачып оныгын эчкә үткәрде.

— Озаграк тоттым бугай. Колагым начар ишетә хәзер, катырак шакырга иде, — диде ул оныгы артыннан атлап.

— Катырак ярамый. Күршеләр уянмасын дидем.

Әби белән онык кочаклашып күрештеләр. Эдик танымаслык булып үзгәргән, ябыгудан янак сөякләре калкып чыккан, шешенке күз төпләре җыерчыкланып эчкә баткан, йөзен шалашта качып яткан кешенеке кебек сакал-мыек баскан. Өстендә нык кына таушалган кәчтүм, якасы керләнеп каткан күлмәк. Оныгын шул хәлдә күргәч, карчыкның эче жу итеп китте, борчылуы йөзенә бәреп чыкты.

Камәрия карчык барысын да аңлады. Буыннары хәлсезләнгәнен тоеп, уфылдап, лып итеп урындыкка утырды.

— И бала... Тагын инәгә утырдыңмыни?

Эдик әбисенен үзенә төбәлгән карашын күтәрә алмыйча башын читкә борды, елап җибәрүдән үзен көч-хәл белән тыеп:

— Ялгыштым ... Тагын ялгыштым шул, әбей.

Әмма Эдик әбисенә элекке наркоман әшнәләренең аны күптән аулап йөрүләрен һәм бер кичне караңгы подвалга алып кереп кыйный-кыйный тәненә героин кадауларын яшерде, әйтмәде.

Камәрия карчыкның бу арада болай да сыкрап торган йөрәге өздереп чәнчеп алды.

— И бала, булсаң да булырсың икән. Әтиең сине шул каһәр афәттән йолкып алу өчен ниләр генә эшләмәде, күпме акча түкте. Әле дә бурычын түләп бетерә алмагандыр. Уф, инде син янадан...

Эдик куллары белән башын тотты:

— Әбей, житәр! Кирәкми!

— Шулай инде ул, беркемнең дә үз ялгышы турында ишетәсе килми. Әтиең дә туган нигезенә юлны онытты. «Ана күңеле балада, бала күңеле далада», — дип юкка гына әйтмиләрдер. Көн туган саен аны көтәм. Күзем гел юлда була. Үзләре ни хәлдә сон?

— Белмим.

— Ничек инде белмисең?

— Мин алар белән тормыйм бит. Йортларыннан кудылар мине, — диде оныкь. Аннан ачынып: — Понимаешь, үз балаларыннан туйдылар! – диде.

— Акча сорап җәфалагансыңдыр. Күпме түзәргә була. Аларны да аңларга кирәк, бала.

— Аңларга? Ә мине, бәхетсез бер наркоманны, кем аңлый? Әйт, бармы аңлаучы? — Эдик сулкылдап елый башлады. Янына килеп кочып алган әбисенең инбашына башын салды. Күңеле тулып елый башлаган Камәрия карчык та яулык очы белән күз яшен сөртеп-сөртеп алды:

— Йә, йә, тынычлан, улым. Бар ул сине аңлаучы кеше. Мин бар!

— Син генә шул. Шуңа сиңа ышанып кайттым да мин. Их, әбей!

— Уф, тәмам башым катты. Әйдә, чишен. Хәзер урын җәеп бирәм. Тукта, баштa чәй эчеп ал.

Эдик чәйнек күтәреп кече якка барган әбисен туктатты:

— Кирәкми чәй, хәзер китәм мин.

— Китмисең. Беркая да җибәрмим. Калганын иртәгә сөйләшербез.

— Кала алмыйм. Мин бик ашыгам. Сиңа зур үтенеч белән кайттым. Миңа акча кирәк. Бик күп акча!

Камәрия карчык сораулы караш белән оныгына текәлде.

— Күп акча?

— Әйе, эшләр начар минем, әбей, до ушей бурычка баттым мин.

— И, Ходаем, ярдәм ит. Күңелем сизенә, шул прашуклар, укуллар өченме?

— Әйе.

Эдик унайсызланудан кызарып башын түбән иде. Камәрия карчык урыныннан торып, ишекле-түрле йөреп килде дә, оныгы каршына туктап, йөрәгеннән ташып чыккан сыкрау белән әйтте:

— Бала! Бигрәк балда-майда гына йөзеп үстен шул син. Студен булганчы гел әниең Мариянең итәге янында булдың. Сүз әйттермәде ул сиңа. Мин синең инәгә утырганыңны ишетеп әйткәч тә: «Булмас, минем бердән-бер улыма яла якма!», — дип җикеренде. Шулай һәрвакыт... баласын яклаган ана арыслан кебек, ырылдап каршы төште. Инде әнә нәтиҗәсе... Башкайларыбызның хәсрәттән чыгасы юк икән. И бала, бала ...

— Кирәкми. Җаныңны сызландырма, әбей. Үкенүдән хәзер файда юк. Соң инде. Алар авыл башындагы каенлыкта көтеп калдылар. Акча бир миңа! Тизрәк илтеп тапшырыйм. Алар көттергәнне яратмыйлар.

Камәрия карчык бөтенләй коелып төште. Бер утырды, бер басты. Аннан кинәт, зур ачыш ясагандай елмаеп, тантана белән:

— Таптым! — диде.

— Таптың? — бер мәлгә Эдикнең да йөзе ачылып киткәндәй булды. Ашыгып сорады:

— Ничек?

— Хәзер үк милициягә хәбәр итик, улым. Эләктереп алсыннар мәлгуньнәрне. Бирәсе бурычыңнан да, үзләреннән дә котылырсың.

Эдик янә күңелсезләнде.

— Юк. Ул юл белән булмый. Алар милициядән курыкмыйлар. Кичтән тотсалар, иртән чыгарачаклар. Ә мине көнендә үк юк итәчәкләр.

Эдикның кесәсендә телефон шалтырады. — Алар бу! Ашыктыралар. Бөтен ышанычым синдә генә, әбей, тизрәк акча тап.

— Кайдан гына табыйм соң ?

— Синдә бар ул.

— Каян булсын инде барлы-юклы пенсиягә яшәгән әбиендә. — Эдик әбисенең муенына сарылды.

— Сытачаклар бит алар мине. Кызган оныгыңны, әбей. Бөтен өметем синдә генә...

— Уф... Менә агай, ә? Үлемтегемә җыйган акчамны бирсәм генә инде. — Камәрия карчык почмактагы сандыгын идән уртасына тартып чыгарып капкачын ачты, калтыранган куллары белән кәфенлеге арасыннан бер төргәк алып сүтте:

— Менә, ун мең. Шуның биш мененен ал.

Эдик акчага карап көрсенде.

— Биш мең? Бик аз бит бу.

— Аз? Бурычың шулай бик күпмени соң? И бала...

— Әйтеп торам бит. Миңа бик күп акча кирәк.

— И Раббем?! Нишлик соң? Булмаса нит, ун менен дә ал. Хәзер житәдер бит инде?

— Юк, житми.

— Булганы шул. Бүтән табар бер генә тиенем дә юк.

— Бар. Синдә мине бурычтан коткарырлык акча бар.

— Әстәгъфирулла! Кайда соң ул? Әйт, кайда?

— Миңа сандыгың төбендә саклана торган асылташлар белән бизәлгән муенсаны бир.

Камәрия карчык бер сандыкка, бер Эдикка карады.

— Муенсаны? — Тәмам гаҗәпләнеп: — Андый муенса барын син каян белдең?

— Малай вакытымда җәйге каникулга кайткач, син сандыгыңны актарганда күрдем. Ул хәзер дә шунда булырга тиеш. Кая әле ...

Эдик сандык төбен актарып, муенсаны тартып чыгарды.

— Менә! Менә ул! — Муенсаны куллары белән сыйпап. — Мине коткаручы хәзинә! Әбей, бир аны мина!

— Юк, сорама. Мин ул муенсаны беркемгә дә бирә алмыйм.

Эдикның күзе усалланып ялтырады, тупас тавыш белән:

— Ник? – диде.

Камәрия карчык муенсаны Эдикның кулыннан кире тартып алды.

— Сатыла тоган хәзинә түгел ул. Хатын-кыз нәселебездән күчеп бара торган мирас. Мина аны әбием бүләк итеп калдырды. Ә мин аны синең сеңелкәшең Идилиягә тапшырачакмын.

— Эделиягә? Син нәрсә, әбей!.. Шул шлюхагамы?

— Тукта! Сеңлең турында шундый сүз сөйләргә ничек телең бара?

— Син бит әле белмисең. Эделия бозык компаниягә иярде, әллә кайларда йөри. Муенсанны ул барыбер сатып җибәрәчәк.

Камәрия карчыкның бу хәбәрдән болай да кечкенә, җыйнак гәүдәсе тагын да кечерәеп калгандай булды. Бөтен тәнен хәлсезлек биләп алды.

— Уф, йөрәгем! Инде сеңелкәшең дә синең юлыңнан киттемени? Тагынниләр күрәсебез бар икән? И Раббем, нәрсә карый бу Ил! Аның да балалары бит сез, кара гүрләргә кертәсез бит инде.

— Әбей, менә бурычымны гына түлим дә, алар белән арамны өзәм. Кабат университетка кайтам. Житте! Мина да кешеләр кебек яши башларга вакыт.

— Бик вакыт. И, бала, ышанулары бик авыр шул сина. Теге юлы да елый-елый ант иткән идең дә ...

Эдик кесәсендә аваз салган телефонын колагына куйды. — Хәзер, хәзер килеп житәм. — Әбей, муенсанны бир, китәм мин.

— Муенсага кагылма, бирмим.

— Мине агачка бәйләп терелэй яндырып үтерүләрен телисеңмени? Китер монда. — Әбисенең кулыннан муенсаны тартып алып, ачу белән әйтте: — Алар килеп өенә ут төртергә дә күп сорамаслар, көл генә өелеп калыр.

Йортта киеренке тынлык урнашты. Камәрия карчыкның күзе яшь белән тулды. Ул елый иде.

— Акчаның биш менен булса да калдыр, бу арада хәлем китеп тора. Үләрмен инде мин, озак тормам.

— Ничава, үлмәссең әле, — диде Эдик, авыз эченнән генә мыгырданып.

— Улым, — диде Камәрия карчык, оныгына яшьле күзе белән мөлдерәп карап: — Тәнемне туфракка хәер-садакасыз гына индерерсез микәнни?

— Эбей! Давай ул турыда сөйләшмик. Прости. Мин ашыгам. Пока! Телэгенә ирешкән Эдикның тавышында тартыну да, үкенү дә юк иде.

Шапылдап өй ишеге ябылгач, йорт эче тынлыкка чумды. Камәрия карчык кыйблага карап тезләнде: «Йә Раббем, гөнаһларыбыз өчен күрәбез бу газапларны. Йә бер Аллаһым, кичер!!! Аталарын өйләндердем, никах укылмады. Балалары туды. Мулла чакырып, Алланы исеме белән азан әйтеп, камә төшереп исем куштырмадык. Исемнәре дә үзебезчә түгел бит аларның Идик, Идилия. Әти-әниләре акча колына әйләнделәр, балаларын онытттылар, акчадан башка күзләренә берни дә күренми. Үзем дә сәждәгә соң бастым. Догасыз елларда, заман шаукымына бирелеп яшәдем. Балаларыма вакытында дөрес тәрбия бирә алмадым. Аларның афәткә төшүләренә үзем гаепле. Барысына да бик үкенәм. Балаларыма, оныкларыма тугры юлга басарга ярдәм ит, Раббем! Гафурын рә ... хим ...

Камәрия карчык кинәт хәлсезләнеп китте. Йөрәген тотып, тезләнгән жирендә авып төште.

# ЯКТЫ ЮЛ

РИЗА ИШМОРАТНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Матур әдәбият әсәрләрендә язучы үзенең дөньяга карашын, тормыш-яшәешне аңлавын, чор куйган сорауларга җавап эзләвен чагылдыра. Аның әлеге эзләнүләренә нинди шартларда үсүе, белем алуы, әйләнә-тирә мохит һәм, билгеле инде, ул яшәгән заман, анда өстенлек иткән идеологик карашлар, рухи һәм матди кыйммәтләргә мөнәсәбәт зур йогынты ясый. Бу фикерләр тулысы белән татар драматургиясе тарихында лаеклы урыны булган Риза ага Ишморатның шәхесенә һәм иҗатына да карый. Аның әдәби, публицистик һәм театр сәнгате белән бәйле эшчәнлеге ул яшәгән XX гасырның давыллы еллары, каршылыклары белән сугарылган.



Риза Фәхретдин улы Ишморатов (Риза Ишморат) 1903 елның 1 ноябрендә хәзерге Башкортостанның Янавыл районы Бәдрәш авылында туып үсә. Әтисе иген игеп, хәлфәлек итеп, соңрак күрше авылда указлы мулла булып торса да, гомеренең ахырында хәзерге Татарстанның Актаныш районы Уразай авылына күчеп кайта һәм крестьян хезмәте белән шөгыльләнә. Әтисеннән укырга-язарга өйрәнгән Риза үз төбәкләрендәге кечерәк мәдрәсәдә, рус-татар мәктәбендә белем алганнан соң, Минзәләдә һәм Уфадагы «Госмания» мәдрәсәләрендә укый. Ә инде 1921 елны Уфада укытучылар әзерли торган курсны тәмамлап, башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли башлый. Шулай да аның күңеле татар дөньясының мәркәзе булган Казанга тартыла һәм 1923 елдан башлап тормышы Казан белән бәйле була. Театр техникумын тәмамлагач, әдәбият-сәнгать дөньясына ашкынып торган егетне Татар дәүләт театрына режиссер итеп билгелиләр. Шул елларда ул Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев кебек шәхесләр белән якыннан аралаша, үзенең беренче иҗат тәҗрибәләрен ясый. Яшь автор «Йокы патшалыгында» (1926), «Өтек философ» (1926) комедияләрен яза һәм аларны үзе үк сәхнәләштерә дә. Билгеле, әлеге әсәрләр яңалык белән аерылып тормый. Р.Ишморат заман рухында иҗат итеп, беренче әсәрендә чит илгә күчеп китәргә мәҗбүр булган эмигрантлардан көлә, ә икенчесендә Яңа икътисади сәясәт (НЭП) шартларында үз эшләрен башлап җибәрергә омтылучыларны спекулянтлар, искелеккә ябышып ятучылар буларак фаш итә. Пьесаларга схематизм хас булып, аларның идеологик фикерне укучы-тамашачыга җиткерү бурычын берьяклы гына башкаруын да әйтеп үтәргә мөмкин.

Риза Ишморат, театр сәнгате өлкәсендә белемен күтәрү максатында, 1927-1930 елларда Ленинград Сәнгать тарихы институты каршындагы Югары театр сәнгате курсларында укый. Казанга кайткач, төрле җаваплы вазифалар башкара. XX гасырның 30 еллары тарихка гаять катлаулы, каршылыклы булуы белән кереп калды. Илдәге сәяси хәлләр Р.Ишморатны да читләтеп үтми. Бу чорда ул Татар дәүләт театрының режиссерлар коллегиясен җитәкли, репертуарны заман рухында

язылган пьесалар белән тулыландыруга зур көч куя. Билгеле булганча, 1937 елны Кәрим Тинчурин «халык дошманы» дигән нахак гаеп белән кулга алына. Баш режиссер вазифасын башкарган Р.Ишморат «халык дошманы»ның әсәрләрен сайлап алуда, сәхнәдә куюда «сукырлыгы» өчен партия сафларыннан чыгарыла. Кәрим Тинчурин турындагы «Соңгы очрашулар» истәлегендә әдип болай дип яза: «Озак та үтмәде, татар театр сәнгате өлкәсендә контрреволюцион тинчуринщинаны гамәлгә ашыручы халык дошманы саналып, партия өлкә комитетыннан килгән Камай Кәримовның актив катнашуы белән, мине дә партия сафыннан, шулай ук театрдан да чыгардылар».

Әнә шундый борчу-каршылыклар булуга карамастан, Р.Ишморат шактый актив иҗат итә. Бер-бер артлы «Данлы чор» («Мәдинә», 1930), «Тургай» (К.Тинчурин белән берлектә, 1932), «Ил өчен» (1936), «Ватан» (1938) «Гөлзадә» (1940) кебек пьесалары языла, сәхнәгә куела. Әлеге әсәрләр утызынчы елларда әдәбиятның торышын күзалларга ярдәм итә. Үзәктә социалистик хезмәт, кешенең үз-үзен табуы, аның әхлакый йөзе кебек мәсьәләләр тора. Автор яна җәмгыять, аның кешеләре тормышы турында уйлана, байтак сорауларга җавабы булмаса да, яңа заман кешесе формалашу күренешен алга куя, укучы-тамашачысы белән бергә уйлана. Дөрес, әлеге пьесалар бүгенге укучыда зур кызыксыну тудырмый, әмма аларның кыйммәте чор рухын, кешеләренең әдәби образларын тарихта калдыру белән бәйле. Бу яктан караганда, драматургның Мәдинә һәм Гөлзадә (шул исемдәге әсәрләре геройлары) кебек образлары аеруча игътибарга лаек. Автор сыйнфыйлыкны калкытып куюдан, схемачылыктан арына алмаган, әмма әлеге хатын-кызлар әхлакый йөзләре, татар хатын-кызының актив эшчәнлеккә, көрәшкә килүен күрсәтү ягыннан укучы күңелендә урын ала.

Р.Ишморат Бөек Ватан сугышының икенче елында үзе теләп фронтка китә. Беренче Украина фронтында татар телендә чыккан «Ватан намусы өчен» газетасында хәрби журналист булып хезмәт итә. Аңа еш кына алгы сызыкта булырга туры килә. Сугышчан бурычны уңышлы үтәгәне өчен Кызыл Йолдыз һәм Икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр белән бүләкләнә. Майор Р.Ишморат сугышны Берлинда тәмамлый. Аның фронтка киткәнче иҗат ителгән «Кайту» (1942) драмасы сугыш чоры татар драматургиясенең иң уңышлы әсәрләреннән берсе була. Әлеге драма, М.Әмирнең «Миңлекамал»ы (1944) кебек, бу елларда сәхнәләрдән төшми уйнала. Колхоз рәисе булып эшләүче Мөршидә һәм аның фронттан авыр яраланып каткан ире Хәмит мөнәсәбәтләренә бәйле, автор мең мәшәкать белән тулы сугыш чорын, татар авылын, халыкның чын мәгънәсендәге батырлыгын күз алдына бастыра.

Сугыштан соңгы елларда Р.Ишморат совет кешеләренең рухи матурлыгын чагылдырган һәм тормыштагы ямьсез күренешләрне фаш иткән пьесаларын яза: «Якты юл» (1947), «Якын дус» (1949), «Бистә кызы Гөлсинә» (1952), «Иске дуслар» (1957) драмалары һәм «Шайтан таягы» (1954), «Серле моң» (1959), «Шаулыйлар дулкыннар» (1964) комедияләре. Иң яхшы әсәрләрендә драматург, алдагы чор иҗатына тугры калып, социалистик хезмәт һәм шул шартларда чын шәхес булып үсүче, тормышта үз урынын табучы, киләчәккә өмет белән карауч кешеләрне үзәккә ала. Р.Ишморат аеруча яратып хатын-кыз образларын иҗат итә. Гомумән, алар әдип иҗатында үзгә урын алып тора. Нәкъ менә хатын-кыз эш-гамәленә бәйле совет җәмгыятенә мәдхия укыла, аның рухи һәм матди кыйммәтләре яклана һәм мактала. Автор хатын-кыз образларын үсеш-үзгәрештә сурәтләве белән уңышлы характерлар тудыра. Алар матур хыяллар белән яши, олы җанлы булулары белән якыннарының хөрмәтенә лаек, тырыш, булдыклы, гаиләнең нигезен саклаучылар буларак күз алдына бастырыла.

Риза Ишморатка киң танылу алып килгән пьесалары булып «Үлмәс җыр» (1955), «Алар дүртәү иде» («Океан батырлары», 1961), «Давылга табан» (1963), «И мөкатдәс моңлы сазым» («Килер ул якты көн», 1982) драмалары санала. Беренче

әсәрдә Володя Ульяновның студент еллары, аның революцион көрәшкә килүе чагыла. Бу – драма-бәхәс. Шуна да ул иҗтимагый һәм сәяси мәсьәләләр турында уйланулары, инкыйлаби карашлары, бәхәс элементлары урын алган диалоглары белән кызыксыну уята. Әмма авторның байтак караш-фикерләре бүген инде кабул ителми. Геройларның эш-гамәле дә гадәтилектән бигрәк, драматург теләгенә буйсындырылган булу белән бәяләнә. Әдипнең «Алар дүртәү иде» пьесасы шторм вакытында ярдан ычкынып, 49 тәүлек буе Тын океанда дулкыннарга буйсынып хәрәкәт иткән паромдагы Әсгать Җиһаншин һәм аның иптәшләре турында. Автор, беренче чиратта, кешегә, аның рухи көченә мәдхия укый. Аларның бу көрәштә исән калуы кешенең үз-үзен җиңү үрнәге буларак тәкъдим ителә һәм укучыда ихтыяр көче, рухи ныклык тәрбияли.

Р.Ишморат Муса Җәлилнең әдәби образына беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итә. «Үлмәс җыр» драмасы патриот-шагыйрьне шәхес һәм әдип буларак ачуның бер үрнәге булып тора. Пьеса күп тапкырлар сәхнәгә куела, күрше халыклар теленә тәрҗемә ителеп, рус, мари, үзбәк театрлары сәхнәләрендә уйнала. М.Җәлил батырлыгын, үлемсез иҗатын бәяләп, автор батыр улы аша татар халкын да зурлый.

Р.Ишморат публицист, тәрҗемәче, тәнкыйтьче буларак та актив иҗатта яши. Ул рус, украин телләреннән әсәрләр тәрҗемә итә һәм аларның татар сәхнәсендә куелуына ирешә. Аның замандашлары, дуслары, остазлары турында очерклары тупланган «Сайрасын тургайлар» (1982), «Дусларым, остазларым» (1988) җыентыклары һәм автобиографик «Гомер сукмаклары» (1987) повесте әдәбият-сәнгать сөючеләр тарафыннан хуплап каршы алынды. Алар әдип яшәгән чор рухын, кешеләрен, теләк-омтылышларын чагылдыру ягыннан гыйбрәтле истәлек-хатирәләр булып тора.

Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет билгесе» орденнары кавалеры Риза ага Ишморат 1995 елның 29 октябрендә Казанда вафат була.

Әйе, Риза Ишморат – үз чорының танылган драматургы. Бүген аның пьесалары театр сәхнәләрендә куелмый. Әмма алар татар әдәбиятында, сәхнә әдәбияты тарихында, аның төрле чор-дәверләрен тоташтыруда мөһим бер буын булып тора. Әдипнең бай мирасы үз чоры кешеләренең якты образларын тудыруы, аларның яшәү рәвешен, әхлакый йөзләрен чагылдыруы белән кадерле. Тарихи хезмәтләрдәге коры фактлардан аермалы буларак, әлеге әсәрләрдә ил, халык тормышындагы хәл-күренешләр әдипнең уйланулары, хыяллары белән үрелеп бирелә һәм укучы күңелендә шул чорларның образы буларак урын ала.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

## Оныткан

Шулай бер тапкыр мәшһүр алман әдибе Томас Манны мәктәпкә очрашуга чакырганнар. Укытучы Манны иң сәләтле һәм иң күп китап укучы бер кыз бала белән таныштырган һәм аңа нинди дә булса бирәр сорау бирүен үтенгән.

— Мәшһүр әдипләрдән кемне беләсең? — дип сораган бу кызыйдан Манн.

— Гомер, Шекспир, Бальзак... һәм Сез! Тик ... мин Сезнең исем-фамилиягезне оныттым... — дигән аңа сәләтле укучы.

## Әдип көлүе

Төн уртасында Бальзакның өенә карак кергән. Хуҗаның йоклавына инангач та, бу өстәл тартмаларын актара башлаган. Кинәт кенә өйдә... гөрелдәвекле көлү тавышы яңгыраган. Як-ягына карана торгач, карак ай яктысында язучыны күреп алган. Курыкса да, явыз ниятле бәндә, кыюланып китеп, сорыйсы иткән:

— Нигә көләсез?!

— Мин көндезен табалмаганны син төн уртасында караңгыда эзлисең — шуңа көләм... — дигән Оноре де Бальзак.

## Бәһале җавап

Бер галантерея фирмасының бик тә-бик тә Эрнест Хемингуэйны үз клиентлары арасында күрәсе килгән. Фирма әдипкә галстук һәм хат юллаган. Хатта исә болай дип язылган булган: «Безнең галстукларны һәркайда яратып тагалар. Сезгә җибәрелгән ошбу галстук өчен ике доллар түләрсез дип өметләнәбез».

Берничә көннән элеге фирма әдиптән мондый җавап ала: «Минем китапларымны һәркайда яратып укыйлар. Сезгә салган ошбу китабымны алырсыз дип өметләнәм. Ул ике доллар да сиксән цент тора. Димәк, сез миңа сиксән цент бурычлы буласыз».

## Ә кемнекен?

Александр Дюма улын тирги икән.

— Житте сиңа җинел акыллы булып йөрергә! Яшең дә бара — хатын алырга кирәк! — ди икән.

— Хатын?! Ә кемнекен? — дип атасын бүлдергән малае.

## Әдәпле җавап

Һолливуд кинойолдызы Грета Гарбо әле кичә генә төшкән фотоларын карап утыра икән дә, начар чыккан дип фоторәссамны сүгә икән.

— Ничек шулай чыккан?! — берни дә анламыйм. Соңгы тапкыр төшергәндә шулчаклы әйбәт иде, ә менә хәзер — үз-үземә охшамаган ич?!

Фоторәссам исә әдәпле вә итәгатьле генә итеп җавап кайтарган:

— Алиһәм, шунысын онытмагыз — ул чагында мин төп-төгәл унбиш яшькә яшьрәк идем шул әле...

### Уйлап кияүгә чыгу

— Сез ни өчен нәкъ менә археолог галимгә кияүгә чыктыгыз? — дип сораганнар детектив жанр алиһәсе Агата Кристидан.

— Чөнки иң яхшы ирләр — археологлар. Хатыны картайган саен, ул аның белән күбрәк, тирәнрәк кызыксына, — дигән биксән яшьлек әби.

### Теш кыйссасы

Франциянең мәшһүр киноактеры Жан Габен тешен алдырган. Берничә көннән соң мона дантисттан хат килгән. Теш алдыру күпмегә төште икән дип конвертны ачып караса... аннан һич тә исәп-хисап кәгазе түгел, ә берничә эре купюра акча һәм кош теледәй генә язу килеп чыккан. Анда болай дип язылган була: «Тешегезне Сезнең ижатка һәм үзегезгә мөкиббән киткән бер ханымга саттым. Ул аны хәзер талисман итеп муенына тагып йөри. Акчаның үземә тиешлесен тотып калдым, калганын Сезгә жибәрәм».

### Бөек бәһа

Шулай бер тапкыр итальян композиторы Джузеппи Верди яшь музыкант белән сөйләшеп тора икән. Вердига — илле яшь, тегесенә исә — унсигез.

Яшь музыкант, өлкән композиторга авыз ачарга да ирек бирмичә, һаман саен үзе һәм үзенең музыкасы хакында гына тәкърарлый икән.

Верди бу егетне олуг түземлелек вә игътибар белән озын-озак тынлап торган да, ниһаять, болай дигән:

— Унсигез яшьләр чамасында мин үземне бөек музыкант итеп саный идем һәм: «Мин!» — дия идем. Егерме бишкә житкәч: «Мин һәм Моцарт!» — дидем. Ә инде кырык яшьтә: «Моцарт һәм мин» — дия башладым. Менә хәзер исә фәкать: «Моцарт» — кына димен...

### Кем нәрсәгә маһир

Бөек итальян сынчысы һәм рәссамы Микеланджело рәссам Франчианың гажәеп матур вә зифа буйлы улын тәүге тапкыр күргәч, аңа болай дигән:

— Атаң, рәсемгә караганда, тере сыннарны яхшырак ясый икән...

### Надан карак

Композитор Феликс Мендельсонның кайчан туганын белмәгәнгә күрә, бер карак төрмәгә утырган. Бу исә болай булган: Мендельсонның «Туй маршы»н уйный торган борынгы сәгатьне карак музейдан урлаган. Антикварлар сата торган кибеткә китергәч, сәгатьнең үзенә бабасыннан мирас булып калуын, әле 1730 елда ук бабасының әтисе аны кемнәндер сатып алуын аңлатырга керешкән бу. Антиквар исә азмы-күпме укыган вә хәбәрдар кеше булган, күрәмсең: чөнки дә ул Мендельсонның 1809 елда гына тууын, һәрхәлдә, бик яхшы белгән...

**Морад ДУСАЙ** *туплады*

Даһи
Гаделшин

# СОҢГЫ БҮЛӘК

САТИРИК ХИКӘЯ

Җөмһүриятнең йөзек кашы саналган районның башлыгы Виллләт Дәүҗанович инде ничәнче төнне керфек тә какмыйча үткәрә. Ул күзен чытырдатып йома да оеп китәргә тырыша, ләкин тәмам тубалга әйләнгән башына, онытылу кая, кемдер үртәгән бал корты күче кебек, яңадан-яңа уйлар отыры ныграк сарыла башлый. Бүген дә йокысызлыктан иртәнгә гәүдәсе шулкадәр авырайган иде ки, кутәрткән мал сыман, бик озак калкына алмый җәфаланды, урамда да августның иртәнге салкынча һавасы аны эчмичә исерүдән айнытып җибәрә алмады.

Беренче карашка, шулай тере мәеткә әверелергә әллә ни сәбәп тә юк шикелле. Бер яклап та үзен таныта-күрсәтә алмаган хәлдә ниндидер кодрәт белән түрә кәнәфиенә менеп утырды һәм минуты-сәгатендә җиң сызганып, үзе аңлаганча иң мөһим, кичектергесез гамәлләргә тотынды: хакимият ихатасына керә торган юлга шлагбаум куйдырды, урам яктагы капканы бөтенләй кадаклаттырды, бинаның алгы ишеге катына полиция сакчысы утыртты. Эш кабинетына евроремонт үткәреп, өстәлгә каршы почмакка йорт кинотеатры җиһазларын урнаштырту аеруча күп көч һәм вакыт алды.

— Менә хәзер бөтен егәрне төп максатка җигәргә була, — диде Виллләт Дәүҗанович, иненнән авыр йөк төшкәндәй җиңел сулап.

Төн үткәнче шушы зиннәтле кабинетын сагынып эшкә дә гадәттәгедән иртәрәк килә башлады ул. Затлы ишекне өф итеп кенә ачып керү белән «кинотеатр» шнуры вилкасын розеткага тоташтыра да, кәнәфи килбәтендә ясалган әйләнмәле, йомшак урындыкка чумып, өстәл өстендә телефон аппаратыннан да якынрак яткан пультны кулына ала. Һәр көнне НТВ каналында иртәнге сәгать сигез белән тугыз арасында күрсәтелә торган «Их, яши бит кешеләр, ә» дигән тапшыруның берсен дә калдырмыйча карап бара. Заман байларының яшәү шартларына күз кызмаслык түгел шул. Әнә беркөнне артистка Ирина Аллегрованың ничек яшәвен күрсәткәннәр иде, бүлмәләре, асыл мебеле, алтын-көмеш йөгертелгән савыт-сабасы, төрледән-төрле кием-салымы күзне камаштырды.

Ләкин Виллләт Дәүҗановичны әлеге вакытта мондый мөлкәт түгел, төньяк башкаладагы Кышкы сарайга биргесез шәхси ташпулатлар, аларның тышкы күренеше, корылышы ныграк кызыксындыра. Тагын да төгәлрәк әйткәндә, бөтен уе гел шулар хакында. Тәүлекнең алар белән хыялланмаган берәр мизгеле бар микән? Бәй, шулай булмыйча, гади халык белән янәшә коммуналь квартирда җәфа чикмәс бит инде шушы вазифада. Ләкин үз-үзен юкка газаплаган булып чыкты ул — вазифасының кодрәтен тулысы белән аңлап бетермәүнең бәласы инде бу — җаваплы урынбасарга ым кагу җитте, якындагы колхозның алма бакчасы белән чиктәш тыныч бистәдә әкияти сарай калкып та чыкты. Теге Кышкы сараең бер якта торсын. Зурлыгы әллә

егермегә утыз, әллә утызга кырык метр. Дивары каләм кебек буйдан буйга тигез юанлыкта итеп юнылган, шыңгырдап торган нарат бүрәнә. Эчтән, тыштан шикәр төсендәге такта белән тышланган. Кәрниз, тәрәзә, ишек йөзлекләре чын чәчәкне хәтерләтеп тора. Веранда диварынын өске өлеше гел пыяла. Түбә ак калайдан. Шомартылган борыс һәм тактадан корылган мунча, җәйге ашханә, бассейн, абзар-кура да кояшта күзне камаштырып ялтырый.

Шушы «оҗмах»та Вилләт Дәүҗанович бер ел яшәдеме, юкмы, аның тагын эче пошып, нидер җитмәгәндәй кыбырсый башлады. Иртән килгәч, кулларының учы белән ике яклап башын кысып аз гына утыра да йомшак урындыгында бер-ике мәртәбә бөтерелеп ала, аннары аякка басып, ишеклетүрле йөренергә керешә. Бүген дә шулай шактый гына килән сарып йөргәннән соң ул кинәт туктап, «Булды!» дип кычкырып җибәрде — шул ук секундта ишектә сәркәтипнен сары чәче пәйда булды.

— Тиз генә ЖКХ начальнигын тап, — диде аңа бүлмә хуҗасы: — Атлап түгел, очып килсен.

Кыска буйлы, ябык гәүдәле коммуналь хуҗалык җитәкчесен Янмас Акмыич дип йөртәләр. Чынында шулаймы, әллә еш кына электр сүнеп, краннан су килми торганга төрттерүме, ул кадәресен анык кына хәтерләүче дә юк шикелле, иллә мәгәр үзеннән өстен кешеләрнең ни әйтергә уйлаганын ярты сүздән аңлый торган гадәте киң даирәгә билгеле. Шуңа күрә Вилләт Дәүҗанович торак йортларны ремонтлау, гомумән, шәһәр хуҗалыгын кышка әзерләү барышы турында кыскача гына белеште дә әңгәмәне туптуры үз тормыш-көнкүрешенә таба борды:

— Үзең дә күреп торасыңдыр, мин өйгә төн уртасы җиткәндә генә кайтып керәм. Үз йортымда квартирант инде мин. Шуңа бу статусны әллә рәсмиләштереп куябызмы?

Янмас Акмыичка башкача тәфсилләп торуның кирәге юк, ул баштүрәнең тел төбен бик яхшы аңлады: абзый үзенең шәхси йортын ЖКХ балансына күчерергә, дөресрәге, сатып бирергә тели. Әлбәттә, олы бер башка өстен түрә алдында җимерек хәлгә төшкән йортларны ремонтларга да акча юк бит әле дип тору үз-үзенә хөкем карары чыгаруга тиң булыр иде. Шуңа ул башыннан андый килделе-киттеле уйларны куып, фикерен йортның хакына туплады. Ә йорт шә-ә-әп! Дүрт миллионнан күбрәккә тартыр. Ә Вилләт Дәүҗанович, «комхуҗ»ның нәрсә исәпләвен йөзеннән укыгандай:

— Үзең беләсең, мин комсыз кеше түгел, нибары сигез «лимун»га да ризамын, — дип әйтеп тә салды.

Кайберәүләр бу урында шундый югары урынны биләгән түрә нишләп әле ирекле баштан җинел генә үз «куышыннан» колак кагып, коммуналь фатирда яшәүне өстен күрә икән, дип гаҗәпләнергә мөмкин. Чыннан да күпләр, «коммуналка»да гомер кичерүдән тәмам гарык булып, тамагыннан өзә-өзә үзенә аерым түбә корырга тырмаша бит. Ләкин Вилләт Дәүҗановичның бу гамәлендә үзенең төп максатына ирешүгә юнәлтелгән астыртын хәйлә яшерелгән иде. Ул инде коммуналь хуҗалык милкенә әверелгән йортын ташлап чыгып китмәде, бәлки сату язу-сызуларын төгәлләп өч-дүрт ай үтүгә аны бушка диярлек хосусыйлаштырып, кабат үзенеке итте дә куйды. Ә ел ярымнан шушы ук алыш-бирешне тагын бер мәртәбә кабатлатты. О, баш түрәнең ул мизгелләрдәге куанычын тулы итеп тасвирларга каләмнең көче җитми. Атлаганда аягы җиргә тими сыман, гүя ки ул ләззәтле рәшә дулкыннарында тибрәлеп-йөзеп кенә бер урыннан икенчесенә күченә. Кергәндә-чыкканда йортның почмагыннан үбеп үтә. Үпмәслекмени, ниндидер ике ел дигәндә саклык банкындагы исәпкә уналты миллионны өстәде бит.

Ләкин кешенең нәфесе учак кебек шул ул. Учак сүрелмәсен өчен аңа утын өстәп торырга кирәк булган шикелле, унай импульслар тәэсир

итеп торганда гына кешенең күнел күтәренкелеге кирәкле биеклектә саклана ала. Виллэт Дәүжанович та озакламый күнеле учагына «утын» таләп ителүен сизә башлады. Урамга чыкса, ике якта тезелешеп утырган юкәләрнең көндезге җылыдан ләшпердәгән яфраклары аның күзенә яшел «кыштырдык»лар булып күренә. Их, шулай булсын икән дә, агачларны берәм-берәм селкеткәндә алардан яшел «кәгазьләр» җиргә шыбырдашып коелсын икән. Берникадәр вакыт шулай хыялланып йөргәннән соң, сөяркәсе урынына күргән «оҗмах йортын» сату турында хәбәр таратты. Атна үтте, ун көн... бер ай... Әмма телефоннан шылтыратып белешүче дә, сорап килүче дә күренмәде. Ахырда Виллэт Дәүжанович дөньядагы иң кадерле нәрсәсен югалткан кеше кебек кара көеп, сәркәтип кыздан дәүләт иминияте җәмгыятенең мөдирен чакырттырды. Алар икәүдән-икәү генә ярты көн буена диярлек нәрсә турындадыр серләшеп утырдылар, һәм шушы тар даирәле киңәшмәдән соң ике көн үтүгә, бөтен халык эштә чагында якындагы авылның шәһәргә килеп төртелгән урамыннан иләмсез зур, әмма төтенсез диярлек ялкын күтәрелде. Баксаң, Виллэт Дәүжановичның әле кайчан гына гөлбакчаны хәтерләтеп торган ихатасын тимерне боламык итәрлек ут чолгап алган, сөяктәй корыган нарат бүрәнә, такта чатыр-чотыр килеп кып-кызыл күмергә әверелә, тирә-якка, күккә күсәгә-күсәгә кисәү, очкын оча. Урамнарда янгын сүндерү машиналарының чыелдык сигналлары колакны ярмаган иде, баксаң, алар килгән икән. Ләкин янгын сүндерүчеләрнең берсе дә су сиптерү, утны басу белән мәш килми. Алар кызыл машиналары янына төркем-төркем булып оешып алганнар да, кулларын каш өстенә куеп көлешә-көлешә утлы мәхшәрне күзәтә. Полиция вәкилләре дә, җир астыннан шытып чыккан сыман, тавыш-тынсыз гына пәйда булганнар, алар янгынны сүндерешергә чиләк-мазар тотып килгән халыкны ихатадан читкә куып тора...

Шыңгырдап кипкән агач җәйге коры көндә озак янамыни, бер сәгать вакыт үттеме, юкмы, «Кышкы сарай» урынында беленер-беленмәс зәңгәрсу ялкынлы куз гына өелеп калды. Шәһәрдә Виллэт Дәүжанович йортка үзе ут төрткән икән дигән чыш-пыш таралды. Дәүләт иминияте исә «каза күрүчегә» комхуҗ биргәннән дә күбрәк акча түләде. Баштүрә гаиләсе «Могҗизалар кыры» дип йөртелгән урамда күптән түгел төзелеп беткән яңа «Кышкы сарай»да яши башлады.

Әгәр кемнең дә булса башына Виллэт Дәүжанович, ниһаять, барына канәгатьләнеп, тыныч күнел белән дөньясына төкереп гомер сөрә башлагандыр, шәт, дигән уй килсә, андый кешенең түрәләр психологиясендә шыр томана икәнлегенә шикләнмәскә мөмкин.

Соңгы атнадагы вакыйгаларны образлы сөйләмгә салып әйткәндәгечә, иске тунны утка ягып яңасын кигәннең икенче көнендә үк, ул импорт җиһазы белән тутырылган кабинетында үз-үзенә урын табалмыйча, гадәтенчә әрле-бирле йөренергә керешә. «Гәзитчеләр минем бүгенге халәттә эчке мөмкинлекләр бетте, хәзер аларны читтән эзләү лазем дияр иде». Ул авыз эченнән шулай мыгырданып, үзәк мәйданга караган киң һәм биек тәрәзә каршына килеп басты. Моннан бөтен шәһәр диярлек уч төбендәге кебек күзаллана. Виллэт Дәүжанович гадәтенчә бу юлы да кинәт кенә кычкырып җибәрде: «Булды!» Ишектә шул секундта ук ялтыраган «сары чәч»кә кирпеч кебек дүрт почмак битле төзелеш урынбасарын табарга әмер бирде. Менә шуннан җәелеп китте инде, мин сина әйтим, керемле гамәлләр колачы. Район биләмәсен аркылы кисеп үткән үзәк юлны киңәйтү турында өстә карар кабул ителеп, хуҗалыкларга моңа алынган җир өчен акча түләнәчәге билгеле булу белән, илле-алтмыш чакрымга сузылачак бу «тасманы», закон баганасын әйләнеп узу әмәлен табып, үзенеке итте.

Ашъяулык чаклы гына жиргә тары бөртеге кадәр генә рашкы сибәләп үтсә дә, дистәләгән мең гектар чәчүлекне боз сугуы турында черки борын тыкмаслык акт төзелә (моны эшләүче белгечләрнең күнелен күреп, әлбәттә) һәм табигать зыянын капларга каралган иминият акчасының алагаем өлеше баштүрә кесәсенә чума. Фермаларны да сулга эшләтү жае табылды. Аларның барлык күрсәткече түбә-түшәмнән алынган саннар белән матурландырыла да районның баш зоотехнигы бизәлгән кәгазьләрне Мәскәүгә алып китә, андагыларга банкнот төрү бәрабәренә хужалыкларга токымчылык заводы мәкаме бирелә. Менә шулай районның кәжәдән кайтыш сыерлары да сөтне гөбердәтеп саудыра торган «токымлы» малга әйләнеп бетте. Дәүләт исә мул продуктлы мондый мал үрчетүче хужалыкларга бик күп өстәмә сумнар бирә. Күктән төшкән акчалы капчыкның яртысы янә шул зиннәтле кабинетка бушатыла.

Дәүләт мөлкәтен бүлешү форсаты да бик оста файдаланылды. Аукцион үткәрелергә тиешле хадәфләр турындагы белдерүне жирле гәзиттә кеше күзенә чалынмасын өчен сукыр чебен башы кадәрле генә хәрефтән жыйдыртып, Виллә Дәүжанович алыш-биреш үткәртми генә районда иң зур табыш китерә торган элеватор, сугым предприятиесе, сөт комбинаты, универмаг, гастроном ише милекләргә хужа булып алды. Житәкче көенә малтабарлык белән шөгыльләнеп, закон боза, дигән гаеп ташланмасын өчен, ул һәр кәгазьдә йә эти-әнисе, йә әби-бабасы, йә агасы-жингәсе исемшәрифен күрсәттерә, хәтта бишбылтыр жан тәслим кылган үлежаннар да эләкте шикелле андыйлар арасына.

— Шәһәрне чистарту турында да онытма, — дип күрсәтмә бирде Виллә Дәүжанович «кирпеч биткә».

Һәм инде төзелеп бетә язган әллә ничә бина кире сүтелеп, кирпечплитәләре, елгачылар һәм авиаторлар бүләк иткән катер белән самолет (алар тир, музей итеп файдаланыла иде) «ә» дигәнче әллә кая югалды. Төзелеш кирәк-ярагының, төсле металлның шулай ай күрде кояш алдыга әверелүе Виллә Дәүжановичка һич тә кайгы түгел, бәлки, киресенчә, сөенеч китерде.

Икенче көнне йомшак «тәхетенә» чумган хәлдә «тагын кайдан, күпме, ничек» дип башын тотып утырганда сәркәтип кабинет ишеген ачып, бүлек мөдиренен керергә рөхсәт соравын хәбәр итте. Ул инеп хәл-әхвәл белешүгә, Виллә Дәүжанович ана сынамак өчен генә телисенме минем урынбасар да булырга, ягъни ике камытны берьюлы кияргә, әйдә, тик бу өстәмә вазифаның хезмәт хакын мина ике, сина бер өлеш итеп бүлешербез, дип сүз тишкән иде, тегесе песигә әйләнеп, авыз суын сызгыртып йотты. Менә шуннан вазифаларны сатарга мөмкин, ләбаса, дигән уй-теләк дөрләпкабынып китте дә инде. Калган эшкә кар явар, дип ниятен кичектермичә гамәлгә ашырырга да тотынды. Иң әүвәл өстәл тартмаларының сул яктагы өстәгесен шудырып алга да, артка да ачмалы иттерде. Бик унайлы килеп чыкты бу үзгәртеп кору: кергән кеше каршыга килеп утыруга, Виллә Дәүжанович тартманы аның ягына шудырып этеп куя да, конверт-төргәк салынгач, йөкле «чананы» үзенә таба тартып ала. Килерне өстәл өстеннән жыеп алып утыру килешми дә, куркынычрак та иде, хәзер биреш-алыш астан башкарылгач, бу гамәлләрне этем дә күрми, сулдан кергәне хәләл белән дә буталмый.

Бу яктан жаны тынычлангач, Виллә Дәүжанович колхоз, төзелеш, транспорт, сәүдә, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм башка оешма житәкчелегенә үрләтелүчеләрнең һәммәсенә биек вазифа урындыгы өчен аерым такса билгеләде. Йомшаграк кәнәфигә утырырга жан атып йөрүчеләр зуррак көмәнле конверт төртергә тиеш. Мәсәлән, өч йөз мең сум чыгарып салсан

гына колхоз рәисе булу бәхетенә ирешә аласың. (Соңыннан андыйларны, элек авыл хуҗалыгын күтәрергә җибәрелгән «утыз меңчеләргә» охшатып, «өч йөз меңчеләр» дип йөртә башладылар).

Борынгыдан шундый тәгъбир калган: бирим дигән колына чыгарып куяр юлына. Виллөт Дәүҗановичның борын күтәрүе дә нәкъ хосусый милекчелеккә юл ачылган чорга туры килде. Халык шул мәлдә үзенең кәсебен башлап җибәрергә дәррәү күтәрелде. Фермер камытын киярга атлыгучылар җир сорап килә, сәүдәгә күнеле тартылучылар ниндидер бинага темсенә, эшкуарлыкка, малтабарлыкка тотынучылар ни күренсә, шуны эләктерергә чамалый һәм башкалар, һәм башкалар. Билгеле инде, хуҗа аларның һәммәсенә якты чырай ката, ниятләрен хуплаган атлы булып кылана, шагыйрь әйтмешли, хәйләсен әкрен-әкрен китерәдер көйгә. Шулай «кыштырдыклар» өстәлдәге теге шудырмалы тартмага салынгач кына гаризага рөхсәт имзасы ишарәте китерелә.

Оешу-оештыру гамәлләре уңышлы тәмамланган очракта да югары вазифага ия булучылар, фермер, сәүдәгәр, малтабар, эшкуарлар тынгылыкта калдырылмый — аларның барысы да айлык взнос түләп барырга мәҗбүр ителә. Тәртәгә тибәргә базнат итүче сүленне сыгып чыгарырлык эскәнҗәгә кыстырыла. Әнә бер эшкуар чыгымчылап маташкан иде, башта ширкәте электрын кырт итеп кистеләр, аннары су торбасы башына имән чөй кактылар. Нигә сораганын биреп котылмыйсың, дип әйтеп караган иде дус-ише эшкуарга, күпме тыгындырсаң да туя белми бит, дип зар елый тегесе. Ә бер колхоз рәисе нинди хәлгә төште: гөнаһ шомлыгына күрә, аның взнос китерү вакыты хуҗаның әнисен җирләү көненә туры килгән; бер сәгать көтә Виллөт Дәүҗанович рәиснең кабинетка килеп керүен зиратка бармыйча, ике... өч... дүрт сәгать... Ә мәет ята кабер кырыенда кадерләп үстергән улын көтеп, мәңгелек йортына ярты көн буена төшә алмыйча. «Нинди кансызлык! — ди Виллөт Дәүҗанович тешләрен шыгырдатып һәм шул ук фикерне урысча да кабатлый: — Какой жестокыс!..» Рәис икенче көнне үк урындыгыннан колак какты. Шушы вакыйгадан соң «кыштырдыклар» пешкән алмалар агачны селкеткәндә җиргә тупырдап коелган кебек, тоткарлыксыз ява торган булып китте.

Ә аларның күләме сөбханалла-машалла дип күзне акайтырлык. Биш катлы йортларның баштүрә карамагына алынган подвалын кибет ачу өчен арендалаучылардан гына да аена сигез миллион сумлык чумара керә. Һәм ул һич тә эчне тишми. Тик шунысы гына бераз кәефне кыра: чумараларның микъдары артмый, гел бер килеш тора. Бу хәл Виллөт Дәүҗановичны тынычсызлый, борчый, саруын кайната, нәфесен шыркылдаттыра. Авыр кичерешләр аның кыяфәтен үк үзгәртә башлады шикелле. Аны шәһәрдә генә түгел, бөтен районда халык Кальтенбруннер дип йөртә. Чыннан да ул «Язның унҗиде мизгеле» кинофильмындагы шушы исемне йөрткән фашист офицерына бик охшаган — суйган да каплаган инде менә: аның кебек үк озын буйлы, чандыр гәүдәле, ач яңаклы, уң як битендә кино героеныкы кебек җөй дә бар (монысын яшь чагында бер ана мәченең март гамәлен кабатларга азапланганда алган җәрәхәт эзе диләр). Даими тынгысызлык, эчтән сызу аркасында, Виллөт Дәүҗанович менә шушы төп нөсхәсеннән дә ныграк суырылды, аркасы кычытуын күкрәгән кашып кына да басарлык дәрәҗәдә юкарды. Соңгы вакыттагы йокысызлыктан маза китү, иртән тору сәгате сукканда күтәрткән малга охшау галәмәтләренең һәммәсе дә башына «ничек күбәйтергә» дигән уй төшүдән килә.

...Менә бүген дә эткә салган сөяккә әверелердәй хәлгә җитеп һәм инке-минке атлап кабинетына кереп утыргач, гадәтенчә, «Их, яши бит кешеләр, ә» тапшыруын карарга керешкән иде, аның кызыгын тапмады, кәҗә кымызыннан ачыган сөт тәме килде. Кулына ниндидер журнал алып,

укырга азапланган иде — юллар тоташ кара сызык сыман күренде, арткы бүлмәдәге диванга сузылып ятып тору да җинеллек китермәде. Ахырда өйлә якынлашуга ихатага чыкты.

— Син машинаны гаражга биклә дә, бар, өеңдә ял ит. Мин җәяү генә кайтыйм әле, хәрәкәттә-бәрәкәт, — диде Виллләт Дәүҗанович шоферына.

Менә ул ылыс урманы исен аңкытып торган бүрәнә өен бензин бөркеп яндырганга кадәр үк кирпечтән салдырган өч катлы йортына таба гомуми юлдан читтәрәк түшәлгән шәхси асфальт сукмактан атлап бара. Тып-тып, тып-тып... Бу тавыш баштүрәгә «тап-тап», «тап-тап» булып ишетелә. Әйе, табарга кирәк, табарга. Шулвакыт ана кемдер кычкырган сыман тоелды. Артына борылып караса, тәрәзәдән хатыны Кәнзимә эндәшә икән. Шул каһәр суккан уйга батып үз өен үтеп китеп бара икән, ләбаса.

Кичкелекне ашарга утыргач, Кәнзимә иренә бер рюмка коньяк салып бирде.

— Шуны эчеп җибәр дә нык итеп аша әле. Ите бик тәмле. Тайныкы икән. Теге янарак кына куйган персидәтелең керткән иде. Аша-аша, казна эше дип корып кибәсең бит инде.

Бертын дәшми генә ашаганнан соң Кәнзимә янә телгә килде.

— Карале, син әле урак, әле кышка әзерлек дип үз дөньяңны бөтенләй онытып барасың түгелме?

— Нәрсәне, мәсәлән?

— Туган көнеңне.

— Андый көн дә бармыни соң әле ул, — дип шаярткан булды Виллләт Дәүҗанович, теге уйларга чумып аны истән чыгарганын хәләл җефетеннән яшерергә тырышып. Үзенең башында хәзер бу көнгә бәйле уйлар кайнаша башлады. Быел ул гади түгел икән ләбаса, алтын икән, әттәгенәсе. Димәк... димәк... Шушы сүзгә мантыйклы дәвам таба алмыйча озак борсаланды ул йокларга яткач та. Төн уртасы җитеп килә иде бугай, Виллләт Дәүҗанович, гадәтенчә, кинәт бөтен бүлмәне яңгыратып «Булды!!!» дип кычкырып җибәрде. Инде күптән әвен базарына киткән Кәнзимә куркудан сискәнеп, юрганын җилләндереп ачып ташлады.

— Син... сиңа әйтәм, саташасыңмы әллә? Нәрсә «булды»? Башламадың да бит әле.

— Башлыйбыз, бишек җырым, башлыйбыз. Атна буена дәвам иттерәчәкбез.

Виллләт Дәүҗанович, хатынын юатырга тырышып, аңа үз башында бөреләнгән планны ике-өч сүз белән генә аңлатып бирде.

Татлы хыялларга уралып килгән берничә сәгатьлек йокыдан Виллләт Дәүҗанович бөтенләй икенче кеше — аек фикерле, күтәренке кәефле, тәвәккәл зат булып уянды. Эшкә баргач, кабинетына кереп йомшак «тәхетенә» чуму белән, моңарчы булмаганча, «кинотеатр» пультын читкә этеп, кулына әчке телефон трубкасын алды. Аны урынына куеп та өлгермәде шикелле, ишектә «мөдир плюс урынбасар»ның почмакка посып, тычкан дулап утырган песинең кыяфәтенә тартым йөзе чагылды.

— Озаклап чәйнәп каптырмыйм. Син эшне астыртын йөртә беләсең. Беренчедән, шау-шулы реклама кирәкми. Икенчедән, беркем әйберләтә бүләк күтәреп килми, конверт кына кабул ителәчәк. Безнең халыкны үзен беләсең инде, конверт үтә күренмәле булмасын, биш-алты урынлы саннар турында сүз тишүнең зыяны тимәс. Өченчедән, ресторан директорын кисәт: өстәл сыйдан сыгылып торсын, ә счет исәпкә бар, сангa юк сыманрак түгәрәкләнсен. И соңгысы, беренче мәҗлескә кемнәрне чакырырга кирәклеген үзем әйтермен, калганнарына килүчеләрне исемләп торуның хаҗәте юк, — дип йомгаклады кабинет хуҗасы күрсәтмәләрен. «Мөдир

плюс урынбасар» ишеккә якынлашканда өстәп өлгерде: — Автомашина, квартир кебек бүләкләр натуралата да ярый.

Мәҗлесләр көткәннән дә кәттәрәк узды. Чәршәмбедә ресторанның зур залына Вилләт Дәүҗановичның дус-ише, башкаладагы кирәкле кешеләре, пәнҗешәмбедә — шәһәрдәге предприятие һәм оешма җитәкчеләре, җомгада — колхоз, авыл рәисләре, шимбәдә — мәгариф, мәктәп вәкилләре һәм якшәмбедә урта звено кадрлары, ягъни бригадир, ферма мөдирләре сыйланып, юбилярга мактау яңгыры яудырдылар. Ә юбилейның килерен, ягъни конвертлар эскертен Вилләт Дәүҗанович өйдән беркая чыкмыйча өч көн исәпләп утырды. Икътисад атамасын кулланганда, туган көннең рентабельлеге мең процентка якынлашты. «Ярый әле туганмын, югыйсә бу кадәр акча каян керер иде», — дип канатланды Вилләт Дәүҗанович, баш һәм имән бармакларын бер-берсенә ышкып.

Ә бер конверт аны сүзнең туры мәгънәсендә чак кына һуштан яздырмады. Конвертның тышына кемнән икәне язылмаган иде. Ачып караса, акча урынына кәгазь кисәге, анда кыска гына язу:

— Район халкы Сезгә башкаладан күп бүлмәле фатир бүләк итә. Ачкычы — караучыда. Адресы...

Вилләт Дәүҗанович бүләкне карарга икенче көнне үк бармакчы булып яткан иде йокларга, әмма төнлә... ашыгыч ярдәм автомашинасы аны хастаханәгә алып китте. Биш көн буена кунаклар исәнлегенә күтәрелгән рюмкалар, конвертлар «эскертен» эшкәрткәндә кичергән чиксез шатлыклар нәтиҗәсе иде бу. Атна буена «система» астында кыймшандырмыйча яткырып кына алып калды аны табиблар.

Хастаханәдән чыгу белән шоферына алдагы көнгә юллама яздырып куярга, автомашинага багын тутырып бензин салырга кушты. Икенче көнне, гадәттәгечә, иртәнге сәгать алтыда ук кузгалдылар һәм әле машиналар хәрәкәте куермаган юлдан башкалага бик тиз барып җиттеләр. Ләкин шәһәрнең конверт эчендәге кәгазьдә күрсәтелгән урамына моңарчы юллары төшкәне булмаганлыктан, аны һәм бүләк адресланган йортны шактый озак эзләделәр. Ниһаять, шофер машинаны бетон плитә белән уратып алынган шыксыз гына хадәф янына туктатты.

— Син ялгышмадыңмы? — диде Вилләт Дәүҗанович, бетон койма өстеннән сузылган чәнечкеле тимерчыбыкларга карап.

— Юк, урамы да, йорт номеры да сез әйткәнчә.

Вилләт Дәүҗанович койманы өзеп төзелгән бәләкәйрәк кенә бина ишеге өстендәге ләүхәне күреп алды һәм «Эчке эшләр...» дип укый гына башлаган иде, шофер «Төрмә бит бу!!!» — дип кычкырып җибәрде. Шул арада ишектән погонлы кеше чыгып (бу погонлы кеше ошбу хатны алып килүченең танышы иде һәм әлеге мәктүпне Вилләт Дәүҗановичка тапшыруны үтенгән иде) машина янына килеп басты һәм:

— Сез Вилләт Дәүҗанович түгелме? — диде һәм, уңай җавап ишеткәч, дүрткә бөкләнгән кәгазь сузды: — Алайса, менә бу язу сезгә була инде.

Погонлы кеше проходнойга кереп киткәч, Вилләт Дәүҗанович кәгазьне җәеп, андагы сүзләргә кадалды.

«Сез җөмһүриятнен йөзек кашы саналган районын үләксә хәленә төшердегез, — дип башлаган иде язу: — Югары вазифадан оятсыз рәвештә файдаланып, төбәкнең бөтен байлыгын убырларча үзләштергән, колхозларны, предприятие, малтабар, эшкуар, фермер һәм сәүдәгәрләрне кычкыртып талаган, урлашкан өчен без, ягъни бөтен район халкы, сине шушы зинданга ябарга хөкем иттек. Очы-кырые күренмәгән илдә ришвәткә сатылмый торган бер прокурор, бер судья табылыр. Аларның халык ихтыярын рәсмиләштерәчәгенә ышанабыз. Син шушындагы как сәкедә

калган гомереннең соңгы көненә кадәр ятып дөмегергә тиешсең. Бу сина безнең соңгы бүләк...»

Язудагы әче сүзләр Вилләт Дәүжановичка яшен суккан кебек тәэсир итте, көчле ток бөтен тәнен көйдерде диярсең. Мондый җәзаны гомерендә бер тапкыр да татыганы юк иде шул. Ул байтак вакыт кыл да кыймылдатмыйча, тораташтай катып утырды. Ниһаять, кәгазьсез кулын алга сузып, теш арасыннан гына «прокурат...» дип әйтә башлаган иде, кулы сынган ботак сыман шәлперәеп төште, гәүдәсе кырау суккан бәрәңге сабагыдай шинеп калды. Шулай да бәлтерәгән иреннәрен һаман хәрәкәткә китерергә тырышты Вилләт Дәүҗанович:

— За моральный... ущерба өчен... миллионнар каермасам... исемем...

Шофер машинаны җәһәт кабызып, аны кардиология үзәгенә таба юнәлтте.

---

## Фарисизмнар

- Иҗатчы акчасыз калыр - эшсез калмас.
- Примитив әсәр сабын куыгы кебек аллы-гөллелеге белән шаккатыра...
- Сынчы утырып эшләсә, сәнгать әсәре чыкмый.
- Рәссам өчен фараз итә белү - белемнән мөһимрәк.
- Рәссамга анатомияне өйрәнергә һәм онытырга кирәк.
- Сыннар җан сорый...
- Өйдә шәрә сыннар булса, хатыннар балага узмас.
- Картиналарны сокланып караучы булмаса, алар кибәләр һәм ярылалар, ә портретлар елый.
- Музейларда күп йөргән кеше тиз картая.
- Музейлардагы борынгы экспонатларда картлык аурасы бар, шуңа яшь кызлар музейда эшләми.
- Иҗатыңның бәллүр чылбырлары чуен богауга әверелмәсен.
- Уйлап чыгару - эшкә ашырудан күпкә җиңелрәк.
- Сынчының һәйкәле турында халык мәзәк чыгармаса - ул сәнгать әсәре була алмый.
- Сынны бер карауда натурасына охшамаган яки охшаган дию, кешене бер күрүдә кем икәнен белем диюгә бәрабәр.
- Рәссам рәссам өстеннән җитәкчелек итсә, сынлы сәнгать бетәчәк.
- Кара квадрат ошамаса, кара өчпочмак ясап кара.
- Чын рәссамга йөз дусның кирәге юк.
- Берәр затлы идеяне эштән чыгарырга теләсәң, булдыксыз башкаручы кулына тапшыр.
- Рәссамның эшләре аңлашылмаган саен, аның иҗаты белән кызыксыну арта гына барачак.
- Сынчының холкы нинди - сыннары шундый.

**Фарис ФӘСХИ**

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2014 елнның беренче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. «Казан утлары»ның индексы физик затлар өчен – **73210**; юридик затлар өчен – **16262**.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан, абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Әлеге квитанцияне кисеп алып, анда тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

90 еллык бай тарихы булган мәдәниятебез елъязмасы — «Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

**Ф.СП-1**

Федеральное государственное унитарное предприятие " ПОЧТА РОССИИ " Ф. СП-1

Бланк заказа периодических изданий

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

*«Казан утлары»* (наименование издания)

количество комплектов

На 2014 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому

Линия отреза

ПВ | место | литер

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА** **73210** (индекс издания)

На ~~газету~~ журнал *«Казан утлары»* (наименование издания)

| Стои-мость | подписки | руб. коп. | Кол-во комп-лектов |
|---|---|---|---|
| | каталожная | руб. коп. | |
| | переадресовки | руб. коп. | |

На 2014 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

почтовый индекс — город, село, область

район

код улицы — улица

дом | корпус | квартира

фамилия и. о.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ ЮЛЛАМАСЫННАН

Хөрмәтле депутатлар, хөрмәтле ватандашлар!

Хөрмәтле татарстанлылар!

2013 ел республикабыз һәм илебез тарихына бөтен дөнья күләмендә спорт һәм мәдәният өлкәсендәге зур вакыйга – XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасын уздыру елы буларак кереп калачак.

Биш ел элек, Универсиаданы 2013 елда, Мәскәүдәге студентлар уеннарыннан соң 40 ел вакыт узгач, Казанда үткәрү турында карар кабул ителде.

Бу Россия Президенты Владимир Владимирович Путин, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Дмитрий Анатольевич Медведев һәм Халыкара студентлар спорты федерациясе ярдәме белән мөмкин булды.

Универсиаданың Оештыру комитеты Рәисе, Россия Хөкүмәте Рәисенең Беренче урынбасары Игорь Иванович Шуваловка һәм Оештыру комитеты Рәисенең Беренче урынбасары, Спорт министры Виталий Леонтьевич Муткога әлеге зур чараны әзерләүгә актив ярдәм күрсәтүләре өчен шулай ук олы рәхмәтемне җиткерәсем килә.

Республика Хөкүмәте һәм Парламенты, Казан мэриясе һәм шәһәр думасы, предприятиеләребез һәм оешмаларыбыз тарафыннан зур эш башкарылды. Республиканың барлык шәһәрләре һәм районнары актив ярдәм күрсәттеләр.

Берәү дә бу эштән читтә калмады. Без бердәм команда булып, тупланып эшләдек.

Универсиада уздыру нәтиҗәсендә республикада нык үскән спорт инфраструктурасы булдырылды, халыкара дәрәҗәдәге яңа стадион, яңартылган аэропорт, тиз йөрешле аэроэкспресс, яңа тимер юл вокзалы, метро станцияләре һәм заманча транспорт киселешләре төзелде. Универсиада авылы базасында илдә иң яхшы студентлар кампусы булдырылды.

Башкалабыз танымаслык булып матурланды. Казанның заманча Европа мегаполисы булуы турындагы сүзләр амбицияле максат кына булып калмыйча, бүген күбесенчә чынга ашты.

Универсиада иминлек саклауны тәэмин итү системасы өчен житди сынау булды. Хокук саклау структураларының килешеп, бердәм эшләве чараның уңышлы узуын тәэмин итте.

Бөтендөнья студентлар уеннарына әзерлек һәм аны уздыру илнең һәм халыкара оешмаларның югары бәясен алды. Казан Универсиадасы студентлар спорты тарихында иң яхшысы дип танылды.

Әлеге уртак эшебезгә үзеннән өлеш керткән һәркемгә ихлас күңелдән бик зур рәхмәт!

Тырышып, тулы көчебезгә эшләгән шушы елларда без төзелештә, кунаклар кабул итү индустриясендә, инфраструктура проектлары белән идарә итүдә яңа технологияләрне һәм коммуникация технологияләрен үзләштердек. Татарстан турында дөнья тагын да күбрәк белде. Без үзебез дә нык үзгәрдек.

Без югары казанышларга ирештек, хәзер артка чигенә алмыйбыз инде. Республика тормышының барлык даирәләрен шушы югарылыкка күтәрү үтә мөһим. Киләчәктәге бурычларыбыз да хәзерге уңышларыбыздан калышмаска тиеш. Татарстанның икътисад, инфраструктура, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм туристлык өлкәсендә киң танылуын тәэмин итәргә кирәк.

Боларның барысын да Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр чорга үсеш стратегиясендә чагылдыру зарур. Ахыргы максат – якын киләчәктә XXI гасырга лаеклы һәм дөнья икътисадый системасына интеграцияләнгән икътисад булдыру.

## МӨСЕЛМАН КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕ

5-11 сентябрьләрдә Казанда IX Халыкара мөселман киносы фестивале булып узды. Жюри рәсе итеп кинорежиссер, сценарийлар язучы, актер һәм режиссер Карен Шахназаров билгеләнде. Нәфис фильмнар арасында беренче урын «Түгәрәкләр» («Круги») фильмына бирелде. Бу әсәр Сербия, Франция, Германия, Словения, Хорватия ижатчыларының уртак эше. Кыска нәфис фильмнар арасында беренче урынны Казакъстаннан килгән «Әти» («Отец») фильмы алды. Бәйгедә катнашкан 10 документаль фильм арасыннан Германиядән «Кундуз буыны – ят сугыш» («Поколение кундуз – чужая война») ин яхшысы дип табылды. Кыска документаль фильмнар арасында Әзәрбайжаннан «Юкка чыгып баручы утрау» («Тающий остров») жинеп чыкты. Мультфильмнар бәйгесендә беренче урын Ираннан «Масулех авылы»на («Деревня Масулех») бирелде.

## «ХАЙТАРМА» ТАТАРНЫ ТЕТРӘНДЕРДЕ

Әмма аны үткәрмәү өчен Мәскәүдән жинелчә генә бармак изәп алу да житкән. Бу киноны карарга халык өерелеп килде, оештыручылар аны берьюлы ике залда күрсәтергә мәжбүр булдылар. (Күпләр интернат аша караган). Фильм беткәч, тамашачылар басып бик озак алкышладылар. Журналистларның да Әхтәм Сәйтәблаевка сораулары бик күп булды.

## КАЗАНДА ТИҮ БИНАСЫ САТЫЛДЫ

Казанның Карл Маркс урамындагы Татар ижтимагый үзәге урнашкан бина тирәсендә соңгы арада зур шау-шу купты. Биредә 1996 елдан бирле тагын берничә милли-ижтимагый оешма эшләп килде. Шәһәр башкарма комитеты бинаны сату карары чыгарып аны аукционга куйды. Сатуга журналистлар кертелмәде. Татар ижтимагый үзәге һәм «Азатлык» татар яшьләре берлеге әлеге бинаны саттырмас өчен төрле пикет, митинглар уздырды, 14 сентябрьдә биш кеше бинаны кире кайтаруны таләп итеп сәяси ачлык игълан итте. Бина сатылу хәбәрен ишетсәләр дә, алар чыгып китмәячәкләрен һәм ачлыкны дәвам итәчәкләрен белдерде. Ләкин күпсанлы ризасызлык акцияләренә карамастан, 20 сентябрь көнне бина аукционда сатылды.

## МИҢНЕХАНОВ АКШ ҺӘМ КАНАДА ТАТАРЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

Бостонда Татарстан президенты Рөстәм Миннеханов АКШ һәм Канадада яшәүче татарлар белән очрашты. Анда студентлар, аспирантлар, Төньяк Американың эре шәһәрләрендәге татар оешмасы вәкилләре катнашты. Очрашуга килгән Канада татарлары Монреаль һәм Торонтодагы татар жәмгыятьләре эшчәнлеге белән таныштырды. Алар Торонтода быел унынчы тапкыр Сабантуй оештырылуын әйтте. Шуннан соң Миңнехановка быелгы Сабантуйда төшерелгән видео тәкъдим ителде. Моннан тыш Татарстан кунаклары өчен концерт оештырылды. Анда ана телендә җырлар башкарылды, биюләр күрсәтелде, шул исәптән «Бәйрәм» һәвәскәр ансамбле артистлары да чыгыш ясады.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Әлмәт шәһәре.


*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Миңзифа Әхмәтшина**.

## Яңа китаплар




**Марат Әмирханов.** Казан-йорт: тарихи романнар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 544 б. Тиражы – 3000 данә.

Танылган язучы Марат Әмирхановның бу китабында халкыбызның үткәненә, катлаулы язмышына янә бер кат борылып карау мөмкинлеге тудырган «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад» һәм «Әлвидаг» исемле тарихи романнары урын алган.




**Азгар Шакиров**. Судьба: размышления, воспоминания, интервью, выступления. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 296 б. Тиражы – 2000 данә.

Әлеге китапта Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әзһәр Шакировның хатирәләре, уйланулары урын алган. Биредә актерның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрындагы сәхнә эшчәнлеге, үткән чорның һәм хәзерге заманның күренекле сәнгать әһелләре турындагы истәлекләр белән дә танышырга мөмкин.



Миңзифа Әхмәтшина

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)